ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.2002



# «КАЗАН УТЛАРЫ» РЕДАКЦИЯСЕНӘ

**Кадерле дуслар!**

**Татар халкының яраткан журналы «Казан утлары»ның чыга башлавына 80 ел тулу уңае беләи аның авторларын, редакция хезмәткәрләрен, дистә меңләгән укучыларын—барлык әдәбият сөючеләрне чын күңелемнән кайнар котлыйм!**

**Илдә Октябрь давыллары тудырган гражданнар сугышы әле тәмамланып бетмәгән, һәркайда җимереклек, Идел буенча, Татарстанда коточкыч ачлык хөкем сөргән шартларда 1922 елның май аенда бүгенге «Казан утлары»ның башлангычы саналган «Безнең юл» журналының беренче саны дөнья күрә. Шул еллардан бирле бүгенгәчә журнал озын данлы юл үтте һәм ул, лаеклы рәвештә, халкыбызның чын мәгънәсендә җан азыгы, тугры юлдашы һәм киңәшчесенә әверелде. Журнал татар әдәби хәрәкәтен әйдәп баручы рухи байрагыбыз дәрәҗәсенә күтәрелде.**

**Үз вакытында бердәнбер әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси басма булган «Казан утлары», әдәбиятта гына түгел, сәнгатьнең башка төрләрендә дә яңа эзләнүләргә юл ачты, театр, музыка, сынлы сәнгать мәсьәләләрен эзлекле яктыртып, аларның уңышына этәргеч көч хезмәтен үтәде. Халкыбызның иҗтимагый-сәяси фикерен үстерүне, фән-мәдәният тарихын барлап-теркәп баруны да «Казан утлары» үз өстенә алды һәм хәзер дә бу бурычны фидакарьләрчә үтәп килә. Төрле кыйтгаларга сибелгән татар халкын рухи берләштерүдә дә «Казан утлары»ның роле зур. Аны дөньяның төрле төбәкләрендә үз итеп яратып укыйлар. Шуңа да «Казан утлары»н хаклы рәвештә халык журналы, гомумтатар журналы дип атап була.**

**Кадерле дуслар!**

**Яңа чор яңа бурычлар алып килә. Без, Россия күләмендә беренче булып, үз алдыбызга фәнни-техник казанышларга таянып, җитештерүдә һәм социаль тормышта дөнья стандартларына күчү нигезендә, туган республикабызны Европа дәрәҗәсендәге илгә әверелдерү бурычын куйдык.**

**Алдыбызда торган мөһим бурычларның тагын берсе—заман шаукымына бирелмичә, халкыбызның күпгасырлык рухи, әхлакый кыйммәтләрен саклап калу. Җәмгыятьләр алышынганда котырынып үскән индивидуализмга, эгоизмга, әхлаксызлыкка, әдәпсезлеккә, эчкечелеккә һәм наркомания чиренә бирешмәү. Безнең буынга туган башкалабыз Казанның мең еллыгын бәйрәм итү бәхете насыйп булды. Мин бу мәсьәләләр даими төстә журналның һәм аның авторларының күз уңында торыр, дип уйлыйм.**

**Шик юк, дөнья биеклекләренә күтәрелерлек яңа әдәби әсәрләр тууга булышлык кылу, мәгърифәтебезне өр-яңадан үзгәртеп, тагын да югарырак баскычка күтәрү, мәйданга килгән яшь талантларны күрә-үстерә белү кебек мөһим эшләр дә журналның асыл мәсләген тәшкил итәр.**

**Татар мәдәниятенең рухи көзгесенә әверелгән «Казан утлары», олуг әдип Галимҗан Ибраһимов традицияләрен киләчәктә тагын да баетып, республиканың мәдәни, иҗтимагый тормышы үзәгендә һәрдаим балкып торыр дип ышанам. Редакция хезмәткәрләренә, каләм осталарына, әдәбият сөючеләргә зур илһам, саулык-сәламәтлек, бәхет телим.**

**Татарстан Республикасы Президенты**

**Минтимер ШӘЙМИЕВ**

*Апрель 2002 ел*

# Казан утлары
# Qazan utları

2002

5

(955)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,
Татарстан Язучылар берлеге,
редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Альбина Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## *Бу санда*

БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ


Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Бу гасырда да балкыр! ........ 5


ШИГЪРИ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР


Bəүrəmgə şiğri bəүləm. ........ 14

Факил САФИН. Саташып аткан таң. *Роман. (Ахыры)* ........ 19

Бәйрәмгә шигъри бәйләм. ........ 84

Халисә МӨДӘРРИСОВА. Бәйге хакы. *Повесть* ........ 92

Фәнис ЯРУЛЛИН. Тауларга карап. *Шигырьләр* ........ 113

Зиннур ХӨСНИЯР. Айның туган-тумачасы юк. *Хикәя* ........ 117

Кави ЛАТЫЙП. Канатлы алмалар. *Шигырьләр. (Рәдиф Гаташның кереш сүзе белән)* ........ 125

Рим ИДИЯТУЛЛИН. Шул бер гомер эчендә. Шигырьләр ........ 129

Радик ФӘИЗОВ. Рәхим итегез, сэр! *Фантастик хикәя* ........ 133


«КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ


Rəsemnərdə jurnal tarixı ........ 12, 186

Айрат АРСЛАН. Халыкка хезмәт итү бәхете ........ 54

Фәрит ИДЕЛЛЕ. 90 еллыгын да бергәләп үткәрергә насыйп итсен ........ 74

Ислам ӘХМӘТҖАНОВ. Тормыш китабы ........ 96

Фатих СИБАГАТУЛЛИН. Милләтнең йөзек кашы ........ 106

Рүзәл ЮСУПОВ. Мөгаллимнәр мәктәбе ........ 164


ПУБЛИЦИСТИКА


Миркасыйм ГОСМАНОВ. Яңадан танышу яки фидакарь хәйриячеләребез хакында ........ 139


ТАРИХ


Солтан ШӘМСИ. Низаглы йортта ........ 153


КИТАП КҮЗӘТҮ


Хужи МӘХМҮТОВ. Төрек теле аша—төрки дөньяга ........ 170


КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ


25—Фуркан *(Яхшылыкны яманнан аеручы китап)* сүрәсе ........ 175


ЮБИЛЕЙЛАР


Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Рухи куәт *(Азат Ганиевкә 60 яшь)* ........ 180

Хатлардан юллар ........ 182

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 189

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«К 80-летию журнала»: Вступительная статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА; «Казан утлары» в моей жизни»—воспоминания А. АРСЛАНА, Ф. ИДЕЛЛЕ, И. АХМЕТЗЯНОВА, Ф. СИБАГАТУЛЛИНА, Р. ЮСУПОВА; история журнала—в фотографиях.
«Проза и поэзия»: окончание романа Ф. САФИНА «Мнимый рассвет»; рассказ З. ХУСНИЯРА «У луны родственника нет», повесть Х. МУДАРРИСОВОЙ «Цена победы», фантастический рассказ Р. ФАИЗОВА «Добро пожаловать, сэр»; стихи аксакалов татар. поэзии на латинской графике и наших современников; стихи Ф. ЯРУЛЛИНА, К. ЛАТЫПОВА (с предисловием Р. ГАТАША), Р. Идиятуллина.
«Публицистика»: статья М. УСМАНОВА «Благородные меценанты».
«История»: С. ШАМСИ. «В скандальном доме» (страницы истории Золотой Орды).
«Книжное обозрение»: Х. МАХМУТОВ рецензирует «Антологию тюркских литератур», изданную в Турции.
«Коран на татарском языке».
«К 60-летию А. Ганиева»—статья Мансура ВАЛИЕВА.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: коллектив редакции журнала.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Commemorating the 80 th Anniversary of our magazin": aditor's word R. FAIZULLIN "Kazan utlari" is the national magazin", "Kazan utlari" in my life" - reminiscences of A. ARSLAN, F. IDELLE, I. AKHMETZIANOV, F. SIBGATULLIN, R. USUPOV; magazin's history in photograph.
"Prose and poetry": ending F. SAFIN'S novel «The seeming dawn»; Z. KHUSNIAR'S story "The moon haven't relatives.", KH. MUDARISOVA'S narrative "The cost of victory", R. FAIZOV'S fantastic story "You are welcome, sir"; the verses of old Tatar poets in Latin graphics and our contemporaries, the verses of F. YARULLIN, K. LATIPOV (with R. Gatash's preface), R. IDIATULLIN.
"Journalism": M. USMANOV'S article "The noble sponsors".
"History": S. SHAMSI "In scandalous house" (the history pages of Gold Orda).
"Book rewiew": KH. MAKHMUTOV'S rewiew "The anthology of Turkic literatures".
Koran in Tatar language.
"Commemorating the 60 th anniversary of A. Galiev": articles of Mansur VALIEV.
The diary of social and cultural life.
In our covers: editorial staff of magazin.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.04.2002 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 9134. Заказ Б—238
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2002 ел.

*Баш мөхәррир сүзе*

# БУ ГАСЫРДА ДА БАЛКЫР!

«Казан утлары»—татар халкының төп әдәби журналы. Бу җаваплы сүзне әйтер өчен тарихи җирлек, ныклы дәлил бар: журнал үткән катлаулы юл, аны чыгарган язучы-әдипләрнең көндәлек хезмәте һәм иҗаты, иң мөһиме—рухи елъязмабызны тәшкил иткән меңләгән әсәрләр менә тулы мөмкинлек бирә.

«Казан утлары»—татар матбугатында аналогы булмаган бердәнбер әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал. Ул үзенең яшәү дәверендә халкыбызның яраткан, һәрчак көтеп алынган журналы булды. Тәкъдиребезгә тигән нинди генә каһәрле чорларда да журнал төрле кыйтга-төбәкләргә сибелгән газиз халкыбыз өчен элек тә, хәзер дә дуслык, туганлык, тупланганлык, аралашу һәм аңлашу мәйданы булып кала алды.

80 яшь. Мең еллык тарихы булган әдәбият өчен бу сан кечерәк түгелме, дияр кемдер. Чыннан да, татарча басма китап тарихына да берничә гасыр бит. XX гасыр башында ук чыккан «Әлгасрелҗәдит», «Шура», «Аң» кебек әдәби-иҗтимагый басмалар безнең журналның чишмә башы санала алмыймыни? Әгәр «Казан утлары»н әлеге элгәргеләрнең варисы, дәвамчысы итеп санасак, табигый, 80 еллык урынына, берничә елдан 100 еллык юбилейны билгеләп үтү дөресрәк булыр иде. Ә инде милли журналлар ярлгысы рәвешендә XIX йөзнең икенче яртысында ук чыга башлаган татар календарьларын да игътибарга алсак, әлеге санны күпкә үстереп булыр иде... Хәер, юбилей санын йөзле түгәрәкләр белән кuру үзмаксат түгел. Журналның совет чорыннан башланган 80 еллык гомере дә халкыбызның иҗтимагый-эстетик фикер үсеше, әдәбият һәм мәдәниятебезнең үткән юлы турында анализ ясап җитди уйланырлык, бәйрәми хис белән юбилей итеп үткәрерлек олы вакыйга.

80 ел—тарих өчен мизгел генә булса да, адәм балалары хәятында берничә буын алышынырлык озын гомер бит ул! Бер кояш астында янәшә-күрше яшәүче халыклар белән уртак язмыш үтеп, безнең татар халкы да ниләр генә кичермәде дә, нинди генә сынаулар үтмәде бу гомер эчендә! Инкыйлаб-революция зилзиләләре дә; аклар-кызылларга аерылып пычакка пычак килүләр дә; ачлыктан яки үләт чирләреннән нәсел-ыру белән кырылулар да; янаны тәзим дип, булганны юк итүләр дә; сыйныф-классларга бүленә-бүленә, диннәр белән көрәшә-көрәшә, алфавит-имлаларны кат-кат алыштыра-алыштыра кыйбласыз, имансыз калулар да; сәяси авантюристлардан культ ясап, үзләре «шөреп-винт» хәленә калып, миллионнарның яуларда, лагерьларда һәлак булулары да; табигать кануннары һәм халык мәнфәгате белән исәпләшмичә, җир-суны мәсхәрә итеп «бөек-бөек» төзелешләр, үтерешләр чыганагы—хәрби промышленность комплекслары корулар да; утопик хыял—коммунизмга фанатикларча ихлас ышанып, хакыйкатькә хилафлык кыла-кыла, физик көч һәм акыл сәләтен кирәкмәгәнгә исраф итүләр дә... Һәммәсе, һәммәсе булган бу дәвердә!

Тарих—канлымы ул, шанлымы—барыбер халык хәтеренә чигелә барган. Телефон-радио яңа керә башлаган, телевидение дигәннәренең әле эзе дә булмаган ул ерак елларда әлеге тарих кайларда чигелеп, чор-дәвер кардиограммасы нәрсәләрдә сурәтләнеп калган соң? Әлбәттә, беренче нәүбәттә, басма сүздә. Китапларда, газет-журналларда. Һәр басманың, һәр журналның—үз биографиясе, үз язмышы. Мәгълүм нәрсә: үткән гасыр башында—халык рухының көчле бер уяну чорында татарча байтак журналлар чыгып алган. Өлкәннәр өчен дә, балалар

өчен дә, хатын-кызлар өчен дә... Диниләре дә, һөҗүле-көлкелеләре дә... 20 еллардан сон да, бик нык идеологияләштерелгән булса да, милли матбугатыбыз тарихында янә бер күтәрелеш булып алган. Әмма бу хәл озакка бармаган шул. Репрессия еллары башланган, сугышлар кабынып киткән. Кайбер журналлар табигый рәвештә гамәлдән төшеп калган, кайберләре махсус ябылган... Безнең журналның бәхете шунда: язмыш тарафыннан нәселне саклап калырга тиешле таза күзәнәкле зат кебек, ул, сәяси катаклизмнарга бирешмичә, күпмедер компромиссларга барып, исемнәрен алыштыра-алыштыра булса да, җисемен-рухын саклады, халык тарихы елъязмасы рәвешендә өзелмичә яшәвен дәвам итә алды. (Бу очракта шуны гына искәртү дә күп нәрсә турында сөйли: Ватан сугышы елларында бик күп басмалар, бик күп журналлар ябылганда да, журнал (ул вакытта «Совет әдәбияты») укучылар белән араны өзмичә даими чыгып килде).

Журнал 1922 елдан алып 1930 елга кадәр гарәп шрифтында «Безнең юл» исеме белән чыккан. Утызынчы елдан икегә бүленеп, «Яңалиф» (Татарстан Мәгариф халык комиссариаты һәм Совет язучылар оешмасы органы) һәм «Атака» (Татарстан пролетариат язучылары ассоциациясе органы») исемнәре белән басылган. Ә 1933 елдан 1965 елга кадәр «Совет әдәбияты», ә соңгы кырык елга якын дәвердә хәзерге «Казан утлары» атамасы белән дөньяга чыгып килә. Заман сәясәте һәм аның шаукымнарына бәйле рәвештә журналның оештыручылары да (Татар социаль Шуралар җөмһүриятенең мәркәз башкарма комитеты һәм халык комиссарлары Советы; Татарстан халык мәгарифе комиссариаты, РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты, Совет язучылары оешмасы; ТАПП һәм Кызыл Армия-флот язучыларының Татарстан оешмасы; Татарстан Язучылар берлеге, Татарстан Министрлар Кабинеты... Титул билгеләмәләре дә (гыйльми-сәяси, әдәби-иҗтимагый журнал; әдәбият-сәясәт, сәнгать, экономика һәм тәнкыйть журналы; әдәби-гыйльми, иҗтимагый басма; әдәбият, сәнгать һәм тәнкыйть журналы; әдәби һәм иҗтимагый-политик журнал; әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал), структурасы да һәм редакциянең эш урыннары да үзгәреп, алышынып торды. Билгеләмә-атамалар төрле чорда төрле сүз тезмәләрендә бирелсәләр дә, аларда төп ике төшенчә һәрчак сакланып килендe—«әдәби» һәм «иҗтимагый». Ягъни, иҗтимагый әһәмияткә ия булган иң яхшы нәфис әсәрләрне бастыручы әдәби журнал дигән сүз.

Ул заманнарны ретроспектив планда искә төшергәч, журналның башында торган, шушы басмада эшләп чыныгу, әсәрләре белән танылу алган кадерле исемнәрне дә хәтерләп узыйк. Мәгълүм булганча, журналның совет чорындагы дәверендә аның юлбашчысы булып бөек әдип Галимҗан Ибраһимов торган. Шушы журнал тирәсенә әдәбиятыбыз елъязмасында алтын хәрефләр белән язылып калган Һади Такташ, Гадел Кутуй, Шәриф Камал, Кави Нәҗми, Шамил Усманов, Фатих Кәрим, Хәсән Туфан кебек әдипләребез тупланган. Журнал белән җитәкчелек итү эстафетасын Г. Гали, Ф. Сәйфи-Казанлылар дәвам иткән. Журналның «Совет әдәбияты» һәм «Казан утлары» чоры (бу чор 70 ләп елны эченә ала!) каһарманнары, журналда эшләгән яки актив язышкан язучылар, шагыйрьләр—(ни кызганыч, алар инде арабызда юк; без аларны өлкән буын вәкилләре дип йөри идек. Хәзер инде без—60 елларда әдәбиятка килгәннәр—үзебез дә олыгаеп, үткән гасыр кешеләре булып барабыз...) Нәкый Исәнбәт, Гомәр Бәширов, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Ибраһим Гази, Мирсәй Әмир, Афзал Шамов, Шәйхи Маннур, Сибгат Хәким, Салих Баттал, Нури Арсланов, Әнвәр Давыдов, Нәби Дәүли, Атилла Расих, Ибраһим Салахов... Саналган һәр исем, һәр шәхес артында күпме иҗат, күпме язмыш!.. Ә исемлекне шактый озынга дәвам итеп булыр иде.

«Казан утлары»—әдәбиятыбызның, мәдәниятебезнең елъязмасы, рухи тормышыбызның тарихи көзгесе. Шуңа күрә дә, журнал язмышы—халык язмышы белән аерылгысыз, диясе килә. Юкса, ачлы-туклы елларда да, илне «боз суккан» чорларда да халык аны саклап калыр идеме? Сугыш кырларында иң кадерле хатлар белән бергә поход биштәрләрендә йөртерләр идеме? Котып тарафларында яки чүлле Кара-ком якларында, шахта баракларында яки тайга кинлекләрендә моңлангән укучылар, туган як сәламе һәм ана телебез аһәңе итеп, зарыгып көтеп алырлар идеме? Ә инде балачакта ук үзен әдәбиятка багышларга, газетта йә журналда беренче нәни мәкаләсен яки шигырен бастырырга хыялланган яшь

жаннар өчен бу журналның бәһасен әйтеп тә торасы юктыр...

Сүз—изгелек кылыр өчен яратылган, диләр. Бәхәсле булса да, бу гыйбарәгә ышанасы килә... Әгәр Сүз, чыннан да, изге икән,—төп коралы Сүз булган язучы кеше дә изге максатка—Хакыйкатькә, Әхлакка, Матурлыкка хезмәт итәргә тиеш. Язган һәр әсәр дә, һәр китап та, күмәк әдипләр чыгарган әдәби басма да... Бүген без юбиляр журналыбызның абруен никадәр генә күтәрергә тырышсак та, нихәл итмәк кирәк, адәм хатадан хали булмаган кебек, аның да ялгышлары, хаклык юлыннан тайпылулары да булгалаган. Гуманизм критерийларына, эстетик идеалларга хыянәт иткән сәхифәләр дә очраштыргалый журнал битләрендә. Олы талант иядәрен буржуа ялчылары дип бәяләүләр дә, чын милләт хадимнәрен «халык дошманнары» итеп фаш итүләр дә, «оборона әдәбиятының магнитостройлары өчен көрәш»ләр дә, якты киләчәккә әйдәүче «юлбашчы»ларга мәдхия укулар да, «коммунизм төзүче» ясалма каһарманнар тудыру да, куркынычсызлыгы шикле АЭСларга дан жырлаулар да... Әмма 80 елда үткән юлның дәрәҗәсен һәм кыйммәтен әле әйтеп узган саташулар билгелиме соң? Һич юк, әлбәттә. Соңгы 60-70 ел эчендә бар булган иң күренекле әсәрләребез нәкъ менә шушы журналда дөнья күрде, укучыларга, халыкка барып иреште. Сугыштан соңгы әдәби хәзинәбезгә карата бу фикер бигрәк тә рас килә. Йә, шушы журналга мөнәсәбәте булмаган яки әсәрен анда бастыруны дәрәҗә санамаган берәр татар әдибен табып була микән? Яки «Казан утлары» дигән Әдәбият Капкасын үтмичә иҗат мәйданында танылу алган берәр язучы булдымы икән? Журналда басылган байтак ул әсәрләр әдәбиятыбызның алтын фондына керде, соңрак кайберләре күп телләргә тәрҗемә ителеп, татар әдәбиятын дөньяга танытты; татар халкы, аның тарихы, тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, хыял-омтылышлары белән бүтән ил-халыкларны таныштырды. Бу очракта Кави Нәҗминең «Язгы җилләр», Гомәр Бәшировнең «Намус», Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре», Г. Әпсәләмовнең «Ак чәчәкләр» кебек әсәрләрне күздә тотып әйтүем.

Гадәттә, «Казан утлары»н—татар халкының баш журналы дип әйтәләр. Төптән уйлап карасаң, дөрес бәяләмә бу. Ничә дистә еллар буе совет илендә яшәүче халыкларның әдәбияты һәм сәнгате көннән-көн чәчәк ата дип әйтелсә дә (дөрес, кайбер милләтләр өчен хосусан шулай булды да ул), безнең ни фән, ни сәнгать, ни музыка, ни тарих буенча махсус журнал-газетларыбыз булмады диярлек (гәрчә китап чыгару буенча инкыйлабка кадәр Россия империясендә иң алдынгы урыннарда торсак та). Шуңа күрә, әдәбият-сәнгать, театр-музыка, фән һәм иҗтимагый фикер буенча ирешкән казанышларыбызны шушы журнал, хәл кадәри үзендә урын биреп, халкыбызга җиткерә килде. Тоталитар режимның «тимер пәрдәле» елларында да, алдыру мөмкинлеге бик чикләнгән булса да, чит төбәкләрдә һәм мәмләкәтләрдә яшәүче милләттәшләребезгә дә шушы журнал аша татар халкының рухи тормышы турында беркадәр мәгълүмат ирешә алды. Шуңа күрә дә, «Казан утлары»н—гасыр дәвамында татар халкының рухи дөньясын—тарихын, әдәбиятын, сәнгатен чагылдырган энциклопедик басма дип авыз тутырып әйтә алабыз.

Бу урында моннан 30 ел элек «Казан утлары»ның 50 еллык юбилее уңае белән язылган Гази Кашшаф (озак еллар журналның баш редакторы булып эшләгән) язмасыннан бер өзек китереп узыйк: «Анда (журналда—Р. Ф.) халыкның рухы салынган. Анда—халыкның иҗтимагый аң үсеше, анда—халыкның матурлыкны тану һәм аны бәяли белү осталыгы, анда—аның әдәби-сәнгать зәвыгы, образлы сиземләү осталыгын үзләштерү баскычлары. Шуңа күрә дә матур әдәбият тарихын тикшерәсеңме, театр, музыка тарихына күз саласыңмы, рухи культура тарихына материаллар эзлисеңме—бу журналны читләтеп узу мөмкин түгел. Журналда басылган һәрбер язма аерым китап яки җыентыкларда тупланып басыла алмый. Шулай булгач, журнал тарихчылар өчен бердәнбер башлангыч чыганак».

Әйе, үткән турында язу (әгәр үтелгән юл мәгънәле һәм шанлы булса, бигрәк тә!) җиңелрәк. Чөнки буласы булган, анализланасы анализланган, Вакыт бәясе алынган... Ә киләчәк турында? Яшермим, журналыбызның бу юбилей санын әзерләгәндә, архив тупланмаларен актарганда, каләмдәш-хезмәттәшләр белән әңгәмәләшкәндә, укучылар белән очрашканда, япа-ялгызың калганда күңелгә еш кына сорау катыш шомлы уйлар да килә. Бу гасырда татар халкын ниләр көтә? Кояш астындагы хәяттә туган телебездә сөйләшүчеләр күпме булыр? Бай мирaслы әдәбиятыбызны кемнәр укыр? Матбугатыбыз нишләр? Галәми

катаклизмнар—«ахырзаман» гарасатлары чыгып, яки глобаль бүлгәләнүләр нәтиҗәсендә аз санлы халыклар тәмам эреп-«тәңгәлләштерелеп» бетеп, бүген без күз нурларын түгеп чыгарган китаплар, газет-журналлар көлгә яки тетенгә әйләнеп юкка чыкмасмы? Уйлата торган замана! Ясалма акыл, компьютерлар заманасы, кешеләрне клонлаштыру заманасы, тулы бер китапханә уч төбенә сыешлы дискетларга кереп бетә алган, электрон почта, электрон газеталар заманасы... Генетик инерция яки саклану инстинкты беләнме, үз һөнәрен-эшен, хезмәтен нәтиҗәсе булган әдәби әсәр, китап, журнал, элеккечә әйтсәк «ташка басылган сүз» турында бик нык уйланасың. Бүтәнчәрәк, бераз рәсмирәк әйткәндә, язучы хезмәтенең хаҗәте, аның җәмгыятьтәге урыны турында уйланасың. Миңа калса, бу табигый халәт. Һәр истәлекле дата, бу очракта журналыбыз юбилее, күкрәк сугып мактану яки канәгать тынычланудан бигрәк, киләчәк язмыш турында җитдирәк фикер йөртер өчен бер форсат бит.

Хәзер әллә нинди басмаханәләрдә төрле телләрдә чыккан газет-журналлар, китап-альбомнар, реклам-буклетлар бихисап. Укучы гына булсын! Сер түгел: халыкны үзенә җәлеп итү «ярминкә»сендә басмалар арасында үзара ярыш шактый кызу: «кеше җаны өчен көрәш бара!» Замана биргән мөмкинлектән чыгып, кем ничек булдыра!—кемнәрдер түбән зәвыкка юнәлтелгән, хәйвани инстинктларны «кытыклый» торган ярымдетектив, ярымпорнографик язмалар чыгара; кемнәрдер бүген дөнья чыгырын әйләндерүче рәсми һәм рәсми булмаган түрәләрнең, бүгенге байларның сурәтләрен басып, аларның яшәү рәвешләрен мактап көн күрә; кемнәрдер реклама-игъланнар дөньясында сәүдәгәрләр кубызына бии... Нишлисең, дөнья бу! Әмма, шушы уртак мохиттә яшәсәк тә, безнең журнал «чуар базарчылык әхлагы»ннан өстен калып, матбугатыбыз тормышында аерым бер абруйлы урын тота дип уйлыйбыз. Академик басма саналырлык журналыбызның халык язмышында үз миссиясе бар. Үзенең башлангычында—үткән гасыр башында нинди төп максат куйган булса, нигездә, ул хәзер дә шул ук курста. Язучылар, сәнгать әһелләре, галимнәр, гомумән, акыл ияләре иҗат иткән әсәрләр белән халыкка хезмәт итү—аның үзаңын үстерү, дәүләтчелек идеясен ныгыту, милләтнең рухи үсешен тәэмин итү, һәм әлбәттә, югары әхлаклы, иманлы яшь буын тәрбияләү... Еллар, чорлар, дәверләр алышынуга карамастан, замана җилләрендә унга-сулга ташланмыйча, олы максатка ирешү юлында тотрыклы бер юл белән бару—һәр басма өчен бәхет һәм дәрәҗә ул.

Ныклы ышаныч, тотрыклылык, әлбәттә, курс-максатның анык, стратегик-тактик планнарның дөрес булуына бәйле. Киңәшле эш таркалмас, ди халык. Журнал даими рәвештә редколлегия әгъзалары—күренекле язучылар, галимнәр, дәүләт хезмәткәрләре, сәясәтчеләр белән киңәш утырышлары җыеп, киләчәктә башкарылачак гамәлләрне билгели. Рухи тормышыбызның төп тармакларын эченә алган, безнең өчен мәсләк саналган кайбер нигез-принципларны, юнәлеш-рубрикаларны тезис рәвешендә генә булса да укучыларыбызга искәртеп узыйк. Менә алар:

—тарихы мең еллап исәпләнгән татар әдәбиятының күркәм традицияләрен дәвам итеп, бүгенге татар язучыларының иң яхшы әсәрләрен бастыру, шулай ук, әдәби мирасыбызның бүгенге көн өчен гыйбрәтле сәхифәләре белән таныштыру;

—Татарстанның дәүләтчелеген яклау, ныгыту юлында эзлекле эшчәнлек алып бару; дәүләт теле буларак татар телен киң кулланышка кертү;

—Татарстанның дөньядагы роле, икътисады, социаль халәте турында язмалар белән берррәттән, Россия биләмәләрендә һәм чит илләрдәге татар хәяте белән укучыларны даими таныштыру; «XXI гасырда—татар халкы» рубрикасында күренекле галимнәрнең, сәясәтчеләрнең, әдипләрнең фикерләрен бәян итү;

—сәнгать төрләре буенча махсус басмалар булмауны истә тотып, традицияләрне дәвам итеп, театр, музыка, сынлы сәнгать казанышларын яктырту; сәнгать өлкәсендәге олуг шәхесләрнең иҗатлары турында язмалар урнаштыру;

—халкыбызның әхлагын, гореф-гадәтләрен саклау юнәлешендә максатчан эш алып бару; дин тәгълиматы турында гыйльми мәкаләләр, ислам әхлагы, дини бәйрәмнәр турында мәгълүматлар бирү;

—укучыларыбызны дөнья әдәбияты классикасының иң яхшы үрнәкләре белән таныштыру;

—әдәби алмаш тәрбияләүне күз унында тотып, «Остаханә», «Яңа исемнәр»

рубрикаларында яшь язучыларның иҗат үрнәкләрен дөньяга чыгару; чит төбәкләрдә туган телебездә иҗат итүче талант ияләренә аерым игътибар бирү;

—әдәби процессны барлап, үсеш тенденцияләрен ачыклап, әтрафлы тәнкыйть мәкаләләре бастыру, «Яңа китаплар» сәхифәсендә төрле нәшриятларда чыккан яңа китапларга рецензияләр һәм күзәтүләр оештыру;

—күренекле әдипләрнең юбилейларын, гомумән, татар дөньясындагы атаклы шәхесләрнең истәлекле даталарын билгеләп үтү; гарәп һәм латин имласында уку үрнәкләре бирү; «хроника» сәхифәсендә иҗтимагый-мәдәни тормыш вакыйгаларын объектив һәм оператив яктырту...

Әлбәттә, чын тормыш беркайчан да язма канун кысаларына сыеп бетмәгән шикелле, журнал эшчәнлеге дә, табигый, югарыда саналган бүлем-юнәлешләр белән генә чикләнми. Заман үзенең яңа таләпләрен, яңа проблемаларын, яңа идеяләрен өстәп тора. Әйтик, Казан шәһәренең 1000 еллыгы ачыклангач, махсус рубрика булдырылды, Казан турында язмалар элегрәк үзагымда чыгарылса, хәзер бу темага язылган материаллар системалы төс алды.

Сез кулыгызга тоткан бу журналның тәртип саны 955. Димәк, тагын берничә елдан бу сан 1000 гә җитәчәк. Уйлап карыйк: журнал 16 басма табак күләмендә (уртача форматтагы 400 битле китап чамасы) чыга, әгәр 80 ел буена ай саен уртача 20 мең тираж белән (берничә мең белән дә, йөз меңнән артык булып та чыккан еллары да булган) басылган дип уйласак, җәмгысы 20 миллионданәгә якын булыр иде ул! Хыял белән һәммәсен бергә өйсәң, үзе бер хикмәтле тау, дөресрәге, Хикмәт тавы күз алдына килә. Баштарак әйткәнчә, әйе, шулай булган, үзенә күрә яхшы булган, әмма бу инде үткән «булган»... Алга таба ни булыр?.. Миләребезне бертуктамый бораулап торган бер генә мәсьәләгә (ә мәсьәләләр күп!) тукталып үтим. Ул—журнал тарату проблемасы. 60 еллар ахырында басмабызның яртысыннан күбрәге Татарстаннан читтә тарала иде, ә хәзер булган тиражның алтыдан бере генә бүтән төбәкләргә чыга... Ул алтыдан бер дигәне дә, нигездә, Башкортстанга туры килә. СССР таркалды. Чикләр хасил булды. «Тимер пәрдә»не геополитик «челтәр» алыштырды. Болай да бердәмлеге җитмәгән татарны яңа барлыкка килгән дәүләти аерымлык-статуслар тәмам таркатты (халык саны алу мәсьәләсендәге әкәмәтләрне исәпләмичә әле!). Шунысы ап-ачык: Советлар Союзы таркалгач (яшермим, моны ностальгия тойгысы белән әйтәм), Россиядәге милли сәясәтнең төп асылы, беренче чиратта, татарларга карата мөнәсәбәттә чагыла. Хезмәтен файдаланып көн күргәч, налог-салымын түләткәч, ул халыкның рухи ихтыяҗын кайгырту бик тә лазем ләбаса!—Тукай әйтмешли, «шул халыкныңмы хокукка хаккы юк?—хаклыбыз уртак ватанда шактый ук!» Күп нәрсә, әлбәттә, үзәкләшкән сәясәттән тора. Вакыт үтү белән сәясәт тә үзгәреп тора, вәзгыять алышына, әмма, дөньяда нинди генә үзгәрешләр булса да, Казан—бөтен җиһанга сибелгән татар кешесенең Өмет Кыйбласы булып кала. Ә «Казан утлары» исә балкышын еракларга сипкән төп рухи учак. Гасырдан гасырга күчеп ул төрле кыйтгаларда яшәүче халкыбыз тормышын сүз сәнгатендә чагылдырып, милләттәшләребезне үзара якынайтырга, берләштерергә, цивилизация дөньясында үзләренә лаек урынны дауларга булышып килә. Иншалла, киләчәктә дә шулай булыр. Шулай дип юаныйк!

80 елның яртысына якыны журналның «Казан утлары» исеме белән чыккан дәверенә туры килә. Бу инде безнең чор, 60 еллар башында әдәбиятка килгән һәр әдип үткән гасырның икенче өлешен «минем чор!» дип әйтергә хаклыдыр. Шәхсән, бу үземә бик туры килә. Журналның исеме «Совет әдәбияты»ннан «Казан утлары»на күчкән 1965 елда мин шушы редакциядә эшли идем. Шул еллардан бирле бөтен әдәби язмышым тегеяки бу рәвешле «Казан утлары» белән бәйле. Шигырьләрем йә мәкалә-язмаларым чыкмый калган ел булмады шикелле. Кырык еллап гомер эчендә байтак нәрсәләр онытылса да, анда эшләгән кешеләр, әдәбият елъязмасын бизәрлек әсәрләр «истә, һаман да истә». Шушы дәвердә журналны җитәкләгән баш мөхәррирләр: Рафаэль Мостафин (1965-1968), Зәки Нури (1969-1971), (1975-1983), Гариф Ахунов (1972-1974), Ренат Харис (1983-1989), 1989 елдан —Равил Фәйзуллин... Журналда бүлек редакторлары булып эшләгән каләмдәшләр: Әхсән Баян, Ләбибә Ихсанова, Яхья Халитов, Вакыйф Нуруллин, Нури Арсланов, Малик Хәлитов, Фәрваз Миңнуллин, Рәдиф Гаташ, Хәмзә Зарипов, Гәрәй Рәхим, Ринат Мөхәммәдиев, Кояш Тимбикова,

Мөдәррис Вәлиев, Роберт Миннуллин, Мансур Вәлиев, Зиннур Мансуров, Әхәт Гаффар, Флүс Латыйфи, Солтан Шәмси, Рашат Низами, Рәшит Әхмәтҗанов, Нияз Акмал, Җәүдәт Миннуллин, Шамил Маннапов, Марсель Галиев, Тәүфикъ Әйди, Марс Шабаев, Наис Гамбәр, Камил Сәгъдәтшин, Мәгъсүм Хужин, Шәһинур Мостафин, Алмаз Гыймадиев, Факил Сафин, Камил Кәримов, Марат Закир...

Тулылыкка һич тә дәгъва кылмыйча шушы чорда басылган кайбер әсәрләр: «Туган ягым яшел бишек» (Г. Бәширов), «Әйтелмәгән васыять» (Ә. Еники), «Чирмешән буйларында» (С. Баттал), «Ямашев» (А. Расих), «Әтил суы ака торур» (Н. Фәттах), «Яшьлегемне эзлим» (Ә. Баянов), «Фронтовиклар» (М. Мәһдиев), «Идел кызы» (Г. Ахунов), «Җиләкле аланнар» (Р. Төхфәтуллин), «Биектә калу» (М. Юныс), «Яшьлегем утравы» (Ә. Маликов), «Язгы ажаган» (М. Хәсәнов), «Тайгак кичү» (И. Салахов), «Иртеш таннары» (Я. Зәнкиев), «Әткәм һөнәре» (Х. Сарьян), «Кубрат хан» (М. Хәбибуллин), «Безне өйдә көтәләр» (Х. Камал), «Йәгез, бер дога» (А. Гыйләжев), «Божра» (Т. Әйди), «Батырша» (Җ. Рәхимов), «Шинельсез солдатлар» (В. Нуруллин), «Яшисе килә!» (Р. Вәлиев), «Җилкәннәрне жил еккач» (Ф. Яруллин), «Хыянәт» (Ф. Латыйфи), «Сират күпере» (Р. Мөхәммәдиев), «Афәт» (Г. Тавлин), «Сөембикә» (Батулла), «Каргышлы этаплар» (Р. Кәрами), «Таң жиле» (Ф. Садриев), «Тәүбә» (Т. Галиуллин), «Болын» (Ф. Бәйрәмова), «Дөя муены» (М. Әмирханов), «Фидая» (М. Маликова), «Утлы божра» (В. Имамов), «Ат караклары» (З. Зәйнуллин), «Догалы еллар» (М. Галиев), «Ялгызак» (Р. Сибат), «Ком сәгате» (К. Кәримов), «Игезәкләр» (А. Тимергалин), «Албастылар» (Г. Гыйльманов), «Татар вакыты» (А. Хәлим), «Саташып аткан таң» (Ф. Сафин), «Терсәк сугышы» (З. Хөснияр)... Шуларга өстәп, С. Сабиров, М. Хужин, Б. Камал, Р. Фәизов, К. Тимбикова, Җ. Дәрзаманов, Ф. Яхин, Р. Зәйдулла, М. Закир һ. б. повесть һәм хикәяләре... Татар прозасының үзгә бер антологиясе бит бу әсәрләр! Ә шагыйрьләр? Күп гасырлык татар әдәбиятының нигезен алар салмаганмы? «Әдәбиятның Әнкәсе—гомердән Шигърият» дип тикмәгә генә тәкрарламыйбыз югыйсә! Көчле шигърият һәрвакыт әдәбиятны күрсәтеп килгән. Журналыбыз тарихында да ул шулай. Күп санлы бик яхшы шигырь-поэма исемнәрен санап китәргә мөмкинлегебез юк, шагыйрьләрнең үзләрен, аларның да кайберләрен генә (бәгъзеләр, шәт үпкәләмәсләр) искә алып үтик: Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арслан, Г. Афзал, И. Юзеев, С. Сөләйманова, Ш. Галиев, Роберт һәм Рәшит Әхмәтҗановлар, К. Сибгатуллин, Р. Харис, Ә. Рәшитов, Р. Мингалимов, Г. Рәхим, М. Әгъләм, Г. Зәйнашева, Ф. Гыйззәтуллина, Х. Әюпов, Зөлфәт, К. Булатова, Р. Миңнуллин, З. Мансуров, Л. Шагыйрьҗан, Б. Рәхимова, Г. Морат, Р. Газизов, И. Гыйлаҗев, Г. Мөхәммәтшин; яшь авторлардан—Р. Әймәт, И. Иксанова, С. Гаффарова, Л. Янсуар... «Казан утлары»ның актив авторлары—драматурглар Х. Вахит, Т. Миннуллин, Ю. Әминов, Ш. Хөсәенов, Р. Хәмид, Ю. Сафиуллин, Д. Салихов, Р. Сәгъди... Публицист язучыларыбыз—М. Зарипов, Р. Хисмәтуллин, Ф. Дунай, М. Әхмәтҗанов... Мәшһүр язучылар, шагыйрьләр белән беррәттән, журналның редколлегия әгъзалары булып торган яки үзләренең мәкаләләре, рецензияләре, бәяләмәләре белән әдәби хәрәкәттә актив катнашкан күренекле галимнәр: Р. Нәфыйгов, Х. Госман, Н. Юзиев, М. Хәсәнов, Ә. Кәримуллин, Ә. Борһанов, Ф. Хатипов, Ф. Урманчиев, Н. Хисамов, А. Әхмәдуллин... Бүгенге редколлегия әгъзаларыннан—М. Госманов, М. Мәхмүтов, Т. Галиуллин, Ф. Галимуллин, Х. Миннегулов... Үзем кәгазьгә җанга якын кадерле исемнәрне тезәм, үзем ирексездән, кайчандыр язылган шигырь юлларымны кабатлыйм: «Кемнәр бар да кемнәр юк!..», «Искән жил, үткән гомер, калган хәтер...»

Тыелган яки онытылган әдәби мирасны халыкка кире кайтаруда журнал эшчәнлеген әйтми узсак, язмабыз тулы булмас иде. Бер генә исемне аерып әйтү дә күп нәрсәне аңлата булыр: бөек әдип Гаяз Исхакый. Аның төп зур әсәрләре бүгенге укучыларга иң әүвәл безнең журнал аша ирештерелде. Бу бөек исемгә өстәп—С. Максуди, Й. Акчура, Г. Газиз, С. Җәләл кебек олуг затларның иҗат үрнәкләре. Борынгы мирастан—«Йосыф кыйссасы», «Идегәй» дастаны... Саный китсәң, алар күп томлыкларга җыелыр...

Журналны әдәби хәрәкәтне оештыручы бер үзәк дип тә, әдипләрнең профессиональ осталыгын билгеләүче мәйдан дип тә, әдәбиятның үзенә күрә бер «диспетчерлыгы» дип тә әйтеп буладыр. Кульязмалар, шөкер, әлегә күп керә. Табигый, һәммәсе журналда дөнья күрә алмый. Әмма, сайланып, редакцияләнеп, әсәр сыйфатында басылып чыкканнары аша да, бүгенге әдәби

тормышыбызда бара торган тенденцияләрне ачык чамаларга була. Әдәби Йортта уйланыр нәрсәләр житәрлек. Язучы хезмәтенен дәрәжәсе яки әдәби алмаш турындамы, жанрлар язмышы яки тематик диапазон хакындамы, яки китап язмышы мәсьәләләреме... Әйтик, халык ижаты традицияләрендә, милли тел стихиясендә тәрбияләнгән өлкән буын прозаикларын—Еники, Мәһдиев, Ахунов, Гыйләжевләрне кемнәр алыштырыр? Шигърияткә килүче яшьләр арасында ир балалар нигә аз күренә? Чын мәгънәсендәге әдәби тәнкыйтьнең булмавы жәмгыятьнең гомум әдәбиятка ихтыяжы кимүе билгесе түгелме? Бүгенге әдәбиятыбыз бөтен татар халкы әдәбияты булсын өчен ниләр эшләргә?.. Сораулар күп. Берничәсенең болай очын чыгарып куюның хикмәте шул: шушы ай ахырында, безнең юбилей саны аенда Татарстан язучыларының чираттагы корылтае узачак. Бу жыенда әдипләрнең милләт, әдәбият, гомумән, киләчәктәге рухи үсеш турында житди сөйләшүләре булыр, әйтеләчәк фикер-тәкъдимнәр, карар-резолюцияләр язучыларыбызны активрак ижат итәргә рухландырыр, шул исәптән журнал куйган олы максатларны үтәргә дә ярдәм итәр, дип ышанасы килә.

«Казан утлары»—үзенең башлангычыннан ук дәүләти басма. Сәяси-мәсләк ягыннан да, масштаб-колач ягыннан да. Ул шулай булырга тиеш тә. Уйласаң, бу тиешлекнең тамырлары тирәндә. Әллә ничә гасыр буе безнең кебек дәүләтчелеген югалткан халыкның киләчәк буыннарга калдырган бар булган рухи байлыгы, хыял-максаты, иман-идеясе, нигездә, сүздә—кульязмала, басмада, китапларда сакланган. Басма сүз, китап (бу очракта журнал да диик) күпмедер дәрәжәдә татар өчен дәүләт тә, дин дә, гыйлем чыганагы да булып торды... Үткән гасыр башында Татарстан республикасы оешкач, житәкчеләрнең язучыларга, язучыларның дәүләткә таянырга тырышуы, әлбәттә, табигый иде. Хәзер яна гасыр башында татарның аннан башка да зәгыйфь дәүләтчелек нигезләре какшатылган елларда төп мәсьәләләрдә халыкның бердәмлеге аеруча мөһим. Каләм ияләре әдипләр дә милли мәнфәгатьләр сагында уяу һәм фидакарь булырга бурычлылар. Дөньяда сүзнең кодрәте кимегәне юк әле! Әйтелгәнчә, журналыбыз дәүләти басма. Аның төп оештыручысы—Татарстан Министрлар Кабинеты. (Озак еллар буе «Казан утлары» фәкать Язучылар Союзы органы булып килде. 1991 елдан, устав нигезендә, журналны гамәлгә куючылар булып Министрлар Кабинеты, Язучылар берлеге, хезмәт коллективы санала). Ижат оешмаларының ижтимагый оешма хәлендә, дотациягә яшәгәннәрен истә тотсаң, журналның реаль кем органы икәнлеге ачык аңлашыла. Милли матбугат эше әбүнәчеләр һәм иганәчеләр хозурына гына калса, хәзерге чорда ерак барып булмас. Татарның үзгә бер гимни жырында әйтелгәнчә, «Заманалар авыр, еллар ябык, дус-иш кирәк гомер итәргә!»

«Казан утлары»на 80 яшь. Безнең өчен, әлбәттә, истәлекле зур дата. Журнал юбилее, ул—асылда, бәйрәмнән бигрәк, әдәбиятыбызның киләчәге турында кумәкләшеп бер житди уйлану, яңа максатлар билгеләү гамәле, әдипләр сүзен халыкка пропагандалауның бер үтемле чарасы. Әдәбиятыбызның зурлыгын, тарихи миссиясен белдереп, аны яңа буыннар тәрбияләүдә файдалану бүгенге көндә бик мөһим дип исәплибез. Юбилей унае белән, әдәби-мәдәни вакыйга буларак, республикабыз районнарында «Казан утлары» көннәре уза. Матбугат битләрендә журналыбыз турында сәхифәләр басыла, радио-телевидение тапшыруларында әдәбиятыбызның асыл әсәрләре, әдипләребезнең чыгышлары яңгырый. «Казан утлары» юбилеена багышланган тантаналы кичә Бөтендөнья татарларының III Конгрессы көннәрендә—август ахырында узачак.

Юбилеебыз уңаеннан редакциягә тәбрикнамәләр күп килә. Аларның берсендә мондый юллар бар: «Татар дөньясының бердәнбер саллы журналын, милләтебез рухының кабатланмас елъязмасын, халыкның әдәбе сагында торучы каләм әһелләренең төп ижади мәйданы булган басманы һәм аның тырыш хезмәткәрләрен олуг бәйрәмнәре белән ихлас күңелдән тәбрик итәбез!»

Зур сүзләр, горурланырлык сүзләр, әмма зур жаваплылык та өсти торган сүзләр. Жавабыбыз шул: зур тәжрибәгә, якты сәхифәләргә ия булган «Казан утлары» халкыбызның бу яңа гасырдагы яшәешенең дә гадел елъязмачысы, килер буыннарның рухи юлдашы булыр дип ышанасы килә.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
*«Казан утлары» журналының баш мөхәррире,*
*Татарстанның халык шагыйре.*

# RƏSEMNƏRDƏ–JURNAL TARİXI



**Elgərlərebez:** "Şura" jurnalının redkollegiəse. *Suldan unğa:* **Ğabdraxman Fəxretdinov, Fatix Kərimi, Rəqib Rəqibi, Riza Fəxretdinov, Ğosman Aqçoqraqlı, Dərdmənd, Yarulla Wəli, Borhan Şərəf.**

*Orenburg şəhəre. 1909 yıl.*



"Beznen yul" jurnalının in aktiv avtorları. *Suldan unğa:* **Ğabdraxman Minskiy, Hadi Taqtaş, Ğədel Qutuy.**

*Qazan. 1928 yıl.*



Tatar yazuçıları Vasilyevo yal yortında. *Alğı rəttə (suldan unğa):* **Xəsən Tufan, Sibğət Xəkim, Musa Cəlil, Əxmət Fəyzi.** *İkençe rəttə:* **Əxmət İsxaq belən Şəyxi Mannur.**

*1940 yıl.*



SSSR Yazuçılarının IV s'yezdı delegatları: *Suldan unğa:* **Xəy Waxit, Xəsən Tufan, Zəki Nuri, Ləbibə İxsanova** həm **Mirsəy Əmir.**

*Qazan. 1966 yıl.*



Watan suğışında qatnaşuçılar jurnal redaksiəsendə. *Alğı rəttə (suldan unğa):* **Ğosman Bakir, Afzal Şamov, Ğabdraxman Minskiy, Əxmət İsxaq, Tixon Juravlyov.** *İkençe rəttə:* **Safa Sabirov, Nur Ğaysin, Mostafa Noğman, Atilla Rasix, Nəbi Dəwli, Səyet Şəkürov.**

*1960 yıllar.*



Redaksiədə uzdırılğan cıılıştan ber küreneş. *Suldan uňğa:* **Nuri Arslanov, Qoyaş Timbikova, Sibğət Xəkim, Zəki Nuri.**

*70 yıllar axırı.*



"Qazan utları" jurnalının 70 yıllığın bilgeləp ütkəndə. Ğ. Kamal isemendəge TDAT səxnəsendə: baş redaktor **Rawil Fəyzullin** həm **məxtərəm qunaqlar.**

*1992 yıl.*



Jurnalnı "Azatlıq" radiosının tatar-başqort redaksiəse citəkçese **Fərit İdelle** təbrik itə.

*1992 yıl.*



**Tuqsan yıldan son.** "Qazan utları" jurnalı redkollegiəse əğzaları həm çaqırılğan qunaqlar. *Suldan uňga (alğı rəttə):* **Flüs Latıyfi, Rədif Ğataş, Raşat Nizami, Ayaz Ğiləcev, Xatip Minneğulov, Əxsən Bayan, Əmirxan Yeniki, Ğəmər Başirov, Ğarif Axunov, Rawil Fəyzullin, Əxmət Rəşit.** *İkençe rəttə:* **Xarras Əyüp, Rkail Zəydulla, Şəwkət Ğəliev, Mirqasıym Ğosmanov, Zinnur Xəsniar, Təlğət Ğəliullin, Rinat Məxəmmədiev.**

*Qazan. 1999 yıl.*

## BƏYRƏMGƏ ŞİĞRİ BƏYLƏM

«Bezdə Ədəbiat Ənkəse—ğəmerdən Şiğriət» dip, şuŋa oluğ ışanıç belən icat itə bügenge şağirlərebez: dimək, Şiğri Süzneŋ borıŋğılığına, ilahi kəçenə, yəşəwçənlegenə, xətta ülemsezlegenə—zur missiəsenə iman kiterü bu.

Jurnalıbıznıŋ 80 yıllıq (annan elgəre yıllar həm basmalar da istə!) tarixına küz salsaq ta, bez, şağirlər, «şaqtıy ezlebez» ikən ləbasa! Əye, moğtəbər jurnalıbız çıga başlagannan alıp, bezneŋ basmada H. Taqtaş, X. Tufan, Ğ. Qutuy, Ə. Fəyzi, Ş. Mannur, M. Cəlil, S. Battal, F. Kərim h. b. kebek kürenekle isemnərne kürerbez: jurnalıbız bitlərendə alar üzlərenəŋ waqiğa-etaplar sanalırday qalqu, çın şiğri əsərləren qaldırğannar. İkençe yaqtan—busı da qızıqlı, meğayın!—şağirlərebez üzlərə də jurnalnı çığaruda turıdan-turı qatnaşqannar—redaksiədə eşləgənnər (həm eşləp kilələr!), məxərrirlər bulğannar. Suğışqa qədər, 1934-1937 yıllarda «Sovet ədəbiatı»nda cawaplı sərkətip bulıp ataqlı şağir Xəsən Tufan eşləsə, 1938-1941 yıllarda Sibğət Xəkim biredə bülek mədire wazifasın başqara... Ə soŋğı distə yıllarnı alsaq, inde baş məxərrir bulıp ta kürenekle şağirlərebez eşləwen kürerbez: 1968—1971, 1974—1982 yıllarda bu oluğ wazifanı Zəki Nuri başqarsa, 1982-1989 yıllarda Renat Xaris dəwam itte. 1989 yıldan—baş məxərrir bulıp xalıq şağire Rawil Fəyzullin eşli (Şiğriətebezgə, şağirlərebezgə zur ışanıç həm məxəbbət bilgese bu, hiçşiksez!). Baş məxərrir urınbasarı bulıp ta şağirlərebez eşləde: Əxsən Bayan (cawaplı sərkətip bulıp başlagan ide) bu wazifanı ozaq yıllar başqardı; Mədərris Wəliev, Rəşat Nizamilar da baytaq waqıt şul xezmətte ide. Cawaplı sərkətip bulıp ta şağirlərebezdən Mars Şabay, Robert Minnullin, Nais Ğəmbərlər eşləwen əytə alabız (jurnalda Xəsən Tufan eşen şağirlər dəwam itü!). Sibğət Xəkimneŋ poeziə bülege məxərrire bulu traditsiəsen də isemle-abruylı şağirlər dəwam itte: Nuri Arslanov (1964-1972), Rəşit Gərəy (1959-1963), İldar Yüziev (1973-1975)... 1975 yıldan bu wazifanı Rədif Ğataş başqarıp kilə.

Tərle büleklərdə məxərrir bulıp eşləgən şağirlərebezne də iskə alu urınlı bulır: mərxüm Rəşit Əxmətcannı, isənnərdən Gərəy Rəxim, Şamil Mannap, Marsel' Ğəli, Zinnur Mansur, Niaz Akmal, Şahinur Əxmətsafa, Kamil Səğədətlərne... Ə inde redkollegiə əğzası bulıp tərle yıllarda eşləgən, redaksiəneŋ dustı, kiŋəşçese bulgan S. Xəkim, Ş. Mannur, Nacar Nəcmi (Ufa), Şəwkət Ğəliev, R. Mingalim, Zəlfət, Mədərris Əğləm, Xarras Əyüplərgə hərçaq rəxmətlebez.

Avtorlarıbız bulğan şağirlərne sanasaq, «tabaq-tabaq qəğəz də citməs ide»: alar küp, gel aktiv bulıp, ədəbiatıbıznıŋ avangardında bardı. Şuŋa da hiç ikelənmi əytə alabız: şağirlər qulı belən jurnalıbıznıŋ küp asıl səxifələre yazıldı həm yazıla kilə... Kiləçəktə də şulay bulır, inşalla!

Uquçılar kürer: bu sanda yubileyğa dip latin yazuında birelgən bəyləm—klassik şağirlərebezdən həm redaksiədə eşləgən mərxüm qələmdəşlərebez icatınnan saylap alınsa, ikençe şundıy bəyləm isən şağirlərebez—jurnal xadimnəre şiğerlərennən tuplandı. Nəni genə şiğri antologiə dip qabul iteler alar, bəlki. Sezneŋ xozurıŋızga!

# Hadi Taqtaş

(1901 – 1931)

## Tan̡ qızı

Pəri qızı! Nik çıqtın̡ da yullarıma,
Utlı qızıl gəllər totıp qulların̡a,
Gəllərenn̡e ırǵıtıp ber yılmaydın̡ da
Nik yəşrenden̡, tərenep tan̡ nurlarına?

Min bara idem yalǵız ǵına urman buylap,
At østendə tirən, serle uylar uylap,
Tirgə batqan turı atımnın̡ yefək yalın
Tuzdırıp, taǵın ürep, uynap-uynap.

Pəri qızı! Nik çıqtın̡ da yullarıma,
Təmuǵ gəlen totıp neçkə qullarıŋa?
Küz attın̡ da küzlərемə, nik ırǵıttın̡
Uynap-uynap mine təmuǵ utlarına?

Şəwkət belən tan̡ nurları arasınnan,
Bəxet ezləp, ildən ilgə barǵan çaqta,
Tan̡ qızı, Gəl, nik çıqtın̡ da yullarıma,
Bəxet gəlen totıp neçkə qullarıŋa,
Man̡ǵayımnan übep mine, nik yuǵaldın̡,
Taǵın kire tərenep tan̡ nurlarına?

Xəncəremne qulıma alıp əkren genə,
Tan̡ aldında qarurmannan yəşren genə
Yaw østenə barǵan çaqta kinət kenə,
Tan̡ qızı, Gəl, nik çıqtın̡ da yullarıma,
Kisken xancər totıp neçkə qullarıŋa,
Çənçep bəǵrem urtasına xəncərenn̡e,
Nik yuǵaldın̡, tərenep tan̡ nurlarına?

Tan̡ da attı. Ay da battı. Min quzǵalmıym:
Tan̡ saxirəsen at østendə tuqtap kətəm,
Taǵın kiler, səyər diep – alır diep
Xəncəren ul qan̡ǵa batqan kükrəgemnən...

# Xəsən Tufan

(1900 – 1981)

## Aq qayın

Yafraqları yəşel aq qayınǵa
Yul buyınnan aqlar kildelər,
Aq qayınnın̡ yarlı awıldaşın
Bilbawına asıp kittelər.

Asuçılar kitkəç, sorıy qayın:
– Awırtmıymı muyının̡, Xəybulla?
– Awırtuǵa tüzər idem, qayın,
Tın aluı bigrək awır la.

Bilbaw qısa, qayın, sulışqaynı,
Buşatsana şuşı bilbawnı!
– Buşatır da idem bilbawınnı,
Min qayında andıy qul barmı?

—Bəgelsənə, qayın, ielsənə,
Ayaqlarım cirgə timəsme?
—Bəgeler idem, buyım qatı minem,
Ütər xəl yuq sineņ kinəşne.

—Səlam tapşır, qayın,—dide yeget,
Tınıp qaldı şunda annarı...
Ber endəşte qayın, əç endəşte,
Bütən ber süz işetə almadı.

Yafraqları qoyıla aq qayınnıņ,
Yafraqları qoyıla yəş kebek.
Əle bulsa tirbələder təsle
Şul qayınğa asqan yəş yeget.

Əytsəgez lə şuşı aq qayınğa:
—Yılama sin, qayın, appağım,
Kiņ qırlarda üze genə tügel,
Eze də yuq inde yatlarnıņ.

## Musa Cəlil

(1906—1944)

### Cırlarım

Cırlarım, sez şıtıp yərəgemdə
İl qırında çəçək atığız!
Küpme bulsa sezdə kəç həm yalqın,
Şulqədərle cirdə xaqqığız!

Sezdə minem bəten toyğılarım,
Sezdə minem kersez yəşlərem.
Sez ülsəgez, min də onıtılırmın,
Yəşəsəgez, min də yəşərmen.

Min qabızdım cırda yalqın itep
Yərəgem həm xaqlıq quşqannı.
Cırım belən dusnı irkələdem,
Cırım belən cindem doşmannı.

Aldıy almas mine tübən ləzzət,
Waq tormışnıņ çuar pərdəse,
Şiğeremdəge çınlıq, ut həm səyü—
Yəşəwemneņ bəten məğnəse.

Ülgəndə də yərək tuğrı qalır
Şiğeremdəge izge antına.
Bar cırımnı ilgə bağışladım,
Ğemeremne də birəm xalqıma.

Cırlap üttem danlı kərəş qırın,
Cırlap kildem tormış yazıma.
Soņğı cırım palaç baltasına
Başnı totqan kileş yazıla.

Cır əyrətte mine xər yəşərgə
Həm ülərgə qıyu ir bulıp.
Ğemrem minem monļı ber cır ide,
Ülemem də yaņrar cır bulıp.

## Sibğət Xəkim

(1911–1986)

### Başqa berni də kirəkmi...

Tuıp-üskən şuşı cirnen yəmen
Alıştırmıy ikən hiçnərsən.

Başqa berni də kirəkmi,
Üzem çapqan peçənnərne
Ber tuyğançı isnəsəm.

Mina ğına şulay toyıla mikən
Bəten rəxətlərə son anın?

Başqa berni də kirəkmi,
Üzem tapqan çişmələrnen
Yatıp eçsəm suların.

Ürlərə də zəngər dulqın-dulqın,
Ul ürlərnen çige qayda son?

Başqa berni də kirəkmi,
Duslarnın min ğəmerem buyı
Toysam cılı qaraşın.

## Nuri Arslanov

(1912–1991)

### Üteneç

Üzen qotqar bəla həm afəttən,
Yərdəmçem bul, nilər kürsəm də.
Tik qotqara kürmə məxəbbəttən,
Uçağında kəlgə dünsəm də.

Ozaq yəşim inde—küp bulğandır
Gənahlar da, üzen yarlıqa.
Tik məxəbbət gənahların qaldır,
Min bəxetle alar barlıqqa.

Yaman teldən, yaman küzdən saqla!
Səyü xisen sayrat, telen aç!
Hiç rəncemən ğıyş wə ğəşrət xaqına
Qalsam da aç həm şır yalanğaç.

Şigen bulsa Veneradan soraş,
Sinnən-minnən kübrək belə ul.
Məxəbbətkə əsir hər ğəziz baş!
Şuna bezdən kələ genə ul.

Cibril wəxiy—ilham kiterə diep,
Kətsəm sinnən zarığıp kiç-irtə,—
Amurları anın kilə biep:
Uynıy-kələ, səyderə, isertə...

Sin üzen də təxeten—biek küktən
Alihəne kürsən, məğayın,
Ğaşiq bulır iden həm məkibbən
Kitər iden buğay, xodayım!..

Bu dənyada tıngı belməgən can
Tegesendə, belmim, tınarmı!
Kisətep quy əle üzen aldan
Qəber taşı yazuçılarnı, –

Taşqa camlı amur yasasınnar,
Camda şərab – şatlıq yəşləre...
«Tınıç yoqla...» tügel, ə yazsınnar:
«Ul, – dip, – tudı, səyde, yəşəde».

## Zəki Nuri

(1921 – 1994)

### Min üzem səyer ikən...

Sizdem, duslar, səğətemnen,
Sizdem səyer ğədəten;
Sizdem səyer ğədəten min –
Sonğa qala səğətem.

Ni dip tə əytergə belmim,
Ni buldı, nərsə səbəp:
Tibeşennən yerəgemnen
Nik artqa qala səğət?

Yərmider kebek tellərе,
Qarıym da qabat boram.

Oçraşu kətkən kənnərne
Gel şuna qarap toram.

Səyer aşqınu bar mində –
«Kətəm!» digəndə irkəm,
Səğətem sonğarır dim də,
Əç səğət aldan kitəm...

Səğətne yuqqa borğanmın,
Anlattı, xəyer, irkəm:
Ülərdəy ğaşiq bulğanmın,
Min üzem səyer ikən...

## Rəşit Əxmətcan

(1941 – 1995)

*

Artqa çigenmədek diər idem,
Kilde yawlar... Bez də çigendek.
İlne səyü ğəmerlekkə bulğaç –
Ul çigenü buldı ber kənlek.

Cinep üldek, cinep isən qaldıq!
Çigenülər bulmas qabattan.
Qollar baş kütərgən kənnən birle
Məngelekkə azat bu Watan.

## Çəçmə əsərlər
## Чәчмә әсәрләр

**Факил Сафин**

# САТАШЫП АТКАН ТАҢ

ИКЕНЧЕ КИТАП

РОМАН

* * *

Алар тукталган йорт—каравыл өе. Бер үк вакытта авыл советы бинасы да, ызба-читальня ролен дә үти икән. Минзәлә "кунакларын" ике кеше каршы алды. Авыл советы рәисе, кызыл йөзле, сары керфекле Сабиров һәм ак чырайлы, тавышын кайдандыр тирәннән кысып чыгарып сөйләшүче Габитов—партия ячейкасы секретаре.

Бераз юангач, кечкенә киңәшмә үткәреп алдылар. Авыл волость үзәге булса да, волком житәкчеләре якын-тирәдәге авылларда советка, коллективлаштыруга каршы кешеләрне ачыклау белән мәшгульләр, һәр волостька, волком тарафыннан исә һәр авылга контроль саннар житкерелгән, шушы саннарның үтәлешенә карап, партия ячейкасы, авыл советы эшенә бәя бирелә. Волком, авыл активлары, көн-төн чабалар, әмма канткомнан төшерелгән саннарны үтәп өлгерә алмыйлар икән.

Каршылаучылар арасында волкомнан вәкил булмавына Шәмтиев пошынып:

—Җаваплылыктан качалар, понимаешь!—дип, сукранып алды. Имеш, авыл советы эшенә тыгылмыйлар.—Ничава, кайткач, Филлиповка әйтеп, җоннарыгызны туздыртам...

Үзенә артык игътибар итүче булмагач, Шәмтиев тынды. Монда кем башлык икәне ярылып ята—Сабиров белән Габитов ОГПУ кешеләре тирәсендә бөтереләләр иде.

Авылга төн үзәге житкәндә, күзгә төртсәң күренмәслек караңгыда килеп кергәнлектән, Әхмәтсафа авыл белән аз гына да таныша алмады, әмма якын-тирәдә Әмәкәй белән тинләшерлек авыллар юк дип кисәткәннәр иде Минзәләдә.

—Әгәр дә уйламыйча, тиешле хәзерлек күрмичә эш башласагыз, кайбер кантоннардагы хәлләр монда да кабатланырга бик мөмкин,—дигән иде Филиппов юлга кузгалганда.—Кулакларны, муллаларны халык чолгап алып, авылдан алып китәргә комаучалыйлар. ОГПУ вәкилләрен үзләрен тотак итеп алалар. Совет вәкилләрен өйләренә үткәрмиләр.

---

Ахыры. Башы 4 санда.

Каршылык күрсәтүче табылса, жебеп, каушап калмагыз, нагайка-чыбыркы тоткан кулларыгыз калтырамасын, кирәк булса, корал кулланырга да тайчанмагыз—сез дөрес юлда, кылган барлык гамәлләрегез акланачак, чөнки сез халык өчен, ил өчен көрәшнең иң авыр участогында бүген,— дип, жилкендереп калган иде.

Шәмтиев шушы ук сүзләрне Габитов белән Сабировка да кабатлады. Сабиров урынында утырып тора алмый, тынгысыз кеше, башта Минзәләдән килгән вәкилләрнең атларын урнаштырып, чабулап йөрде, аннан вәкилләрнең үзләренең тамакларын туйдырып мәш килде. Габитов исә, Шәмтиевнең сөйләгәннәрен төче елмаю белән тынлап торды-торды да, тавышын кысып кына, тагын каядыр чыгып китәргә жыенган Сабировка эндәште:

—Иптә-әш Сабиров, исемлекне бир әле-е... Иптә-әш Шәмтиев белән киңәшеп алыйк, дим. Нәрсә житми-и, нәрсә арты-ык дигәндәй...

—Бар, исемлек, бар, ул. Инде өч көн кесәдә саклап тотам...

Сабиров ара-тирә "гөлт-гөлт" итеп ялкын чөеп алса да, гамәлдә сүрән янган куыклы лампа кукыраеп утырган өстәл янына килеп, исемлек язылган кәгазьне җәеп салды.

—Әйе, исемлек ба-ар ул...—дип төчеләнде Габитов.—Бер генә дошман элемент та төшеп калмады. Тырыштык инде, тырыштык. Бәй, соң... кулдан килгәннең барысын да эшләдек, әйеме, иптәш Сабиров? Шуны да эшләмәскә ни-и..

—Йокы-мазар күргән юк бу арада, гел исемлек барлап утыру булды инде.—Сабировның тынгысыз карашы Дәүләтьяровка төртелеп туктап калды. Чыннан да үтә тырышлык күрсәтүләре хак иде, хәлне кантком вәкилләренә төшендереп, теләктәшлек табасы килә иде.—Нидер сизенә кулак, авылда кот калмады бу көннәрдә, әмма без алай капчыкны төбеннән тотып селкемәдек...

—Сизенмичә, иптә-әш Сабиров, кайткач хатыныңа ычкындыргалый торгансыңдыр. Хатын колагына кергән сүз авыздан чыкмый калмый ул!— Габитов аерым бер ләззәтле мизгелләр кичереп, исемлекне укый башлады. Ара-тирә аңлатма биреп тә бара иде.—Исемлеккә, иптәш Шәмтиев, дүрт мәчетнең дә муллаларын, мөәзиннәрен керттек. Түбән оч мәчеттән—Бакир мулла, Фазыл мулла, Шәрәфетдин мулла... Бусы-сы Түбән оч мәчете-ете... Урта мәчеттән—Шәйхелислам мулла, Мирзасалих мулла, Нурлыгаян мулла-а... Менә бусы-сы Урта мәче-ет... Югары оч мәчетеннән—Әхмәтшакир мулла, Мирзаян мулла, Әхмәтзакир мулла-а... Менә бусы-сы Югары оч мәчете-е. Манарасыз мәче-ет... Бусы-сы яна мәчет була инде-е... Анда бер Хөснетдин хәзрәт кенә гыйбадәт эшләрен алып барды.

—Габитов төгәл кеше ул! Исемлекне бик җентекләп төзеде,—диде Сабиров житди кыяфәт белән.

—Бар, бар, монда барысы да бар, иптәш Шәмтиев. Категорияләрен шапылдатып сугып чыгыйммы соң? Бездән калмасын дигәндә-әй...— Габитов куштанланып, кулына каләм алды.

—Озак сузабыз!—Шәмтиев тынычсызлана башлады. Ишек төбендә утырган ОГПУ вәкиленә шөбһәле караш ташлап алды. ОГПУ вәкиле аның сүзен җөпләп, баш какты.

—Ашыгырга кирәк, авылдагы күп өйгә һаман ут элсенгән килеш. Соң дип тормый халык, йокларга ашыкмый, нидер сизенгән шикелле.

—Борчылмагыз, Әмәкәй халкы бик чуар халык ул,—дип тынычландырды аларны Габитов.—Иптәш Сабиров активистларны чыгарып жибәрде инде, барысын да жилтерәтеп китереп житкерерләр. Шым чыгаручы да булмас. Монда бит борынгыдан теләсә кайдан җыелган халык. Берсенә яманлык эшләсән, ике як күршесе сөенеп утыра. Безнең халык шундый бит ул.

—Активистларыгыз кая соң? Күзгә-башка күренмәде.

—Һи-и,—дип, нечкә тавыш белән көлгән булды Габитов.—Аларны өч көн шартлы тотак итеп, күршедәге Якуб бай келәтендә яткырдык.

һәркайсына задание житкерелгән, хатыннары килеп ашатып йөрделәр. Үзләре дә ялыгып беттеләр, бичаралар. Инде бәйдән ычкынган эт шикелле кылана торганнардыр. "Әгәр үзегезгә беркетелгән кешеләрне китереп житкермәсәгез, үзегезне тотып жибәрәбез,—дидек.—Хатыннарыгызны камчы белән ярабыз, балаларыгызны авылдан куабыз,"—дип куркыттык. һи-и, шүрләделәр, иптә-әш Шәмтиев. Кая барсыннар, безнен халык куркак бит ул. Берсе өстенә өстерсән, икенчесен ботарлап ташларга да әзер.

ОГПУ вәкиле каравыл йортындагыларга кирәксә-кирәкмәсә чыгып йөрмәскә кисәтеп, чыгу ягына кузгалды. Каерып ачылган ишектән бөркелеп суык керде. ОГПУ вәкиле чыгып киткәч, Шәмтиев, үзен зур түрәгә санаган кебек, түшен киерә төште. Вәкарь рәвештә Габитовтан сорашуын дәвам итте.

—Хуш, кемнәр киләчәк инде монда? "Минзәләгә, төрмәгә алып китәргә",— дип, жыясызмы халыкны?

—Юк инде, иптәш Шәмтиев, без дөнья күрмәгән кешеләр түгел бит. Минзәләдән вәкилләр килгән, бер кәгазьгә кул куясыз да, кайтарып жибәрәләр, дип әйтергә куштык. Әйе-е, иптәш Шәмтиев, моны гына беләбез инде без. Сабиров булса, ул да жөпләр иде сүземне.

Шәмтиев, кинәт кенә Әхмәтсафаны исенә төшерде булса кирәк, ана борылды:

—Иптәш Дәүләтьяров, менә бу исемлектәге язылган адәмнәрне тиз генә категорияләргә бүлеп яз әле!

—Категориягә?—дип, аптырап сорады Әхмәтсафа.—Мин бит аларнын ни үзләрен, ни кылган гамәлләрен, матди хәлләрен белмим. Моны иптәш Габитов үзе генә эшләсә инде...

Шәмтиев ризасызлыгын белдереп, кашларын жыерды, мыгырданып алды:

—Минзәлә тиклем жирдән килеп, кул кушырып утырмассын бит. Нәрсә дә булса эшләргә кирәк.

—Мина кушылган кадәргесе шул—мондагы хәлләр белән танышырга, тәжрибә алырга, кайткач, хисап бирергә.

—Хисап бирүчеләр буа буарлык, эшләргә дисән—Шәмтиев... Әйдә, Габитов, укып чык, мин үземә язып алып, категорияләргә бүлеп чыгармын.

Габитов тырышып исемлекне укый башлады. Ара-тирә шәрехләп тә ала иде.

—Муллаларны әйттем инде, алар жәмгысе ун кеше була.

—Булсын, булсын, бер сүзекәем дә юк...

—Инде байларга, кулакларга килсәк, эш болай тора-а... Хөснелгата бай, Хәсән бай, Биктимиров Өммәткол—бик зәһәр адәм, усал, куатле кеше бу... Инде дә килеп Шәвәлиев Гыйзетдин, Латыйпов Якуп—бай Якуп дип йөртәләр, монын уллары Гыйззәт, Габдрахман, Салих... Инде дә килеп Мөхәммәди Закиры, Суфиянов Миркасыйм, Йосыф...

Габитов укый бара, Шәмтиев анын артыннан яза барып, һәркайсын үзенчә категорияләргә бүлгәләп бара иде. Кешеләрнен язмышына карата шундый битарафлык белән Әхмәтсафа бу дәрәжәдә, бәлки, беренче мәртәбә очрашкандыр.

Исемлекне барлап чыккач, Шәмтиев тузына башлады.

—Нинди хәл бу?—дип жикеренде ул Габитовка.—Контроль сан житкерелмәгән идеме сезгә? Бер кешен житми, панимаешь!

—Житкерелде-е...—Габитовнын тавышы еламсырап чыкты бу юлы.—Тырыштык, иптә-әш Шәмтиев, кулдан килгәнчә. Авылда хәлле дигәннен барысын да жыеп тутырдык... Ничек үтәп чыкмак кирәк—егерме жиде кеше-е бит ул, егерме жиде...

—Әкият сөйләмә, Габитов! Әмәкәйнен һәр икенче кешесе мондагы өч категориянен берсенә керерлек. Кара аны, үзенне алып китәбез, заданияне үтәмәсән!

—Ни бит, иптәш Шәмтиев, күпләре авылны ташлап, чыгып киттеләр, теге вакытта ук. Моннан алда да жыеп жибәргәләдек... Кими бит, халык.

Бер кеше тулмый инде, шуңа да бәйләнеп...

—Житте, Габитов, әнә ОГПУ вәкиленә әйтеп, кул-аягыңны бәйләтеп, чанага чыгарып салдырам. Тап бер кеше!

Габитов куркынган күзләре белән ишектән кереп килүче ОГПУ вәкиленә карап алды, бер тын уйланып утыргач, ниһаять, тәвәккәлләп авызын ачты.

—Менә безнең авылда Сөләйман карт бар. Бик ачы телле нәмәкәй. Әле кичә дә, ураза аенда мәчетләрне ачтырмыйсың, дип бәйләнде миңа. Ата күркә дип мыскыл итте. Әллә соң...

—Язып куй исемлеккә! Сөләйман картмы-чуртмы, анда бер кешенең дә эше юк, контроль сан гына үтәлсен.

...Озакламый каравыл өенә халык җыела башлады. Барысының да йөзе сүрән, барысы да хәлләренең мөшкел икәнен аңлыйлар. Үзара бер-берсенә нидер әйтеп алалар да, тынып калалар. Бары берсе генә гайрәт чәчеп азапланды:

—Кая, нинди кәгазьгә тамга саласы? Озаклап маташырга вакыт юк, сәхәр ашар вакыт житә...

—Ашыкма-а, Өммәткол абзый,—диде Габитов, әүвәлгечә төче тавыш белән.—Жыелып бетсеннәр инде. Кеше саен бер амин дигәндәй, һәркайсыгызга аерым-аерым аңлатып-сөйләп тора алмый бит инде кантком вәкиле. Минзәлә тиклем жирдән юкка килмәгән.

Шәмтиев, Габитовның жавабын ошатып, баш какты. Халык жыелып беткәч, исемлек буенча барлап чыктылар. Тышкы якта, каравыл өе тирәсендә хатын-кыз, бала-чага тавышлары ишетелә башлады. Күрәсең, алар да хәлләрнең хәтәр икәнлекләрен төшенәләр. Ир-атларның өсләрендә төн, толып. Тиз генә кайтмаска мөмкин икәнлекләрен болары да яхшы чамалыйлар булса кирәк. Мылтыклы гаскәриләрне күреп алгач, эшнең ниндидер кәгазьгә тамга салу белән генә бетмәячәге ачык иде инде аларга. Күбесенең йөзендә күндәмлек, язмышка буйсыну, чарасызлык ярылып ята иде.

Әхмәтсафа урамга чыкты. Арылган, йончыткан. Таңга ерак калмый, авыл шомлы хәбәр күтәп басылып, чүгеп калган сыман. Сизелеп тора, бүген беркем дә йокламый, авыл уяу иде. Офыкта ниндидер яктылык уйнап алды кебек. "Тагын бер шайтан таңы" дип, ачынып уйлап куйды Әхмәтсафа.

Каравыл өе тирәсенә унлап олау жыелган. Олаучыларны ОГПУ вәкиле бер тирәгә жыйнап, нидер сөйли, аңлата иде. Каравыл өенең кечкенә ихатасы алдында киеренке тартыш бара. Кемнәрдер, күрәсең, монда жыелган кешеләрнең туганнары яки бала-чагасы каравыл йорты эченә үк үтеп кермәкче була, атка менгән ОГПУ гаскәриләре, кулларына камчы тоткан авыл активистлары андыйларга каршы төшеп, капкага якын жибәрмәскә тырышалар. Анда сәер тартыш, шау-шусыз буталыш бара иде...

Тынлык озакка сузылмады. Бер малай үзәк өзгеч тавыш белән:

—Әткәй! Әткәем!—дип кычкырып жибәрде. Тавыш иясенә камчы тоткан бер активист ташланды, һаваны ярып камчы чыжлады. Баланың инрәп:

—Күзем... күзем...—дип ачыргалануы ишетелде.

Әхмәтсафа авыр уйлар белән эчкә үтте. Шәмтиев, ике ягында ике гаскәри торган хәлдә, жыелган халыкка соңгы сүзләрен житкерә иде инде:

—Шулай итеп, туганнар, кәгазьне безнең кулга бирмәделәр, һәркем Минзәләнең үзенә барып, кул куярга буласы булып чыкты. Без канткомда уйлаштык. Авыл халкының эше күп, урык-сурык йөрергә вакыты юк. Аерым-аерым килеп, тамга салганнарын күтәп ятсаң, ай үтәр дидек. Эшне жинеләйтергә булдык, бергәләп олауларга төялеп юлга чыгабыз, Минзәләдәге эшләрне бетереп, иртәгә үк, төштән соң, кире кайтырга чыгарсыз шул ук олаулар белән. Олаулар әзер. Иптәш Сабиров, кем кайсы атка утыра, аңлатып чык. Кисәтеп куям, кем дә кем урамдагы халыкка коткы таратырга маташып, мин әйткәнне башкача аңлатып

азапланса, гаскәриләргә фәрман бирелгән, урында ук атып егабыз. Аңлашылдымы?

Халык бу кадәр кискенлектән, телсез калган иде, шулай да "иртәгә төштән соң үк кире кайтып китәсез" дигән сүзләр күбесенең җанында өмет чаткысы уяткан иде, нидер әйтеп, кабат-кабат сорашып-белешеп торасы итмәделәр. Кемдер уфтанып куйды:

—Ходайның язганы булыр инде... Изге ураза айларында...

Сабиров кулындагы кәгазьгә карап, авылдашларына яңы белән баскан хәлдә, калтыравык тавыш белән укый башлады.

—Беренче олау—ат тотучы Сафиулла малае Мөхәммәт. Миргалим мулла, Фазлый мулла, Габдрахман утыралар...

Сабиров укыганда, Габитов бу эшләргә бөтенләй катнашы юк шикелле, җыелган халык белән рәттән басып, тынлап торган булды.

Әйтеләсе сүзләр әйтелеп беткән, җыелган халыкны олауларга урнаштыру башланды. Эшнең шома гына баруыннан Шәмтиев канәгать иде, кешеләр чыгып беткәч, каравыл өендәге авыр тынлыкны бозып, күтәренке тавыш белән Габитовка эндәште:

—Кара аны, Габитов, без киткәч, авылда тынычлык булсын. Башың белән җавап бирәсең...

—Бер дә шау-шу чыгарасы килми дә, иптәш Шәмтиев. Кара як бит бу. Халык сарык белән бер. Берсе башласа, икенчесе иярергә генә тора...

—Иярмәсләк ит! Таң сызылуга, Минзәләгә озатылганнарның хатыннарын каравыл өенә җыегыз, һәркайсына утыз-кырык камчы. Кайсын базга, кайсын келәткә ябып, телләрен тешләтерлек итегез. Авызын ачсалар да, сүз әйтерлек хәлләре калмасын. Кемнең кайсы категориягә керүенә карамастан, иң беренче эш итеп, өйләреннән куып чыгарыгыз. Бала-чагасы белән авылдан сөрегез. Кемнең ике-өч хатыны бар, олы хатыннарын кыйнап ташлагыз, башка хатыннарын авылда байгыш булып йөрүче әтрәк-әләмгә хатынлыкка таратыгыз. Риза булмаганнарны, чамалыйсың инде нишләтергә.

—Беләбез, иптәш Шәмтиев. Ризалаштырырбыз, әйе-е...

—Сиңа өч көн вакыт, Габитов, әгәр йөз процент колхоз булмаса, үзеннең хатыныңны шәрә килеш урам буйлап йөртәбез. Гыйбрәт булсын, пешмәгән ячейка секретарьларына.

Габитов бөрешеп, иягеп якасы эченә яшерде.

—Үтәрбез, иптәш Шәмтиев. Бүре көтүе олакса, авылда Сабиров белән миңа каршы сүз әйтүче калмый. Активистларыбыз да бик әйбәт, тыңлаучан кешеләр. Ни әйтсәң, шуны үтиләр. Өч көн эчендә барысы да колхоз булып бетәр, боерган булса...

—Нинди "боерган" ул тагын?—дип җикерде Шәмтиев.—Кем нәрсә боера сиңа, әллә боеручыларың бармы бездән башка?

Габитов кызарып чыкты.

—Тфү-тфү, нәләт, авыздан ычкынды, иптәш Шәмтиев. Йөз процент колхоз булыр, коммунист сүземне бирәм...

—Шулай диген, "боерган"ны күрсәтермен мин сиңа, әнә олаулар китмәгән, сиңа да урын табылыр... Тагын шунсын да исеңдә тот, бүреләр киткәч, этләр батырая. Берсенә дә пощады бирмә, колагыңа киртләп куй.

Габитов эндәшмәде.

Исәнсеф дигән авылга җиткәч, олаудагылар кыбырсып алдылар. "Сәхәр вакыты үтеп бара, кереп чәй генә булса да эчик. Барыбыз да ураза тотабыз, мөселман кешеләр бит сез, нигә ул кадәр имансыз кыланасыз,"—дип ялыну-ялваруларына җавап кыска булды—олауны як-яктан саклап баручы гаскәриләрнең берсе шартлатып һавага атып җибәрде, шуннан соң, кабат сүз куертып торучы булмады.

—Шәп килеп чыкты, Дәүләтьяров. Аягың җиңел икән, мондый эшкә гел сине йөртәсе... Әмәкәй тиклем Әмәкәйдән шау-шусыз олавы белән кулакны алып чыгып кит инде. Филлиповка әйткәч, ышанмаган булыр әле. Ну булды инде, кузгалып киткәнче хатын-кыз, бала-чага

олауны сырып алгач, күнелгә шик кергән иде, камчы белән яра башлагач, бер-ике мәртәбә һавага атып та җибәргәч шыр җибәрделәр тагын. Акырабакыра авылны чыкканчы арттан ияреп бардылар, ну якын килергә курыктылар.—Шәмтиев көлгән булып, янәшәдә утырган Әхмәтсафаның җилкәсенә суккалап алды.

Әхмәтсафа ни дип әйтергә белмәде. Йөзенә бары хәсрәтле дулкын гына йөгерде. Әлеге хәлләрнең барысын да үз күзе белән күреп, йөрәге аша кичергән иде. Минзәләгә куылучы халыкны нинди язмыш көтә? Кайчан да булса авылга кайтып егылырлармы алар? Гаиләләр кавыша алырмы кабат? Шәмтиев бүлгәләгән категорияләрне игътибар белән кем дә булса яңадан карап чыгармы? Ай-һай, илдә сыйнфый көрәшнең кызган чоры, кат-кат тикшереп торучы табылыр микән... Әхмәтсафа үзе дә шушы көрәшнең уртасында хәзер. Болай җебеп тору килешмәсен дә белә. Ул коммунист, фирка карарларын фәкать тимер мускуллы, нык ихтыярлы көрәшчеләр генә үти алачак. Сафта җебегәннәргә урын юк. Бүгенге хәлләр зур көрәшнең башы гына. Алда әле ниләр күрәсе, кичерәсе булыр...

Олаучылар атларны куаламаска тырышалар, бахбайларны алҗытасылары килми. Саклап баручы гаскәриләр исә һаман ашыктыралар. Олаучылар баш өстендә нагайкалар уйнап ала.

Ык аша чыгып, шактый текә тоелган таудан күтәрелгәч, ниһаять, олауларга туктарга әмер бирелде. ОГПУ вәкиле олауга төялгән халыкка кузгалмаска кушып, олаучыларны янә үз янына чакырып китерде. Әхмәтсафа да аягын язасы итеп, шул тирәгә елышты.

Чаналарның берсендә иң ахырдан каравыл өенә китерелгән Сөләйман карт тынгысызлана:

—Имансызлар аркасында, сәхәрсез уразага кердем бүген. Кәҗә авылында ни калган безгә? Мөртәт урыслар арасында мәсхәрә итеп утыртканчы, тизрәк Минзәләгә җитик, Алла коллары. Ник вакыт уздырасыз? Җыен җир бит,—дип, каһәрли-каһәрли сүгә иде ул гаскариләрне.

Әхмәтсафа картның сүзләрен ишетмәгәнгә сабышып, алга үтте.

ОГПУ вәкиле олаучыларга сәфәрдә бару тәртибен соңгы мәртәбә аңлата иде.

—Монда кадәр әйбәт кенә килеп җиттек. Алда—иң җаваплы өлеш,—диде ул, тавышын баса төшеп.—Минзәлә урманың бер тында үтәргә кирәк. Сәбәп-мазар табып туктап тору юк урманга кергәч. Кайсы олаучы туктап кала, шуның маңгаена пуля.

—Атлар өшәнделәр, бик куып булмас... Көне буе ялсыз киләләр бит...—диде Мөхәммәт исемле яшь егет. Олаучыларның күбесе яшьләр, үзләренең нинди хәлдә булуларын аңлап житкермиләр иде. Олаучы егет, кайнарланып, үзенекен тәкърарлый иде.—Кайтасы да бар бит әле халык төяп. Атларны харап итмәбезме?

—Тилегә сабышма! Сезнең белән гәп куертып торыр вакыт юк. Атларыгыз шәп, үзегез елгыр егетләр күренәсез, аңларсыз кебек, кабат әйтәм, Минзәләгә кадәр туктау юк! Минзәлә урамына кергәч, безнең арттан барасыз, кая барып керергә икәнен үзебез күрсәтербез. Өстәмә бер генә сорау да бирмисез, олаудагыларга монда сөйләшкәннәрне җиткермисез, шушы тәртипне бозучылар, чамалагыз, үзегез дә төрмәдән чыкмыйсыз!

—Төрмә?..—дип кайтарып сорады кемдер.—Без төрмәгә илтәбезме халыкны?..

ОГПУ башлыгы, артыгын ычкындырганын чамалап, боргалана башлады:

—Мин моны болай гына, башыгызга тизрәк барып җитсен өчен генә әйттем. Онытыгыз монда ишеткәннәрне, сүзем бетте, кузгалабыз!

Олаучы егетләр теләмичә генә үз чаналарына табан киттеләр. Гаскәри урыныннан кузгалырга ашыкмаган Әхмәтсафага каты гына итеп дәшеп алды:

—Сина аерым боерык кирәкме, вәкил иптәш? Кузгалабыз, дим бит!

Чыннан да урманны чыкканчы да, Минзәлә урамында да туктап торулар булмады. Мангайга кемнең пуля аласы килсен инде? Шәһәргә кереп, кин генә урамнан өскә табан күтәрелгәч, таш койма белән әйләндереп алынган бина янына туктагач кына, олауда утырып килүчеләрнең берсе:

—Бәй, инәннең баш баласы, Минзәлә төрмәсе бит бу?—дип аптыраулы-ачыргаланулы сөрән салды.

Ана йончыган тавыш белән Өммәткол жавап кайтарды:

—Әбиенә утырмага алып килделәр дип уйладыңмы әллә? Безнең юл шушында өзелә инде туганнар. Белгәннәрегезне укып керегез...

Олаудагылар бу хәбәрдән өнсез калып, тавыш-тынсыз утырдылар да, исләренә килеп, кисәк урыннарыннан кузгалыша башлаганнар иде, гаскәриләр аларны тиз туктатты:

—Кузгалмаска! Чаналарга ятыгыз! Кем башын күтәрә—атабыз!

Ул арада авыр капкалар ачылып китте, барлык олаулар, чиратлап шул исәптән Әхмәтсафа утырган ат та төрмә ишек алдына кереп тулды. Чаналарны гаскәриләр урап алды, кулга алынган Әмәкәй адәмнәрен сафка тезеп, гаскәриләр саклавында калдырдылар, кантком вәкилләрен исә ашыктырып, бер бүлмәгә алып керделәр. Әхмәтсафа аруын онытты. Минзәлә төрмәсе дигәнне ишеткәне булса да, бу кадәр котны алырлык, жанны өшетерлек бина дип уйламаган иде. Калын стеналар, авыр ишекләр, өзек-төтек кенә сөйләшү—барысы да ингә баса, гәүдәне үзеннән-үзе жиргә сендерә сыман иде.

Бүлмәдә берничә кеше утыра. Керүчеләргә урын тәкъдим итүче булмады, Шәмтиевне күрмәкче, Әхмәтсафа да стена буендагы утыргычка сенде.

—Мин прокурор Госманов булам,—диде, түрдә утырган чандыр гәүдәле, усал кыяфәтле кеше.—Йә, кайсыгызда исемлек?—Ул каш астыннан гына әле Шәмтиевка, әле Әхмәтсафага сөзеп карап алды.

—Монда, иптәш Госманов, үзем алдым исемлекне.

—Бир монда!—Госмановның каты тавышыннан Шәмтиев коелып төште. Калтырана-калтырана кәгазь сузды.

—Барысы да тәртиптәме?

—Тәртип, иптәш Госманов. "Шылт" иткән тавыш та булмады.

—Анысы өчен ОГПУ жавап бирә. Исемлектә тәртипме, дип сорыйм мин синнән. Категорияләргә кем бүлде?

—Үзем, иптәш Госманов, үзем.—Шәмтиев кисәк төртелеп калды.—Менә иптәш Дәүләтьяров, өлкә комитеты вәкиле белән...

Госманов беренче мәртәбә күргәндәй, сөзеп Әхмәтсафага карап алды.

—Өлкә вәкиле дә булгач, сорамый булмый. Иптәш, э-э...

—Дәүләтьяров...—диде Әхмәтсафа кыю рәвештә. Исәбе—сер бирмәү иде.

—Сезнең карашка ничек? Аңлашылып бетмәгән нәрсәләр, сораулар юкмы?

—Сораулар дип... Шулай да исемлектәге бер кешегә шигем калды.

—Кем?

—Сөләйман карт... Нигезле булмады шикелле аны монда китерү.

—Төрмә кунакка гына килеп-китеп йөри торган жир түгел. Ябып тоту урыны бу. Кулга алганчы ныклап уйларга кирәк иде. Хәрби комиссариат вәкиле кайда әле?

Ишек төбендәрәк утырган хәрби киемле, базык, әмма нык гәүдәле яшь кеше урыныннан кузгалды.

—Мин булам, иптәш Госманов.

—Син, иптәш Шәйхетдинов, Әмәкәйнеке бит, әйеме? Исемең Заһир бит, ялгышмасам.

—Әйе,—диде юаш тавыш белән хәрби комиссариат вәкиле.

—Иптәш Дәүләтьяров телгә алган Сөләйман карт кем ул, беләсеңме?

Шәйхетдинов туры җавап бирәсе итмичә, авыз эченнән ботка пешерә башлады.

–Ни инде, иптәш Госманов, Сөләйман дигән кеше безнең авылда бар инде ул.

–Конкрет!

Шәйхетдинов нигәдер муенын яка астына яшерде. Мондый ук хәлне Габитовта да күзәткән Әхмәтсафа түзмәде, сүзгә кушылды:

–Картны кулга алу өчен нигезле дәлил юк дип саныйм. Габитов белән тәртә башлары эләгешеп киткән димме.

–Кулак түгелме?

–Түгел. Кулак та, мулла да түгел.

–Соң алайса, ник баш катырасың, кайтарып җибәрегез. Калганнарына ордер тутырабыз. Габитов белән тәртә башы эләккән өчен төрмәгә яба башласагыз, тиздән Әмәкәйдә бер кеше дә калмас,–Госманов күзләрен мөлдерәтеп үзенә карап торган Шәйхетдиновка ачулы караш ташлады.

Әхмәтсафа гаскәри озатуында ишек алдына чыкты. Сафтагылар исәнгерәгән хәлдә басып торуларын дәвам итәләр иде. Әхмәтсафа сак башлыгына юнәлде, хәлне аңлатты. Аның сүзләрен теге гаскәри дә җөпләде.

–Сөләйман абзый,–диде Әхмәтсафа салкыннан куырылып торган карт янына килеп, артык шауламаска тырышып.–Син кайтып китә аласың, син азат.

Сафтагылар кузгалышып куйдылар.

–Ә без?!.

Дистәләгән кешенең шушы тәкатьсез соравыннан, Әхмәтсафаның тыны кысылып куйды.

–Сөйләшмәскә!–Мылтык затворы тавышы чынлап куйды.

Сөләйман карт, Әхмәтсафага игътибар итмәстән үзенә ияреп чыгып килүче Шәйхетдиновка ташланды. Заһирның үзе артыннан кузгалганын сизмәгән дә иде Әхмәтсафа. Сөләйман карт килгән шәпкә, ике кулын авылдашына сузды:

–Алланың рәхмәте төшсен, Заһирҗанкай, күршекәем. Башка нинди бәлаләр килде микән дип, аптырап торадырыем. Нәмә булды мин әйтәм, кемгә ярамадым, нәмәгә өтерменгә китереп тыктылар дип, зар җылап торадырыем. Әле дә син булгансың, Ходайның рәхмәт төшкере. Син әйткәнсеңдер инде, Сөләйман абзый гөнаһсыз бәндә, Алла колы, монда өтерміндә тотмагыз дигәнсеңдер, әйеме, күршекәем.

Заһир астан гына сафта торган авылдашларына карап алды да, пышылдап кына:

–Бар, Сөләйман абзый, чыгып сыз моннан!–дип кырт борылып кире прокурор утырган бүлмәгә кереп китте.

Әхмәтсафа урамга чыкканда, Әмәкәйдән килгән олау кире кайтырга кузгалган иде. Мөхәммәт чанасына утырган Сөләйман картның:

–И-и, Заһирҗанннның игелекләре-е...–дип сөйләнгәне ишетелеп калды.

Әхмәтсафа арып-талчыгып беткәнен сизде. Ашыкмый гына фатирына кайтырга чыкты. Аны Шәмтиев куып җитте. Йөгергән дә бугай, сулуы капкан.

–Иштең ишәк чумарын,–диде ул ачу белән.–Бөтен эшне б...ладың, контр! Синең аркада мин закун бозып, бер гөнаһсыз кешене кулга алдыручы булып чыктым әнә. Синнән соң прокурор мине ничек өшкерде, беләсеңме?.. Теленә тилчә чыккыры, цифрлар үтәлгән иде, "шылт" та юк иде... Контр!

Бу сүзнен бәясен белә иде Әхмәтсафа. Барган җиреннән шып туктап, көчле куллары белән Шәмтиевнең кыска тун якасын эләктереп алды да, аны үзенә үк тартып китереп, теш арасыннан гына ысылдап алды:

–Тагын шушы сүзеңне кабатласаң, бел, үзеңне җибәрәм, Сөләйман

карт урынына. Контроль цифрын-ниең белән төрмәдә сөрсерсен, анладыңмы?

Шәмтиев, мондый каршылыкны көтмәгән иде, жебеп төште.

—Анладым, иптәш вәкил, бетте, бетте. Кызып кителгән. Нервылар калмаган инде, суган кыягы сыман бөрешеп беткән нервылар. Шул харап итте, каһәр...

Әхмәтсафа аны тынлап тормады, борылды да, тулай торакка кайтып баруын онытып, кантком бинасына табан атлады.

* * *

Канткомда кирәкле бер кеше очрамады, әйләнде, тулганды да, янә тулай торакка кайтып китәргә булды.

Ике тәүлек диярлек юлда йөрү, авыр тойгылар эчендә бәргәләнү арыткан иде. Кайткач, тиз генә капкалап, ятып йокларга уйласа да, үзен йокы алмады. Инде кышкы кыска көн үтеп бара, жиргә төн кара канатын жәяргә жыена. Эт булып арган хәлдә йокысыз интегеп ятудан да кыен нәрсә юк. Күз алдында бүгенге вакыйгалар тулгана, колакта—туктаусыз чана табаны чыжылдавы. Төрмәгә алып кителгән ирләрнең чарасыз карашлары, Әмәкәйдә хатын-кызларның тавышсыз гына инрәве, бала-чаганың "әткәй, әткәем" дип, ачыргаланып кычкырулары, гаскәриләрнең, авыл активистларының халык өстенә атлар белән килүләре, камчы уйнатулары күз алдыннан китми юл буе эзәрлекләп килде, хәзер дә туктамаган иде әле.

Әхмәтсафа, түзмәде торып киенде, кәгазь-каләм алды да, Рабигага хат язарга утырды. Бу көннәрдә башында жыелган уйларын, күнел түрендә бәргәләнгән хисләрен бер генә кеше—сөекле Рабигасы анласа анлар иде. Рабиганың жинел гәүдәсе, сылу йөзе хәтерендә янарды, битләренә жылы сулышы килеп бәрелгәндәй тоелды, йомшак тавышын ишеткәндәй булып, йөрәге кымыржып алды. Хыял дулкыны аны күз ачып йомганчы Казан якларына, Рабига янына алып китте. Мәктәптә дәресләр тәмамлангандыр, Рабига да жылы, жыйнак фатирына кайткандыр. Гадәтенчә, тын, бик тын гына монлы көй көйләп, ашарга хәзерләп алгандыр. Тирән уйлар эчендә, ялгызы гына чәй эчкәндер. Хисләнүчән иде Рабига. Ара-тирә сәгатькә күз салып ала торгандыр. Шул арада яктылык бөркелеп торган керфекләре арасыннан яшь тә сыпылып чыгарга өлгергәндер. Ул да сагына торгандыр.

Их, хәзер Әхмәтсафа үзе булсын иде сөеклесе янында! Кош булып очыпмы, жил булып исепме тиз генә барып жит иде аның янына. Әле кайчан гына бергә иде алар! Әхмәтсафа ТКУдан укудан кайтып, пәлтәсен салып чөйгә элеп куйган уңайга, каршысына килеп баскан Рәбушын (ул аны яратып шулай атап йөртә), ашкынып күкрәгенә кыса. Рабига дәрт-дәрман тулышкан иренең күкрәгенә башын куеп бер тын тора да, сак кына ирен читкәрәк этәрә: онытылып китмә, янәсе, дөньяда без икебез генә түгел. Әнә күрше бүлмәдә Шираз дәрес караштырып утыра... Бик мут егет ул, бер нәрсәне дә колак яныннан, игътибарсыз үткәреп жибәрми. Житмәсә, Арчадан Жамал апасы кайтып төшкән икән. Ул инде, Рабиганы табалап кына тора. Әхмәтсафа белән сүзгә мавыгып китүен күрсә дә, шелтәләп ала:

—Нәрсә, кызый, дөньяңны оныттың? Дәресләреңне кем әзерләр, иртәгә балаларыңа ни сабак бирерсен?—ди ул, төксе генә.

Әйтерсең, Рабига чит-ят ир янында шулай бөтерелә дә, чит бер кеше белән сөйләшеп утыра. Жамалга бусы мөһим түгел. Әхмәтсафа белән сөйләшергә, серләшергә, кайбер чакта бәхәс куертып жибәрергә дә бердән-бер лаеклы кеше дип үзен генә хис итә ул. Рабиганың берәр эшен килештереп-өнәп бетермәсә, ярып сала инде:

—Бу кадәр җебек булырсың икән, каян килеп шушы сөлектәй иргә тап булдың син, ә? Адәм имгәге дисәң, хәтерең калыр, һи-и, мондый ир соң сиңа әрәм бит, әрәм...

Башта бу сүзләрне Рабига җанына авыр алып, яшереп күз яшьләрен түксә дә, Әхмәтсафаның Җамалның сүзләренә игътибар итү түгел, апасы Рабиганы битәрләгән саен, үзенең сөеклесен тагын да ныграк яратуын, кирәк булса җанын-тәнен бирергә дә әзер икәнлеген тоеп, вакытлар үткәч, тынычлана төште. Әхмәтсафа исә мутланып күз генә кыса андый чакларда: "Сөйләнсен,—янәсе,—тел сөяксез, Җамал ни әйтсә дә мәхәббәткә күләгә төшерә алмый, киресенчә, мин һаман саен ныграк сиңа тартылам." Җамал чәпчи башласа, Әхмәтсафа кызык тапкан кебек, авыз ерып тик утыра, тегесе, моны килештерми, отыры котыра гына.

—Утыр инде, шул пешмәгән хатыныңа карап, куанып. Бакчи, син нинди ир инде, шул хатыныңа эш рәте өйрәтә алмагач? Мөкиббән киткән булып утыруынны әйтерием! Кулына бер кисәк шикәр тоттырган штансыз малай-шалаймыни?! Сөенепләр утыра бит Рабиганың минем сүзгә керфеген дә селкетмәвенә. Әллә мин начарга әйтәмме? Ул яшь совет гражданкасы, үрнәк совет гаиләсе төзергә тиешле кеше. Ә ул ни майтара? Күр инде, ике коймагының берсе—көйгән. Ризык әрәм иткеч. Җитмәсә, үчекләп, үзен дә көйгән бер коймакны минем алга шудыртасың. Моннан соң ике аягымның берсен атлап кермим фатирыгызга. Шираз булмаса, бүген дә кагылып тормас идем. Арчага машинага утыртып алып кайтырга әзер кешеләр бар иде. Кадеремне генә белеп торасы урынга...

Әхмәтсафа исә көлеп җибәрүдән тыела алмый:

—Мин яратам көйгән коймакны, Җамал. Рабига, шундый тәмле пешерә... Мин аңа сокланып туя алмыйм, һәр эшкә дә өлгер синең сеңлең.

Җамал женләнеп, коймак тулы савытны Әхмәтсафа алдына җилпеп җибәрә:

—Мә, аша алай бик яраткач! Күмер ашап, социализм төземәкче буласыңдыр, мингерәү коммунист!

Рабига, нишләргә белми, яшьле күзләрен әле иренә, әле Җамалга төбәп, авызын турсайтып тик тора. Җаныннан да якын күргән Рабига апасына Шираз ярдәмгә ташлана:

—Гел шулай инде син, Җамал апай! Үзең килми тора алмыйсың, килсәң Рабига апайны җылатмыйча китмисең.

—Тик тор, мин синең сыман шамакай булырга укып йөрмим. Мин кантком кешесе! Кәмит уйнарга болай да остарып беттек инде. Эшләргә генә кеше юк.

Җамал, ачуы килеп, берничә мәртәбә өстәл яныннан кузгалып китмәкче булса да, көне буе Казанда бер оешмадан икенчесенә чабулап йөреп, ачыккан. Тамак гүргә кертер, диләр. Хәер, мондый элгәләшеп алуга аның да әллә-ни исе китми, кайсы оешмага керсә, шунда ачуланышып, кәефе тәмам беткән инде аның бүген, совет бюрократиясенә булган ачуын сеңлесеннән алганын да аңлый. Сеңлесен битәрләп, елатты менә. Күзләрендә яшь күренгәнен сизеп алгач, хикмәти Ходай, Җамал тынычланып та калды—күңеле күкәй салды бит. Дәшми генә өстәл өстендә нәрсә бар, рәттән сыпыра башлый.

Җамал "көйгән" коймакларның соңгысын "төпсез казанга" озаткач, Әхмәтсафа, шаян күз кысып, Рабигага дәшеп ала:

—Рәбуш, ник инде коймакларны читкә алып куйдың? Җамалга андый ризык ярамаса да, миңа бик әйбәт бара бит.

Җамал үзеннән көлеп утырган Әхмәтсафага ашардай булып карап ала да, кайдандыр бик тирәннән үк чыккан сүзләренең һәр авазын үт суына манчый-манчый:

—Мәгънәсез... Мингерәү коммунист...—дип, урыныннан сикереп тора, хуҗабикәгә рәхмәт тә әйтми, чаршау артындагы бүлемтеккә кереп, җәелмәгән урын өстенә барып ава. Бу Әхмәтсафа белән Рабига урыны

булып, Җамал йокы туйдырмыйча, кузгатып булмаячак аны. Рабига баш очына пәлтәләрен салып, үзләренә йоклар өчен урын хәстәрли башлый. Барысы да көйләнде, тынычланды, үпкә-сапкаларның эзе дә калмаган, өстәлне җыештырып, иртәгәге көнгә дәресләрен әзерли башлый. Әхмәтсафа исә, өстәл бушавын көтеп, бераз ял итеп алырга була. Рабиганың эше тәмам булгач, сабакка утырачак. Дәресләргә ныклап әзерләнеп йөри ул, төнен китапка багынып үткәрәчәк, таң беленми йокларга ятмаячак...

Хыялда гына булса да сөеклесе янына кайтып килү, Җамалны, Ширазны искә төшереп алу тынычландыра төште Әхмәтсафаны. Ул сүрәнләнеп барган утка карап алды. Әле кәгазьгә бер генә сүз дә төшмәгән икән бит. Шул, бергә чактагы кадерле минутларны искә алып, бөтенләй онытылып киткән. Тик истәлекләр генә һаман күңел түреннән югалмыйлар, аның ихтыярын богаулап торалар.

Уе Җамал тирәсендә бөтерелеп алды. Бу чибәр, яшь хатынны күптәннән белә. Әхмәтсафа Хивада чакта, Җамал мәркәз юлламасы белән округ комитеты эше белән танышырга килеп чыккан иде. Җинел арбага рәттән утырып шәһәр буйлап көне буе йөргәннәр иде. Рабиганың бертуган апасы икәне башына да килмәде ул чакта.

Әхмәтсафа Хивадан Каргалыга кайтып кергән көнне аны өйләрендә иң беренче кеше булып Җамал каршы алыр дип тә уйламаган иде.

Ул кайтып кергәндә, өйдә беркем дә юк, түр яктагы тәрәзә янында бер яшь хатын-кыз ниндидер кәгазьләр белән әвәрә килеп утыра иде. Әхмәтсафаның җилкенүле:

—Исәннәрмесез-саулармысыз,—дигән тавышына теге хатын битараф кына башын күтәргән иде, авызын ачты да калды.

Әхмәтсафа да бер караш ташлауга таныды аны:

—Җамал? Сез...

Хатын урыныннан сикереп торды.

—Әйе, мин... Сине кайда күргән идем соң әле... Тел очымда гына тора, әйтә алмыйм. Хәтер дисәң, хәтерең калыр...

—Хивага килгән идегез бит. Тәҗрибә таратып йөрдегез. Мин сезне округком кушуы буенча, озатып йөрдем. Ул көнне минем карамакта булдыгыз,—дип егет көлеп җибәрде. Хатынның үзенә сырпаланулары исенә төшеп, битенә алсулык та тибеп чыкты. Моны хатын да сизеп, карашын читкә алган булды.—Инструктор идем округкомда, Әхмәтсафа Дәүләтьяров булам.

—Әхмәтсафа Дәүләтьяров... Син буласыңмы инде, минем сенелемнен башын әйләндергән егет...—Җамалның тавышы кырысланган шикелле тоелды.—Исемә төште, әйе, йөрдек. Ну, син исеңдә тот, округком кушмаса, мин сине яныма ике адым якын җибәрмәс идем. Малай-шалайдан туйган. Ә болай, бик күңелле йөрдек без синең белән. Ярый әле сиңа күзем төшмәгән, күңелгә ятышлы егетләрне тиз генә кулдан ычкындырмыйм мин.—Инде хәзер Җамал сәер генә көлеп куйды.—Баксаң, кияү тиешле булып чыктың.—Җамалның күзләре янә серле ялтырап китте. Бу карашта ниндидер тыелгысыз дәрт, хәтта ниндидер әрсезлек бар иде кебек.—Шулай, сеңлекәш тырнаклырак булып чыкты диген,—Җамал җавап көтмәстән, нык басып Әхмәтсафа каршысына килеп басты, күрешергә сыңар кулын сузды.

Әхмәтсафа йортта үзен хуҗаларча тоткан бу хатын-кыз затына уңайсызланып кына ике кулын сузды. Һаман аптыраулы халәттә басып торуын абайлап, сорау биргән булды:

—Безнекеләр кайда соң?

—Һе, кайда булсын, халык эштә. Синең кайтуны көтеп утырсаң. Белүемчә, май ахырларында ук кайтырга тиеш идең бит син. Рабига төн йокысыз калды инде. Сине көтеп, көтек булды.

—Барып чыкмады.

—Әйбәт булды кайтуың, Рабига саргаеп үлә инде дип куркып йөридер идем. Җитмәсә, артыннан бер өер җегет йөри. Берсенә дә күз салмады,

күрәсең, каты сөйләшеп киткәнсез инде. Хәер, безнең нәсел нык холыклы. Сүз бирсә, өзми калмый.

—Без вәгъдәләшкән идек.

—Буржуй сүзен сөйләп торма инде, нинди вәгъдә ул? Тагын, ярәшкән идек дип тә җибәр. Беләсең килсә, коммунистлар социализм төзү эшенә генә ант бирә алалар. Калганы барысы да сафсата! Ант, вәгъдә дигәннәрне китап та яратып бетерми аны. Рабиганы әйтәм, кайбер җегетләрен охшаткан идем. Соңгысы бигрәк тә үҗәт кыланды. Муса Җәлилов дигәнен әйтәм. "Әхмәтсафа кайтмадымы әле?"—дип керә дә китә. Үзе синс сораган була, үзенең күзе Рабигада. Бәхетең, нык холыклы кызга күз салгансың. Тәки сынып төшмәде. Җегете шәп иде болай, үткен иде...

Әхмәтсафа каршысында торган Җамалны урап үтте дә, мич янындагы утыргычка барып утырды. Арылган, йончылган, шулай да Җамалның сүзләре күңел түрендә давыл куптарды.

—Муса Җәлил? Безнең авылда нишләп йөри ул? Әллә Каргалыда эшлиме?

—Юк ла инде, губкомда эшли иде, Рабига комсомол ячейкасын иярли бит. Серләре күп булгандыр. Тынычлан, китеп барды инде ул.

—Муса хәзер кая китте соң? Монда йөри дигән идегез...

—Сезләп-безләп тормале, ачу китереп. Муса Мәскәүгә китте, укырга. Университет дип хыяллана. Әле үзем дә уйлап торам, әллә Мәскәү ягына китәсе...—Дөресен әйткәндә, Муса җилкенүле Җамалның күңелен яулап өлгергән булса кирәк. Яшь аермасы булмаса...

—Мин дә укырга чакыру алдым, Казаннан...

Җамалның күзләрендә очкын кабынды.

—Казан? Вәт, мин дә Казанга китәм, алайсам...

—Сез... әй, син лә, Кокандта эшләмисеңме инде?

—Юк,—дип кырт кисте Җамал.—Күрәсем дә килми үзләрен. Бер үзбәккә, зур партия работнигына кияүгә чыккан идем. Яңа совет гаиләсе төзим дип, тормыш зинданында зар чиккән меңләгән үзбәк хатын-кызларына үрнәк булырлык яшим дип ашкынып чыктым кияүгә. Өйләнешкән көнне үк минем үзбәгем битемә пәрәнҗә бөркәп, кышлакка, әткәсе-әнкәсе янына кайтарып ташламакчы була бит, әй... Кәҗә бәрәнемени? Кияүгә чыккач кына белдем, мин аның өченче хатыны икән. Өйләнә дә, кышлакка кайтарып ташлый бичәсен. Кокандта исә буйдак булып йөри. Шәп бит. Менә син йөр Үзбәкстан буйлап, үзбәк хатын-кызларының бәйсезлеген тәэмин итәм дип. Билгеле, кышлакка бару түгел, шәһәрдә калуны да күз алдыма китерә алмадым. Алдашуны женем сөйми, тавыш чыгардым. Ризалата алмагач, миңа кизәнеп маташа иде, күлмәк астына яшеренгән револьверымны тартып чыгардым да, "шарт," мин сиңа әйтим.

—Үлдеме?—дип, сорау биреп ташлады Әхмәтсафа.

—Үлә, ди, нәләт төшкән нәмәрсә. Мин аңа төзәп атканмыни? Шыр җибәрде, үзбәгем. Идәнгә ятып шуыша, "Бетте, мин андый начар имәсмен, ялгыш кына сүз кузгаттым,—дигән була.—Зинһар, өлкә комитетындагы иптәшләргә тишмә бу хакта,"—дип ялвара.

—Ничек бетте соң бу эш?

—Ничек булсын, шул ук көнне партиядән чыгарып аттылар үзен. Миңа эләксә... Әйтәм бит, безнең холык шундый, өзми туктау юк. Аннан күрәм, болар миңа каныга башладылар, документларны алдым да кайтым да киттем. Нишләп чиләнеп ятарга тиеш әле мин анда. Үзләре йөрсеннәр хатыннарыннан пәрәнҗә салдырып. Мин гарык инде.

Ишек ачылып китте. Акка кара бөрчек сибелгән күлмәк кигән Рабига килеп керде. Рабиганы күргән унайга, Әхмәтсафа урыныннан сикереп торып, каршысына ташланды.

—Рабига!—диде ул, тамагына төер утырып, сүзсез калды..

Рабига, исә куркынып калды, йөзенә алсу тимгелләр бәреп чыкты. Унайсызлануыннан, үзе дә белештермичә, ишекне ачты да, өйалдына сикерде, үзе ачмасыннар дигән сыман, арты белән ишеккә сөялде.

Әхмәтсафа, сак кына этәреп, ишекне ачты һәм, карангы өйалдында Рабиганың кулларын эзләп тапты.

—Рабига...—диде ул янә, сулышы кабып.

—Кайттыңмы, бөтенләйгәме?—диде кыз хәлсез тавыш белән.—Быел да кайтмый калырсың дип уйлаган идем инде. Сонаргач...

—Бөтенләйгә...—диде Әхмәтсафа. Кыюлана төшеп Рабиганы кочагына алмакчы иде, ишек ачылып китте, аларга күзләрен шар ачып Җамал карап тора иде.

—Берәүнең жегете кайткан,—диде ул, сеңлесенә мыскыллы караш ташлап. Әмма бу тавышта көнләшү чаткылары күбрәк иде бугай.—Егет күргәч, һушын җуйды, кер өйгә, нәрсә анда торасың, тораташтай!

Рабига да исенә килде, кыенсынып кына өйгә үтте.

—Минем апам, Җамал исемле,—Рабига озын керфекләрен сирпеп, апасына карап алды. Аннан куркамы, әллә шулай егете белән рәттән басып торуыннан каушый-ояла идеме, йөзеннән һаман кызыллык китми, аяк буыннары жинелчә генә калтырый да иде бугай әле.

—Һе, таныштырды. Без, үскәнем, Дәүләтьяров белән Хива урамнарын буйлап шәп атларда рәттән утырып, парлашып үткән кешеләр инде. Күптәнге танышлар, фиркадәш дуслар. Шулай бит, иптәш Дәүләтьяров?

—Әйе шул, Хивага килгән иде Җамал. Миңа аны көне буе төрле оешма-учреждениеләргә озатып йөрергә туры килде.

Рабига йөгереп диярлек өстәлдәге самаварга барып тотынды.

—Син юлдан гына бит әле, Әхмәтсафа, чәй куеп җибәрим.

—Көйлә инде жегетенне, серләрегез дә бардыр.—Җамал нинди дер риза булмаган кыяфәт белән, ишек алдына чыгып китте.

—Һай-ли бу апаң синең, Рабига. Усал күренә.

—Сөйләшүе генә шулай аның, Әхмәтсафа. Ә болай бик йомшак күңелле, туган җанлы кеше үзе. Аннан эше шундый булды бит—гел көрәш, тартыш. Шуңа кырысланган. Без аны яратабыз, мәрхәмәтле ул. Чыгырдан чыгып, төртмә сүзләр әйткәләсә дә, үткәреп җибәрәбез инде...

...Әхмәтсафа Казанга Җамал белән килеп төште.

Җамал укуга барам дип ашкынып килсә дә, кулында ни юллама, ни чакыру булмагач, җитмәсә, соңарып та килделәр, аны ТКУга алмадылар, башка уку йортына керергә теләмәде ул, өлкә комитеты аша Арча кантоны Чүриле волостенә хатын-кыз эшләрен оештыручы булып китте. Күп тә үтмәде Арчаның үзенә үк күчерделәр. Әмма белемсезлек нык сиздерә иде, менә гыйнвар башыннан ул ТКУ курсларында укый башлады. Кызык хатын Җамал, җилле кеше.

...Рабиганы исә Казанга икенче елны гына алып килә алды ул.

* * *

Җилкенүле, күңелле көннәр иде. Бөтен шәһәр кайный—шушы көннәрдә Казанга бөек пролетар язучысы Максим Горький килә! Моны иң беренче мәртәбә Әхмәтсафа Шамил Усманов авызыннан ишетте.

1928 елның августы иде ул. Каргалыда каникул чорын үткәргән Әхмәтсафа айның беренче матур көннәрендә Казанга Рабига, Шираз, Бибкәй белән бергәләп килеп төшкән иде.

Алып килде дигәч тә, тиз генә һәм жинел булмады ул. Рабиганың әнисе Хәлимә апай кызының кайдадыр белем эстәп йөргән бер егет—Әхмәтсафага ышанып йөреп, «утырып» калуыннан шикләнеп-шөбһәләнеп тә йөри иде бугай инде. Ара-тирә, өйдә үзләре генә ялгыз калган чакларда Хәлимә апай:

—Син, кызый, һавадагы торнага ышанып, кулыңдагы чыпчыкны ычкындыра күрмә. Башлы-күзле булу, күлмәк алыштырып кию генә

түгел. Казан якларыннан безгә әүвәл бер сәүдәгәр килеп чыккалый иде. Ул: «укыган кеше—чукынган кеше,»—дия торганые. Әүвәл чукынмаган кешеләрне зур мәптәкләргә алмаганнар, имеш. Сабакка йөри башлаганчы мөселман булса да, укуы беткәнче, муенына тавык тәпие асканнар. Уйлап-уйлап йөрим дә, ул синең җаныңны кымтырыклап торган егет яңадан да янына кайтыр микән? Бер дә ышанасы килми.

—Ә мин Әхмәтсафага ышанам!..

—Ирләргә ышанма, Иделгә таянма, дигән әүвәлгеләр.

—Борынгылар сүзе ярап бетми бит ул хәзер, әнкәй.

—И акылсыз кыз, җүләр баш. Беркайчан да үзгәрми торган ике генә нәрсә бар—берсе аның Коръән аятьләре, икенчесе—борынгылардан калган хикмәтле сүзләр,—диде Хәлимә апай ачулана төшеп.—Инде Җамал апаңа акыл кертеп булмас, үз акылы үзендә, үсмер чакта ук тәртә арасыннан чыгып китте. Син бит бөтенләй икенче табигатьле, кызым. Йомшак син, сабыр. Сабырлык—иң күркәм сыйфат бәндә өчен. Сабырсыз кыланган кешедән дә яман кеше юк. Күр, шушы Каргалыда гына күпме егетләр сиңа сүз кушарга тилмереп йөри. Су сөлегедәй үзләре, Сал-сал батыр кебек, җегәрлеләр, кулларында ут уйнаталар. Син китаптан башканы белмәгән егеткә чат ябыштың, ачуым да бер килмәгәе...

...Бу сөйләшү хакында җәйге ялга кайткач, Рабига көлә-көлә Әхмәтсафага үзе сөйләгән иде дә, егет чын-чынлап хафага калды. Чыннан да, уйларга кирәк иде. Яше егерме икедә. Рабига аннан бер яшькә кече. Авылда бу яшьтәге кызның кияүгә чыкмый йөрүе гайре табигый хәл дип санала. Андый кызлар хакында: «Сазаган, кияүгә чыкмыйча утырып калган кыз,»—дип, көлеп җырлар да чыгаралар. Зәһәр җыр, мыскыллы җыр:

Яшел тасма телеп тактым
Кәҗә мөгезләренә.
Егермедән үткән кызлар
Нәсел үгезләренә.

Йорт хуҗасы юаш булса, мондый җырны тәүфыйксыз егетләр турларыннан бер төн эчендә өчәр мәртәбә «янгыратып» үтәләр. Чыдасаң чыда, чыдамасаң—юк. Аптырашта калды Әхмәтсафа, һаман-һаман сузып йөрсә, ике арага суык җилләр үтеп кермәсме? Әнә Рабига да, авыр сулап:

—Казанда кызлар бетәсе түгел, безнең ише авыл кызларына исен дә китми торгандыр инде,—дип тә ычкындырды.

Шул ук вакытта «илдә чыпчык үлми» дип, сөйгән ярыңны житәкләп калага алып китеп, йортсыз-нисез хәлдә аны җәфа чиктереп йөрүе дә эш түгел. Чыпчык үлми дә, рәхәт тә күрми шул. Эшләрнең көйләнеп беткәнен көтеп утырсаң да әйбәт түгел. Йөргән аякка җон иярә ди, йөрсәң-эзләсәң торырга фатиры, Рабигага эше дә табылыр иде. Тәвәккәлләргә кирәк! Ашыктырмый чара юк, хәлләр бөтенләй икенче төс алуы бар. Рабигалар бер кечне клуб итеп үзгәртелгән мәчеттә театр куйдылар. Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» иде сәхнәдә. Ул Рабиганың җаны-тәне белән бирелеп уйнавына сокланы утырса, тагын бер нәрсәгә исе китте—быел гына җиденче сыйныфны тәмамлаган Ширазның сәхнәдәге уены иде. Коеп куйган артист, бүгеннән театр училищесына илт тә бир!

Әхмәтсафа вакыты булганда Казан театрларына йөргәли иде, күп артистларны күреп белә, хәтта якташы, Орск якларында туып-үскән Хәким Сәлимҗан дигән җор телле артист белән сөйләшеп тә торганы бар. Казан сәхнәсендәге артистлардан ким уйнамый, Шираз. Әхмәтсафа күнеле булып, эченнән генә «шайтан малай» дип куйды. Хәким Сәлимҗанның житди рәвештә әйткән сүзләре дә хәтердә янарды:

—Җанлана татар театры. Матур-матур әсәрләр язылa. Әмма театрга яшь көчләр кирәк, карт артистлар, иске багаж белән генә татар театрын үстереп булмаячак,—дигән иде ул бер очрашканда.

Менә Шираз коеп куйган артист булачак. Тамчы да шикләнми моңа! Казанга алып китәргә кирәк үзен, зур артистларга күрсәтеп карарга тиеш ул аны.

«Су чокырга җыела» дигәндәй, Бибкәй дә җиде сыйныф тәмам итеп, Шәмсия әнкәсе белән Каргалыга кунакка кайтып төште. Кызга акыл кертә башлаган, авылдан китәсе, туганнарыннан аерыласы килми борлыгып йөри. Шуларның барысы җыелып, ахырда, Әхмәтсафаның җаны тулышты, ул бер көнне Рабига янына мәктәпкә китте. Яңа уку елына хәзерлекнең кызган көннәре, кыз көннәрен мәктәптә үткәрә иде. Барып керде. Рабиганы эзләп тапты һәм кызның аптыраулы карашына игътибар итмәстән, кеше-фәлән ишетер дип тә уйлап тормады, икеләнер урын калдырмыйча, ярып салды:

—Җыен, Рәбуш, китәбез! Шираз белән Бибкәйне дә үзебез белән алабыз.

...Хәлимә апай бу хәбәргә сөенсә дә, артык җебеп тә төшмәде.

—Болай гына җибәрмим Рабиганы!—диде ул тавышын күтәрә төшеп. Бу җыйнак гәүдәле карчык беркайчан да төшенкелеккә бирелми, шаянтапкыр сүзле. Шираз, суйган да каплаган, гел әнисе инде. Әмма, җитди эш булса, шаянлык, шуклыклар онытыла, Хәлимә апай җитдидән дә җитдигә әйләнеп куя, әйткән сүзеннән чигенер димә.

—Әнкә-әй...—дип сузды Рабига.—Сөйләштек бит инде...

—Юк, җибәрмим болай гына!—диде Хәлимә апай каты итеп һәм, миннән башка сүз көтмәгез дигәндәй, иреннәрен нык кысып, мич алдында нидер эшләп азаплана башлады.

—Әби...—дип, җайлап кына сүз башламакчы иде Әхмәтсафа, Хәлимә апай җәһәт егеткә күтәрелеп карады. Аның күзеннән очкыннар чәчелде. Апай зәһәрләнеп карадымы, әллә шаяртасы итәме?..

—Әле «әби» түгел шул... Менә никах укытсагыз, китап кушканча кавышсагыз «әби» булырмын. Аннан соң теләсә нишләгез.

«Дин—халыкка әфьюн ул. Аннан башка да шәп яшәргә була,»—дигән фикергә ияләнә башлаган Әхмәтсафа аптырап, муенын кашып алды.

—Никах дип...

Рабига да үз сүзен әйтәсе итте:

—Әнкәй-й, без бит өйләнешмибез. Язылышу турында сүз бармый. Казанга китү, Ширазны, Бибкәйне укырга урнаштыру турында сөйләшәбез.

—Бара шул!—дип, кызын шелтәләп алды Хәлимә абыстай.—Син нәрсә, яхшыдан яман туган нәмәкәй сыман... Егет кешегә болай гына ияреп китәргә... Китәсең икән, никахлашып, ир белән хатын булып китәсез. Вакыты җиткәч, язылышырсыз. Анысы качмас, Ходай каршысында дөрес булыгыз сез.

Бу сөйләшүнең шаһиты булган Бибкәй, чытлыкланып Рабигага килеп сарылды:

—Ур-ра, Рабига апа минеке булачак!—диде ул, өйне янгыратып.—Дөньяда иң матур апам дип йөртермен сине!—дип битеннән үбеп тә алды.

Рабига кыенсынып, Бибкәйнең чәчләреннән сыйпап алган булды:

—Шушы әнкәй...—диде, авызын турсайтып.—Кеше ишетсә...

—Пәрәмәч, ишетсә ни-нәрсә булган? Чыгасың килмәсә әйт, Әхмәтсафага чыкмыйм диген. Әнә егетең дә бәлшәеп утыра. Алам дип тормый әле бер дә. Андый сүз ялгыш та колакка кермәде. «Әби» дию генә әле ул...

Әхмәтсафа, чәчрәп урыныннан торды:

—Ни сөйлисең, Хәлимә апай! Ничек инде...—Ул нәүмизләнеп Рабигага карады.—Без бит, совет яшьләре, никах дисәң, көләрләр бездән...

Рабига да аны хуплады:

—Никах дип, әнкәй... Хәзер бит инде башка замана.

—Кара син боларны!..—дип бот чабып куйды Хәлимә апай, тәмам

аптырап.—Акыллы эштән беркем дә көлми, җүләр эштән көләләр. Никахсыз тормыш кормакчы булалар бит, адәм страмнары. Тотыгыз капчыгыгызны, ачуым бер килмәгәе, хәзер чыгарып җибәрәм ди мин кызымны бер егет кисәгенә ияртеп. Алайса, аяк та атламыйсың, Рабига! Өйдән чыгып китәсең юк! Фатыйхамны көтмә дә! Китәбез Оренбурга, фатиры да, ачтан үлмәслек эше дә табылыр. Гел кеше күзенә карап яшәү булмас!

Рабига елап, мич арасына кереп китте.

Нишләргә дә белми, Әхмәтсафа, идән уртасында башын иеп тик басып тора.

Хәлимә апай үзе ярдәмгә килде.

—Әгәренки, иманыгыз зәгыйфьләнеп, куркып йөрисез икән шәригать белән ата-баба йоласыннан, никахны Оренбурга барып укытыйк сон?.. Кем икәнегезне дә белмәсләр. Бер бик гыйлемле хәзрәт бар, бүген үк белешеп кайтам, иртәгә, боерган булса, никах укытырбыз.

Шушы йодрык кадәр генә карчыкны икәүләшеп җинә алмаячагын аңлаган яшьләр риза булдылар. Никах укыткач, җаннарында үзләре дә аңлата алмый торган бер җинеллек хасил булды. Югыйсә, тормыш арбасына җигелергә җыеналар, нинди җинеллек хакында уй килсен башка. Юк икән шул, өлкәннәрнең фатыйхасы һәр эштә кирәк икән.

Оренбурда Әхмәтсафа Гомәр агасы янына кереп, аны яшь бичәсе—Рабигасы белән таныштырып чыкты. Гомәр агай инде шактый бирешкән, борынгы бер карт сыман иде.

—Китәбез инде, китәбез,—диде ул, уфтанып. Әхмәтсафаның кулына сак кына кагылып.—Дөнья сезгә кала, балакайлар. Оренбур мәркәз иде, татар мәркәзе иде. Хәзер юк инде, без ашкынган идеаллар сүнеп бара, ислам нуры азларның гына җанын яктырта. Денсез кавем басып бара илне. Бик куркам, Әхмәтсафа энем, денсез илнең киләчәге юк бит аның. Ходайдан узып эш майтармакчы булалар да, белмим шул, барып чыгар микән... Ленин кәгазьдә сурәтләп биргән яшәеш агачы белән табигый үсештә булган тормыш агачы арасында аерма зур, ай-һай зур шул.—Яткан түшәгеннән калкына төште.—Җәмәгатең, ни атлы сон әле? Хәтердән дә чыкты инде...

—Рабига...—диде кыз, керфекләрен түбән төшереп. Ул бу өйдәге затлылыкка, китапларның күплегенә исе китеп тора иде.

—Күркәм исем... яз... Мәгънәсе—яз дигән сүзне белдерә,—дип, нигәдер урысчалап та өстәп куйды.—Весна! Үзең дә яз шикелле якты, матур, син сеңлем... Матурлыкның кадерен бел, энем.—Ул инде Әхмәтсафага карап сөйли иде.—Матурлык үз бәясен алырга хаклы. Ин гүзәл нәрсә—иҗтиһад итү. Аяк өсте йоклап йөрүче бер кайчан да матур була алмый. Анда булган матурлык та йоклый. Баеп баручы кояш бик матур, әмма ул тиз уна, бетә, караңгылык эченә кереп югала. Сез югалмагыз, балакайлар... Кешеләр белән сөйләшә белмәүче—телсез, табигатьне аңлый алудан мәхрүм җан—чукрак, игелекле гамәл мәгънәсенә төшенмәгән—уйсыз. Андыйлардан ерак йөрегез. Бәхетле булыгыз!..

Әхмәтсафаның күзләренә яшь тыгылды. Ул ашыгып хушлаша башлады.

—Рәхмәт, агабзыкай. Изге сүзләрең, фатихаң өчен рәхмәт. Без кузгалабыз инде, тизрәк терелә күр, сиңа һич килешми болай яту.

Гомәр абзыйның йөзе яктырып китте.

—Әле бирешергә исәп юк иде,—диде ул, авыр тын алып.—Салкын тигездем бит уйламаганда.—Ә сез ашыкмагыз әле. Хәзер кай якларга юл тотмакчы буласыз?

—Казанга. Белем алырга исәп , үзебезчә...

—Ә-ә, Казанга ук мыни?! Татарның мәркәзе инде ул. Оренбур биреште. Кибеп бара. Кызганыч... Укымышлы кешеләр булып кайтырсыз инде. Кайтсагыз. Казан булдыклыларны җибәрергә атлыгып тормый ул. Башта җегәрне сыгып ала, аннан гына җибәрә. Зыялылар буласыз димәк,

киләчәктә. Аһ, бар иде заманалар...—Гомәр абзый күзләрен тәрәзәгә төбәп тын калды. Янә авыр сулап куйды. Сүзен дәвам итте.— Мәгърифәтчеләр диләр иде безләрне. Җәмгыятьтә акылның өскә чыгуына ышанучы бер катлы җаннар. Менә кемнәр алар зыялылар. Укымышлы булу—әле зыялы булу дигән сүз түгел. Зыялыларны түрәләр, хакимнәр яратып бетерми. Аларга үз фикереңне генә әйт, шуны расларга омтыл—хәзер гаугачы, җәнҗалчы исеме тагып куялар. Баштан кичте инде.

—Дөньялар үзгәрде бит инде, агабыкай. Укымышлы кешегә караш үзгәрде .

—Зыялыга караш беркайчан да үзгәрми ул, энем. Яман анын хәле, яман. Халыкка якын булсалар, үз хәлләре мөшкелләнә—ачлык, хәерчелектән качып котыла алмыйлар, хакимнәр аларны үзләренә якын китерми тек китерми инде. Алар исем өчен бер-ике кешене үз даирәсендә йөртә. Башкаларны бар дип тә белми. Кирәкми аларга милләт мәнфәгатен кайгыртучылар. Электән шулай килде инде ул. Хәзер генә үзгәрер микән? Кем гаепле? Зыялы дип аталган кавем бик чуар. Бәхәс, тарткалаш, ызгыш алар арасында. Килешеп эшләргә сәләтсез кавем.

Әхмәтсафа күңелсезләнеп калган Гомәр абзыйның күңелен күтәрәсе килеп:

—Бу хәлне төзәтәбез аны, без бит яңа чор кешеләре, зыялыларыбыз, һичшиксез, элекке мескен хәлдә яшәмәс,—дип әйтеп ташлады.

Гомәр абзый көлемсерәп җавап кайтарды:

—Сак бул энекәш, күп нәрсә төзәткәндә ватыла. Яңадан төзәтеп булмаслык итеп...—Барысы да көлеп җибәрделәр. Әмма бу көлү күтәренке көлү түгел иде.

...Казан вокзалы. Поездан төшеп, ыгы-зыгы килгән арада, Әхмәтсафа як-ягына каранып алган иде, каршысына килүче Хәким Сәлимҗан белән Шәриф Камалны күреп, кулындагы авыр чумаданын җиргә «дык» итеп кенә куйды да, аларга каршы китте. Билгеле, аларның егеттә бер эшләре дә юк, әмма Әхмәтсафаның аларда эше бар. Ул үзенә игътибар иттерәсе килеп, ашыгып үтеп баручы Хәким Сәлимҗанның юлына төште, тегеләр исләренә килгәнче, шаяртып сүз башлады:

—Заданиегезне үтәп килеш, иптәш Сәлимҗан!

—Нинди задание? Каян киләсең?—дип, аптырап туктап калды таныш артист.

—Каргалыдан киләм. Оренбурдан. Менә бер егетнең бик тә артист буласы килә.—Ул чумаданнар белән мәшәләнгән Ширазга ымлады.

Хәким Сәлимҗан, күрер күзгә юаш кына, житмәсә, юлдан шактый йончыган, таушалган үсмергә карап, күтәрелеп-бәрелмичә генә сорау биреп ташлады.

—Сәхнәне күргәнең бармы соң? Зиһен яклары ничек?

—Авылда катнашмаган кичәсе юк. Спектакльләрдә дә катнаша. Әле «Сүнгән йолдызлар»ны куйдылар. Артист инде, ясап куйган кебек.

—Табигый булсын ул, ясап куйган сыман булгач...—Сүзгә монарчы бер читтәрәк торган Шәриф Камал да кушылды.

Әхмәтсафа үзе дә сизмәстән:

—Исәнлек-саулыкмы, Шәриф абзый,—дип, күрешергә кулларын сузды.

Шәриф Камал, күзләрен кыса төшеп:

—Төсмерләгән дә кебек... Оренбурда күрештекме соң?—диде акрын тавыш белән. Егетне таный алмаганга кыенсына иде шикелле ул.

—Әйе!..—Аларны тоткарлавына үз-үзен битәрләгәндәй, ашыгып, Шәриф Камал сүзен җөпләде Әхмәтсафа.—Оренбурда сез балалар йортында директор идегез. Без барып кичәләр оештыра идек. Аннары ТИНОда әдәбият түгәрәге оештырдыгыз...

Шәриф Камалның йөзе яктырып китте.

—Тукта, тукта. Исемә төште! Ут борчасы шикелле тиктормас егет—

Әхмәтсафа Дәүләтьяров буласың! Шәп егет!—дип, Хәким Сәлимҗанга борылды.—Кызык чаклар иде.—Өстәп куйды.—Авыр иде, кызык иде. Яңа тормыш төзибез дип җенләнгән чак. Ченәкәй, Афзал Таһир, Муса Җәлил... Һай, санап бетермәле түгел... Истән чыкмый берсе дә...—Хәким Сәлимҗанга сер итеп кенә әйткәндәй, дәвам итте.—Оренбур ераклаша бездән, ераклаша, туган. Ул елларның тарихын бөртекләп җыясы иде. Бу эш сезгә—яшьләргә кала инде.

—Менә сиңа тагын бер задание!—диде Хәкимҗан Сәлимҗан.

Көлешеп алдылар.

Хәкимҗан Сәлимҗан Ширазга сынаулы караш ташлады да, кулын аның җилкәсенә салды:

—Ничек егет, артист буласың киләме?

—Килә шул, абый.

Ширазның ачык итеп, чатнатып җавап бирүе охшап китте бугай, телен шартлатып:

—Хуп, егет, бик хуп,—диде.—Ниндирәк спектакльләрдә катнашканың бар?

Шираз санап китте:

—«Галиябану», «Асылъяр», «Сүнгән йолдызлар»...

—Кара син аны, авыл сәхнәсе генә димәссең! «Сүнгән йолдызлар»да кемне уйнадың?

—Мәхдүм ролен...

Хәким Сәлимҗан яктырып китте. Эшне хәл ителгәнгә санап, Әхмәтсафага борылды:

—Иртәгә үк Гомәр Дәүш янына барыгыз, вакыт тапсам, мин дә кагылырмын, бер-ике кәлимә сүз әйтермен егет файдасына. Гомәр Дәүшне беләсеңме?

Бу сорауга Әхмәтсафага мәзәксенгән шикелле, каударланып җавап кайтарды:

—Белмичә! Дәүләт театрының баш режиссеры ич.

—Шәп, яратам зирәк егетләрне!—Хәким Сәлимҗан көлә-көлә китәргә кузгала башлаган иде, Шәриф Камал нидер исенә төшеп, аны җиңеннән сак кына тартып туктатты һәм Әхмәтсафага эндәште:

—Кара әле, туган, Оренбурда гыйлем иясе бер карт яши иде. Гомәр Дәүләтьяров. Сезнең нәселдән түгелме ул? Исәнме икән әле ул?

Мондый сүзләрне кемнән генә ишетмәде инде Әхмәтсафа. Болай читтән караганда, тыныч, тыйнак холыклы, шау-шуларны җене сөймәгән, «мин» дип күкрәк сугып йөрмәгән Гомәр аганы белмәгән татар зыялысы юк. Ул көр тавыш белән җавап кайтарды:

—Безнең агабыз була ул. Казанга китәр алдыннан күрешеп, хәл-әхвәлләрен белешеп чыктык менә...

—Рәхмәт,—диде Шәриф Камал, бер үк вакытта сабырлыгын югалтмыйча һәм куанычын да яшермичә.—Андый олпат затлар сирәк ул безнең халыкта. Халкыбыз күңеленең бар асыл сыйфатын үз җанына сыйдырган ил агасы бит ул. Халык андыйларга һәрвакыт мохтаҗ. Кызганычка каршы, мөхтәрәм затларыбызның кадере юк шул. Хәер, зыялыларыбыз сөттән ак, судан пакъ түгел. Олпатлык җитми, һай җитми. Бу—чир, бу—бәла...

Инде кузгалмакчылар иде, әллә каян Шамил Усманов килеп чыкты. Әхмәтсафа аны шундук танып алса да, якын килергә батырчылык итмәде, әмма Усмановның:

—Иртәгә Казанга Горький килә, бөтен шәһәрне аякка бастырырга кирәк, егетләр! Онытылмаслык итеп каршы алуны оештырасы иде. Сәйдәшне эзлим, корт чаккыры, аяклар калмады, кибәнгә төшкән инәмени?! Гастроль-мазарга китеп бармагае. Оркестр булмаса, эш харап!..—дигән сүзләре ишетелде.

—Сәйдәш театрда,—диде Хәким Сәлимҗан.—Яңа гына килеп калды.

Усманов артык бер сүз дәшми, кырт борылып, килгән якка чапты.

...Каргалы мосафирлары тулай торакка юл тоттылар. Инде Әхмәт-

сафаның башында бер генә уй бөтерелә: «Горький Казанга килә! Максим Горький, дөньяга танылган мәшһүр язучы килсен әле шәһәргә! Ничек шатланмыйсың, ди, монда? Күреп калырга кирәк, һичшиксез, күреп калу чарасына керешергә кирәк!»

* * *

Тулай торакка кайтып, бераз тын алгач, Әхмәтсафа Рабига белән Бибкәйне ияртеп курсташы Вильдания Хәсәнова бүлмәсенә юнәлде. Вильдания аксыл озынча йөзле, конгырт чәчләрен кыска итеп кистергән, чандыр гәүдәле, чәчелмичә, сибелмичә, бар күнелен укуга биргән кыз, бәхеткә, үз бүлмәсендә булып чыкты. Әхмәтсафаны күрүгә, күзендә тояк уйнап алды, очкыннар чәчелеп киткән иде, егет артында тагын ике кыз күренгәч, шул мәлдә үк йөзеннән куләгә йөгереп үтте.

Әхмәтсафа Вильданиянең үзенә ничектер сәеррәк каравын тоеп йөри иде, юкка булмагандыр, ахры, күңелендә ниндидер сер йөрткәндер, бүлмәсенә ят кызлар ияртеп керүен өнәмичә, авызын бөрештерде, күзләрен чепиләндереп бер егеткә карап алды, аннан кызларга күз салды.

Чибәр иде кызлары. Шул арада Вильдания үзенә таныш булмаган кунакларга бәя биреп тә өлгергән иде инде. Әхмәтсафа үзе буйга озын булмаса да, нык бәдәнле, чүкеч кебек таза егет, ни житте кызлар ияртеп йөрмәс. Кызларның яшькә олырагы гадилеге, ихласлыгы белән күңелне җәлеп итәрлек шул. Бөрчекле күлмәге гәүдәсенә шулкадәр килешә, кыздан ниндидер сафлык, садәлек бөркелеп тора. Озын чәчләре дулкынланып иннәренә төшкән, үзе оялчан, житмәсә. Хәленнән килсә, Әхмәтсафаның кин жилкәсе артына посып, дөньяга күз дә салмый тик йөрер иде. Икенчесе исә—сусыл чия иренле, алсу йөзле искиткеч чибәр яшь кыз бала. Әхмәтсафага охшаган, сеңлеседер мөгаен, алай тартынуны да белеп бетерми бугай, әнә абыйсын этеп-ерып, кыр кәҗәсе елгырлыгы белән бүлмә эченә үтте, бүлмә хуҗасының рөхсәтен сорап тору кая—караватөстендә яткан киергегә тартылган чигүне алып кулында әйләндерә дә башлады. Вильдания сизгер күңелле, һавадан йолдыз чүпли торган кыз түгел, һәрхәлдә, тиз аңышты, мондый кызлар ияртеп йөргән егеткә аның кебек сазап килүче кыз нигә? Ул мизгел эчендә тынычланып калды, үз-үзен кулга алып, көтелмәгәнчә ачылып китте, елмаеп, кунакларны түргә үтәргә өндәде:

—Ник өелештегез ишек төбенә? Үтегез, утырыгыз...

Бу сүзләр Бибкәйгә кагылмый иде инде. Ул караватка менеп кунаклаган да, авызын жырып утыра. Вильдания ана күз төшереп алган иде, көлеп җибәрә язды. Чак тыелып, курсташына дәште:

—Бер дә күзгә-башка чалынмадың, Әхмәтсафа, әллә быел килергә уйламый микән дип уйлап йөри идем, ә син мут егет, поезд кебек, бер вагон кызлар тагып йөрисең икән әле.—Вильданиянең тавышында берниндә киная юк, ул инде егетнең чыннан да үзенә мәңге тәтемәячәген төшенгән иде. Нәфес—шайтан, акыл—иман дигәннәр. Кыз акылны нәфескә баш итеп куярга өлгергән иде инде. Ул: «Тыңлыйм, ни йомыш?»—дигәндәй, буйсынучан кыяфәт белән Әхмәтсафага текәлде.

—Ярлының сүзе ертык турында булыр, һаман да бер сүз, Вильдания, кызларыма төн йоклап чыгарга урын кирәк,—диде Әхмәтсафа бер кавым хәл-әхвәлләр сөйләшеп утырганнан соң.

...Вильдания янына мондый йомыш белән кергәләгән иде инде ике-өч мәртәбә. Җамал йомышы төшеп, Арчадан Казанга килсә, Әхмәтсафа янына керми калмый, кайбер чакта, бик соңга калынса, куныи та киткәли иде. Әле яз көне, кинотеатрларда гөрләп барган «Броненосец Потемкин» дигән киноны карарга дип, килгән иде. Әхмәтсафа белән икәүләп кинога бардылар, Җамал гел егеткә сыенып, колагына йомшак сулышын өреп, ниндидер шаян сүзләр әйткәләп утырды. Корабны

кулга төшереп, матросларның шатланып, җилкәнеп йөргән кадрларны күргәч, тамашачылар, түзми, кул чабарга тотындылар, берара тамаша залы гөр килеп алды. Җамал исә, кинода барган вакыйгаларга күз дә салмый, һаман егеткә сыена, тыйгысыз дәртен Әхмәтсафага да күчерергә тырыша иде. Тегесе исә моны сизмәмешкә сабышып, экран эченә кереп йотылган сыман утыруын белә. Җамалның үкерепләр елап җибәрәсе килде әлеге минутларда.

Сеанстан соң, экранда күргәннәрен өр-яңадан күңеленнән кичереп, кинода барган вакыйгалар тәэсиреннән аерыла алмый, исәнгерәп кайтып барган егеткә бәйләнеп тә азапланды Җамал.

—Юкка килдем, ахры, бүген...—диде ул, уфтанып.—Өйрәледә бер кич, боткалыда ике кич гомер үткәреп йөрүче әрсез алабай сыман инде үзем. Чүриледә эшем калды өелеп, Арчада, волкомда бетермәгән эшләрем бар иде. Ә мин, җүләр, монда йөрим юкны бушка аударып...

Әхмәтсафа, дәресләрдән соң тамак та ялгап өлгермәгән иде. Ул көнне киногa җыенмаган да иде бугай. Җамал шаулап килеп керде дә:

—Киногa алып бар!—дип ялына, тәкатьсез рәвештә бүлмә буйлап бөтерелә башлады.

Егет, ни чарадан бичара, билет юнәтергә чыгып чапты. Нәрсәгәдер пошынып, бәлаләп барган Җамалга Әхмәтсафа сәерсәнеп, әйтеп ташлады:

—Аңлап бетермим мин сине бүген, Җамал. Үзең кино дип авыз суы корыттың... Охшамады дисәң, көфер сүз булыр. Шундый шәп картина... Әле ярый, килгәнсең. Карарга җай чыкмый йөри иде.

—Авызыңнан җил алсын. Нишләп охшамасын кино? Охшады-ы...—диде Җамал чытлыкланып. Болай кылану аңа килешми иде...

Җамал—революция тудырган яңа тип кеше, анда һәрчак көрәш дәрте, аңа кем беләндер тартышырга, шушы тартышта үзенекен эшләп калу кирәк. Моның ахыр чиктәге нәтиҗәсе ничек булыр, гомумән, мондый юл белән бару аны кая китереп чыгарыр—анысын ул уйлап тормый. Ул башкаларның аның ихтыярына буйсынуын тели, әгәр каршылыкка очраса, артын-алдын уйлап тормый, даулаша башлый. Барып чыкмаса—фаҗига, ул моны кабул итә алмый. Юк, ул чигенми, үзен яклардай кешеләрне барлый башлый, коллектив туплый. Ниндидер шайтан колагына пышылдаган кебек, бер нәрсәне тоя—коллектив акыл теләсә нинди акылсыз эшләрне дә җиңел генә һәм рухи тетрәнүләрсез эшләп ташлый ала. Кем өстәшул көчле. Җамал югарыга омтыла, белә—өстә кем генә утырса да түбәндәгеләрнең иреген чикләү белән шөгыльләнәчәк. Теләсә нинди хакимият өчен уртак сыйфат һәм иң прогрессив дип саналган хакимият өчен дә хас бу. Җамал моны аңлап бетермәсә дә, тоя. Аның үз ирегең теләсә кемгә чикләтеп, йомылып яшисе килми. Юлына кем очраса да, аны буйсындырасы, үз көенә биетәсе килә. Ул үзен җәмгыятькә көчләп тагарга маташа, андыйлар исә тора-бара тиранга әверелә. Тик менә Әхмәтсафа белән генә барып чыкмый. Җамал сизә, егеткә мәхәббәте уянды аның, җанда мәхәббәт кабынган мәлдә күңел күзе сукырая. Мәхәббәт—мангай күзе җимеше булса да, аның өчен җан газаплана. Егет алдында Җамал җебеп кала. Какшамас большевик катылыгы югала. Елыйсы килә башлый. Елау—большевик холкы өчен хурлыклы гамәл. Менә бит, Әхмәтсафаны пыр туздырып ташласы урынга, ул һаман аңа сарылып, чытлыкланып кайта. Җамал мондый чакта үзен-үзе күрәлми, үзеннән чиркана, нәфрәтләнә иде.

Әхмәтсафа хатынның җанында барган тартышны аңлый кебек.

Каргалыда укыган чакта, Мифтах хәзрәтнең һәрдаим кабатлый торган сүзе бар иде: «Тартынуда гына табарсың үз хакың!—ди иде ниндидер хыялый җилкенү белән. Аннан өстәп куяр иде: «Балалар, моны әдәбият күгемездә балкып кабынган Гаяз хәзрәт Исхакый әйтә. Андый кешеләремез бар чагында безнең милләткә килер ул якты көннәр. Килер, боерган булса. Әле татар милләтенең үз сүзен әйтер көннәре алда. Таныта-чак әле ул үзен дөньяга! Гаяз хәзрәт, Тукай, Риза хәзрәт Фәхретдин, Фатыйх

Әмирхан, Галимҗан Ибраһим... Һәй, саный китсәң, азмы бөек затларымыз! Мондый гүзәл фикер ияләре белән теләсә кайсы милләт горурлык ләззәте чигеп йөрер иде. Болар бит соңгы дәвердә мәйданга чыккан каһарманнарымыз. Аңлап, кадерләрен белеп бетермибез. Хәер, Тукай хәзрәтләре моны үзе үк әйтеп биргән. Тыңлап карагыз әле, балалар, күңелегездән үткәреп тыңлагыз:

> Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадерен белү,
> Без аны кайдан белик, мискин үлеп аңлатмагач?!

Бу сүзләрне әйткәндә аның күңелендә нинди өермәләр уйнап узгандыр, күзеннән нинди ачы яшьләр тамгандыр? Бүгенге хәлемез безнең шулай, балалар. Әмма килер көн, чыгар кояш, хөрмәткә лаек затларымызны берәмтекләп барлармыз, аларның авызларыннан чәчелгән җәүһәрмәрҗәннәрне кадерләп җыеп, милләтебезнең акыл китабына алтын хәрефләр белән язып куярбыз. Әлегә без моңа әзер түгел, татарның фаҗигасе бу... Гасырлар буе милләтемезнең иң алдынгы, иң гаярь, иң тапкыр, иң зирәк затларын чүпләп килгән карагруһ баскынчылар. Вагайган халык, идеалын җуйган. Денем өчен түгел, көнем өчен дип яши башлаган...— Мифтах хәлфә, кай ара үзенә карап, авыз ачып тыңлаган балаларны да онытып җибәрә иде бугай, үзалдына уйлаган-сөйләгән кешегә ошап кала иде.—Яшәүме соң ул? Җан асрау гына бит! Әле анда күпме эшләр тора безнең. Күп казганырга кирәк әле безгә... Белмим, морадка ирешеп булырмы, асыл максатларымызга өлгәшербезме? Җанда мең еллар тәрбияләнгән иң гүзәл сыйфатларын җуйган хәлдә басты егерменче гасырга халкымыз. Хөсетлек, бер-береңә яла ягу, ышанмаучылык, көнләшү—менә нәрсә үтерә безнең милләтне. Егерме беренче гасырга исән-имин барып җитәрбезме? Җитсәк нинди хәлдә, нинди төстә? Нинди иман белән? Шәхескә карата битарафлык—татар белән урысны якынайта торган төп сыйфатларның берсе. Уйлый башласаң, башлар чатный. Бер сорауга да җавап таба алмый изаланам...—Аннан кинәт исенә килеп, балаларга дәшә:

—Сез алай булмассыз бит инде, балалар? Начар сыйфатларны ияртмәссез үзегезгә диюем?

Шәкертләр, бер авыздан:

—Юк, без алай булмабыз!—дип, ярып салалар. Мифтах хәлфәнең йөзе яктырып китә, ул дәртләнеп сабак өйрәтергә тотына.

Аннан ара-тирә кабатлый торган сүзләрен хәтердә яңартып ала.

—Ходай сөекле бәндәсенә иң олы сынау җибәрермен дигән. Мөгаллим, хәлфәләр менә шушы сынауга дучар булган затлар инде. Фани дөньяда җәзага дучар ителгәннәр дисәң дә ярый... Башкаларга анбелем, тәгълим-тәрбия бирә торгач, хәлфә үзе зәгыйфьләнә, сула, берзаман ана үз шәкертләре үк көлеп, өстән карап үтә башлыйлар.

Юк, үкенеп, сыктап түгел, болай гына сөйләнеп ала ул.

Әхмәтсафаның күкрәгенә ниндидер төер килеп утыра иде мондый чакта, нигәдер бик тә җәл, кызганыч сыман тоела иде хәлфәләре. Кызык, кешенең тормышыннан бер генә көнен дә, сәгатен дә, минутын да алып ташлап булмый икән. Гомернең һәр мизгеле җанда сулкылдап яткан кебек... Менә бит кайчангы хәлләр хәтердә уянып, күңелне актарып ташлады.

Җамал, егетнең уйларын укып барган диярсең, дәшми-тынмый, үз эченә йотылып барган Әхмәтсафага нык кына төртеп алды:

—Әй, шәкерт, кайда йөрисең син, ә?

Егет сискәнеп китте.

Кемне дә булса сискәндерә аласың икән, димәк әле син бөтенләй үк бетмәгәнсең. Җамал үз шаяртуыннан күңеле булып, көлеп җибәрде.

—Аяктан калдың бит, өстерәп алып кайтып барам, үзең сизмисең дә.

—Гафу ит, Җамал, онытылганмын икән шул...—Әхмәтсафага кыен булып китте. Үе әллә кайларга йөгереп алды. Ул, болай уйга бирелүнең

сәбәпчесе —Җамал үзе икәнен әйтеп тормады инде, билгеле. Кызганычка каршы, яңа зыялылар, милләтнең белдекле оланнарын тәрбиялим дип йөргән Мифтах хәлфәләренең өметләре акланмады бугай шул. Тартышуда үз хакын табу мәсьәләсен яңа буын башкача аңлый. Моның иң ачык мисалы—Җамал буладыр да. Аның идеалы—хатын-кызның бәйсезлеге, буйсынмас холыклы, нык рухлы булу. Рух—мәсләк дигән сүз. Ә Җамалның мәсләге нинди? Монсын инде Әхмәтсафа һич аңлый алмый. Ниндидер чиксез бер омтылыш. Дөньяда төпсез күктән башка һәр нәрсә чикле. Кая ашкына бу хыялый хатын, аңламассың...

—Гафу ит, имеш. Таптың сүз! Ник дип әле юк кына нәрсә өчен дә гафу үтенеп маташасың? Һай, бу укыган мингерәүләрне...—Җамал аны үчекләп алды.—Рабиганы уйлап барасыңдыр әле. Каргалыда калган былбылыңны,—диде ул, үчекләвен дәвам итеп.—Рабига яңа тормыш төзи алырга сәләтле түгел ул. Юкка күңеленне саласың син аңа.

Егет бу кадәресен үк көтмәгән иде.

—Ник алай дисең? Рабига акыллы кыз. Бәлки нәкъ шундый кешеләр кирәктер безгә хәзер. Арт белән киртә җимереп йөрүчеләр чоры үтеп бара.

Җамалның җене чыкты.

—Тәвәдәй буй биргәнче, төймәдәй уй бир. Нәрсәгә генә укыта торганнардыр сине...

—Беләсеңме, Җамал, сиңа да укырга кирәк. Кабатлап әйтәм, революцияне ясаган иптәшләрнең күбесенең анкетада күрсәтерлек бер генә белеме бар иде—төрмә университеты. Әмма ил үскән саен, төрмәдә җыйган белемнәр генә җитми. Илнең нигезе нык булсын дисәң, аны салуны белемле кешеләргә тапшырырга кирәк.

—Барына фатиха, югына әттәхият!—Төксе генә җавап кайтарды Җамал.—Белемем үземә бик җиткән. Кесәләрендә өчәр уку йорты тәмам иткәнгә язу йөрткән кешеләр дә минем белән сөйләшергә шүрләп торалар әле,—диде ул һаваланып.—Мин аларны чәйнәп кенә төкерәм, ачуым чыкса.

—Анысы булыр. Моның өчен белем кирәкми бит. Әмма алга карап яшәргә кирәк. Надан кеше генә киләчәк хакында уйланмый. Их, киләчәк?!. Нинди булыр ул, ә, Җамал?

—Житте, шундый матур иде кәефем, күчәр дегетенә әйләндердең, чистый.

Җамал кебекләрне хак юлга чыгарам дип тартышу көлке икәнен аңлап алды егет. Әхмәтсафаның сүзләре тәгәрмәчкә уралган чытыр кебек, Җамалның саруын кайнатып кына баралар иде. Кеше җанының гариплеге—башкалар җанын аңлый, тоя белмәү.

—Ачуланма инде, Җамал, кинодагы хисләрдән айнып бетеп булмый. Көчле эшләнгән.

Җамал тагын Әхмәтсафага елышты.

—Ташла инде шул акыллы сүзләреңне... Хәер, киләчәк, дип юкка гына чәбәләнмисең син, зур кеше чыгар синнән, түрәләрнең түрәсе булырсың.

Егет көлеп җибәрде.

—Каян алып әйттең әле син моны?

—Гел үзеңнекен тукып барганга әйтәм... Түрәләр шулай бит алар. Башкаларның үзләре ишетәсе килгәнне генә сөйләүләрен телиләр. Кинодан чыкканнан бирле мине акылга китермәкче булып азапланасың.

—Ничек уйлыйм, шулай сөйлим инде. Үлемнән качып котылып була, үзеңнән качып та котылып булмый. Акыл кешене биеклеккә әйди, йөрәк сабырлык читлегенә ябып куймакчы, тыйнаклык мокытлыкка өстери. Кызык инде кеше дигәнең, һәр нәрсәнең чиген-чамасын белү кирәк тә, барып чыкмый шул алай. Чик-чаманы югалтабыз да куябыз. Гаҗәп...

—Мин менә бернәрсәгә дә гаҗәпләнмим, беркемгә ышанмыйм...

—Син моны үҗәтләнеп кенә әйтәсең ич... Гаҗәпләнә, соклана белмәү—бәхетсезлек. Игелекле, матур кешеләр азмы дөньяда? Ничек сокланмыйсың, ничек ышанмыйсың аларга?

Җамал көлеп, егетнең беләген чатырдатып кысып алды.

—Житте сиңа, миемне кайнатып чыгарасың инде. Кая, табып бир шундый әүлияне! Матур да булсын, игелекле дә булсын, изге дә булсын. Ышанмыйм мин мона! Матурлык сокландыра, ышандырмый. Бу сөйләшүгә нокта куярга кирәк. Житте! Үзен әйтмешли, чаманы югалтасың. Аннан мин бөтенләй башка нәрсә хакында уйлап барам әле...

—Нәрсә хакында?

—Бүген мине кайда кундырып чыгарасың?—диде Җамал, пышылдап кына. Кайнар сулышы янә Әхмәтсафаның колак яфрагын көйдереп алган сыман булды.

—Табарбыз, күнелең киң булса, кайда да сыярсың!—дип шаяртты егет.—Бер кичкә, кер мичкә...

Җамал моны үзенчә аңлап, тәненнән җинелчә калтырану уйнаклап үтте.

—Шәп егет син, Әхмәтсафа!

Әхмәтсафа исә Җамалның Рабигага карата рәхимсез сүзләрен исенә төшереп, эчтән рәнҗеп тә алган иде, яшь хатынның кайнарланып пышылдаган сүзләрен ишетмәгәнгә сабышты.

Тулай торакка кайтып, үзенең инде берничә мәртәбә куныл чыккан Вильдания янында төн үткәрәсен белгәч, Җамал бүселеп, Әхмәтсафага зәһәр генә карап алды:

—Ну шушы сала гыйбатларын!—диде ул, үртәлеп һәм, артык бер сүз дәшмичә, Вильдания бүлмәсенә теркелдәде. Төн буе җуннәп күзенә йокы кермәгән Җамал таң сызылу белән Арча поездына йөгергән, Әхмәтсафа исә дәресләргә ашыкты, янадан шактый күрешми тордылар алар. Җамал бик нык үпкәләгән иде егеткә, каникулга кайтып китәргә җыенып йөргәндә кисәк килеп кереп, артык сүзгә керешми генә Каргалыдагы әнисенә күчтәнәчләр калдырып чыгып китте...

...Вильдания тыз-быз килеп чәй әзерләп йөргәндә, Әхмәтсафа онытылып китеп, шуларны да уйлап алды.

Чәй әзер булгач, Әхмәтсафа авыл күчтәнәчләрен дә алып килде, ана, моңарчы егетләр бүлмәсендә утырып торган Шираз да ияргән иде.

—Монсы кем була тагын?

—Кайнешем!—Әхмәтсафа тартынып торган үсмергә карап күз кысты.

Шираз гәүдәгә Әхмәтсафаны үтеп бара, таза, нык бәдәнле, һич тә, быел гына җиде сыйныфны тәмам кылган димәссең, авылда эшләп, чуендай кара янган сөйкемле егет иде ул.

—Бәр-рә-мәч, мин һаман искә алмый йөрим икән, әллә өйләнеп килдеңме син? Һәй, Әхмәтсафа, үткер дә үзең, нинди кызны эләктергәнсең!—дип, көлә-көлә тимер кружкаларга чәй агыза башлады Вильдания. Үзе инде хәзер аерата бер кызыксыну белән астан гына Рабигага карап-карап алгалый.

—Ә кәк же! Күпме өйләнми йөрергә була, кадерсезләнеп?

—Кадерсез халыкның кадерсез балалары инде без...—диде Вильдания уфтанып.

Әхмәтсафаның шаяртуын килештермичә, Рабига кулларын чәбәләндереп алды.

—Юк-юк, Вильдания, алдаша ул. Нинди өйләнешү ди ул?!.—Рабига кызарып чыкты. «Ник алай сөйләшәсең инде?»—дигәндәй, шелтәле күз сирпеп алды Әхмәтсафага.

Вильдания, сер тотмас үрдәк, сөйләнә бирә:

—Кызлары күп аның,—диде Әхмәтсафага төрттереп.—Әле Арчадан Җамал дигәне килеп йөрде кыш буе. Син ачуланма, егеткәем, мин дөресен әйтәм, әгәр Рабига ярата икән, мондый вак-төяккә генә игътибар итмәс. Шулай бит? Куркасы юк, гел минем янда кундырды Җамалны.

Үзем шаһит,—Вильдания хихылдап көлгән булды.

—Җамал—минем апам ул, бертуган апам,—диде Рабига акрын гына.—Башка туганнарыбыз юк бит Казанда, Әхмәтсафа янына килеп йөри инде.

—Юкәдә икән чикләвек, малайкаем, боларның араларында ни бар микән соң, дип, борлыгып йөргән булам мин тагын. Сез инде алайса күптән танышлар, кушылып кына җитә алмыйсыз. Ник сузасыз, күпкә киткәч, кызыгы калмый ич анын?!

—Сүзләр хуш та, кесә буш бит, Вильдания. Рабига эшкә урнашсын, минем дә мактанырлык чамам юк. Җайлашып кына килә шәһәр тормышына. Бераз гына сабыр итик, ул чагында оя корып та җибәрергә булыр.

—Әйтәм бит, уен-муен уйнап йөрмисез икән! Кыек атсам да туры тигердем, ахрысы, тәки сер төенегезне чиштем. Бер дә аптырап тормагыз, үзем шаһит булам ЗАГСта, өйләнегез генә!—диде ул һәм каударланып чәен уртлап куйды.—Нинди бәхетле сез!—Бу сүзләрне чын йөрәктән, эчке сагыш белән әйтте ул, күзләреннән моң бөркелеп чыкты.

...Икенче көнне иртүк Горькийны каршы алырга бару иде исәпләре. Җыена башладылар. Тулай торак гөр килә, кайда, кайчан киләчәк бөек язучы—барысына да билгеле. Эчендә жаны булган кеше түзеп бер читтә калырлыкмы соң?!. Иртәдән ду купты студент халкы, өс-башын рәткә китергән була, төзәнә, ясана, спайлана. Мәхшәр купкан диярсең. Әхмәтсафалар көч-хәл белән жыенып чыгып киттеләр. Җитмәсә, тулай торак хуҗасы—комендант бәйләнеп азапланды—Әхмәтсафаны өч кенә сәгатькә кизү торырга ризалаштырмакчы булып, ниләр генә кыланмады. Имеш, кизү торырга тиеш Сәгыйтовның үтә ашыгыч эше килеп чыккан, аны алыштырырга кирәк. Чыккан ди, чыкмый. Горькийны күреп калырга ашыга. Иртәдән бирле түбән курста укучы бер егетнең чалбарын сорап, тегенең бәгыренә төшеп йөри иде. Горькийның Сәгыйтов кигән чалбарда ни эше бар, ямаулы кием күрмәгәнме, үзе андый кием кимәгәнме ул? Кизүлеген икенче берәүгә ташлап, зур кешеләр арасында кайнашасы, үзен күрсәтеп каласы килә анын, шул гына. Өлешенә төшкән көмешен, дускай, бигайбә, чиратын җитеп, кизү булырга язган икән бүген, торасын инде. Мондый чакта кем генә сине Горькийны каршыларга җибәреп, үзе авыз күтәреп тулай торакта калыр микән?

Шулай ыгы-зыгы килеп йөргәндә, җай табып, аны Вильдания бер читкәрәк чакырып алды һәм кулына дүрткә бөкләнгән кәгазь тоттырды.

—Өченче көн генә бер кыз килеп, сине эзләп йөргән иде. Шундый чибәр, мин сина әйтим. Үзе ачык, сөйләшергә ярата. «Бергә укыдык, дуслар идек,»—диде. Сина шушы язуны калдырды. Ачулансаң ачулан, Әхмәтсафа, мина ул кыз ныграк охшады. Бусы да әйбәт. Тик аз сөйләшә Рабиган...

Хат Заһидән иде. Һәм ул Әхмәтсафаның кулын яндырып алган кебек тоелды. Мангаена тир бәреп чыкты. Укымыйча йөрәк түзми, кызыл почмак түренә үтте дә, тәрәзә янына басып, тиз генә хатка күз йөртеп чыкты.

«Заһидәне онытып барасындыр инде, егеткәй. Мина рәнжеп йөргән чакларың да булгандыр. Яшь чакта жирдә йөрмәдем бит. Инде жиргә төштем. Як-ягыма карыйм, гомеркәйләр искән жил икән, сызгырып үтеп бара яннан, кешедә бер гаме юк. Мин исә һаман ялгыз. Үзем медтехникум тәмамладым. Быел институтка керергә жыенам.

Теге вакытта, Бохарада очрашкан көнне искә алам да, үкенеп туя алмыйм. Яннарында каласы гына иде бит. Ялгызына кыен булгандыр инде. Хәер, син түзем, көчле, нык холыклы кеше шул. Менә исән-имин кайтып житкәнсен, престижный уку йортына кергәнсен. Зур кеше чыгачак синнән, егеткәй. Заһидә әйткән иде диярсен. Яннарында кала алмадым шул... Мин ул үзбәк якларында йөреп, туеп беткән идем шул инде. Газиз әнкәем кабердән торып үгетләсә дә, белмим, калыр идем микән анда.

Ул чакта башым тәмам әйләнеп беткән иде. Трохома, корчангы, бет... Әрсез үзбәк аләмнәренең юлыма төшеп, өченче, бишенче хатынлыкка әләктереп калырга маташулары... Бар күргәнем шул булды. Жек чиктем. Жай чыгута, алны-артны карамый Казанга качтым. Хәзер инде сабырландым. Яшьлектәге җүләрлекне искә алам да, үземне битәрләп туймыйм. Кирәк бит, Такташ дип хыялланып йөр имеш. Аңа тиң идемме соң мин? Шуны да аңларлык булма инде. Көлеп үләрсең, валлаһи. Боларны нигә язам соң әле мин? Болай гына. Күрәсем килгән иде, сөйләшәсе килгән иде. Килдем, син авылда икән әле. Кайчан килеп житәрсең?.. Килсәң, нинди уйлар белән килерсең, анысы да билгесез. Шулай да сина хат калдырырга булдым. Бәлки күрешергә насыйп булыр. Соңгы араларда еш хәтергә төшәсең...

Каян эзләп тапкан, дип аптырама. Синең хакта мина Сәгыйтов әйтте. Бергә укыйсыз икән. Аның белән татар яшьләре клубында, әдәби кичәдә очраштык. Кутуй белән Туфан дигән шагыйрьләр оештырган кичә. Шәп шагыйрьләр, шәп егетләр. Кызлар биһуш иде икесенә дә. Сәгыйтовка нәрсәдер охшамады, сәхнәгә менеп, икесен дә «тунады» гына. Анадан тума калдырды. Вәт тел кешедә. Каян табып бетерә бу кадәр ачы, әремле, үт суы кушылган сүзләрне?

Сәхнәдән төшкәч, янына бардым. Куркып кына барган идем, сәхнәдәге зәһәрлегенең эзе дә калмаган, йомшак кына сөйләшә. Синең адресыңны да ул бирде. Ә шулай да явыз кеше бугай ул. Саграк бул аның ишеләрдән. Очрашасың килсә, кил, шат булырмын...»—дип тәмамлаган иде хатын Заһидә. Адресын да күрсәткән.

Бу хат бөтенләй аптырашта калдырды Әхмәтсафаны. Вильдания берничә мәртәбә кабатлаган «чибәр» дигән сүз дә үз эшен эшләде бугай, йөрәк түрендә утлы нәрсә кузгалып алды, канына кайнарлык йөгерде. «Һи, шайтан кыз, каян килеп чыктың син тагын?—дип битәрләде эчтән генә Әхмәтсафа Заһидәне.—Оныткан идем бит инде, жанымда сина тары ярмасы кадәре дә урын юк иде. Хатны укып чыкканчы жебеп, боламыкка әйләнеп калды күнеле, тез буыннары сыекланды әнә. Кузгалып китә алмый. Ул кәгазьне чалбар кесәсенә салды да, йөзендәге аптырау галәмәтләрен җуярга теләгәндәй, ике кулы белән нык кына битләрен сыпырып алып, үзен бүлмәдә көтеп утырган Рабига янына ашыкты.

Күрәсең, Рабигада хатын-кыз сизгерлеге үтә көчледер, Әхмәтсафаның йөзенә күз ташлау белән, имәнеп китте, тавышын күтәрмичә:

—Ни булды, Әхмәтсафа, төсен үзгәргән?—диде.

Әхмәтсафа, игътибар итмә, дигәнне аңлатып, кулын гына селтеп алды.

—Юк ла... Тулай торакта беркем дә калмый, дип, кизү калырга кыстап йөриләр. Таптылар бер кеше... Ачуым килде...

—Син нәрсә диден?—Рабиганың күзендә курку чагылды, бөек язучыны каршы алу чарасына бара алмый калудан, йөзенә гажизлек чаткылары сибелде.

—Җүләрме әллә мин?!—диде Әхмәтсафа.—Кемгә тиеш, шул калсын кизүдә. Баш бутап йөрмәсеннәр.

—Кемгә тиеш, соң?

—Кемгә булсын, Сәгыйтовның чираты инде. Ул болгатып йөри...

—Ачуланмасалар ярый да инде үзеңне.

—Сәгыйтовның сүгенмәгән чагы юк аның. Беренче тапкыр гына юлга аркылы төшүе түгел...—Егетнең ачуы кабарган иде. Инде дә килеп, бу Заһидәсе каян килеп чыкты тагын... Сәгыйтов юкка гына бирмәгән ана адресны. Ул белә иде бит, Әхмәтсафа өйләнергә жыена, сөйгән кызы бар. Аның өчен Әхмәтсафа белән Рабига арасындагы мөнәсәбәтләр һич тә яналык түгел. Әле Рабига институтка килгән көннәрдә үзе дә кыз тирәсендә чуалып алган иде. Кыз бер дә ыркым бирмәгәч, ачуланып: «Харап икән!»—дип, кызны тупас кына этеп жибәреп, ана әйтмәгән сүз калдырмаган иде. Ахырда, кыз һаман бирешмәгәч, «ялыныр чаклар үткән,

үкенерсең, соң булыр» дип, көйләгәндәй иткән дә, кул селтәп китеп барган. Бу хакта аңа көлә-көлә Рабига сөйләгән иде. Юк, болай гына бирмәгән ул Заһидәгә адресны. Әхмәтсафа мәхәббәт мәсьәләсендә буталсын, саташсын, акылын җуеп, ахырда барысыннан да коры калсын дигәндер. Менә хәзер кызның хаты тәнен пешереп кесәдә ята. Җанның тынычлыгы югалды да куйды... Укып та тормый ертып ташлыйсы калган икән... Ул Рабига алдында үзен гаепле сизеп, әкрен генә коридорга чыкты. Кесәсеннән хатны алып, кеше-кара күрмәсен дигәндәй, аны ашыга-ашыга ерткалап, почмактагы чүп чиләгенә ташлады. Аргы башта Сәгыйтовның сүгенгәне ишетелә, урынына әле һаман кеше таба алмаган, шуңа дулыйдыр.

...Пароход туктыйсы пристань Усиядә, Казанка елгасының Иделгә кушылган урында. Әхмәтсафалар килеп җиткәндә, анда ырып чыккысыз халык иде. Һәркем алга үтәргә маташа, тавышсыз гына этеш-төртеш, урын өчен көрәш бара. Тырыша торгач, алар да бер җай белән алгарак үттеләр. Бәхет дисәң дә бәхет, алар нәкъ оркестр каршына килеп чыктылар. Оркестр алдында кулларын җилпеп дирежерлык итүче Салих Сәйдәшев шәйләнә. Оркестр әле кызып җитә алмаган, ниндидер көйләрне өзек-төтек уйнап ала да тагын тына. Тагын бер көйне башлый, музыка коралларын кемдер кисәк кенә бер читкә селтәп җибәргән кебек, сәер авазлар чыгарып, янә кырт туктап кала. Туктап торган арада Сәйдәш сабыр гына музыкантларга нидер сөйли, аңлата. Янәдән җилкәнеп таягын өскә күтәрә...

Пристаньга якын иркенрәк мәйданда Шамил Усманов, Кави Нәҗми, Гадел Кутуй, тагын берничә яшь кеше тынгысызланып йөренәләр. Алар вәкарь, йөзләре җитди. Яннарына килеп сүз әйтермен димә! Рабигага Әхмәтсафа кемнең кемлеген бәйнә-бәйнә аңлатып торды.

—Кутуй—радио дикторы, атаклы шагыйрь... Теге гел читкә карап сөйләшкәне—Кави Нәҗми. Зур язучы, шагыйрь кеше. Шамил Усмановны кичә күргән идек. Сугыш герое... Атаклы язучы...

Монда да тыныч кына торырга язмаган. Халык җыела тора, әйбәт урын таптык дип, сөенергә өлгермәделәр, кысрыклап читкә этәрә башладылар. Бу әйләнештән чыгып котылмасаң, тиз арада әллә кайда, койрыкка барып чыгасы иделәр. Әхмәтсафа чамалап алды, кайбер үткеррәкләр, тәртип сакчыларына ипле генә:

—Каршы алу комиссиясе,—дип дәшәләр дә, алда җыела башлаган кечкенә төркемгә барып кушылалар. Нигәдер, берсенен дә кәгазен-пропускысын тикшереп тормыйлар, үткәреп җибәрәләр.

Әхмәтсафа да тәвәккәлләргә булды. Рабиганы кулыннан кысып җитәкләде, Шираз белән Бибкәйгә: «Миннән калмагыз!»—дип ым какты, җитди кыяфәт белән халыкны аралап үтте дә, сакчыга шыпырт кына:

—ТКУ делегациясе, каршы алу комиссиясе...—дип, туктап та тормастан, алга үрмәләвен дәвам итте.

—Дүртәүләпме?!.—Кычкыра төшеп сорады сакчы.

—Әйе, мен кешелек коллективтан дүрт кеше!—Телгә килгән беренче сүзләрне әйтте егет, сакчыга өстән генә караган булып.

Әрсезлек—ярты бәхет, диләр, номер барып чыкты бит, әй. Сакчы, риза булмагандай:

—Комиссия кешеләрен үзләрен сакларга бер полк кирәк монда,—дип сөйләнә-сөйләнә үткәреп җибәрде. Алар, сихерләнгән кебек, оркестрдан ерак түгел җиргә килеп бастылар. Ул арада Сәйдәш янына атылып Усманов килеп басты:

—Йә, Сәйдәш, берәр нәрсә чыгамы?

—Чыгармый карасыннар!—Сәйдәшнең тавышы шаяртулы иде. Шундук җитдилеккә күчте.—Мондый җаваплы чакта да сынатсак, ни була, бәгырь?..

—Анысын белəм лә...—Монда сүз артык дигәндәй, Усманов ары чапты. Күрәсең, каршы алуга җаваплы кешеләр арасында иң зур вазыйфа биләүче иде ул. Аның һәрнәрсәдә эше бар кебек, бер мизгел тик тормый,

әле Кутуйлар төркеме янына барып нидер сөйләп ала, әле кемнедер чакырып алып, аңа кызу-кызу нидер аңлата, ул да булмый, кемнәрдер аның үзе янына йөгерешеп килеп, аннан нидер сорашалар, белешәләр иде.

Әхмәтсафа ирексездән Сәйдәшкә карап алды. Сәйдәшев бу минутларда илаһи күтәренкелек кичерә иде, дулкынланган сыман да. Соңгы мәртәбә күрешүгә дә алты еллап гомер узган, әмма Салих Сәйдәшев артык үзгәрмәгән, шундый ук басынкы, кемгә генә дәшсә дә йөзендә якты дулкын пәйда була, шул ук вакытта, үз эшенең барып чыгасына тирән ышануыдыр инде, ниндидер җинеллек күзәтелә хәрәкәтләрендә. Шунсын да искәртте егет, Салих Сәйдәшев карашында ниндидер үзгәлек бар кебек. Ара-тирә күзендә шундый тирән сагыш уйнап ала, ниндидер гаҗәеп зур югалтуга дучар булган кешедә генә була торгандыр мондый караш. Мизгел эчендә ул онытылып китә. Тиз арада үзен кулга ала. Аның күңелендә нидер бөргәләнә, җанында ниндидер яу, көрәш барган сыман. Гәүдәсе монда, күңеле әллә кайларга очына, уйлар еракта, биектә, үзе хыялда әллә кайларга барып кайта шикелле. Нәрсә тынгысызлый аны, җанын нәрсә кыйный, бәгырен ни әрнетә?.. Егет, билгеле, боларны аңлаудан бик ерак иде.

Алгы рәттә гайре тынгысызлык сизеп, Әхмәтсафа уйларыннан бүленде. Анда Сәгыйтовны күреп алды. Ул кычкырып-кычкырып сакчыга нидер аңлата, алга үтмәкче була, сакчы исә егеттән гарык булган бугай, аны дорфа рәвештә читкә этә, куа иде. Сәгыйтов елардай булып сөйләнә, муенын уңга-сулга бора, үзен яклардай кеше эзли. Менә аның күзләре Әхмәтсафага килеп төртелде, бер мәлдә әллә нишләп китте, шинеп, кечерәеп калгандай булды, кызарды, бүртенде, чарасыз гына сакчыга кызгандыргыч караш ташлады да, кинәт зәһәрләнеп, Әхмәтсафа ягына йодрыгын селкеп алды һәм халык арасына кереп юкка да чыкты.

Ниһаять, күптән көткән пароход күренде. Халык өнсез калып, параходның пристаньга якынлашканын күзәтеп торды да, күңел түрендә кайнаган хисләрнең тулышуына түзә алмый, сакны ярга табан кысрыклап, тыйгысыз рәвештә пристаньга табан шуыша башлады.

Кемдер ачык итеп:

—Әнә, Горький палубага чыгып баскан!—дип кычкырды.—Шул үзе, Горький бит инде! Мин бит аны күргән идем, ун еллап элек.

Әлеге түземсезләнеп сөйләгән кешегә игътибар итүче дә булмады, сакчылар, беләкләренә кызыл бәйләгән таза егетләр ярдәмендә мыш-мыш килеп, халыкны билгеләнгән чиктән үткәрмәскә тырышып азапланалар. Төркемдәге халык җәтмәгә эләккән балык сыман һаман тыгызлана, тагын ике-өч минуттан ни буласын искәрешле түгел.

Шул чагында дебаркадер ягыннан йөгерә-атлый Шамил Усманов килеп чыкты. Ул, кулын өскә күтәреп, шундый гаярьлек белән беренче рәтләр алдыннан җилләнеп үтте ки, ыгы-зыгы шундук басыла төште, ташкын басымы күзгә күренеп кимеде:

—Сабыр!—дип кычкырды Шамил Усманов.—Тәртип, тагын бер тапкыр тәртип! Сабыр булыгыз...—Сүзен тәгәлләп бетермәс борын, Сәйдәшкә борылды.—Әйдә, Салих, музыка!

Сәйдәшнең бер кул хәрәкәте җитте, оркестр дәрте, ашкынулы музыка уйнап җибәрде. Әле генә барлык киртәләрне җимереп алга томырылырга әзер халык шушы көй аһәңенә буйсынып, тып-тын калды. Этеш-төртеш, ыгы-зыгының эзе дә калмады. Әхмәтсафа бу көйне кайдадыр ишеткәне дә бар сыман, бик тә гүзәл һәм күңеленә кереп калган таныш бер көй иде ул. Җан гына түгел, гәүдә дә очына, каядыр күккә күтәрелгән сыман, хисләр актарыла, серле аһәң җанның иң нечкә кылларына чиртә. Көй үзенә әсир итә, җилкендерә, сафландыра иде. Идел өсләре яктырып, киңәеп китте сыман, күкләр биекләнде, һаман-һаман якынлашып килүче ак пароход музыка тәэсирендә иләс илаһилыкка бирелеп, җилкәнчә генә бәллүләп алган кебек хәтта. Бар дөнья шушы якты моңга буйсынды,

күзләр пароходта булса, хисләргә көй хуҗа иде. Янәшәдәге ханым үзе дә сизмәстән:

—Әфарин, Сәйдәш!—дип кычкырды.

Әхмәтсафаның хәтер түре буйлап таныш шәүләләр чагылып үтте. Зиһене уянып, әллә кайчан булып үткән хәлләр—Оренбурның үзәккә үтәрлек салкын кышы, ачлык дәһшәте бумаклаган чорлар исенә төште. Шушы шыксыз чорны нурландырып торган газиз минутларны да хәтерендә яңартып өлгерде: балалар йорты; Шәриф Камалның талчыккан йөзе; нинди эшкә алынса да аерым бер җаваплылык белән үтәргә керешә торган Муса: аның арык гәүдәсе, аның юка йодрыкларын селкеп ала-ала шигырьләрен укуы, йөзендә ике кара энҗе күзләре генә утырып калган үзенең, ә нинди көч яшеренгән аларда, ниндидер серле дәрт, җегәр. Пианино янында утырган ак йөзле Салих Сәйдәшев... Клавишлар өстеннән шундый да җиңеллек белән йөгереп үткән озынча нәфис бармаклар... Әйтерсең, инеш өсләп өрфия җил фирүзә дулкын уйнатып уза. Бармакларның йөгерешен шуның белән генә чагыштыра алыр иде Әхмәтсафа. Әлбәттә, үзәкләрне өзеп яңгыраган моңлы көй истән чыкмый. Кая барса да ана ияреп барды бугай ул көй... Күңел түрләренә үк үтеп, йокымсыраган җаныңны кубарып, хисләрне йөзләр, күзләр аша тышка чыгарып түгәргә мәҗбүр иткән аһәң онытырлык кына түгел шул. Хисләр чайпалып тулыша да, бер мәл ярларына сыеша алмый түгелә, җан сафлана, түгәрәкләнә, күңел бөтенлеккә ирешә бара. Моң тәэсирендә туган хисләрдән дә изгерәк, илаһирак хисләрнең булуы мөмкинме?!.

Әхмәтсафа шушы сәер халәттә күпме торгандыр, әмма монда ни өчен килүен исенә төшереп, сискәнеп куйды. Шул мизгелдә зиһене дә уянды. Соң бу нәкъ шул көй—Оренбурда ишеткән, аны әсир иткән моң бит инде. Тик ул инде тагын да камил эчтәлекле, ныклы шәкелгә салынган, дәртле, җиңел төс алган иде, теге чакта Сәйдәш бармаклары арасыннан сагыш түгелгән иде, бүген ул сагышлы аһәңнәр юкка чыккан, өметле яңгырый көй, ышаныч белән сугарылган.

Ул бар дөньяны онытып, авызларын ачып пароходның пристаньга килеп җитүен күзәтеп торган Рабигага, Шираз белән Бибкәйгә күз ташлап алды. Көлемсерәп куйды. «Их, сез!—диясе килде аның кычкырып.—Күп нәрсәләрне күрмәдегез бит сез, күп нәрсәләрдән мәхрүм. Шушы көйне ишетү өчен генә дә килү кирәк булган сезгә Усия буена. Ә сез нишлисез?.. Авызыгызны ачкансыз да пароходка баккансыз. Хәер, ни дип әйтәсең инде, зур әдип каршыларга төштек ич, Сәйдәш музыкасын сирәкләр генә искә ала бу минутта. Күпләр үзләреннән өч-дүрт адым ераклыкта торган бөек музыкантның барлыгын да онытты шикелле. Шулай инде, без читтән килгәннәргә табынабыз, аларга мөкиббән китәбез, үзебезнең арада йөрүчеләргә кадер дә, сан да юк».—Бу сүзләр, әйтерсең, шушы мизгелдә аның баш миеннән йөгерешеп үтмәделәр, бәлки, кемдер кычкырып әйтте аларны. Кем дә түгел, колакка тавышы аермачык чагылды—бу... Мифтах хәлфә тавышы иде. Ул өскә, биеккә менгән дә, һәркайсын акылга китерергә тырышып, җыелган халыкка шундыйрак нәсихәт бирә иде. Горький килүен өнәми дисәң... Ул бит Горькийның һәр әсәрен укып, балаларга сөйләп бара иде. Бөек әдипне хөрмәт итмичә булмый. Бары тик: «Башка бөекләр янында, татарымызның бөекләрен дә истән чыгармагыз!»—дип әйтергә, аңлатып калырга омтылуы булды, ахры...

Әхмәтсафа, саташулы уйларыннан тәмам айнып, пароходка табан талпынды, пароход күп юл үтеп хәлдән тайган дәү бер җанвар кебек авыр мышный-мышный, ара-тирә ян якка су парлары бөркеп пристаньга якынлашып бетеп бара иде.

...Еллар үткәч кенә Горькийны каршылаган чакта оркестр беренче мәртәбә Салих Сәйдәшевнең «Кызыл Армия» маршын уйнаганын белде ул. Әмма бу көй әле яңадан да шактый үзгәрешләр кичергән иде, бусы беренче яңгыраш, халыкка тәкъдим итеп карау гына иде...

...Пароходтан юан баулар ыргытылып, аны тимер бүкәннәргә аркан-

лап әвәрә килгәндә, ягъни, әле параход җүнле-рәтле килеп туктарга да өлгермәде, Кутуй, Такташ, Усманов палубага ыргылдылар, үзен каршы алырга килгән халыкны күзләп, бераз югалыбрак калган Горькийны камап алдылар, күрешү, танышу башланды. Алар тирәсендә яшь кенә егет кайнаша, кулында фотоаппарат, җай чыккан саен каршы алу мизгелләрен сурәткә алып калырга тырыша иде.

Горький сакланып кына траптан төшеп, пристаньга үтте, үзен сырып алган яшьләр белән, каршы алу комиссиясе әгъзалары булгандыр инде, бер-ике кәлимә сүз алышты. Нәҗми нидер әйтте, аның сүзләрен Горький аеруча ошатты, ахры, ачылып китеп, елмайды, яшьләр чыр-чу килделәр, аннары язучы эре адымнар белән ярга таба атлады. Сәйдәшев бер хәрәкәт белән оркестрны уйнаудан туктатты, ул да булмады, музыкантлар ниндидер сагышлы урыс көен уйнарга керештеләр.

Бу минутта үз белеклегән Шираз—булачак артист күрсәтте:

—«На дне» пьесасыннан «Кояш чыга да бата» көен уйныйлар,—диде ул шыпырт кына. Ә Горькийның мәһабәт гәүдәсе алар белән янәшәдә басып тора иде инде. Ничек алар янына килеп баскандыр, сизми дә калдылар. Шушы бөек язучы белән рәттән басып тор инде. Их, бу югалып кала торган сыйфаты булмаса адәм баласының! Горький янәшәсендә Әхмәтсафа бөтенләй бәләкәйләнеп, кечерәеп калды кебек. Рәхәтләнеп карыйсы, йөз чалымнарын, сөйләшүен, хәрәкәт-ымнарын күзәтеп, хәтергә сендерәсе урынга, коелды да төште. Ник бер җүнле уй килсен башка... Ярый әле Сәйдәш музыкасы җанны кузгатып куйды. Бу көйгә Горький үзе дә битараф калмады. Мыегының озын чалгыйен төзәткәндәй итеп, оркестрга табан борылды, сәер генә калгынып, тукталып калды. Сәйдәшкә, хуплаган рәвештә, ягымлы елмаеп баш какты. Каяндыр биектән гөрелдәүле тавыш ишетелде:

—Яхшы, бик шәп, якташларым. Сөенеп басам Казан туфрагына бүген...

Кая югалып торгандыр, Горький янына ашыга-ашыга Кави Нәҗми килеп басты һәм олуг язучының беләгенә сак кына кагылып, аны читтәрәк торган кунакны каршы алу, озатып йөрү өчен махсус әзерләнгән машинага күрсәтте:

—Алексей Максимович!..—дип өзгәләнде ул.—Машинага... машинага, зинһар... Сезне көтәләр анда...

Горький, аптырап Нәҗмигә карап алды, сагышлы күзләре белән янә бер мәртәбә Идел өстен, үзен Казанга китергән «Урицкий» теплоходын күздән кичерде, бер сүз әйтми, озын гәүдәсен алга ия төшеп, ашыкмый гына машинага табан кузгалды.

Оркестр исә сагышлы көйне күнелле, дәртле татар көйләренә алыштырды. Горький халыкка эшләпә тоткан кулын килешле итеп болгап алды да, машинага утырды, теге җинел гәүдәле егет тә аннан калмый, берничә сурәт алгач, Горький янына менеп кунаклады.

—Улы, Максим Пешков белән килгән,—диде бер белдеклесе.

Халык арасында сүз йөгереп үтте:

—Малае белән килгән... Максим Пешков... Ул сурәткә төшерә.

Андый чакта табыла бит ул, кайберәүләр, форсат чыгуына куанып, Горький хакында шактый хәбәрдар икәнлекләрен искәртмәкче булып, белгәннәрен чыгарып җилпергә ашыктылар. Кайта торгач, шактый мәгълүмат туплады Әхмәтсафа.

—Ә бит Горькийны, башка интеллигентиклар белән илдән куып җибәргәннәр иде,—диде берсе.—Олы пароходны шыплап тутырып озаттылар аларны теге чакта. Ленин үзе кушкан ди...

—Дөрес тә эшләделәр. Ул сөрсеп беткән интеллигенция белән ни кырмак кирәк? Ленин дөрес әйткән—интеллигенция б... ул! Яна тормыш төзергә көч, мускул кирәк, интеллигенциянен камыр беләге белән төзеп булмаячак социализмны.

—Алар акыл сатарга оста, эшкә килгәндә—юк.

—Бик беләсегез килсә, Ленин үзе 1921 елда Горькийга илдән китәргә тәкъдим ясый.

—Һе, ясамассың... «Новая жизнь»ны эзләп табып укый иде халык. Ниләр генә юк иде бу гәҗит аламасында. Горькийның «Несвоевременные мысли» дигән язмалары революция өчен иң куркыныч коралга әйләнде ул чакта. Вәт, шуннан соң аны Ленин үзе янына чакырып, илдән китәргә кушкан да инде. Әнә хәзер тәүбәгә килгән, ил буйлап сәяхәт кыла. Без, большевиклар, мәрхәмәтле халык бит инде, гафу иттек...

—Итми, кая барасың? Бөтен дөнья таный хәзер безнең илдәге уңышларны. Аз гына кырын күз белән карасыннар буржуйлар, кырып-себереп чыгарга да күп сорамабыз!—дип әтәчләнде озын чәчле егет.—Дөнья хәзер безнең кулда, егетләр. Капитализмның көннәре санаулы. Моны башы булган һәркем белә. Горький да шуңа ышанып кайткан чит илдән. Рәхәт булса, дүрәк түгел бит ул, Италиядән Рәсәйгә кайтырга. Димәк ки, капиталист ипине чамалап кына ашата андыйларга.

—Егетләр, боргаламагыз фактларны,—дип, «белек»леләргә каршы төшәсе итте өлкәнрәк яшьтәге кеше.—Горькийның алтмыш яше тулып килә. Юбилей. Сталин әйткән: «Чит илдә каңгырап йөрмә. Кайт совет иленә, чын совет гражданы булып яшә, ким-хур булмассың,»—дигән. Бөек язучыбыз күп уйлап тормыйча, ризалашкан да кайткан. Сталинның бик тә күңеле булган диләр...

—Дөрес эшләгән,—диде озын чәчле егет.—Карышып торса, абруена күләгә генә төшәр иде. Әнә халык ничек каршы ала үзен! Мондый кадер-хөрмәтне кем, кайда күрсәтә аңа?

Бәхәс шунда тәмамланды, халыкны төрле тарафларга сузылган Казан урамнары үзенә суырып алып, сафларны сирәгәйтә, эретә бара иде.

Ул көнне Әхмәтсафа Горький булган урыннарга бара алмады. Рабиганы эшкә урнаштырырга, Шираз белән Бибкәйне укырга кертергә кирәк. Үзен йөрмәсәң, каршыңа чыгып: «Әйдә, монда килегез,»—дигән кеше юк. Шулай да Горькийның Казандагы һәр адымы хакында белеп торасы килә иде. Кич радиодан Гадел Кутуйның матур тавыш белән соңгы хәбәрләр укуын түземсезләнеп көтеп алды. Кутуй эфирга нәкъ вакытында чыкты.

Горький «Казанское подворье» кунакханәсендә тукталган икән, бүген зур театрда шәһәр советының киңәйтелгән утырышында чыгыш ясап, үзенең Казанда үткән гыйбрәтле, газаплы тормышы хакында сөйләгән. Шулай да ул кыенлыкларны инде оныткан, Казан турында якты истәлекләр белән генә яши икән хәзер. «Бу сүзләрне ишетү куаныч иде,—дип тә өстәп куйды Кутуй.—Гомумән, аерым шәхесләрнең тарих алдында күргәннәре, кичергәннәре шул кадәр вак нәрсәләр һәм мөһим түгелләр ки, болар хакында артык җәелеп сөйләп тору да урынсыз, диде бөек язучы,—дип сөйләвен дәвам итте Кутуй.—Никадәр хак һәм гадел сүзләр!» Кутуйның сөенече тавышына чыккан иде... Алдагы көндә Горький хөрмәтенә Яшь тамашачылар театры бинасында концерт була икән. Кутуй халыкны шушы кызыклы очрашуга чакырып, сүзен төгәлләде.

Әхмәтсафаның уенда Горькийның аерым кеше язмышы хакында әйткән сүзләре бөтерелде. «Чыннан да, аерым шәхеснең язмышы тарих өчен чүп нәрсә генә микән, ә?—дип аптырады ул, бөек язучының сүзләрен шик астына алып.—Кеше язмышына, шәхси кичерешләренә, әрнүләренә, хәтта омтылышларына да битарафлыкка өнди торган сүзләр түгелме соң болар? Шәхес белән теләсә ничек эш итәргә юл ачмыймы бу сүзләр? Шәхесләр булмаса—тарих та юк. Тарих дигәнең табигать сулышы, вакыт агышы гына булып кала. Ә кеше, шәхес күргән газапларны җәмгыять үзе тудырса нишләргә? Шулай ук җайлы җавап белән генә чикләнергәме. Җәмгыять кылган начар гамәлләре өчен гафу үтенә белмәсә, сабак алмаса, бу—куркыныч. Үз шәхесләрен танымау, аларны инкарь итү, кимсетү, рәнҗетү җәмгыятьнең чиренә әверелсә нишләргә? Боларны да вак-төяк дип кенә атаргамы?» Кутуйның авызыннан ишеткән сүзләрне бер дә Горький

әйткәндәр диясе килми иде шул, әмма бу сүзләрне Горький икенче көнне очрашу вакытында да кабатлады... Сәер, сәер иде мондый фәлсәфәне аның авызыннан ишетү. Вәзгыятькә ярыйм дип кыйбласын алыштырган кеше башкаларны ничек яшәргә өйрәтергә хаклымы? Хәер, кеше нәрсәгә булса да ирешү теләге белән ашкына икән, ул ялгышлардан азат була алмый. Бөтен хикмәт шунда, Горький нәрсәгә омтыла, нәрсәгә ирешмәкче?..

Концертка барасыларын белгәч, Рабига, аңа караганда Шираз белән белән Бибкәй шулкадәр сөенгәннәр иде, насыйп булмады—кичкә табан тулай торакка, гадәтенчә, гаять эшлекле кыяфәттә Җамал килеп керде. Ул Әхмәтсафаның җәйге ялдан килү-килмәвен белешергә дип кенә кереп чыкан икән, инде анда Рабиганы күргәч, бөтенләй телсез калды.

—Син ничек монда?—диде ул, күзләрен чепиләндереп.—Кем сиңа рөхсәт бирде? Каргалыда әнкәйне ялгызын калдырып...—дип сүз башлаган иде, Рабига, сабырлыгын җуеп, аңа каршы төште:

—Әнкәй ялгызы түгел. Аның янына Гариф энебез дә килде быел...

Гариф—төпчек энекәшләре, монарчы Атбасарда яшәгән иде, Җамал чыгып киткәндә ул кечкенә бала гына, өлкән апасы аның дөньяда барлыгын да онытып бара иде инде. Кече энесенең исемен ишетеп, кисәк кенә тертелеп калды, үз-үзен кулга алып, тагын да гаҗәпләнүен белдерде:

—Гариф? Аның белән нишләмәк кирәк? Әнкәй үзе дә кеше өстендә.

—Кеше өстендә түгел!—дип тынычландырды аны Әхмәтсафа.—Безнең Гомәрхан абый быел өйләнеп җибәргән, шушы бик акыллы кыз, әтиәнисе, туганнары юк, апасы белән гомер кичергәннәр. Гомәр колхоз оештырып йөри, идарәгә дә якын булыр дип, кәләше өенә күченеп китте. Хәлимә апай белән Гариф энекәш безнең өйгә хуҗа булып калды.—Тартай телennән табар, дигәннәре дөрестер инде, Әхмәтсафа шаяртасы килеп, өстәп тә куйды,—без Рабига белән никахта хәзер. Рабиганы Казанга алып килергә булдым. Эш тә табып җибәрсәк...

Җамал чәчрәп урыныннан сикереп торды, Рабигага табан атылды. Күзләрендә зәһәр очкыннар биешеп алды.

—Никах?!.—диде ул ачу белән.—Нинди никах, нәрсә дигән сүз була бу, Рабига?

—Әй, куй инде, Әхмәтсафа, шаяртма...—диде, кыз бәйләнчек Җамалдан котылырга теләгәндәй.—Теләнә ни кылсә, шуны сөйли...—Кыз үпкәләгән сыман, читкә карап утырды.

—Бәй, дөресе шул булгач,—Әхмәтсафаның бирешәсе килмәде.—Хәлимә апай Рабиганы никахсыз миңа ияртеп җибәрмим диде. Оренбурда муллага барып кайтырга туры килде.

Җамалның битләренә ут кабынды.

—Иске авыздан яңа сүз! Әнкәй сүзен сөйләп, нүҗәли никахка бардың, кызый?—Ул Рабигага ябырылуын дәвам итте.—Нүҗәли, юрган бөркәнеп, ир астына кереп яту синең өчен бар нәрсәдән кыйммәт—идеал да юк, намус, вөҗдан да?.. Комсомолка, күрегез, ха-ха... Никах укытып йөри, яшь совет гаиләсе төзи, имеш, бәрәү!

—Ярый инде, Җамал, чәпчемә. Әби... әй лә, Хәлимә апайның сүзен аяк астына салып таптамыйк, дидек. Ни әйтсәң дә әйт, үз башыңа төшкәч кенә беләсең икән аны, бер дә өлкәннәрнең хәер-фатихасын алмый, гаилә корып җибәрәсе килми бит, малай.

—Мәсхәрә!..—диде Җамал чыдаша алмый.—Син, коммунист, Ленин призывы кешесе. Нинди түбәнлек? Тиз арада партбюрога чакыртып, пешертергә кирәк син егет кисәген!

Әхмәтсафа эшнең зурга китү мөмкинлеген уйлап, үкенеп куйды. Нигә сүз башларга инде? Акыл телгә күчсә, акыл болыдан туктый шул...

—Ни булса булган, әмма бездә бит син әйткәнчә, юрган астына кереп китү кайгысы юк. Урнашырга кирәк, аннан чын советча никахлашу булыр. Ә мулла никахы хакында күңелле истәлек итеп кенә сөйләргә

калыр. Нишлисең, әле халык бар гореф-гадәттән, йолалардан, шәригатьтән аерыла алмый. Ата-ана фатихасы дигәннәре дә бар. Аяк астына салып таптап булмый...

—Сезнең кебек миңгерәүләр бар чагында халык искелектән беркайчан да аерыла да алмаячак!—Ул мышык-мышык елап утырган Рабиганы табалап алды.—Күз яше түгеп утырма! Җыен, мин сине Арчага алып китәм. Монда бер генә көн дә тормыйсың! Ха-ха, совет укытучысы, имеш... Башыңдагы чүп-чар уйлардан арынмый торып, Әхмәтсафа белән көрешү юк сиңа!

Рабига, тәмам аптырап, бер Әхмәтсафага, бер Җамалга карап алды.

—Арчага?—диде ул, әкрен генә.—Мин бит... Казан... Шираз белән Бибкәй кая кала? Кем карый аларны?—Ашыгып, өтә-төтә сүзләр атты ул, тел ачылганда әйтеп калыйм дигәндәй.

—Башта уйлыйлар аны, никахлы гыйшык! Аптырап торасы юк инде хәзер. Эш үткән. Шайтаныма олаксагыз да бер-берегезне эзләп табарсыз. Әйдә, сезнеңчә булсын, чукынып китегез, сез өйләнеште дип дөнья бетмәс, социализм төзү уеннан да чигенмәбез.—Йомшара төште Җамал.—Эш юк дип аптырап йөрмә, Казанда синең ише укытучы кисәкләре буа буарлык. Кемне китереп төртмә—укытучы, мөгаллим булыр. Кем бирсен сиңа Казанда эш. Әмма бар ул! Күпербаш дигән авылда рабфак ачмакчы булып йөрибез. Арчадан ерак түгел, теләсәң, көнендә Казанга килеп, йомышыңны йомышлап китәргә була, Әхмәтсафага да килеп-китәргә уңай булыр, поездга утырып кына килер дә житәр.—Җамал, әйтерсең, яна гына дөнья җимерердәй булып дуламаган, бөтенләй йомшарды. Аның чын күңел халәте дә шушы иде булса кирәк—йомшак, кайгыртучан, ә җикеренүләре, дуамаллыгы, фәкать кылану, революцион үзгәртеп кору чорында шулай сөйләшү лазем, йомшак агачны корт баса, синең күңел халәтенне, асылыңны беркем сизәргә тиеш түгел, йомшаклык күрсәтү—дошман алдында ярамаган кебек, дуслар, туганнар өчен дә зарарлы сыйфат дип, ышанып йөрүдән иде. Аннары Әхмәтсафа алдында үзен күрсәтергә теләү, акланмаган хисләре өчен үч алу тойгысы да кузгалып, җанында гарасат купты, әле анысын да тиз генә басып куеп булмый, үзүзен кулга алып, эзгә төшкәнче күпмедер вакыт кирәк. Апасының холкын белгән Рабига да, күз яшьләрен түгеп алса да, эчтән генә Җамалның тынычланганын көтеп утыра иде, яктыра төште.

—Чыннан да, апа әйткәнчә эшләсәк...—дип, Әхмәтсафага күз сирпеп алды.—Әле Казанда эш табып буламы, юкмы? Балалар да үз янымда булыр.—Ул Бибкәйне кочып, аркасыннан сөеп алды.—Аннан авыл авыл инде, ашау ягы да бар бит әле.

Әхмәтсафа телгә килергә өлгермәде, Җамал үзенең фикерен алга сөрүен дәвам итте:

—Шулай булмый соң! Әхмәтсафаның үз акчасы үзенә җитми аның. Кая сезне туйдырып тору.

—Анысын карар идек әле, Җамал. Җан биргәнгә җүн биргән, бер-бер жае чыгар иде.

—Йә, йә, телеңә салынма! Ничек кенә булса да Рабиганы яныңнан җибәрәсең килми синең. Ха-ха...—дип көлеп җибәрде Җамал. Сүзләреннән нинди кызык тапкандыр инде, бер Ходай белә.

—Мин авылга бармыйм!..

Өлкәннәр тып-тын калдылар. Бу сүзне кистереп әйтүче Шираз иде.—Мин театр техникумына керергә килдем. Авылда сөт белән күкәй ашап утырырга түгел.

Бибкәй пырхылдап көлеп җибәрде.

Җамалның күзләре зу-ур булып ачылды, авызын бөрештереп, күзе белән түшәмне айкап алды:

—Булсалар булырлар икән! Берсендә дә эләккән эш юк бит боларның. Каян керде ул нәмә башына, энем? Әртист булып, кәмит уйнап йөреп, яна тормыш төземәкче буласыңмы, чүлмәк баш!

Сүз иярә сүз чыга, аннан күз чыга. Әхмәтсафа сүзне артыкка җибәрмәскә теләп, тезгенне үз кулына алды.

—Болай итәбез, алайса,—диде ул, барысын да үзен тыңларга мәҗбүр итеп. Көчле, гайрәтле тавышы гаярь ир-егет икәнлеген сиздереп торганга, Җамал ана үз итеп, Рабига исә яратып карап алды. Әнисе сүзе келт итеп исенә килде: егет икән батыр булсын! Җебеп утырмасын, кирәк чагында сүзен әйтә белсен! Әхмәтсафа үзенә сынап караганнарын искәрмәгәнгә сабышып, дәвам итте.—Җамал дөрес әйтә булса кирәк, әлегә Казанда әллә-ни эш кыра алмабыз, якын-тирәдәге бер авылга урнашуны үзем дә хуп күрәм. Яшереп торасы юк, минем башта андый уй йөри иде инде. Рабига белән Бибкәйне Күпербашка озатабыз. ТКУ Арча кантонына шефлык итә, мина барып йөрергә җай чыгып кына торыр. Ә Шираз Казанда кала. Керсен ул техникумга, үзе яраткан һөнәрен алсын, артист булсын, шәп артист булсын! Минем янда яшәр, аннан күз күрер. Бәлки техникумның да тулай торагы бардыр...

Барысы да җинел сулап куйдылар. Шул ук кичтә Рабига белән Бибкәйне алып Җамал Арчага китеп тә барды. Шираз белән Әхмәтсафа аларны озатып, ярты төндә генә тулай торакка кайтып егылдылар.

...Икенче көн Ширазның документларын техникумга тапшырып үтте дияргә дә була. Документларны алган унайга күрше бүлмәгә кереп, әңгәмә үткәрүче комиссиягә күренеп чыкты егет. Шигырь сөйләтеп карадылар, этюд та ясап күрсәтте: ул нәкъ Әхмәтсафага охшатып «итек тегеп» шаккаттырды комиссия әгъзаларын. Сәхнәдә йөреп шактый шомарып та беткән икән: Ширъяздан Сарымсаков дигән егеткә «имтиханнар вакытында аерым игътибар кирәк» дигән тамга салынды. Шираз тулай торакка кош тоткандай кайтты, бүлмәгә атылып та керде, дәреслекләрен барлап, имтиханнарга әзерләнергә дә тотынды, шуна күрә Әхмәтсафа Горький белән очрашуга ялгызы гына китте.

...Ул килгәндә театр бинасы шыгрым тулган иде. Күбесе яшьләр. Алдагы рәтләрдә таныш йөзләр күзгә ташлана. Әнә Такташ беренче рәттә утыра. Салам чәчләрен әледән әле бармаклары белән аралап, җай гына артка тарап куя. Кемдер анын каршысына баскан да, тегенә нинди дер кызык вакыйга сөйләп булса кирәк, авызына караткан. Такташ ара-тирә як-ягына күз төшерә, йөзе кояштай балкыган, тыенкы гына көлеп тә ала.

Концертны Шамил Усманов әзерләгән. Концерт башланганчы, үзенең кичәгә хуҗа икәнлеген белдергәндәй, пәрдә читен ача төшеп берничә мәртәбә тамашачыларга күз ташлап алган булды.

Көне буе чабып арыткан иде, кичә башланып китә алмый, Әхмәтсафа онытылып бетә язган иде, колак төбендә:

—Таптым бит, егеткәй!—дигән яңгыравык тавыш ишетеп, сискәнеп китте. Күтәрелеп караса—каршысында шатлык-сөенечтән битенә алсулык йөгергән көләч һәм сөйкемле Заһидә басып тора.

Әхмәтсафа урыныннан күтәрелә төшеп:

—Заһидә... Син ничек?..

—Һи-и, танымаганга сабышыр микән дигән идем...—Кыз күнелле генә гөрләп алды. Казан аңа килешкән: гәүдәгә тазарып, тулыланып киткән, ә чибәрлеккә килгәндә, күз тимәсен, бүгенге тамашага килгән кызлар арасында аңа тинләшерлек гүзәлләр булса да ике-өчтән артмыйдыр.

Әхмәтсафа берәр танышы күзгә чалынса дип, үз янында бер урын буш тота иде, Заһидә, чакырганны да көтми шул урынга чумды. Шуннан сон гына чытлыкайланып сораган булды:

—Бу урынны кемгә тота идең, Әхмәтсафа?

—Сиңа инде, кемгә булсын!—Әхмәтсафага күптәнге сыйныфташын очрату күнелле иде, әлбәттә. Шундый чибәр кызның анын янына атылып килеп басуын, теленә бетеп, рәттән урын алуын әнә күпме күзләр күзәтә.

—Хатынны алдым. Рәхмәт, искә төшерүенә...—диде Әхмәтсафа, кызга иелә төшеп.—Инде онытып бара идем сыйныфташларны. Ара-тирә Саттар килеп чыга—ул да Казанда укый. Тик еш аралашып булмый, ул—авыл

хужалык институтында бит. Аны, тәҗрибәле кеше буларак, күбрәк районнарга чыгарып җибәрәләр. Бер командировкадан кайтып керергә өлгерми, икенчесе әзер.

Кыз серле тавыш белән:

—Сәгыйтов...—дип сүз башлаган иде, аны Әхмәтсафа бүлдерәсе итте.

—Сәгыйтов белән борчак артык пешми, үзең беләсен...

Заһидә, шул сүзләрне генә көтеп торгандай, Фатыйхка ябырылды:

—Фи-и, Сәгыйтовны күргәләгән бар ла аны! Яшьләр клубында әдәби кичә булса, тол чыпчык, килә дә менә сәхнәгә. И тотына яманларга шагыйрьләрне, и пыр туздыра, мин сиңа әйтим. Түз генә. Каян табып бетерә сүзләрен, кем өйрәтә?.. Үзе бер юл шигырь язмаган кеше башкаларны ничек өйрәтә ала, һушым китә инде.

—Такташка да эләгәме соң? —Әхмәтсафа киная белән әйткән сүзеннән көлеп куйды..

—Такташка шул кирәк аңа.—Заһидә алгы рәттә утырган Такташка зәһәр караш ыргытты.—Бар иде, яшь чагым, җүләр чагым, шул кеше артыннан Ташкентларга китеп олактым бит, исәркәйгенәм. Җүләрлекләр үтте, акыл утырды, хәзер инде күктән йолдыз чүпләү исәбеннән кайтып, җирдәге асылташларны эзлим.

—Бар микән соң алар? Асылташлар дим...

—Нишләп булмасын? Менә янымда берсе утыра,—дип, Заһидә аның инсәсенә кулын тигереп алды.—Авыл килешкән, егеткәй, кара чутырга әйләнеп килгәнсең. Әллә төнлә дә кояш яктысы сүрелмәде анда? Көндез генә булса, болай ук янмас иден.

—Көндезге кояш та мул сипте нурын, төнге кояшым да бар иде.—Шаяртып җавап кайтарды егет.

—Кызларны акылдан яздырып бетергәнсеңдер инде, чибәр син, Әхмәтсафа!..

Ул арада шаулатып оркестр уйнап җибәрде. Сәхнәгә Максим Горький чыгып, президиум өстәле артыннан урын алды. Озакка сузылган алкышлар. Сүз өзелде, Заһидә егеткә сыеныбрак утырды. Салих Сәйдәшев житәкчелегендә музыкантлар татар халык көйләреннән тезмә башкарды. Аннан бер-бер артлы артистлар, язучылар сүз алды. Атаклы язучыга сораулар яудырырга да өлгерделәр. Бигрәк тә, башы пеләшләнә башлаган берәү каныкты аңа.

—Сез Рәсәйдә яшәүче халыкларның әдәбият үрнәкләрен туплап сайланмалар бастыра башлаган идегез. Ни өчен татар әдәбиятын бастырып чыгармадыгыз?—дип сорау бирде ул.

—Булды ул хәл,—дип гөрелдәде Горький урысларның нижгар сөйләше белән.—Әрмәннәр чыкты, Литвалылар... Татарларга килсәк... Тәржемә әйберләр бит. Сыйфаты начар булды, вакыт үтә торды.

—Ә Гаяз Исхакый әсәрләре?

Горький күптәнге танышын очраткан шикелле яктырып китте.

—Әйе, Гаяз Исхаков белән ижади хезмәттәшлек иттек без. Берничә әсәрен урысчага тәржемә итеп бастырып чыгардык. Үзем булыштым. Әмма ният тормышка ашмады—аның да сайланма әсәрләрен жыентыкка туплап бастырырга иде исәп. Бик тынгысыз егет иде бит, әле төрмә, әле сөрген... Житешә алмадык. Кайда соң әле ул бөек язучыгыз?

Зал шаулашып алды.

—Эмиграциядә,—диде Шамил Усманов тәксе генә.—Советны кабул итә алмады...

—Әйе-е,—дип уфтанды Горький, тирән уйга чумган хәлдә.—Күпләрнең фажигасе бу.—Совет хөкүмәтенә жиңел түгел. Дошманнар чолганышында яшәүнең ничек икәнен моны үзе кичергән кеше генә белә. Без ил белән кичерәбез. Ил белән килгәнгә түзәрбез, авырлыкларны ерып чыгарбыз. Мин моңа ышанам. Сезгә дә, дусларым, тормышка аек акыл белән карарга кирәк. Һәр өлкәнең, республиканың эчке дошманнары

бар, аларны фаш иткәндә жирле үзенчәлекләрдән оста файдаланырга иде. Алда—көрәш, алда—жиңү!..

Сүзне Кутуйга бирделәр. Ул, ялкынланып, яттан Горькийның «Давыл хәбәрчесе турында жырын» татарча укыды. Укый башлаганчы ук тәржемәнең үзенеке булуын әйтеп куйган иде. Горький Кутуйның укуын зур игьтибар белән тыңлап утырды, сүзләрне аңламаса да, интонация, йөз мимакасы, кул хәрәкәтләренә карап, әсәргә ияреп, кайсы төше икәнен чамалап барды булса кирәк, Кутуй укып бетергәч, Горький халыкка кушылып, озаклап, чын күңелдән кул чапты. Аның бармаклары озынча, уч төпләре киң сыман күренде Әхмәтсафага. Янында Заһидә утыруы бу кичәне иркенләп карарга комачаулый иде,—барыбер ул үзен бу хәлдә уңайсыз хис итте. Ара-тирә кыз аның беләкләренә кагылып ала, кызык тоелган жирләрдә ихлас көлә, үзен иркен тота иде. Әхмәтсафаның игьтибарын яуларга теләвен яшерми дә иде, ахры. Егет моны сизеп утыра, эчендә ут, әледән-әле Рабиганың монсу карашын тойган сыман була, мондый хәлгә төшүе бер дә күңелле түгел икән, шуңа күрә көләр чакларда да ул, житдилеген югалтып бетермәде.

Горькийга да, тамашачыларга да Асия Измайлова жырлавы нык тәэсир итте. Якты тавыш, һәр борманы жиренә житкереп башкаруы ук күңелләрне үзенә жәлеп итә иде. Чибәр үзе, гәүдәсенә килешле ятып торган зәңгәрсу күлмәк кигән, сәхнәдә үзен-үзе тотышында аерата затлылык, мәһабәтлек бөркелеп тора. Һәр хәрәкәте төгәл, үлчәнгән, мең кат уйланган кебек. Килмәгән жире юк иде бу жырчының. Башта ул Горький үзе дә яратып жырлый торган «Кояш чыга да, бата да...» жырын башкарды. Татарчага «Тормыш төбендә» әсәреннән Сәгыйт Рәмиев тәржемә иткән икән.

Кояш чыга да, бата да...
Төрмәм мәңге караңгы...
Көннәр, төннәр зөбанилар , их!
Тәрәзәмне карулый...

Горький жырны алга иелә төшеп, бөтен барлыгы белән йотылып тыңлады. Ул да булмады, Асия Измайлова жырны чип-чиста урыс телендә дәвам итте:

Как хотите, стерегите...
Я и так не убегу...
Мне и хочется на волю,—эх!
Цепь порвать я не могу...

Язучы, урысча жыр башлангач, калкынып китте, үзе дә авыз эченнән генә кушылып жырлый башлады. Жыр тәмамлангач, Горький урыныннан басып, баш ия-ия алкышлады жырчыны. Озын гәүдәсен жил уйнатып, чайкалдырып торган кебек иде ул минутта.

Аннан Асия Измайлова халык көйләрен, композитор әсәрләрен жырлады.

Жыр бетеп, алкышлар тынып өлгермәде, сәхнәгә Кави Нәжми атылып менде, ул дулкынлана-дулкынлана Горькийга бер хикәясен бүләк итте.

—Урысчага үзем тәржемә иттем, иптәш Горький. «Шобага» исемле. Беренче уңышсыз тәжрибәләремнән...—дип, үз янына килеп баскан Шамил Усмановка өнәмичәрәк карап, сәхнәдән төшеп китте.

Концерт беткәч, Горькийны яшьләр урап алдылар. Ул исә, беркемгә дә игътибар итмәстән, башта Асия Измайлова янына килде.

—Шамил Усмановның хатыны ул,—диде Заһидә, ниндидер үкенечле тавыш белән.—Пар да килгәннәр инде. Сокланып туймаслык!.. Менә кемнәр бәхетле дөньяда.

Шамил Усманов башкаларга сиздермичәрәк Асия Измайлованы алга этә төште, Горький янына үткәрде. Горький балкып, яктырып Асия Измайлованың кулына үрелде... Усманов бөек язучының үз хатынына карата бу игьтибарына гаять сөенеп, баскан урынында сабый бала шикелле

сикергәләп алды. Горький чал башын җинелчә генә ия төшеп Асия Измайлованың кулын үбеп алды. Берничә мактау сүзләре әйтте. Шамил Усманов һаман да Асия Измайлованы Горькийга табан этәрә биреп, нидер сөйләнеп алды. Язучы аны хуплап, башын селкеп, җырчы ханымның кулын озак кына учларында тотты. Аннан ул Салих Сәйдәшев янына юнәлде. Аны, ничектер, үз итеп кочаклап, колагына нидер пышылдады, икәүләшәп көлешеп тә алдылар. Бу сүзләр шушы икәү генә белгән мәңгелек сер булып калдылар...

...Урамга чыккач, Әхмәтсафа беләгенә сарылган Заһидәгә ни әйтергә белмичә, шактый изаланып барды.

—Теленне йоттыңмы, Әхмәтсафа,—дип шаярткан булды Заһидә. Әмма ул нидер сизенә иде, шукланыуын үзе дә килештереп бетермәгән шикелле, тынып калды.

—Син дә сөйләшмисең бит...

—Мин, Әхмәтсафа, болай гына телчән сыман күренәм. Кирәк чакта бер сүз таба алмый тилмерәм...

—Аңлашылды... Син кайда яшисең, озатып куям үзеңне.

—Иренмәсәң...—диде Заһидә, күнелсезләнеп.—Ерак яшәмим, бер әбидә фатирда торам. Син бит минем хакта бөтенләй сорашмадың,—дип, үпкәләгәндәй итте кыз.—Житмәсә, үзеңне сыйныфташ, яшьлек дустым дип йөргән булам тагын...

—Хатыңда барысы да бар иде бит. Котлыйм, техникумны тәмамлагансың, институтка керергә җыенасың. Уңышлар телим.

—Уку дип... Гомер үтә, Әхмәтсафа. Холкым да әйбәт инде үземнең... —Заһидә көлеп куйды. Тик бу көлү ясалма кебек иде.—Төскә-биткә дә ким-хур түгел, тик мин ялгыз... Япа-ялгыз мин шушы шәһәрдә, күз алдына китерәсеңме?

—Егетләр очрамадымы юлыңда? Сайланасыңмы, дигәндәй.

—Күңелемә охшаганы юк, Әхмәтсафа. Минем җанымны аңлаучы юк. Озата килүчеләр күп, гәп куерта башласаң, үзләренең өч тиенлек проблемалары хакында сүз куертып, баш әйләндерергә тотыналар. Янәшәдә барган кыз ни

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ

## «QAZAN UTLARI»NA 80 YIL

**Айрат Арслан,**

*Татарстанның һәм Россиянең халык артисты*

## ХАЛЫККА ХЕЗМӘТ ИТҮ БӘХЕТЕ



***«Казан утлары» журналы укучыларның көтеп алына торган басмасы булган кебек, минем өчен дә әдәбият яңалыклары белән даими танышып бара торган, эшем буенча да еш кына аңа мөрәҗәгать итәргә туры килә торган әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал ул. «Казан утлары» республикабызда гына түгел, ерак төбәкләрдә яшәүче укучыларында да әдәбият, мәдәният яңалыклары, тарих, сәясәт һәм иҗтимагый мәсьәләләр белән таныштыруда зур эш башкара.***

***Мин Казанга укырга килгәндә, хәтерем ялгышмаса, «Совет әдәбияты» журналына 25 ел тулган иде. Театр мәктәбендә безне татар әдәбияты буенча күренекле галим, мәшһүр педагог Якуб Хәлил улы Агишев укыта иде. Ул безгә: «Оланнар, әдәбиятыбыздагы яңалыкларны белеп барасыгыз килсә, «Совет әдәбияты» журналы белән дә танышып барырга кирәк, анда басыла торган яңа әсәрләрне укып бару сезгә, булачак актерларга да, зыян итмәс, Ленин китапханәсенә баргалагыз»—дия торган иде.***

***Менә шул елларда журнал белән дуслыгыбыз башланды һәм еллар үткән саен ул дуслык ныгый һәм үсә бара дип горурланып әйтә алам. Алтмышынчы елларда, Г. Тукай исемендәге Татар***

уйлый, нинди утларда яна, жаны кайда ашкына—уйлап та карамыйлар, жыен кисәү агачы. Үз туксаннары туксан. Тынлап-тынлап йөрим дә, куам да жибәрәм үзләрен. Бармы бу дөньяда чын егет?! Шыншып йөрүчеләрдән туеп беттем инде, гарык!

—Соң алар да ялгызлыктан туеп беткән, үзләрен тынлаучы табылды дип сөенүче беркатлы татар егетләре ич инде. Бәлки сабырлык белән тынлап бетерсәң, сөйләргә сина да чират житәр иде. Аннан егетләргә зарлану, үзләрен кызгандырырга тырышу хас бит. Психологик адым, моны гына анларлык инде син, артык акыл сатасым килми.

—Алай булдыра алмыйм, Әхмәтсафа,—диде Заһидә үжәтләнә төшеп.—Кая хатын-кызны анларга тырышу? Кая хатын-кызга хөрмәт? Алтыдагы алтмышка. Башта ук шулай икән, янадан холкы үзгәрер дисенме аларнын? Татарнын татарлыгын кислота белән дә бетереп булмаячак. Кызларны кулына төшергәнче былбыл булып сайрый ул, аннан... Ә хәзер андый сайраучысы да очрамый башлады. Күрәсен, гомер уза, туннар туза...—Заһидә жанланып китте.—Ә син күрдеңме, Шамил Усмановнын Асия Измайловага мөнәсәбәтен?! Нинди игътибарлы ул ана, нинди манера! Ис китәрлек. Менә моны анлыйм мин!

Шактый сүзсез бардылар. Яртылаш жиргә сенгән йорт янына житкәч, Заһидә туктап калды.

—Мин кайтып життем. Үзгәрмәгәнсен, һаман да шул Әхмәтсафа икәнсен син. Күп сөйләшмисен, хисләренне жилгә чәчмисен, уйларынны тотып селкемисен. Серле егет син. Кызлар андыйларга тартыла, беләсен килсә...

—Өч тиенлек сүзем белән ничек инде синен башынны әйләндерим.—Егетнен сүзләре кинаяле иде.—Минем дә татарлыгым мангаема язылып куелган, язмыштан узмыш юк.

—Йә инде, төрттереп сөйләшмә! Бөтен хикмәт шунда, Әхмәтсафа, мин сине сәгатьләр буе тынларга да әзер. Син мина охшыйсын. Көлмә, көлмә, төшемә кермә-

*дәүләт филармониясендә сәнгатьле сүз жанрында эшли башлагач, журнал минем аерылгысыз дустым һәм юлдашыма әверелде. Мин әдәби-музыкаль лекторий бүлегендә эшләдем, ә бу бүлекнең эш алымы эстрада бүлегендә эшләүчеләрдән аермалы буларак, һәр айны диярлек яңа программалар әзерләргә кирәклеге белән аерыла иде. Хәзер архивымда сакланган афишалар, буклетлар белән танышып утырганда, безнең программаларыбызда күпме татар язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләре яңгыраганын күреп, бераз гаҗәпләнеп тә куям, күп эшләнгән...*

*Әлбәттә, яңа программаларга яңа әсәрләр эзләгәндә журналларга еш мөрәҗәгать итәргә туры килә иде. «Казан утлары» минем өстәл китабым кебек була иде. Һәрбер журнал үзе белән күпме проза, шигърият байлыгы алып килә. Яңа авторлар белән танышыра! Ничә еллар дәвамында җыелган жур-налның күп саннары өемдә саклана, алар белән аерылышасы килми, җәй көннәрендә дачама барсам, анда да китап шкафы тулы «Казан утлары» саннары, буш вакытыңда аларны кулыңа аласың, бик күп таныш авторлар искә төшә, аларның күп әсәрләрен эстрадада, радиода, телевидениедә яңгыраткан еллар исеңә төшә...*

*«Казан утлары»ның һәр яңа санын гастрольләргә алып чыгу гадәтебез бар иде, яңа матур әсәрләр безнең игътибарыбыздан читтә калмый торган иде.*

*Республика районнарында гастроль вакытында мәктәпләрдә, китапханәләрдә була торган идек, ул елларда укучылар арасында «Казан утлары»ның зур популярлыгын күреп шатлана торган идек. Авыл интеллигенциясе белән очрашулар вакытында журналда чыккан яңа әсәрләр, аларның авторлары турында да сүз чыга иде. Әлбәттә, ул елларда журналның тиражы да шактый зур иде. Татарстан радиосы күп еллардан бирле «Казан утлары»нда басылган әсәрләрне тыңлаучылар арасында пропагандалау буенча зур эш алып бара. Журналның яңа саннарына күзәтү, журналда чыккан әсәрләр буенча радиокомпозицияләр, һ. б. формаларда алып барыла бу эш.*

*Шәхсән минем үземә журналда дөнья күргән төп әсәрләрне радио аша башкару бәхете насыйп булды. Журнал*

гән төнем юк. Әллә каян, аксыл томанннар арасында адашып йөрисең кебек. Көндезләрен уйлап йөрим. Ни өчен кирә микән төшкә, дим. Бер-бер хәл булмадымы, минем ярдәмем кирәк түгелме дип хәсрәтләнәм. Ахры, түзмәдем, үзем эзләп киттем. Бәхеткә, теге Сәгыйтов очрады.

—Ул сина минем турыда бер нәрсә дә әйтмәдеме?

—Ни әйтсен? Аны тыңлап торырга исәбем дә юк иде. Конкрет сорауга конкрет җавап кына кирәк иде. Әллә бер-бер хәл булдымы?—Кыз, капканы ачарга җыенган җирдән туктап калды.—Баядан бирле сүзеннән ата-анасы юк, бәлки сезенүем дөрестер, ә? Бер-бер хәл булдымы?..

—Әйтә алмыйм, ни дәрәҗәдә дөрестер. Сүзләрең бик серле, әлбәттә, ак томаннарда адашу дисең бит. Без барыбыз да шундый хәлдә бугай инде. Каядыр барабыз, каядыр ашкынабыз, кая барып чыгасын күз алдына китереп тә бетермибез.

—Илгә, тоткан юлыбызга ышанмау дип аңлыйммы, үз-үзенә ышанып бетмәү дипме?

—Икесе дә бар кебек. Мин киләчәккә ышанам, тик нәрсәнедер кирәгенчә эшләмибез бугай. Шуна эчем поша кай вакытларда, уйланмыйча эшләүгә күнегеп барабыз шикелле.

—Әллә ничек сөйлисең син. Бугай... кебек... шикелле... Икелемикеле сүзләр шунда. Син дә шулай сөйләнгәч инде. Югары белем алырга җыенасын, булачак партия хезмәтчесе!

Әхмәтсафа ачыклык кертәсе итте:

—Шушы укунын хикмәтләре инде. Күп укыган саен, белмәгән нәрсәләрнең тагын да күбрәк икәненә төшенә барасың. Шикләр дә арта... Ә болай, әлбәттә, мин ышанам, илебезнен киләчәге матур булыр, тик без генә булмабыз... Оча алудан мәхрүм булсак та, гомер буе күккә, югарыга омтыла кеше. Җан таләбе—биеклек. Һәр кешедә ике мин яши. Берсе—җирнеке, икенчесе—күкнеке.

—Менә шулай, сөйли белеп сөйләгән кешене тынлап туймыйм

***мине күп әдипләребез һәм шагыйрьләребез белән, аларның яңа әсәрләре аша бәйләп тора торган матбугат чарасы ул.***

***Татар эстрада сәхнәсеннән миңа күбрәк поэзия әсәрләрен яңгыратырга туры килде. Илленче еллардан бүгенге көнгә кадәр берничә буын шагыйрьләр белән таныш булырга, әлбәттә, аларның яңа әсәрләрен «Казан утлары» битләрендә күреп алып, аларны тизрәк сәхнәдәнме, яки радио ашамы тыңлаучыларга җиткерү, башка башкаручыларныкы кебек, минем дә изге бурычым иде. Сүз сәнгате өлкәсендә ярты гасыр эшләү дәверендә күп әсәрләр укылган, радио фондында сакланган әсәрләрне, аларның авторларын гына искә төшерсәң дә, кайвакыт үзең дә гаҗәпләнеп куясың, ә бит ул фондта сакланганнары шул унъеллыклар аралыгында укылган әсәрләрнең күпмедер өлешен генә тәшкил итә. Кыскасы, минем татар поэзиясен пропагандалау эшемдә «Казан утлары» журналының ярдәме зур булды һәм мин моның өчен журнал коллективына олы рәхмәт хисләремне җиткерәсем килә.***

***Журнал аша таныш булган барлык авторларымны да санап чыгу бурычын куймадым мин бүген, алар бик күп, аларга үз вакытында актуаль, бай эчтәлекле, матур әсәрләр язганнары өчен мин шулай ук рәхмәтләремне әйтәм, ә укылган әсәрләре өчен мин авторлардан иҗат гомеремдә бихисап рәхмәт сүзләре ишеттем. Алар мине иҗат эшемдә һәрвакыт илһамландырып торучылар булдылар. Әйе, шагыйрь әсәрләре белән зур илһам ялкынында эшләгән кебек, журналда яки китапта басылган әсәрне башкаручы тыңлаучыга җиткерүдә дә үз иҗат алымнарын кулланып, үз «палитрасы»ндагы ысуллар ярдәмендә илһамланып эшләгәндә генә сәхнә яки радио өчен матур иҗат җимеше туа.***

***Соңгы елларда шигырь язучылар саны, элеккеге еллар белән чагыштырганда, күпкә артты. Нәшриятлар күбәйде, акчасы булган, бераз гына шигырь язуда сәләтле кешеләр, үзләренең мәҗмугаларын чыгаралар, гәҗитләрдә дә шигырь димәсәң, хәтере калырлык кайбер шигъри әсәрләр дөнья күрә. Ә бит мондый «җитлекмичә туган» шигырьләр яшь укучыларның зәвыгын зәгыйфь-***

мин. Каян табасың сүзләрен? «Без генә булмабыз» диюең белән генә килешәсе килми. Авызыннан жил алсын. Яшәргә язсын, яна тормыш җимешләреннән безгә дә авыз итәргә насыйп булсын.—Заһидә, егетнең беләген эләктереп алды.—Шулай да әйт әле, Әхмәтсафа, Сәгыйтов миңа ни дип әйтергә тиеш иде?

—Тиеш дип... Минем кызым бар бит. Вәгъдәләшкән кызым. Рабига исемле. Бер-беребезне яратабыз. Ышаныч дигән идек бит, минем иң нык ышанычым—шул кыз инде. Турысын әйтәм, Заһидә, син дә акыллы, чибәр кыз. Теләсә кайсы егетнең башын әйләндерерлек. Үз тиңең табылыр, һичшиксез табылыр. Синең хатны алгач, сөендем мин, күңелдә яшьлек хатирәләре уянды. Яшьлек истәлекләре беркайчан да җуелмый, уңмый икән ул.

—Сине сөендерә алу—үзе бер бәхет инде. Миңа шуңа сөенәсе генә кала,—диде үртәлгәндәй Заһидә.—Иртә уңмаган—кич уңмас, кич уңмаган—һич уңмас. Инде дөньяга ачуым да юк, беркемгә үпкәләмим дә, аңлый гына алмыйм—ни өчен шулай? Шушы якты дөньяда үз тиңемне таба алмый бәргәләнәм бит. Мин теләгән ярлар әллә кайчан парлы булып беткәннәр. Шул кадәрле берәүгә дә кирәкмим микәнни соң мин, ә?—Кыз елый иде...

—Кирәк, Заһидә, бик кирәк син. Әйтәм бит, табарсың син үз парыңны. Сабыр гына ит. Шулай килеп чыкты бит инде, нишләтәсең. Теге чакларда мин сиңа килдем, син миннән качтың. Хәзер мин шундый хәлдә. Язмыш...

—Ярый, Әхмәтсафа, үткән эшкә салават, бүген синең белән очрашу, сөйләшү дә бер юаныч булды күңелгә.—Кыз яшьле күзләрен сөртте. Ул елаудан туктарга тырышып, сөйләнүен дәвам итте.—Башка вакытларда, очрашкан чакларда дию[е]м, танымыйча да үтеп китмә, ярыймы?!. Юкса, ачуланырмын...

Заһидә җавап та көтеп тормастан, җәһәт кенә капканы ачты һәм караңгы ишек алдына кереп юк булды.

...Укулар башлангач, көннәрнең агышы үз эзенә төшкән кебек

***ләндерәләр, классик поэзия үрнәкләрен уку да соңгы вакытларда сизелерлек кими төште кебек.***

***Моннан 15-20 еллар элек авыл китапханәләрендә яхшы шигырь китапларының һәм журналларның күп укылу нәтиҗәсендә тузып бетүләрен күреп гаҗәпләнә һәм шул ук вакытта шатлана торган идек. Проза белән беркүк дәрәҗәдә шигъриятне яратып һәм бирелеп укыйлар иде!***

***Соңгы елларда авылларда еш булырга туры килми, китапханәләр хәлен белеп бетермим. Ләкин төрле җыелышларда, сессияләрдә авыл китапханәләре китап белән бик начар тәэмин ителәләр дигән сүзләрне ишетәбез. Бу хәл укучы яшьләребездә тулы канлы әдәби әсәрләр укып ләззәт алу дәрәҗәсен киметмәсме? Бу мәсьәлә күпләрне борчыйдыр дип уйлыйм.***

***Ә безнең әдәбиятыбыз сафларында сокландыргыч, тирән фикерле шигырьләр, поэмалар, балладалар язучы шагыйрьләребез, матур-матур проза әсәрләре белән укучыларын шатландырып торучы әдипләребез җитәрлек. Укучылар да ул авторларны лаеклы бәяли беләләр, аларга хөрмәтләре искиткеч зур.***

***Мин бу язмамны шагыйрь сүзләрен китереп тәмамлыйсым килә: «Әйтерлегең бар икән—әйт, кәгазь әнә алдыңда тора. Язу—рәхәт. Яза алу—көч. Язу—көрәш.***

*Йә иң бәхетле дип уйла син,*
*Йә иң бәхетсез дип уйла син,*
*Әгәр дә төннәрен уянып,*
*Шигырьләр язарга ябышсам!*

***Ә шулай да язу рәхәт, иҗат итә алу—кешеләргә хезмәт итү бәхет».***

***Хезмәт кешеләренә, үзләренең укучыларына зур хөрмәт белән караучы, гел иҗат дәрте белән януучы «Казан утлары» журналының хезмәт коллективын Олы юбилейлары белән котлап, нык сәламәтлек, ак бәхетләр, яңа иҗат үрләре теләп калам.***

булды. Әхмәтсафа, җай чыкан саен Рәбушы янына йөгерә. Ялга каршы Рабига үзе дә Казанга килеп төшә. Мондый көннәр һәр икесе өчен бәйрәмгә әверелә. Көзге кичләрнен берсендә бергәләп Таҗи Гыйззәтнен «Наемщик» драмасын карадылар. Театрны ярату аларга Шираздан йокты, ахры, һич кенә дә яна премьераларны карамый түзә алмыйлар. Бу спектакль аларны биһуш итте. Хәзер Рәбушы исенә төшсә, үзе дә сизмәстән Сәйдәш язган җырны авыз эченнән көйләп җибәрә:

Сайрар кошым, сандугачым,
Сайра иртән тан саен.
Мин дә сина кушылырмын,
Иркәм, сагынган саен.
Туган илләрдә, сөйгән җирләрдә,
Сандугач баласын очырдым һавага.
Син дә оч иреккә, шат яшә дөньяда;
Күтәреп эчегез балларны,
Шат үткәрик алдагы көннәрне.
Күтәрегез чәшкеләрне бал белән,
Үтсен гомерләр сөйгән яр белән!

Көннәр сизелми дә үтә тордылар. Язга чыккач, Бибкәй көйсезләнә башлады:

—Авылны сагынам, кайтам,—дип үкереп елаган көннәре дә күп булды. Көч-хәл белән укулар беткәнче түздереп, аны Каргалыга озаттылар. «Бу кадәр дә чибәр булса булыр икән кыз бала, бәхеткәйләрен була күрсен, сенлем,»—дип, эчтән теләкләр тели-тели озатты аны Әхмәтсафа. Нигәдер бу минутларда исенә Заһидә төшеп, күнеле сулкылдап куйды. Эзләп-эзләп тә бәхеткә ирешмәсән, җан өшеткеч бит... Шираз уку алдынгысы. Ситдыйк Айдаров, Галия Кайбицкая, Зәйни Солтанов, Сара Садыйкова кебек сәхнә йолдызлары анын теленнән дә төшми. Шундый кешеләр белән аралаша алуына сөенеп, бөтен күнелен биреп укый иде ул.

Ә 1929 елнын декабрендә, яна елны каршылаганда Әхмәтсафа белән Рабига якын дусларын җыеп, туй мәҗлесе ясадылар. Туйдан сон озак та үтмәде, Әхмәтсафаны Минзәләгә җибәрделәр. Китми чара юк иде, өлкә комитетында ачык әйттеләр: ТКУ да алган гыйлемне гамәлдә куллана алучылар гына дипломга ия булачаклар. Башта эш күрсәтегез, аннан белем турында таныклык...

...Әхмәтсафа уйларына шулкадәр бирелеп киткән иде, бүлмә ишеген дөбердәткәнгә сискәнеп китте. Бернәрсә анлыша алмый, як-ягына каранып алды. Кая Рабига, кая Бибкәй, Шираз кая! Кая килеп эләкте ул? Нинди өермә китереп ташлады аны монда? Ялгыз һәм кызганыч хәлдә тойды ул үзен. Тышта карангы төшкән, бүлмәсе дә карангы... Ул бүген Әмәкәйдән кайтып житүләрен, Минзәлә төрмәсендәге хәлләрне һәм өйгә кайтуга, Рабигага хат язарга утыруын исенә төшерде. Менә бит, бер генә җөмлә язып өлгергән килеш онытылып киткән икән: «Исәнме, сөеклем Рәбуш...» Күпме вакыт үткән сон болай мәрткә киткән сыман утыруына?..

Тагын ишек дөбердәттеләр, Әхмәтсафа каударланып урыныннан торды, барып ишекне ачты. Инде хәтерләми дә ни өчен ишекне эчтән бикләгәндер. Тиз генә хат яза да, йоклап ала, имеш. Йокларсын бар, йомышчы аны канткомга чакыра килгән иде

—Тиз килеп житегез, озакламый кинәшмә башлана!—диде дә, карангы өйалдында нәрсәгәдер абына-сөртенә чыгып чапты йомышчы агай. Бу кадәр кая ашыгалар, кая чабалар—анламассын. Бүген дөнья бетәргә җыенмыйдыр бит. Татлы уйларыннан аерганнары өчен канткомнын кинәшмә җыюдан бушамаган түрәләренә чын-чынлап ачуы килеп, Әхмәтсафа киенә башлады.

V

—Һәр авылга вәкилләр җибәрми торып, күмәк хуҗалыклар төзүне тизләтеп булмаячак,—диде кантком кинәшмәсенә ерак Семиостров волостеннан килгән фирка сәркатибе Фәйзуллин.—ВКП(б)нын волком комитеты тырыша тырышуын да... Хәлдән килгәнчә...

Сәркатип сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, Филиппов кисәк урыныннан күтәрелде һәм ярсыган тавыш белән Фәйзуллинны тынарга мәҗбүр итте:

—Хәлдән килгәнчә?!. Тырыша?!. Ни дигән сүзләр бу, иптәш Фәйзуллин?.. Волком рәисе Харисов мондамы?—Ул, акайган күзләрен кинәшмәдә утыручыларга төбәп, бер кавым тын торды.

Шинель кигән берәү акрын гына урыныннан кузгалды.

—Монда, иптәш Филиппов... Кайда булыйм инде мин....—Харисов дигәннен тавышы бик зәгыйфь иде. Әллә юлдан килеп йончыган, әллә Харисов чыннан да үшән кешеме, Әхмәтсафа үзеннән ике генә рәткә алда утырган бу кешегә кызганулы караш ташлады.

—Син, нәрсә, эчен жыя алмаган бәбкә кебек...—дип, жикеренде Филиппов.—Син дә Фәйзуллин кебек, ты-ры-шы-ып кына йөрисенме?

Харисов эндәшмәде.

—Әле ул ныгып та житмәде, иптәш Филиппов, Суыксуда кулаклар белән бәрелештә нык кына эләккәние...—Харисовны үз канаты астына алырга ашыкты Солтанов.

Филиппов, өнәми генә кантком рәисенә борылды:

—Әйе, иптәш Солтанов, әгәр дә без шулай «тырышып» кына йөрсәк, безне кулаклар берәм-берәм чүпләп бетерәчәкләр. Урман авызында, башы белән карга чумган көртлекләр кебек бит хәлебез. Башны яшереп, к... өстә тырпаеп торгач, билгеле, өшкереп кенә үтәчәк кулак өере өстән. Сабый балалар нидер майтарырга ты-ры-шып азапланалар һәм карт-корылар. Алар үз йомышлары белән дә ты-ры-шып кына ишек алдына чыгып керәләр. Ә без—коммунистлар, совет кешеләре, кулда власть, үзебез һаман урыннарда авыл хуҗалыгы артельләре төзүне суза киләбез. Болай барса... Татарстанда иң артта сөйрәлүче канткомга әйләнеп барабыз түгелме соң? Темп кирәк, темп! Мусин,—ул президиумда утыручы оештыру бүлеге башлыгына эндәште,—Семиостров волостенә кем бара вәкил булып?

Мусин кулындагы кәгазьләрне тиз-тиз актарып, шул арада сөйләнеп тә алды:

—Э-э, иптәш Филиппов, ни әле, э-э, бу волостька ин ерак авыллар керүен исәпкә алып, э-э, иптәш Филиппов, яшьрәк, белемлерәк иптәшне җибәрергә булдык, э-э...—Ул кирәкле кәгазен тапкач, сөенеченнән кычкырып ук җибәрде—Менә ул, иптәш Филиппов, бар исемлек... Өлкә вәкиле—Дәүләтьяров Әхмәтсафа, канткомнан Такташев Габдулла. Икесе дә бик грамотный, укыган иптәшләр.

—Дәүләтьяровны беләм...—диде төксе генә Филиппов.—Кстати, Әмәкәйдә әйбәт кенә эшләп кайттылар алар Шәмтиев белән. Габитов мондамы?

Габитовның нечкә тавышы ишетелде:

—Килеп житте-ек, иптәш Филиппов...

—Ничек эшләр Әмәкәйдә? Вәкилләргә тел-теш тидерерлек түгелме?

—Вәкилләр шул хәтле әйбәт эшләделәр, иптәш Филиппов,—диде Габитов. Анын ялайгалануы ачыктан-ачык сизелеп торганга, бу адәмгә Дәүләтьяров чирканып карап алды.—Кулак элементларын төбе-тамыры белән йолкып аттык авылда.

—Шуннан...Аларны җыеп алып киткәч халыкны, бутап йөрүчеләр булмадымы? Дөресен сөйлә, Габитов, утырыштагы иптәшләргә сабак булыр, әле күп авыллар кулакларны җыеп бетерә алмый иза чигә, кулагын җыйсалар, муллалары кала, аларын да аткарып бетерсәләр—

гаиләләрен сөрә алмый ты-ры-ша-лар. Сездә ничек булды?

—Шул хәтле әйбәт булды, иптәш Филиппов, оешкан төстә үтте, сөенеп бетә алмыйбыз инде менә,—диде Габитов. Мактана төшеп, өстәп тә җибәрде.—Без инде, иптәш Филиппов, кайберәүләр кебек «тырышып» тормадык, дошман элементлар аннарына да килеп өлгермәделәр.—Ул учын учка шапылдатып сугып куйды.—Кулакларны озаткач, активистлар урамга чыккан кешеләрне өйләренә кадәр нагайка белән яра-яра озаттылар. Хи-хи-хи, кулак хатыннарын өйләренә үк куып кертеп, базларына ябып куючы батыр йөрәкле активистларыбыз да бар безнең. Бүгенгә кадәр һаман базда ятты күбесе. Ие, чыгып карасыннар! Габитов ике сүләшми ул... Бүген кулак, мулла гаиләләрен авылдан сөрү комиссиясе эшен башлады. Беренче-икенче категориядән берәү дә калмады, сөреп чыгардык авылдан.

—Өченче категорияне нишләттегез?

—Ялгышлык чыкмасын дип, иптәш Филиппов, аларын да сөрдек авылдан. Әле без Минзәләгә киткәндә авыл башында исәнгерәп йөриләрие, бала-чагаларын җитәкләп. Шунда катып үлсәләр дә, авылга кире кайтару юк аларны. Ие, белсеннәр сәвит блачының ни икәнен!

—Дөрес эшлисез, Габитов!—Филиппов утырыштагыларны янә күзе белән сөзеп чыкты.—Менә кемнәрдән үрнәк алырга кирәк. Власть ул балык кебек, каты кулны ярата, тота белмәсәң кулдан шуа да чыгып китә. Шулай бит, иптәш Габитов?

—Шулай булмыймы со-он, иптәш Филиппов! Бер тоткач ычкындырмаскае инде аны... Ничек тә халыкны бәхетле тормышка тизрәк чыгарасые да бит...

Әхмәтсафа үз алларында нинди эшләр торуын бераз чамалый иде инде, Габитовның төче тавышы күңелен болгата башлады. Башкаларны көчләп бәхетле итә алуыңа ышану—җүләрлекме, әллә наданлыкмы? Икесе бергә бугай. Залда утыручылар арасыннан вәкил булып барачак Такташев фамилияле кешене күзли башлады.

Такташев... Такташ.... Күпме күзләп маташса да ул Габдулла исемле таныш булмаган кешенең кемлеген, йә исә мондамы-юкмы икәнлеген дә чамалый алмый иде. Киңәшмә күптән башланып, инде төн уртасы үтеп бара, һаман да бер сүз, бер таләп: февраль урталарына авылларны йөз процент колхозлаштырып бетерүне алга сөрә кантком. Филиппов кат-кат тәкърарлый:

—Без Тат республикада үрнәк булырга тиеш. Иптәш Разумов бездән шуны көтә дә! Минзәлә канткомында колхозга кермәгән бер генә хуҗалык калмаска тиеш. Аерым хуҗалык калса, салым-налоглар белән тәмам тезләндерергә, ихатасында каккан казык калмасын, өендә идәне белән түшәгенә кадәр сүтеп алып бетерергә! Андыйларның юлы шул—йә күмәкләшү, йә—сөрген. Партия установкасы шушы.

Ул көнне, хәер, киңәшмә таң атканда гына таралды, төнне дисән тагын да дөресрәк булыр, Әхмәтсафа күпме эзләнмәсен, Габдулла Такташевны күрә алмады. Мусиннан сорашкан иде, исе дә китмәгән хәлдә:

—Аптырама, Дәүләтьяров, ул әле килеп җитмәде. Мәскәүдә укыган егет,—диде.—Семистров волостенә кергән Суыксу авылында активистлар өчен курслар оештырган идек. Аны шунда җибәрәбез дип йөрү, нишләп тоткарлана торгандыр. Кәгазе килде, үзенең күзгә күренгәне юк. Мәскәү ашыгырга кушса да, үзендә чарланып кайткан кешеләр бер дә кабаланмыйлар әнә. Сина әле берәр атна көтәргә туры килер, канткомда кәгазь эшләре күбәеп китте, һич өлгереп булмый,—дип, зарланып та алды Мусин.—Киңәшмәдән бушанып булмый, ә Казан кәгазь сорый. Аңа кәгазь генә булсын. Иптәш Филиппов әйтмешли, без бумажки—ты букашка, с бумагой—человек! Шундый хәлләр, Дәүләтьяров монда.

* * *

Суыксуга Әхмәтсафа гыйнвар ахырында, төгәлрәге, айның егерме сигезендә чыгып китте. Юлга кузгалыр алдыннан, аны Мусин янә үз янына чакырып алды, өлкә вәкиленә сынаулы караш ташлап, бераз тын торгач, сүзне уратыбрак башлады:

—Семиостров волостеннан кайткач, Харисов белән Фәйзуллиннан сиңа холыкнамә-характеристика сорап алачакбыз. Өлкә комитетының кушуы буенча. Аеруча Комвуздан җибәрелгән вәкилләрнең эшен аерым контрольда тотарга кушылган. Сәбәбен төшенеп тә житмим, син ничек уйлыйсың, ни өчен сезгә аерым игътибар, Дәүләтьяров?—дигән булды Мусин, хәйләкәр көлемсерәп.

—Белмим шул...—диде Әхмәтсафа, аптыравын яшермичә.

—Иң куркынычы шунда шул, без сыйнфый сизгерлекне югалта барабыз. Бухаринчыларның партия үзәк комитетына ыргылуларын күргәч кенә, бераз аңга килдек. Анда да иптәш Сталин барысы хакында бәйнә-бәйнә аңлатып биргәч кенә. Хәзер инде сер түгел, Комвуз озак еллар буе Бухаринчылар оясы булып килде. Аларның һәр идеясе ТКУ да шытып, үсентеләр биреп, чәчәк атты, бәхеткә сәбәп, жимешләре өлгереп житмәде, ягъни, сезнең кебек шәкертләргә бу чир ныклап йогып, заразасы киң халык массаларына үтеп керергә өлгермәде. Без бүген синең белән суган суы сыгып утырмыйбыз, гаять мөһим нәрсә хакында бара әңгәмә. Миннән калмасын, сиңа киңәш тә, таләп тә: Комвузда колагына кереп калган бухаринчыл бер генә идея дә Минзәлә кантКомы җирләрендә борын төртеп, шытып чыгарга маташырга тиеш түгел. Ишетсен колагың, Дәүләтьяров, һәр эшең, кантком карарларына нигезләнгән булсын, үзбашка эш майтарырга уйласаң, үпкәлә. Юлың—туп-туры Минзәлә төрмәсенә! Кулакларны инде жыеп бетереп барабыз, ләкин яу тукталмаган, авылларда кулак куштаннары соңгы көрәшкә күтәрелә, алар һаман каршылык күрсәтәләр. Решительный бул, җебеп, йоклап йөрмә, хәлләр катлауланып китсә, шундук кантКомга хәбәр сал, монда без кораллы комсомол отрядлары оештыра башладык. Алар ярдәмгә килеп житәр.

Әхмәтсафа, сез сөйләгәннәр минем өчен яңалык түгел, дигәндәй, Мусинның сүзләренә артык әһәмият бирмәгәндәй тыңлады, шулай да җавап кайтармый булдыра алмады:

—Сез юкка кызасыз, иптәш Мусин. Бухарин сөйләгән нәрсәләр әле күптән түгел генә партиянең генераль линиясе иде бит.

—Сукыр тавыкка бар да бодай, Дәүләтьяров. Бухарин үзәк комитетның башын белеп әйләндерде, кәнишне. Ул «генераль линияне» яхшы беләбез. Иптәш Сталин илдә социализм нигезен салганда, вакыт һәм көч сарыф итмәү өчен, ул лыгырдыкларга әллә ни игътибар итмәде, ил ныклы адымнар белән алга бара башлагач, түземлеге төкәнде, кәнсә дә кәнис: аларга да чират житте. Аң бул, Дәүләтьяров, социализм төзелеше тамырлана барган саен, сыйнфый көрәш тә көчәя. Без бүген кулакларны кырып-себерербез себерүен, әмма болары бит аның ачыктан-ачык дошман, күзгә күренеп торганы. Әгәр дә, кулаклар бетү белән авылда сыйнфый көрәш бетте, дип, йокымсырап йөрибез икән, бигәйбә, барып чыгачакбыз. Иң авыры—яшерен дошманнар белән көрәш.

—Алары нindirәк була? Партизаннар юк бит хәзер.

—Ай-һай, Дәүләтьяров, Комвузда укуыңның поты бер тиен икән. Нәрсәгә генә өйрәттеләр соң сине, анда?

—Политэкономия...

—Күренеп тора, җирдән, тормыштан аерылгансыз. Бухаринга сезнең кебек сары томшыклы чәүкә балалары кирәк булган да инде. Яшерен дошман—кешенең аңында яткан, әле тышка бәреп чыкмаган дошманлык ул. Аның тышка бәреп чыгуын көтеп ятсак, ахыры начар булачак. Һәр өч крестьянның икесе шундый чир белән авырый. Безнең бурыч—иң яман чирләләрен аерып алып, дәвалау, барып чыкмаса, ящур эләккән мал кебек,

юк иту. Әйе, әйе, гөнаһсыз күзләреңне төбәп торма миңа, юк иту!—»Юк иту» сүзенә басым ясап кабатлады Мусин, калын кашларын җыерып.

Әхмәтсафаның аркасына салкын тир бәреп чыкты. Минзәләгә килгәннән бирле бер төрле сүзләр ишетә ул: «юк иту, тамырын корытабыз, кыру-себерү, сөргенгә олактыру.» Ул авылларда кемнәр калыр да, колхоз дигәненә кем кереп, кем эшләр, бу хакта баш ватып та торучы юк.

—Габдулла Такташев... кем була ул?—Кабатлап сорамый булдыра алмады Әхмәтсафа.

Мусин, дустанә көлеп җибәрде:

—Фамилиясе таныш тоеламы?

—Әйе шул. Кемнедер хәтерләтә.

—Һади Такташның энесе ул. Мәскәүдә укуын тәмам иткән. Абыйсы кебек үк башлы егет. Безнең бәхеткә—шигырьләр язмый икән.—Әхмәтсафаның ничектер сәерсенеп каравын күреп, ачыклык кертергә мәҗбүр булды.—Беләсеңме, Дәүләтьяров, ул шигырь язучыларга ышанып бетмим мин. Әллә ничек, җир кешеләре түгел бит алар, к... чыгарып язган белән социализм төзеп буламы? Юк! Димәк, шагыйрь-магыйрьләрнең дә совет иленә керәге шуның хәтле генә. Менә язсыннар иде алар, ничек итеп колхоз төзү фронтында Мусин дигән большевикның кан-тир түккәнен. Рәсәйне, кулга кылыч тотып, аркылыга буйга айкап чыктым мин. Минем хакта язарга тиешме алар? Тиеш! Юк, язмыйлар. Ә болай... Ниемә кирәге бар аларның?

—Сезнең кебек дөнья күргән кешегә ярап бетүләре кыен... Шагыйрьләр халык җанын җырлыйлар бит алар. Халыкның күңелендә—шагыйрьнең телендә. Аның табигате башка бит, шагыйрь һәр бөредә могҗиза, тылсым күрә...

—Төкерим мин аларның теленә, бөресенә, тылсымына. Такташның шигырьләрен укыган бар—гыйшык-мыйшык, мәхәббәт тәүбәсе, әтәч урлау, тун кайгысы...

Әхмәтсафа, тел чарлап торуның файдасы юк икәнен аңлап, чыгу ягына кузгалды. Суыксу якларын ишетеп кенә белә, таныш түгел авылда аны көтеп торучы бармы, соңга калынса, кайда барып баш төртер!.. Көн үтә тора, ашыгырга кирәк.

—Кстати,—диде Мусин, Филипповча итеп,—Такташевне мин Казанда үзем таптым. Аны Мәскәүдән Казанга, наркомпроска юллама белән җибәргәннәр иде. Мин дә кадрлар мәсьәләсендә анда сугылып чыгарга булдым. Кабул иту бүлмәсендә танышып киттек, сөйләшә торгач, тәки ризалаштырдым моны Минзәләгә килергә. Уен түгел, Мәскәү университетын тәмам иткән кешеләр минут саен юлда очрап тормыйлар. Шулай, иптәш Дәүләтъяров кадрларны бөртекләп җыябыз. Тик менә...—Мусин әйтим микән, юкмы дигәндәй бер кавым сүзсез торды, кулын кулга сугып, әйтеп салды,—ул үзе дә кулак нәселеннән бугай. Үзенең килеп күренгәне юк, язу килде өстеннән. Кулак малаена мондый җаваплы эшне тапшырып булмас кебек. Суыксуга җибәрүне әйтәм. Кадрлар житмәгәч, исемлеккә кертқән идем инде. Көтмә син аны, иң яхшысы шул булыр... Күрәсеңме, аз гына сәяси уяулык житмәү, нинди хаталар китереп чыгара.

—Такташ ничек кулак булсын?—дип, ишек катында тукталды Әхмәтсафа.—Егерменче елларда, ачлыктан качып Оренбур якларына килеп, кангырап йөрде ул. Кулак булса, рәхәтләнеп өендә ятар иде.

—Күп сүз бозау имезә, юк икән, бик әйбәт. Әмма шундый сигнал булды. Без сыйнфый мингерәүлек күрсәтергә тиеш түгел. Егетне Суыксуга җибәрмәячәкбез, мәктәптә укытсын әнә.

...Такташ белән егерме тугызынчы елның көзендә кара-каршы очрашкан иде Әхмәтсафа. Ул истматтан профессор Разумовский үткәргән консультациягә йөгерә, ә Такташ аксыл плащы кесәләренә ике кулын тыгып, шулай ук каядыр ашыга, җил-җил атлап бара иде. Кремльгә борылган почмакта маңгайга маңгай бәрелә язып очрашкач, Әхмәтсафа ирексездән, үзе дә аңышып бетмичә:

—Һади агай... Исән-саулармысыз!—дип, кычкырып исәнлек бирде. Такташ, көзнең шактый салкын көннәре булуга карамастан, юка плащтан, киң кырлы эшләпәдән иде. Яшь кенә егетнең шулай капыл каршысына килеп чыгып, үз исемен әйтеп исәнләшүенә күнеле булып, зәңгәр күзләрен балкытып җибәрде:

—Исән, кәбәм, исән әлегә... Үзенне төсмерләгән дә сыман, юк та кебек. Очрашканыбыз бардыр шикелле,—диде ул, күнелле гөлдерәп.—Әйтерсең, шушы минутта күнелендә яна шигырь юллары туа иде аның, көйләп дәвам итте.—Таныш та без, таныш түгел дә күк...

—Оренбурда... ТИНО да укыганда... Кичәләр үткәрә идек...

—Тукта, тукта, кәбәм, син бит теге, сәхнәдә баш-аркан әйләнеп безнең һушларны ала торган егет. Декламация сөйләргә дә оста иден. Да-а, менә бит ничек!..

—Әйе,—диде, сөенечен яшерә алмаган Әхмәтсафа. Инде ничә еллар үткән, шагыйрь һаман аның сәхнәдә кәмит куеп йөргәнен онытмаган икән бит.—Шул егет, Әхмәтсафа Дәүләтьяров булам мин.

—Выт-выт,—дип, бытылдап алды Такташ.—Синең фамилиян шәп икән, кәбәм, янгырый—Дәүләтьяров! Шаир булсаң, ошы фамилиян генә дә сине бер баш биеккә күтәрер иде.—Елмаеп, һаман сөйләнә бирде Такташ. Каядыр ашыгуын бөтенләй онытты да бугай. Әхмәтсафага исә, аның белән шулай сөйләшеп торуы үзе бер бәхет, консультациягә барасын исенә дә алып карамый, шагыйрьнең авызына караган да, дөньясын оныткан.—И-и, ул Оренбур хәлләре...—дип сузды Такташ, тавышындагы күнеллекне югалтмый.—Ай, андагы кызлар! Юк, андагы чын сөю белән янып сөя торган кызларны башка бер җирдә дә очратмадым мин. Гөнаһсызлар, керсез күнелләр, мәхәббәтән күкләргә аша торган садә җаннар... Берсе... аты коргыры... исемнән чыккан... арттан ияреп Ташкентка килде. Күз алдына китерә аласынмы—шаир артыннан Ташкентка?! И-и, кәбәм, бар иде яшь чаклар!..

—Заһидә исемле кыз...

—Выт-выт, Заһидә! Исемә төште. Хәзер кая микән ул кыз? Исәнметүгелме? Сагындыра бит алар хәзер. Ул чакта гына әллә ни һуш китми иде...—дип, мут елмаеп җибәрде Такташ.

—Ул Казанда.—Кызның исемен атаганда, үзенең дә йөрәге сулкылдап алды.—Медицина институтында укый хәзер.

—Аһ, чибәр кыз, тәки тарихның бар җил-давылларын җинеп, яна чор кешесе булырга омтылып яши икән бит! Ай, бәгырем, киләчәге матур, ямьле булсын иде аның. Беләсенме, мин кызларга гел бәхет кенә телим. Күнелемә җәрәхәт салганнарын да каһәрләмим.—Такташ кинәт кычкырып көлеп җибәрде.—Әле шушы көннәрдә бер хатын очрады каршыма. Чибәр, каһәр үзе, ну кулында яшь баласы бар. Ана бәхете йөзенә чыккан бу хатынның. Шуңа сокланып бара идем, туктатты бу мине: «Иптәш Һади Такташ, беләсезме бу синең кызың бит»,—дип, сабыен күрсәтә мина. Башыма шаулап кан йөгерде. Нишләмәк кирәк мондый очракта? Моныңише хәлдән чыгу юлын бер ВУЗда да өйрәтмиләр. Тыныч бул, Һади, кәбәм, тыныч бул,—дим үз-үземә. Вәзгыять катлаулы, ерып чыкмый ярамый. Ә хатын... ай эзләп йөреп, кояш тапканмыни! Йөзе-күзе балкый. Алсу иреннәре мимылдап тора, прәме, йөрәгең ярылып үләрсең. Күрәм, хатын көлми, җитди булырга азаплана. Шулай сөйләшү бара, хатын һөҗүмен дәвам итә, минем аптырап калганны чамалап алгач, бөтенләй канатланып китте. «Бу кыз туугa сез генә сәбәпче»,—ди, каһәрен. «Тукта әле,—мин әйтәм,—кәбәм, уртак балабыз тусын өчен кайбер шартлар эшләнергә тиеш бит. Без бит... Инде килеп мин әтисе икән, анасы кем була соң, матур кызның?»—дим, аптырап. Кызы чыннан да искиткеч сөйкемле. Хатын күзен дә йоммый. «Мин...»—ди. «Аңлашылмый, кәбәм,—дим,—әллә син буталасың, әллә мин бүген үзем үзем түгел,»—дигән булам. Миңа вәзгыятьтән дөрес чыга белү мөһим, аның өчен вакыт кирәк. Выт, мин шулай вакыт сузмакчы. «Нинди җүләр хатын бәйләнә мина, дип, аптырыйсыз инде, и дөрес тә эшлисез,—

ди бу.—Әмма мин дә буталмыйм,—ди чибәр ханым. Ни китеп барыр чара юк, арттан кычкырып килә башласа, нишләргә? Кругом үз кешеләр, мине танымаган песи малае да юк Казанда.—Әйе, шул, без танышлар гына, бары тик очраклы танышлар гына»,—дип, һаман көлүен белә теге хатын. Күнелгә шик керде. Дөнья булгач, булгандыр инде дигәнрәк уй йөгерде башка. Яшь чакта... Очраклы танышлык... Ай, азмы алар! Булган—беткән, дип йөрелгәннәр күпме, онтылганнары... Әнә бит, очраклы булса да, танышлар, ди. Шулай да эчкә жан керде. «Кызымның тууына сез сәбәпче!»—дип кабатлады да, мине башка аптыратмыйм дигәндәй, сөйләп китте. Хатынның моннан ике еллар элек ВУЗда укып йөргән чагы. Кияүдә. Авырга узган. Тик ятмасаң, шулай була бит ул.—Такташ көлеп жибәрде.—Выт, бу абортка жыенган, ире каршы икән, хатын үзенекен тукый.—Ул Әхмәтсафаның күкрәгенә сак кына төртеп алды.—Кыз-хатыннар шулай алар, егет, башларына бер нәстә керсә, бер ничек тә куып чыгарып булмый. Выт шул, киткән бу аборт ясату нияте белән чиратка язылырга. Акчасын да түләп куйган. Шулай йөгереп йөргәндә, очраклы гына моның кулына «Азат хатын» журналы килеп керә. Анда минем шигырь. «Мәхәббәт тәүбәсе.»

...Ярый әле сезнең песи малайлары
Ни булса да тере туалар.
Ә кешеләрнең күбесе,
Бала табудан куркып,
Корсакта чакта ук буалар.

Хатын шушы юлларга төртелеп калган да, бетте-китте, кәбәм, жиргә кадакланган кебек тик тора икән. Аяк атлап китәргә көче юк. Шуннан нишли диген? Бөтен кызыгы да шул—аборт ясатмый! Кыз туа. Айсылу. Шәп бит! Менә шылай, кәбәм, шиырьнең көче. Шунын өчен генә дә шаир булу ярый дөньяда!—дип, саубуллашырга кулын сузды Әхмәтсафага.—Югалма, егет, редакциягә кереп йөр. Хәзер мәдәни тормыш редакцияләрдә. Һәр янага фикер ишетәсең килсә, бездән читләшмә, әдипләрдән читләшмә!—Шагыйрь жавап көтмәстән, кызу атлап китеп барды.

...Мусин сүзен беткәнгә санап, Әхмәтсафага кулын сузды.

—Әйдә, күрсәт егетлек. Нинди генә хәлләр булса да, без сине ташламабыз!

Ул каударланмый гына урамга чыгып китте. Салмак кына кар ява иде, кисәк жил күтәрелеп, ул кар өермәсе уртасында калды. Бөтен өсте кар гына, хәтта куенга кар тулып, тәнен өтеп алды. Ә күңелдә теге чорның кадерле истәлеге булып Такташның соңгы сүзләре ишетелә: «Читләшмә бездән!»

«Читләшмәссен,—дип, хәсрәтле көлемсерәп куйды Әхмәтсафа.—Ничек кенә читләштерә дөнья. Әле кайчан гына Казан урамында йөри иде, хәзер менә Минзәләдә күз күрмәгән, колак ишетмәгән хәлләр эчендә кайный.»

...Суыксуда активистларга «Күмәк хужалык итүнең икътисадый нигезләре» хакында дәресләр бирә башлагач, «читләшү» дигән сүзнең асылына янә бер мәртәбә төшенде Әхмәтсафа. Белем бер нәрсә, гамәл икенче нәрсә икән. Айхенвальд түгәрәгендә алган белемнәрне монда кулланып булмый, аларга партия үзәк комитеты «дошман казынулары» дип бәя бирде, бер чара кала, ул Казаннан ук алып килгән газеталардан үзәк комитет һәм өлкә комитеты чыгарган карарларның асылын аңлаткан булып көннәр үткәрде. Фирка карарлары каршылыклы, күп тезисларын шәрехли башласаң, аларда акылга муафыйк бер нәрсә юк икәнлеге жүләр кешегә дә аңлашыладыр кебек.

Шул рәвешле, Әхмәтсафа Дәүләтьяров партия таләбе буенча, крестьяннарны ирексезләп колхозларга куып кертү тарафдары булып китте. Бер төрле уйлап, икенче төрле эшләүнең ачык мисалы иде болай гамәл кылу. Әмма, ВКП(б) үзәк комитеты карарларына каршы килүне ул башына да китерми, кантком киңәшмәсендә кабул ителгән: «Йөз

процент кумәкләштерү» шигарен тормышка ашыруны үзенең намус эше дип карый, аның үтәлүе өчен көн-төн йокламаска да әзер иде. Кызык бит адәм баласы, беренче карашка ук көлке тоелган идеяләрне туктаусыз кабатлый торгач, Әхмәтсафа аларга тәмам ышана, алар белән агуланып, чынны ялганнан аера алмый башлады.

Ул көннәрдә йокы аз эләкте ана...

* * *

Әйе, үзәкләргә үтә икән ул йокысызлык... Дәресләр, аннан волком йомышлары белән йөгерү, бетмәс-төкәнмәс кинәшмә, җыелышлар... Өлкә комитет вәкиле буларак ул берсеннән дә калырга тиеш түгел, һәркайсында чыгыш ясарга кирәк, канткомга тиешле информация биреп бару да аның өстендә.

Менә бүген дә дәресләр тәмамланып, урамга чыгуга, шундый арыганын тойды ул. Суыксу урамында этле җан да юк. Ул авыр адымнар белән фатирга таба атлады. Көн төшкә авышып килә. Авыл буйлап үткәндә, күптән түгел генә нардомга әйләндерелгән мәчеткә күзе төшеп, йөрәге кымырҗып куйды. Элекке елларда бу вакытта мәчет тирәсендә илаһи җанлылык сизелер иде; инде өйлә намазына азан әйтелгән, мәчет картлары намазга гына йөри торган кыска кунычлы каталарын аякларына элеп, урам уртасыннан вәкарь кыяфәттә, әмма аерым бер ашкыну белән мәчет ягына юл алырлар иде. Хәзер мәчет үзгәртеп корылып, нардом, ягъни халык йорты дип атала. Яшьләр, барысы да түгел, әлбәттә, үзләрен комсомол ди атаучы сугышчан, аяусыз төркем мәчет бинасында һәркөн диярлек кичәләр үткәрәләр, китапханә оештырып җибәргәннәр. Әнә китапханәче егет үзе дә мәчеттән килеп чыкты. Төшке ашка кайтып килергә чамалый торгандыр инде, муенын бишмәт якасы эченә җыерып яшергән, шикләнеп, як-ягына каранды һәм ишекне бикләргә җыена башлады. Килүенә йозагына кемдер тизәк сылап куячак. Егет берничә мәртәбә бу хакта кантком вәкиленә җалу белән килде, саклап та торган булдылар, әмма, көндез булмаса, төнлә, кич яшьләр таралгач, йозакка мул гына итеп шушы «нигъмәтне» сылап китәләр иде. Суыкта шакырдап каткан нәмәрсә белән беркемнең дә мәшәләнәсе килми, комсомол ячейкасы секретаре сукрана-сукрана үзе ачып биргән йозакны өченче көнне. Китапханә мөдире: «Бу хәшәп эш тукталмаса, янадан мәчет ягына борылып та карамыйм,»—дип, ясканган булды да бит. Кая барсын, авылның ин хәерче кешеләреннән берсе ул, ни җире юк, үзенең йорты исә: «бүген аумасам, иртәгә чамалый башлармын, ахры», дип кенә тора. Егет телгә-сүзгә шәп булса да, кулыннан әнә шул йозак белән булышудан башка бер дә эш килер сыман түгел. Ә үзе башлы күренә, Казанга укырга китәм, белем алам, хөкүмәт кешесе булам дип, адарынып йөри. Үз хуҗалыгында тәртип урнаштыра алмаган, үз йортының түбәсен кирәгенчә ябып куярга хәленнән килмәгән кешедән нинди хөкүмәт кешесе чыгар, бер Алла белә...

Арыткан иде. Фатирга кайтып керүгә, ашык-пошык чишенде дә, урын өстенә тәгәрәде. Ул кантком тарафыннан ин зур волостьларның берсе булган, җирле халык атап йөрткәнчә—Семиастрауга вәкил итеп билгеләнде. Авылның татарча исеме—Өшәр[1]. Суыксуда ачылган курсларда сабак бирүне авылларга чыгу белән алыштырып алып барырга туры килә. Волостьта утыз биш авыл бар. Һәркайсында булырга, хәлне контрольдә тотарга туры килә.

—Кара як,—диде бу төбәк хакында Мусин, аны озатканда.—Эш ягыннан әйтмим, тырыш. Дөнья көтүнең рәтен белгән, мул тормышлы

[1]Хәзер Актаныш районына керүче авыллар хакында сүз бара. Бу авылларның кайберләре, мәсәлән, Өшәр дә, Кама сусаклагычы төзелгәч юкка чыкканнар.

халык яши иде монда элгәре. Совет чорында күбесенең көймәсе комга терәлде.—Мусин масайган рәвештә, күкрәген алга чыгарды.—Күрсәттек без аларга ничек мул тормышта яшәргә икәнен. Ояларын туздырдык! Хи-хи... Менә шуна да карангы як дип атыйбыз хәзер ул якны. Советка бик тә каршы төбәк ул. Гомер-гомергә үз кануннары белән яшәгән халык. Бүрек ыргытып кына җинешле түгел. Охшатмасалар, дин әһелләрен дә куып кына җибәрә торган як. Шуңа күрә дини яктан бик көчле, укымышлы һәм бер нәрсә алдына да җебеп-калтырап төшми торган хәзрәт-муллалар җыелган иде бу тирәгә.

—Табигый сайланыш...—диде көлемсерәп Әхмәтсафа. Бу сүзне еш һәм яратып куллана иде ул.

Мусин ялт ана карап алды. Йөзе житдиләнде, суырылып калды. Инде ничә мәртәбә искәртте, әйбәт кенә сөйләшеп торган жирдән, Казан студенты кинәт кенә ул бик үк аңлап бетмәгән телгә күчеп, гәп куерта башлый. Үзенең белемле, зиһенле булуын күрсәтергә тырышамы?.. Бу хәл аның ачуын китерә иде.

—Нинди нәмәрсә ул «сайланыш» дигәнең?

—Тимирязев дигән академикның хезмәтләрендә укыдым мин аны. Дарвин дигән инглиз галиме булган. Ул жир йөзендәге һәр жан иясе шушы табигый сайланыш нәтижәсендә эволюция, ягъни үсеш-үзгәреш кичерә дигән. Шартларга яраклаша алган жан иясе исән кала, яраклаша алмаса—һәлак була. Көчлеләр генә яшәргә хокуклы. Хәзрәтләр дә шулай яшәп, тернәкләнеп калганнар, димәк, бирелә.

—Хәзер ул якларда хәзрәтләр калмады дисән дә була,—диде эчке горурлык белән Мусин.—Җыеп бетереп барабыз. Шулай да Суыксуда сак бул, анда усал, явыз халык яши. Гомер-гомергә җыен сугыш чукмары, алаканат-зимагурлар ягы.

Әхмәтсафа монда килгәч, шуна төшенде: Суыксуга карата әйтелгән сүзләрне һәр авылга төбәп әйтергә булыр иде. Ниндидер үҗәт, үчлекле кешеләр. Бер-берсен сатарга да күп сорамыйлар. Сәбәбе хакында сораша башласаң, әллә кайчангы хәлләрне искә төшерәләр. «Ярый әле бу якларда тау халыкларындагы кебек кан үче булмаган, күрсәтерләр иде алар бер-берсенә хикмәтләрне!»—дип, көрсенеп, уйланган чаклары да булгалады. Ә менә берәрсенә авырлык килсә, мир белән җыелышып, хәзер күтәрелеп чыгарга әзер булулары тагын да гажәп иде. Аерым-аерым бер-берсен өнәмиләр, хәтта күралмыйлар, шул ук вакытта сәер оешканлык белән аерылып торалар.

Әхмәтсафа болай озаклап аунап ята алмасын аңлап, тиз-тиз генә капкалап алды да, жаны тынгысызланып, көндәлегенә үрелде. Соңгы елларда көндәлек язып барырга һәвәсләнгән иде ул, тик Рәбүш белән өйләнешкәннән соң көндәлек язуга игътибары кимегән иде, Минзәләдә, колхозлар оештырып йөргән көннәрнең ядкаре булыр дип, кичә Чалманарат авылында күргән кичергәннәрне кыскача гына теркәп куярга булды.

«Егерме бишенче февраль, утызынчы ел...—дип язды да уйга калды. Күз алдыннан алдагы көннең вакыйгалары йөгерешеп үтте.

Иртәнге жиледә Чалманаратка кузгалды алар. Авыл советы рәисе ат белән олаучы жибәргән иде. Үткер егет, комсомолец икән. Юл буе теләсә нәрсә такылдап барып, авылга ничек килеп житүен дә абайламый калды.

Совет йортына барып керү белән, активны җыеп алдылар. Тугызлап кеше. Колхоз төзү хакында һәркайсының үз карашы, үз тәкъдиме. Бер агай, мескен бүреген әвәләп, урынында таптана-таптана үзенекен тукый.

—Ибдәш кем, вәкилетдин, теге ни әле аты коргыры, ие, шул инде, күмхужга каршы түгел бед,—ди ул, күзләрен нигәдер идәнгә төбәп.—Түлкем дә, манау бөтенебед бер журган астына кереп жоклау дигәненә катыннарны бер дә ырыйдалаштырып булыр кебек сыман тоелмый, ие, вәкилетдин, ибдәш. Мин кичәгенәк тә шуның өчен күмхужга каршы тештем. Ушы сорауга дөрес жавап ишетмәенчә, хәл кылып булмас кебек сыман тоела. Иеме, ибдәш вәкилетдин.

Ибрай агай, сиңа сүләргә куш инде,—дип, авыл советы рәисе йөзен чытып куйды.—Каян алдың шул бер журган асты дигән сүдне. Тукыйм, тукыйм, һич башыңа кермәсә, керми икән.

—Син, ибдәш рәис, әтәчләнмә алай, вәкилетдин ибдәш китәр дә барыр ул. Аңа ике дөньҗа бер моржа, сала саен бер маржа, дигәндәй, сиңа беднең белән каласы...—диде Ибрай, саллы йодрыгын тун кесәсеннән чыгарып.—Синең тукыган синең тукыган ул, синдәге грамота гына беднен үдебеддә дә бар ул, бигрәк кыдыл булып бетәсең кайвакытларда, менә ибдәш вәкилетдин әйтеп карасын. Ул сүләгән рас кебек сыман тоела бедгә.

Әхмәтсафа аңламаган кыяфәттә, рәискә караш салды.

—Нинди уртак юрган? Бу хакта сөйләшүләр булмадымыни соң?—диде ул ачулана төшеп.—«Һаман төсе уңып беткән жыр жырлап маташалар икән Чалманаратта»—дип, кайтып әйтсәм, тавыклар көләчәк Минзәләдә. Бу ялганнар мең мәртәбә фаш ителде бит инде. Кулак жыры. Кулак коткысы!

Рәис башын боргалап, гөнаһсыз тавыш белән сүзгә керешге.

—Әйтмәгән кая да, аңлатмаган кая, иптәш Дәүләтьяров. Кеше башын әйләндерергә туган инде ул Ибрай агай. Аңлаттым—бернинди юрган асты да, юрган өсте дә юк, дидем. Өйгә, өй жиһазларына тимибез, комиссия төзеп, һәркемнең мал-мөлкәтен исәпкә алабыз, аннан соң, хәл кылырбыз, дидем. Ашыкмый, кабаланмый...

—Киресен сүлисең, ибдәш рәис,—дип, аңа каршы төште Ибрай абзый.—Кичә әйттең, тид тотарга, вулычта кумхужны беренче итеп төдеп бетерәбед диден. Хәдер ни сүлисең? Аннан шуны төшендереп бир әле, ибдәш вәкилетдин, менә беднең рәис әйтә: төдибед дә бетерәбед, ди. Тыңлап кына тор әле син, иеме. Уйлап-уйлап куям да, бер дә хут алып китәр төсле күренми кебек сымак тоела кумхуж дигәннәре. Төдибед дә, бетерәбед дә дип яскангач ни... Бу мәләкәдән ни генә калыр соң, шымытыр башымы? Шуңа аптыраш...

Жыелган халык көлешеп алды.

Әхмәтсафа һаман сабырлыгын жуймыйча, башында баядан бирле бөтерелгән уйларын әйтергә булды:

—Үзегез актив дип аталасыз, үзегез ниләр генә сөйләмисез? Мондый актив белән, белмим, колхоз төзеп булыр микән?

Рәис, йодрык белән өстәлгә китереп сукты.

—Була, иптәш Дәүләтьяров! Авылда бер контрны калдырмаячакбыз. И без аны калдырмадык дисәң дә ярый, жыеп бетереп барабыз. Алга табан да шулай булачак: кем кумәк хужалык төзүгә каршы, авылдан сөреләчәк. Ибрайның сүзенә карамагыз, ул гражданнар сугышы партизаны, авылда беренче совет төзегән кеше, колхоз турында сүз кузгалгач кына, сөртенә менә. Хәлле, таза хужалык алып бара, үз малыннан колак кагасы килми, шунсы жәл аңа.

Ибрай, ниһаять, житди сөйләшә башлады.

—Шул шул, ибдәш вәкилетдин, совет өчен кан койганда бед кирәк булдык. Карап-карап торам да, кумхужга бед артык. Беднең мөлкәт кирәк, үдебед кирәкмәй булып чыга. Сүдебедгә колак салучы да юктыр кебек сымак тоела. Әүвәл өйгә кереп, баш астына салып яткан мендәрләрне, кетәклектәге тавыкларга кадәр санап чыктылар, халык шикләнә башлады. Төрле сүд китте, чыш-пыш. Бед, совет членнары, аңлата алмайбыд, чөнки үдебедгә жүнле-башлы аңлатучы юк. Рәис ибдәш дөрес әйтте, авылда укымышлы кешеләр бар иде, жыеп алып китеп бетерделәр. Хәзер жыен әтрәк-әләм, ура кычкырып йөрергә өйрәнгән кешеләр генә калды авылда. Укымышлы кеше бетсә авылда, иң белдекле кеше хатын-кыд булып кала икән ул. Беднең хатыннар көн-төн жылайлар, бер журган астына жаткырып адәм мәсхәрәсенә әйләндермәкчеләр икән дип дулайлар. Бед монда утырабыз, хатыннар абыйстай янында «белем» арттыралар, гайбәт тараталар, сүд жөртәләр, итәк астыннан ут жөгертәләр. Менә бит ул, ничек.

Әхмәтсафа активка кумәкләштерү хакында тулы бер дәрес биргәч, авыл буйлап, һәр хуҗалыкның малын, мөлкәтен барлап чыктылар. Шунда күрде инде ул кешеләрнең бер-берсенә сәер мөнәсәбәтен.

Бер кешеләрнең малларын язган чакта, бер адәм шыпырт кына килеп:

—Ибдәш вәкил, жукка мескенләнә бу Шәрип дигән кеше, аның би-ик шәп биясе бар, күрше авылындагы киявендә тота. Тегенең үткән көд аты үлде, бу шуңа шылдырды атын. Кем әйтте дисәләр, үдем белде диген, биясен өстәп жадып куй, алып кайтсын Шәриптән биясен, кумхужга тапшырсын!

Ибрайның мөлкәтен исәпкә алганда, икенче бер активист чыш-пыш килде:

—Һи-и, аның трантасыннан жилләр искән икән бит, ишек алдында гына тота иде. Бер дигән трантасын жәшергән, шельма. Кормаштагы кызына илтеп куйгандыр инде. Тагын кашка тае күренми. Төртеп куй, иптәш вәкил. Бар ул аның, бар, яшереп маташа, мыкыр. Таптырырга кирәк барысын да!..

Советка кайтып, һәр хужалыктан ни-нәрсәне кумәкләштерү мәсьәләсен хәл иткәндә, Әхмәтсафа исемлектән шундый «яшерелгән» милекне дә әйтеп бара башлагач, башта шаулашып алганнар иде, аннан тындылар, аңлап алдылар булса кирәк, монда кемнең-кемне сатканын тикшереп утырасы юк, бу «барлауга» һәркем үзенең өлешен керткән иде.

Ибрай гына, ачу белән:

—Ил күденнән жәшерен эш булмас, барысын да теркәгән икән, каһәр,—дип куйды. Аңа каршы дәшүче булмады, бер-берсенең күзенә күтәрелеп карарга да кыймый иделәр бугай. Милек барлау караңгы төшеп, кичке сәгать жиделәрдә генә бетте.

Актив утырышы кичке унынчы яртыга кадәр сузылды. Капкалап алырга өлгермәделәр, тагын халык жыйнала башлады. Көн тәртибендә —ярлылар жыелышын үткәрү каралган иде.

Әхмәтсафа һәркемгә аңлаешлы булсынга тырышып, авылда кумәк хужалык төзү тәртибе хакында аңлатырга кереште.

Әмма аны шунда ук бүлдерделәр:

—Апай, энекәш, бедгә бу хакта суган суы сатма син. Үден, үд күдләрең белән берәр кумхужны күргәнең бармы? Ни майтаралар алар анда?—дигәнрәк сораулар яудырырга керештеләр.

—Күргәнем бар,—диде Әхмәтсафа тавышланучыларны тәртипкә чакыргандай, кулын өскә күтәрә төшеп.—Мин үзем Оренбур ягыннан, Татар Каргалысы дигән авылдан...

—Жәһәннәмнән икән...—диде кемдер.—Соң, апай, седдә дала, кумхуж булса ни, аерым булсагыд ни, ике чабата бер кием, жангыр бирсә Ходайиген уңа, ад гына корырак булса—басуыгыд көеп бетә. Гомерегез ач даланы жырмачлап үтә инде шунда. Безнең туфраккайларны белсәң син, апай. Тәгәрмәч кумсәң, трантас үсеп чыга бит. Шушы алтынга биргесед жиркәйне теләсә нинди әтрәк-әләмгә ышанып тапшыр инде?! Белер-белмәс жиргә тотынсаң, жирнең хәдер көе югала бит аның, апай. Уйлап караганың бармы, бу жиркәйләрдән ни калыр, әгәр дә ки теләсә кем кулына жир тапшыра башласаң?

—Аптырама, Шәрип абзый,—дип бүлдерде аны рәис,—сине жир өчен жаваплы итеп куярбыз. Агротехник дип атала ул вазыйфа йөкләнгән кеше.

—Анысын куярсыд, куюын,—диде абзый, һаман бирешәсе килми.—Вадыйфасы булса, кешесен табарсыд аның. Бер эт жалкавы жирне мыскыл итеп, бәрәкәтен жибәреп жөрсен, аның өчен мин жавап бирергәме? Жук инде, бигайбә. Аннан мин кумхужга ике ат, шыңгырдап торган бүрәнәдән өч келәт бирәм, ди. Шулай жадып куйгансыд, әнәтерәк. Минем күрше—жангыд баштан дөнжа көтүче Бакый корткасы да кумәкләшеп жөрмәкче. Ихатасында бер шырпы салам кисәге жук, эскәк

белән эдләсән дә табам димә. Минем өйдә айгыр хәтле ике жегет, пләмәннәй үгед урынына жөк тарта алар, кирәк булса. Бакый корткасының тилебәрән ашаган малаеннан ни көтмәк кирәк?

Халык көлешә, шаулаша башлаган иде, алгы рәттә утырган хатын сикереп торып, чәр-чәр килә башлады:

—Мыскыл итмә, Шәрип тәресе, туйдым шул мыскылларыңнан, илаһым. Минем Бакыем шушы совет өчен башын салды, улым Рәхмәтуллам җәтим-җилпе үсмәсә, синең айгырларыңнан кәм булмасые, әле дә, Аллага шөкер, үд көчебед белән көн күрдек. Курыкмыйм, теләсә ни әйт, мин кумәк хуҗалыкка керәм. Күрербез, бергә-бергә эшли башлагач, кемнең айгыр, кемнең алаша икәнен...

Халык тагын гөр килде, тагын әйткәләшү, әрепләшү китте. Авылдагы ярлыларны барлап, аларның бер-берсен сүз-тел белән рәнҗетүләрен тынлап утыра торгач, төнге уникe житте.

Көне буе чабып арыган рәиснең башы әледән-әле бер якка кәнкәеп ала. Ләкин әле эш тәмамланмаган. Ярлылар җыелышы тәмамланугa, гомуми җыелыш башлануы хәбәр ителде. Килгән һәр кеше совет йортына кереп тула торганга, инде тын алу кыенлаша иде, ишекне ачып, бүлмәне җилләтеп алырга булдылар. Сулыш алу иркенәйде, баш бераз җиңеләйде кебек. Әмма бу озакка бармады, халык:

—Суык керә, ябыгыз ишекне, катырып үтерергә җыйдыгызмы безне?!—дип, шаулаша башлады.

Җыелыш әрепләшү-анлату рәвешендә иртәнге өчкә кадәр барды. Ник бер кеше: «Җитәр, булды!»—дип сөрән салсын да, ник бер кеше кайтыр якка кузгалсын. Тәмам арып беткәч, ниһаять, уртак фикергә килеп, «кумәк хуҗалык» төзергә дигән карар чыгарылды. Халык көне буе, төне буе үз-үзе, гаиләсе белән дә, күрше-күлән, таныш-белеш белән дә киеренке бәхәстә-тартышта иде, шуңа күрә күзләрдән йокы качкан. Авыл тормышында, һәркайсы язмышында иң мөһим мәсьәлә—җирне, милекне кумәкләштерү мәсьәләсе хәл ителгәндә ничек күзенә йокы керсен дә, ничек бәхәсләшмисен? Йокысызлыктан исәнгерәгән кебек күренсәләр дә, монда һәркем уяу, һәркем зиһенен тулы куәткә эшләтә иде...

...Менә хәзер Әхмәтсафа Дәүләтьяров шушы көннәрнең кайнар сулышын көндәлегенә теркәп куймакчы булып утыра. Бу вакыйгалар хакында еллар үткәч кем дә булса кызыксынырмы, әллә искә дә алмасмы, анысы киләчәк эше. Әхмәтсафа, тәне кызышуын тойды. Йокысыз төннәр, туктаусыз авылларда йөрү сәламәтлеген какшата, җегәр кими иде. Вакыт бар чагында, тагын кемдер килеп, кайдадыр алып киткәнче ял итеп алырга кирәк. Тиз-тиз генә көндәлегенә көн вакыйгаларын чагылдырган түбәндәге сүзләрне сызгалап куйды: «Бишенче февраль, 1930 ел. Иртәгә жиде сәгатькә Чалманаратка. Иртән актив белән сөйләшү. Иртән тугыздан кич җидегә кадәр опись. Җиде сәгать ярымнан тугыз сәгать ярымга кадәр актив җыелышы. Төнге уникедән иртәнге өчкә кадәр гомуми җыелыш.

Ник бер кеше китсен. Бары да кадаклаган кебек, ябышып ята.»

Шушы сүзләрне язып куйгач, Әхмәтсафа урынына барып ауды һәм саташулы йокыга талды. Үзен һаман Чалманаратта хис итә ул. Күз алдында әле Ибрайның чиләк кадәр авыр йодрыгы чагылып китә, Шәрипнең ачулы йөзе шәйләнә, Бакый хатынының чәр-чәр тавышы колакта яңгырап, баш миләрен калак белән тишкәләгәндәй итә. Гәүдә әле һавага күтәрелә, әле бәргәләнә-бәргәләнә упкынга оча. Шушы сирәк эләккән йокыда килеш тә Әхмәтсафаның аны кумәк хуҗалык «төзү» белән мәшгуль иде...

* * *

Эшләр көйле генә киткән кебек иде. Авыл кешеләре туктаусыз басым астында кумәк хужалыкларга кереп беттеләр. Җиң сызганып язгы чәчүгә хәзерлек башлап җибәрделәр. Беренче эш һәм иң әһәмиятлесе дә шул—колхоз фондын булдыру зарур иде. Гомуми амбарга чүчүлек орлык, фураж салына башлады, хужалыклар, күп үгетләрдән соң, сабан-сукасын, тырма ише кирәк- яракларын пай взносы тәртибендә колхозга тапшырдылар. Колхоз милке күзгә күренеп арта иде. Колхоз терлеге дә ишәйде. Атлар мәҗбүри колхозга бирелде, колхозчы кулында бер генә ат та калмады, һәр хужалыкта бер генә сыер калдырылды, умарталар тулысы белән колхоз милкенә күчте. Хужалыклардагы амбар, келәт-сарай ише корылмаларны сүтеп, колхоз дворына китереп өю башланды. Кыскасы, Әхмәтсафа туккән тирнең әрәмгә китмәвенә сөенеп йөри иде бу көннәрдә. Әмма көйле эшнең көе китте. Сәбәпчесе... Сталин, тагын да дөресләп әйткәндә, аның исеменнән чыккан мәкалә иде.

«Правда» газетасының икенче март саны әле Әхмәтсафаның кулына килеп эләккәнче үк Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү»мәкаләләсе хакында авыллар гөж килә башлады. Мәкаләне Фәйзуллин белән икәүләп, аның бүлмәсендә бикләнеп укып чыктылар. Башлар шаулый, күз алдында утлар биеште. Сталин колхозлаштырудагы бөгелешләрне күрсәтеп, бөтен гаепне урындагы житәкчеләр өстенә аударып куйган иде. Һәр башбаштаклык өчен урындагы партия-совет житәкчеләре җаваплы! Акка кара белән язып куелган бу сүзләр авылдагы һәр кешегә билгеле инде, авыл умарта күче сыман гөжли. Урамнан тыныч кына үтеп китешле түгел, ир-ат халкы юлдан үтәргә бирми, мәкаләдә язылганнарны, үзләре аңларга теләгәнчә төшендерүне таләп итеп, янаулар башланды. Киеренке хәлдән чыгу юллары хакында уйларга кирәк иде.

—Әллә ничек булып китте,—диде Фәйзуллин, такыр итеп кырдырган башын кашып.—Кыш буе без иптәш Сталинның: «Колхозлаштыруда темпны киметмәскә, кумәкләштерүне утызынчы елның көзенә төгәлләргә!»—дигән генераль курсәтмәсен үтәү өчен тире ерттык түгелме соң? Кумәкләштерүдә социалистик ярыш тәртибен кем хуплады, йөкләмәләрне кем раслады, рапортны без кемгә юлладык? Боларның башында үзәк комитет тормадымыни?!

—Кызма әле, иптәш Фәйзуллин,—дип, аны бүлдерде Әхмәтсафа.—Һәрхәлдә без үзәк комитет директиваларын да, өлкә комитет күрсәтмәләрен дә бозмадык. Аларны мин биш бармагым кебек яхшы беләм. Төн уртасында уятып сорасалар да...

—Болай булса, төн уртасына барып житмәвебез дә бар.—Фәйзуллин йөзен чытып, читкә борылды.—Авылларда ни барганын бер Ходай үзе белә. Иртәгә үк колхозлар таралачак, әнә кая барма, каршыга килеп жырлап торган булалар: колхуд тары ала микән, колхуд кад ала микән, дип.. Жыен тиле-миле көлә бездән. Канткомнан да бер хәбәр юк, телен тешләде Филиппов. Теге чакта барысы да батыр, барысы да гаярь иде. Хәзер су каптылар, авызларына печ итим.

—Ашыгып нәтижә чыгару хата булыр иде. Без әле гәжитнен шушы санында ук басылган крестьян хужалыкларының Үрнәк Уставын яхшылап өйрәнмәдек. Бераз күз салып чыгуга ук аңларга була, үзәк комитет крестьяннның мөмкинлеген, холык-халәтен истә тотарга тырыша. Өлкә комитет, кантком шуларны өйрәнеп, акыл аша уткәрергә омтыла. Ашыгып эш итүнен жимешләрен татыдык инде. Күп өлкәләрдә крестьяннар чуалышлары булып үтте әнә. Хәтәр хәлләр булуы хакында төрле хәбәрләр ишетелә.

—Бездә дә озак йөрмәс, халык бик кыжырый. Сыер дуласа, аттан яман, ди. Сина рәхәт, син жүләр, дигәндәй, син бит, иптәш Дәүләтъяров, вакытлы кеше монда. Казанына китәрсен дә барырсын, ә безгә бу кызган таба өстендә нишләргә кала?

—Беренчедән, кемнен кайчан, кайда китүе фирка кулында. Икебез дә фирка әгъзасы. Икенчедән, паникага бирелмик. Әгәр без дә шулай сөйлибез икән, башкаларга нишләргә кала? Әйткәнемчә, без мәкаләне яхшылап өйрәнмәдек әле, өстән фикер йөртәбез. Иптәш Сталин темпка бәйләнми, аны хуплавын белдерә. Егерменче февральгә илле процент коллективлаштыруны унай яктан бәяли. Унышларны ныгытырга чакыра. Бу ни дигән сүз? Димәк, безнең хезмәт бушка китмәгән. Танырга кирәк, кайбер бөгелешләр булды, тизрәк рапорт бирик дип, акланмаган гамәлләр дә кылынды. Бигрәк тә авылдан кулак гаиләләрен сөргән чакта. Исенә генә төшер, Кормаштан Нурлыгаян дигән кешене сөргән чакта, ана карата гадел була алдыкмы? Жиде баласын урамга куып чыгарып, йортын советка тартып алдык. Ач-ялангач, йортсыз калдылар бит. Авыл халкы бәддога укыды безгә. Ишетмәгәнгә сабыштык. Андыйлар күпме жыела ил буенча?.. Шулай шул, без борын төбендәген күреп бетерә алмыйбыз, иптәш Сталин ил күләмендә уйлый, масштаблы фикер йөртә.

—Ничек ишетмәдек?—дип, гажәпләнеп сорады Фәйзуллин.—Директива буенча без Нурлый гаиләсен авылдан ук сөрергә тиеш идек. Шулаймы? Сөрдекме авылдан? Юк! Нурлыйның бертуганында сыену тапты алар. Без күрмәмешкә салыштык. Дошман элементларын төбе-тамыры белән йолкып атмаганга, авыллар кайный хәзер. Иптәш Сталин белеп яза торгандыр, анысына шигем юк, әмма анлашылып житми—күмәкләшү ирекле дә булсын, бөгелешләр дә булмасын, шул ук вакытта партиянен: көзгә кадәр коллективлаштыруны төгәлләргә, дигән күрсәтмәсе үтәлсен. Үз акылында булган крестьян өч атын, сука-сабанын, мал-мөлкәтен төяп: «Мине колхозга алсагыз сана!»—дип, килерме безнен каршыга? Мәнге килмәячәк! Кормаш Нурлыйга килсәк, ул үзе гаепле. Совет кылган һәр гамәлгә каршы төшеп, комсомоллар белән бәйләнешеп, канга тоз салып ятты ул.

—Миндә башка информация бар. Кантком вәкиле Маловка Нурлы-гаян абзыйның айгыры охшаган. Шуны тартып аласы килгән икән. Шәп айгыр, туры айгыр... Синен дә күзен төшкән диләр ана.

Фәйзуллин жилләнеп, сикереп торды.

—Сон, алай бик барысын да белгәч, өстән жалу яз, канткомга рисвай ит. Күнелен күкәй салыр, Нурлыйны да кире кайтарт. Малов белән туры айгыр хакында бәхәс булып алды булуын. Ну, аны нигә сөйләп йөрергә. Атны Маловка волком решениесе белән бирдек.

—Аны кире кайтарып булмый инде,—диде Әхмәтсафа ачуы килеп.—Башбаштаклыкка юл куймаска иде. Малов дигән адәмне күргән юк әле.

—Белемен күтәрергә китте ул, жәйгә кайтып житә. Кыю егет, шундый егетләр житми безгә, тотса сындыра торган. Жәл, атын алып китте Минзәләгә. Менә хәзер кирәк булды ул, барасы жиренә сәгать эчендә барып житәсен, арттан жил генә сызгырып кала. Ә син беләсенме, иптәш Дәүләтъяров, Кормаш халкынын нинди явыз, усал икәнен? Әйтеп кенә «и»гә килә торган халык түгел ул. Нурлый гел үзенекен генә тукыды, бөтен халык анын авызына карап тора, анын сүзе генә сүз иде. Менә бит ул ничек?! Һәр эшкә аяк чалып жәфалагач, башкаларга сабак булсын дип эшләнгән эш. И шулай булды да. Бераз артлары басылды. Шулай инде, эшләмәгән кеше генә ялгышмый. Әле алда ниләр күрергә язган... Аннары, шунсы да бар бит әле, без сине үзебезнен мөгаллимгә санийбыз. Сез нәрсә ди торган идегез? «Жәмгыятьне тамырдан үзгәртеп корганда, аерым бер кешенен күргәннәре чүлдәге ком бөртеге дәрәжәсендә генә булып кала, исәпкә бар, санга юк.»—диярргә ярата идегез. Шулай булгач, кайдадыр Кормаш дигән бер авылда бала-чага үрчетеп яткан Нурлый исемле кешене авылдан сөрү социализм төзү эшенә тап булып төшә аламы? Юк, төшми!

—Горький сүзләрен мин бераз үзгәртә төшеп кабатлаган идем...

—Шунда шул хикмәт, Горький дөрес әйткән!

...Вакыйгалар көттермәде. Икенче көнне үк волость башкарма

комитетына һәр авылдан махсус сайлап җибәрелгән кешеләр килә башлады. Һәркайсының кулында күмәк хуҗалыкка халыкның көчләп кертелүе хакында фактлар язылган кәгазь. Таләпләр охшаш—колхозларны таратырга, мәчетне мәхәллә халкына кайтарырга, мал-туарны, мөлкәтне хуҗаларына кире өләшергә! Ул арада идарә йортына Иске Кормаштан гөрс тонып комсомоллар Газиз, Әбүш, Алатыр Мәрфуш килеп керделәр. Кыш көне дә кызыл яулыгын башыннан салмаган Мәрфуш, чая яшь хатын, волостьта хатын-кызлар арасында иң активы, чибәрлеккә чибәр булса да, бу минутларда тәмам төсен җуйган иде, ана якын килергә, сүз кушарга куркыныч, йодрыгын өскә күтәреп, авызыннан күбек чәчә башлады:

—Башларын себер җибәреп бетерәсе калган икән, иптәш вәкил, авыл контрлар кулында! Тиз арада Минзәләдән гаскәр чакыртырга кирәк!— Ул сүзен әйтеп бетермәстән башыннан яулыгын тартып алып, почмактагы чиләккә капланып, голт-голт су эчә башлады. Бераз тынычлана төшеп, күзләрен алартып, як-ягына карап алды. Өлкә вәкиленең сүз башларга ашыкмавын күреп, янә чәчрәп, аның каршына килеп басты.—Контрлар активистларны чебен урынына кырып бетергәнче, чарасын күреп калыйк, иптәш Дәүләтьяров. Көч-хәл белән качып котылдык. Мәчетне клуб иткән идек, сөреп кенә чыгардылар безне, әле укытучы Әхәт Сәфәргалин белән ячейка секретаре Фатыйх Уразаев кайда йөри торганнардыр?.. Аларга бигрәк каныктылар, тотып, бәкегә салабыз, дип котырыналар.

Әхмәтсафа югалып калуын белдермәскә тырышып, җай гына сораша башлады.

—Нәрсәдән риза түгел халык? Нинди таләп куялар? Ни өчен егетләргә каныгалар?

—Һы, әстәгекәем, болай итеп утыра башласак!—Мәрфуш ишек төбендәге бүкәнне тибеп аударды.—Этем белгәнме аларның ни-нәрсә таләп итүләрен! Гәҗит укып котыралар. Иң беренче гәҗитне кем алып кайткан авылга, шуны судка бирергә кирәк! «Көчләп колхозга керттегез, җавапка тартабыз»,—дип, тузына халык. Картлар мәчет алдына җыелып тәкъбир әйтәләр, халык амбарларны ачып, ашлыкны талап алып бетерде, озаклап, меж-меж килеп, сорау-җавап кичәсе үткәреп утырсак, монда да килеп житәр алар. Тир түгеп төзегән колхозкаебыздан көл генә калды...—Мәрфуш үкереп елап җибәрде.

Башка авыллардан да шундый хәбәрләр килеп иреште. Мона Байсар, Әмәкәй, Мөслим волостьлары да кырмыска оясыдай кайный дигән хәбәр килеп өстәлде. Чыннан да, хәлләр хөрти, озаклап уйларга вакыт юк, шул ук вакытта эшне нәрсәдән башларга икәнен дә белеп бетереп булмый. Элекке кебек, гадәткә кергән кул каеру, боргычлау, көчләү сәясәтен эшкә җигү шикләндерә—иптәш Сталин ни дияр? Бәхеткә, канткомнан: тиз арада волость активын җыярга; икешәрләп бүленеп, авылларга таралырга, ярсыган халыкны тынычландырырга, гәҗиттә язылганнарны «дөресләп» аңлату эшен җәелдерергә, дигән фәрман килеп төште. Кирәк очракта кораллы комсомол отрядын чакырып, хәбәр җибәрергә боерылган иде. Урындагы хәлләр өчен җаваплы итеп өлкә комитеты Әхмәтсафа Дәүләтьяров билгеләнүе дә күрсәтелгән.

Әхмәтсафа беренче чиратта чамадан тыш тынгысызланган авылларга активистларны җибәрү ягын кайгыртты. Иске Кормашка—«Үрнәк» колхозына Фәйзуллин белән Дәүләтьяров, үзе киләчәк иде, тагын ике кеше—Мари Суыксуында укытучы булып эшләүче үтә актив Миляев Морзагали белән комсомол әгъзасы Бусарин дигән егет ерактагы Күҗәкә авылына бүген үк кузгалырга тиеш дип табылды. Башка активистлар да иртәгәге көнгә үзләре билгеләнгән авылларда булырга кирәклеге искәртелде. Колхозларны тараттырмау, мөмкин булганча мөлкәтне саклап калу бурычы куелды. Шуның белән утырыш тәмамланды, Әхмәтсафа белән Фәйзуллин юлга җыена башладылар. Аларга авылдан качып чыккан комсомоллар да иярде.

...Яз аеның ямьле көне иде бу. Әхмәтсафа төшлектән авышкан

язгы кояшка күтәрелеп карады да, Оренбурда укыган елларын искә төшереп, күнеле кыбырсып куйды. Әле якында гына кебек, инде күпме сулар аккан, җилләр искән ул көннәрдән. Язгы бер көнне шулай Каргалыга җыелып кайтканнар иде алар. Арада Муса да бар иде. Юл буе шаярып-көлеп, әллә нинди эшләр майтарырга хыялланып, гәпләшеп чакрымнарны үткәнне сизми дә калганнар иде. Кич авыл яшьләре белән уеннар оештырдылар. Әйе, бар иде күнелле чаклар. Ул елларның авырлыклары онытыла бара, әйтерсең, ачлык, ин якын кешеләрне югалтулар булмаган да, барысы да ал да гөл генә үтеп киткән кебек, шаулап торган яшьлек елларының якты мизгелләре хәтергә теркәлеп, тирән уелып калган...

Иске Кормашка ярты юлны үтеп барганда, каршыларына томырылып чабучы атлы күренде. Ат тотучы агай юртакны тыя төшеп, юл читенәрәк каерды. Каршыга килүче алар белән тигезләшә башлагач, көч-хәл белән атын туктатты. Волость агрономы Осипов булып чыкты ул. Аты туктап җитмәстән, чанасыннан кар өстенә сикереп төште һәм куркынган тавыш белән ашыга-ашыга сөйләнә башлады:

—Иптәшләр, кире борылыгыз! Башыгыз ике булмаса, хәзер үк волостька ычкыныгыз! Гаскәрсез кереп булмый авылга, дулаган халык, кулларында күсәк тә сәнәк. Мин көч-хәл белән качып котылдым...

Әхмәтсафа үзе дә, юлдашлары да чанадан юлга сибелделәр, Осиповны урап алып, авылда нинди хәлләр булганын җентекләп сораша башладылар.

—Син каян анда барып чыктың?—диде, Әхмәтсафа гаҗәпләнгән кебек.—Җыелышта да булмадың...

—Харисов җибәрде мине Кормашка. Иртүк, халык анга килгәнче җыелыш үткәреп, колхоз милкен саклауны оештыруны йөкләгән иде. Сакларсың бар, авыл кешесе волостьтан мин килгәнне көтеп ята ди ул. Авылда бер актив калмаган,—ул ачу белән Мәрфушка карап алды.—Менә болар бик харап йөриләр иде дә көннәр тыныч чакта, кирәкләре чыккач, табып алырмын димә...

—Шулай даниләр кыра алдың?

Осипов аты-юлы белән сүгенде.

—Бар, кырырсың син анда! Идарәгә килеп туктау белән чанадан өстерәп кенә төшерделәр. Баш бетте инде дигән идем. Халыкка бер дә начарлык кылмавымны искә алып, мин нәрсә, гомерем буе крестьянны җир эшенә өйрәткән кеше, бераз тәпәләп алдылар да, келәткә ябып тоттылар. Ярый әле, атка тимәгәннәр. Өйлә намазыннан соң, картлар акылга килеп, кайтарып җибәрделәр менә.—Агрономның ике күзеннән сыпылып яшь чыкты.—Өемә исән-имин кайтып булмас инде дигән идем, насыйп булгач...

Осиповны кире борырга маташу файдасыз иде, аны кайтарып җибәреп, юлны дәвам иттеләр. Комсомоллар да шинеп, бер авыз сөйләшми баралар. Кузгалып киткәч тә, бик батыр кыланып, бөтен контрны минут эчендә авылдан сөрү хакында җилкәнеп кайталар иде. Мәрфушына кадәр тынып калды.

...Аларны авыл кырыенда унлап ир каршы алды. Кулларында күсәк. Волость вәкилләрен күргәч, юлны бүлеп, тезелеп бастылар. Ат тотучы агай атын туктата башлаган иде, Әхмәтсафа кесәсеннән наган тартып чыгарып, агайның җилкәсенә нык кына кагылып алды:

—Абзый, каушама! Мин ат алдына чыгам, арттан басып барсын атың... Без әйткәнне генә үтә, чамала аны!—Өлкә вәкиленнән калышасы килми, аның артыннан Фәйзуллин да иярде. Яшьләр чанада калдылар.

Гайрәтләнеп басып торган ирләр, каршыларына наган тотып килеп чыккан ике адәмне күргәч, югалыбрак калдылар шикелле. Шау-шу тынды, әмма шундук үзләрен кулга алдылар, арадан берсе алгарак чыгып, вәкилләргә бер артын, бер алдын күрсәтә-күрсәтә чинаган тавыш белән җырлап җибәрде. Кыюлык өчен моңа бераз әче бал эчергәннәр иде, ахры. Башкалар аны хуплап, аны куәтләп тордылар. Теге, тиле дигән саен, тигәнәк буе

сикерүче адәм иде булса кирәк, аның саен шамакайлана, инде Әхмәтсафа белән Фәйзуллин алдына ук килеп жырлый. Кызып китеп, хәтта аптырабрак торган Фәйзуллинның кулындагы наганына да үрелә башлады. Моны күргәч, авыл ирләре ихахайлап, аяусыз көлеп жибәрделәр. Алар, исләренә килеп, бернәрсәдән дә курыкмагандай тоталар иде үзләрен.

Жыр башлаган адәм торган саен шаша, тиләрә:

Ват, жимер коймасын,
Жул өстендә тормасын!
Бедне көчләп кара йөдләр
Калхуд-малхуд кормасын!

Сталинны төштә күрдем —
Гел кыдылга үрелә.
Колхуд дигән нәмәкәйнең
Шәрә к... күренә.

Биек тауның башларында
Ленин т... утыра.
Сталины исәр икән —
Кесәсенә тутыра.

Әхмәтсафа тыныч булырга тырышып, алларында шамакайланган жырчы адәмне, читкә этәрә төшеп, алга атлады. Юл өстендә торган ирләр, кулына наган тотып, тәвәккәл адым белән үзләренә табан килгән кешенең Казан вәкиле Дәүләтъяров икәнен беләләр иде инде. Колхоз төзегән чакта ничә мәртәбә генә Кормашка килеп жыелыш уздырмады да, колхозга керергә үгетләмәде ул. Күпчелек халык шуның сабыр, акыллы сүзләре аркасында гына керде дә инде кумәк хужалыкка. Менә хәзер ни әйтер ул?

Ирләрнең үзенә юл саба башлауларын күреп, эченә жылы йөгерде.

—Клубка барабыз туганнар, жыелышыйк, сөйләшик,—диде ул, булдыра алганча, тыныч тавыш белән. Бер кусәкләргә ым кагып, бер кулындагы наганга керфек кагып сүзен дәвам итте.—Боларны эшкә жиксәк, чамалыйсыздыр инде, ерак китә алмабыз...—Ирләр кусәкләрен кысып тоткан килеш, шаулашашаулаша Әхмәтсафага иярделәр.

Монарчы клуб хезмәтен үтәгән мәчетне инде яшьләр кулын-

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ

## «QAZAN UTLARI»NA 80 YIL

**Fərit İdelle,**

*«Azatlıq» radiosının tatar-başqort redaksiəse citəkçese*

### 90 YILLIĞIN DA BERGƏLƏP ÜTKƏRERGƏ NASİP İTSEN



***Zamanalar nindi tiz ütə. Əytersen lə əle kiçə genə Qazanda «Qazan utları» jurnalının 70 yıllığın qotlarğa cıılğan idek. Xalıq şığrım tulğan zalda kemnər genə çığış yasamadılar, kemnər genə nindi genə büləklər birmədelər, kemnər genə nindi izge teləklər beldermədelər. Un yıl uzdı da kitte. Yana ğasırğa da ayaq bastıq. «Qazan utları» jurnalı da siksən yəşen bilgeləp ütərgə cına. Bu olug yubiley, əlbəttə, zurlap qotlanır. Niçek kenə əytmə, tatar ədəbiatının, mədəniətenen kəzgese bulğan bu jurnal millətebeznen uzğan ğasırdağı qatmarlı tarixında zur rol' uynadı. Ana telebez, milli mədəniətebez qısrıqlanğan çorlarda da ul, qulınnan kilgənçə, mona qarşılıq kürsətte, saqçı rolen uynadı.***

***Minem şəxsən «Qazan utları» jurnalı belən berençe mərtəbə tanışuım, anı qulğa alıp qarawım 1969 yılda, «Azatlıq» radiosında eşli başlağaç buldı. Mona çaqlı Tatarstan yəisə Başqortstanda basılıp çıqqan ğazet-jurnal kürgənem, qulğa***

нан тартып алганнар икән, клуб дигән нәрсә калмаган авылда. Мәктәп итеп үзгәртеп корылган Нурлыгаян дигән кешенең зур өенә жыела башлады халык. Өй эче тиз тулды халык белән, инде ишек алды ерып чыккысыз, әллә тагын якын-тирә авыллардан да килә тора кеше.

Өстәлне түргә үк күчереп, президиум сыман нәрсә әмәлләп, утырышырга өлгермәделәр, халык өстәл тирәсенә ябырылды. Һәркайсының кулында колхоздан чыгулары турында гариза. Өстәл өстендә минут эчендә кәгазь өеме пәйда булды. Өй эченә керә алмаганнар шаулаша-кычкырыша, гаризаларын башкалар аша тапшыралар, кәгазьнең вәкилләр кулына килеп керүен белергә тырышып, шау-шу кубаралар иде.

Көн кичкә авышканда гаризаларны жыеп бетереп, көч-хәл белән халыкны тынычландырып, жыелыш үткәрә башладылар. Идарә әгъзалары алгы рәттә идәнгә чүмәшкән. Фәйзуллин кычкырып гариза укый тора, тегеләр хәлсез, битараф тавыш белән: «Чыксын, чыксын...»—дип, авылдашларын кумәк хужалыктан чыгара торалар. Ярты төн житеп килгәндә, «Үрнәк» колхозында барлыгы унбер хужалык калды. Халык таралыша башлады. Инде эш бетеп килгәндә, кинәт ишек каерылып ачылып китте, аяусыз тавышланып кулларына күсәк тоткан берничә ир килеп керделәр. Берсе алгарак үтеп, ачык итеп, кычкыра башлады:

—Әгәр дә мәгәр, халыкны колхозга көчләп кертkән мөгаллим Әхәт Сәфәргалин белән мәчетне клубка әйләндергән денсез Фатыйх Уразаевны тотып бирмәсәгез, моннан исән-имин чыгу юк сезгә!

Фәйзуллин кулына наган тотып, өстәл артыннан сикереп торган иде, кемдер түшәмгә асылган лампаны күсәк белән бәреп төшерде. Өй эче дөм караңгы. Әхмәтсафани дип уйларга белми калды, башына күсәк белән китереп ордылар. Бәхетенә, бүреген киеп өлгергән иде һәм күсәк туп-туры түгел, аның башына эләккәнче, кемгәдер тиеп, бераз сугу көчен киметкән иде. Бер генә мизгел исәнгерәп, почмакка табан елыша төште. Шул мәлдә үк

*alğanım yuq ide. Jurnalnı qulıma alğaç, yөrәgemne qarşılıqlı xislәr sızlattı. Qarşılıqlı xislәr düuemnen sәbәbe şunda: ber yaqtan Tatarstanda basılıp çıqqan jurnalnı berençe mәrtәbә qulğa aluım sәbәple tuğan nindider ber sөyeneç, izge xis. İkençe yaqtan ul tatarça bulsa da, kiril xәreflәre belәn yazılğanlıqtan, niçekter yat bulıp toyıldı, çөnk ul waqıtqaça min ğәrәp yәki latin xәreflәre belәn genә yazılğan tatarça tekstlar kürgәn idem. Başta qıyınraq bulsa da, waqıt ütü belәn kirilça yazılğan tekstlarnı da uqırğa künektem. Menә şul 69 yıldan alıp bügengәçә «Qazan utları» jurnalı minem nindider ber dәrәcәdә ayırılmaslıq iptәşem buldı. Әlbәttә, 69 yıldan birle zur sәyәsi üzgәreşlәr jurnalnın eçtәlegendә dә çağıldı. Torğınlıq yıllarında «Qazan utları» tuğan telebezne, әdәbiatıbıznı, mәdәniәtebezne, üzanıbıznı saqlawğa zur өleş kertkәn ide. Gorbaçov çorında isә ul, tuğan mөmkinleklәrdәn faydalanıp, sovet çorında tıyılğan әsәrlәrne millәttәşlәrebezgә citkerü, dini qağidәlәrebezne tanınttıru, şulay uq, milli anını uyatu өçen armıytalmıy tırıştı. Tuqsanınçı yıllarda isә Tatarstannın suverenlığın yaqlaw, tuğan telebezne saflandıru, kөndәlek tormışta rolen üsterü өçen zur ğәyrәt sarıf itte.*

*«Qazan utları» turında sөylәgәndә anda basılıp çıqqan ber әsәrne ayıruça iskә alırğa telim. Ul da bulsa Flüs Latıyfının «İşelep tөşkәn bәxet» romanı. 1999 yılda anı «Qazan utları»nda uqığaç mindә «Ğailәbeznen yazmışın çağıldırğan roman» digәn tә'sir qalğan ide. Şunda uq anın fotokopiәsen çığarıp, Amerikada yәşәwçe, ul çaqta әle isәn bulğan әtiemә һәm әniemә cibәrdem. Alar romannı alğaç uq ber tәwlek eçendә uqıp çıqqannar da şunduq mina şaltıratıp üz tәessәrәtlәre belәn urtaqlaştılar. Avtorğa rәxmәtlәren belderüemne soradılar. Min bu*

уйлап та өлгерде, әгәр дә хәзер үк йорттан чыгып өлгермәсәләр, аларның җәсадларын гына алырга киләчәкләр волостьтан иртәгәсе көнне...

Ул наганын чыгарып, түшәмгә атып җибәрде, болай да шау-шу иде, инде бөтенләй мәхшәр купты: кемдер җүләрләнгән шикелле кычкыра, кемдер чиный башлады. Әхмәтсафа өстәлне күтәреп, бүлмә уртасына ыргытты. Янәшәсендә Фәйзуллинны чамалап, аның җилкәсеннән умырып тотты да, тәрәзәгә табан өстерәп, әллә нинди ят тавыш белән:

—Миннән калма!—диде. Шул унайда тәрәзә өлгесен тибеп ватты, тышка сикерде. Ишек алдында ниндидер күләгәләр йөгереште, ул көне буе халык таптап бозга әйләнгән сукмак өстенә дык итеп килеп төшүгә, мәтәлеп китте, тагын бер мәртәбә, чамалап, һавага атты. Өстеннән таптап диярлек Фәйзуллин йөгереп үтте. Ул да берничә мәртәбә наганнан гөрселдәтте. Нигәдер, алар артыннан берәү дә тышка сикермәде. Ишек алдында да кеше-фәлән күренми. Күсәк тотып наганга каршы һичкемнең бергә-бер чыгасы килми иде, ахры. Әхмәтсафа, ирексездән, башын югары күтәреп карады. Анда ана табан шыксыз елмаеп, ай карап тора иде...

Волость үзәгенә таң атканда кайтып керделәр. Алар артыннан Күҗәкәгә киткән Миляев белән Бусарин кайтып төштеләр. Миляев башын яулык белән бәйләгән, яулыктан кан саркып тора. Аларны да Күҗәкәдән тукмап җибәргәннәр, болары көч-хәл белән качып котылуларына, исән кайтып җитүләренә сөенеп бетә алмый утыралар.

Икенче көнне Иске Өшәрдә халыкның советка буйсынмавы, алай гына да түгел, беренче категория белән авылдан сөрелгән Габдулла Арсланов дигән кешенең гаиләсен яклап, хатынын, балаларын авылдан чыгарып җибәрттермәү өчен чын-чынлап көрәшкә күтәрелүе турында хәбәр килеп иреште. Әгәр тиз арада чара күрелмәсә, монда кан коелачак тек коелачак иде. Иртән бераз черем итеп алырга өлгергән Әхмәтсафа Дәүләтъяров эшләрнең зурга китүен чамалап,

*üteneçne Rimzil Wəligə citkerdem. Ul beznen əmanətne ütəgən: ətiəniemnen rəxmətləren ul waqıtta xastaxanədə yatqan Flüs əfəndegə citkergən.*

*Əlbəttə, jurnalnın yünəleşen anın baş məxərrire bilgeli. «"Qazan utları» jurnalının millətebez yazmışındağı role turında səyləgəndə, anın baş məxərrire Rawil Fəyzullinnın mona kertkən eleşen də onıtırğa yaramıy. Rawil əfəndenen tuğan telebez, ədəbiatıbız həm millət yazmışı turında qayğırtuın hər oçraşuda bik nıq sizdem. Bu «Qazan utları»n uqığan hərkemgə məğlümder. Andıy zıyalılarıbız, idealistlarıbız kübrək bulsın dip əytəsem kilə.*

*«Qazan utları»nın 80 yıllıq yubileye unayınnan jurnalnın baş məxərrirenə, anın barça xezmətkərlərenə, yanadan kire qayta başlağan qıyın çorda, tatar millətenə anın mədəniətenə zur eleş kertüləren dəwam ittersennər digən teləktə qalam. Allahı Təğələ «"Qazan utları»n 90 yıllığı belən tağın irkenrək, bəysezrək moxitta bergələp qotlarğa nasıyp itsen. Tatar millətenen də, «Qazan utları»nın da yalqını berwaqıtta da sünməsen! Mənge dərləsen!*

*20 mart 2002 yıl.*

*Praga.*

кораллы ярдәм сорап, Минзәләгә кеше жибәрде. Миляевны чакырып китертте, ана авылдагы комсомоллардан отряд тупларга, корал табарга йөкләнде. Көн уртасына кадәр киеренке оештыру эшләре белән мәшгуль булды, тамак ялгап алырга утырган иде, волость идарәсенә кош тоткандай Миляев атылып килеп керде.

—Фәрман үтәлде, иптәш вәкил,—диде ул кирә-керешкә кычкырып.— Отряд сезнең карамакта!

Әхмәтсафа өстенә шинелен бөркәнеп, ишек алдына чыкты. Идарә каршында аркаларына ау мылтыклары аскан ун егет һәм бер хатын кыз. Хатын-кыз дигәне Кормаштан Мәрфуш иде. Ул инде авылына кайту хакында уйламый да, совет өчен жанын да бирергә әзер булып йөри. Хәер, аны авылга кертмиләр дә, авылдашларының канына шактый тоз салырга өлгергән, күзләренә күренсә, хәзер тукмап ташлаячак аны халык.

Әхмәтсафаның күңеле күтәрелде. Баш сызлавы басылды кебек хәтта. Отрядтагылар атка атланганнар, әмер генә көтеп торган сыман. Ул тиз генә идарәгә кереп, киенеп чыкты да, отряд башында Иске Өшәргә юл тотты. Уйга ирек кенә бир, гаярь егетләре белән Каргалыга килеп кергән Шамил Усманов исенә төшеп, көлемсерәп куйды. Хәлләр тагын катлауланып китте бит менә, инде совет хакимияте тәмам жинеп, моның өше отрядлар кирәклеге башка да килмәгән чакта, мә, күрмәсәң күр, дигәндәй, тагын коралга тотынырга туры килә. Крестьянның күңел түренә үк кереп утырган милекчелек психологиясен кайчан да булса тулысынча жинеп булырмы?.. Ичмаса, Шамил Усманов чын бөркеттәй егетләргә баш иде, анда хәрби тәртип, сыналган, тәжрибәле сугышчылар иде аның отрядында. Ә ул кемнәр белән контрга каршы бара? Ихахайлап кычкырып йөргән Мәрфушларны жыеп...

Иске Өшәрдә хәлләр чыннан да житди иде. Авылга килгән өч ГПУ кешесе чарасыз калган. Совет Габдулла Арслановның хатынын балалары белән мунчага сөреп чыгарган булган. Аларны авылдан куарга ГПУ килүен сизенгән халык, дәррәү күтәрелеп, мунчаны камап алган да, ана беркемне дә якын жибәрми. Бигрәк тә авыл хатыннары чая кылана. Кулларында сәнәк. Алар мунчаны әйләндереп, камап алган. Читтәрәк жыелып торган ирләр күсәкләр, иске ау мылтыклары белән коралланганнар. Берничә урында имән казыкларны очларын өскә каратып «кәжә»ләр ясап куйганнар. Алар янында ирләр сакта тора, якын килеп кара!

Әхмәтсафа килгән унайга ирләр белән сөйләшмәкче булган иде, аларга якынлашырга өлгермәде, шартлап мылтык атылды. Баш очыннан гына жәдрәләр сызгырып үтте. Үзе дә сизмәстән жиргә чүкте. Әйләнеп караса, ат өстендәге отряд жиргә сибелгән, кымшанмый да яталар. «Болар белән яуга чыксан...» Әхмәтсафаның күңеленә килгән хәсрәтле уй, аны айнытып жибәрде, ул тиз генә калкынып, тагын ирләргә каршы китте. Ирләр чигә төшеп, сагаеп аны каршы алдылар. Шактый дәшми, карашып торгач, өлкә вәкиле ни өчен килүләрен аңлатырга тотынды. Каршылык күрсәтүнең файдасыз нәрсә икәнен төшендерергә керешкән иде, мунча янындагы хатыннар разбой салып, кычкырырга тотындылар:

—Үтерәләр, нәрсә карап торасыз, безгә мылтык төзиләр! Нәрсә карап тора бу ирләр? Үтерәләр!—Чыннан да ГПУ гаскәриләре мылтыкларын алга сузып, мунчага якынлашып киләләр иде.

Хатыннар отыры кычкыралар, разбой салалар иде:

—Нәмә карап каттыгыз?—Бусы ирләренә төбәп атылган сорау иде.— Күрмисез мени, итәк астына кереп, бөтен жирне актарырга маташалар солдатлар! Коткарыгыз, талыйлар, көчлиләр!

Минут эчендә барысы буталды. Авыл ирләре хатыннарының кыздырулына түзә алмый, отряд өстенә ташландылар. Туктаусыз кычкырыш, мылтык тавышлары астында отряд авыл читенә чигенергә мәжбүр булды.

Кичкә табан Минзәләдән кырык сигез кешелек кораллы комсомоллар килеп кенә, Габдулла Арслановның хатынын авылдан алып чыгып, Минзәлә төрмәсенә алып киттеләр. Әхмәтсафа үз өстенә Ходай да, бәндә дә кичермәячәк янә бер гөнаһ алды...

Әхмәтсафага исә Минзәләгә кайтып китү насыйп булмады. Отряд командиры аңа кантком күрсәтмәсен житкерде: Әмәкәй волостена кергән авылларда күпләп колхоздан чыгу башланган. Хәлне урынга барып тикшерүне һәм колхозларны таралып бетүдән саклап калырлык кичекмәс чаралар күрүне оештыруны өлкә комитеты вәкиле буларак, аңа йөкләгәннәр иде. Әхмәтсафага ярдәмгә ун кешелек коралы жайдак бирелде, ул шул ук көнне умарта күче кебек тузгыган бу төбәкне калдырып, юлга кузгалды. Өшәр тирәсендәге авылларда кантком карары үтәлеп, шактый кешене төрмәгә озату һич тә совет властенең яңа тормыш төзү юлында аерым казаныш, жиңү дип саналырлык нәрсә булмавын тоя башлаган Әхмәтсафаны күнелсез уйлар биләп алды. Мондый аяусызлык белән халыкны сыйнфый катламнарга аерып, акыллы, гаярь дип саналган һәркемне читкә сөрә башласак кемнәр калыр авылларда, колхозларны кемнәр белән төзерләр, советны нинди кадрлар белән нытырга—менә шушы гап-гади сорауларга жавап таба алмый иде ул. Юкса, аның хәлендәге кешегә сөенергә генә кирәк, шушы өч-дүрт көн эчендә генә дә әле менә үзе язмышлары өчен борчылып барган «акыллы һәм гаярь» адәмнәр аны ничә мәртәбә теге дөньяга озата яздылар. Ничек исән калгандыр—берьяктан, үзенең үтә сак, икенче яктан, кыю һәм тәвәккәл адымнары каршы көчләрне иң кирәк мизгелдә каушатып калдырдымы, әллә Рабиганың саф, керсез күнелдән теләгән изге теләкләреме, боларын аңлау-аңлатудан гажиз иде ул. Белгәне шул—һәр ике яктан кирәкмәгән кан коела, тиешсез гамәлләр кылына. Шушы вакыйгаларның уртасында ул—Дәүләтъяров кайный. Ул бу казанны ташлап чыгып та китә алмый, анда бер генә минутка каласы да килми. Тик моны кемгә әйтергә? Кемгә аңлатырга һәм моны кем дә булса тынлап, зиһененә сеңдереп торырга теләк белдерерме? Ай-һай. Бүгенге көндә колхозлашу хәрәкәтен тизләтү максаты белән адарынган бер генә кеше дә тын алырга тукталып, болар хакында ныклап уйланасы, баш ватасы килмәс. Алга, алга, жиңү арты жиңү, үр арты үр яуларга чакырулар... Нииндидер иблис бөтен илне, дөньясын алга куалый да куалый, тын алырга да ирек бирми иде.

Бу көннәрдә кичерешләр, тетрәнүләр күп булды, әмма хикмәтле хәлләр алда икән. Төнне Байсарда үткәрү нияте белән совет йортына якынлашып килгәндә, аны коралы солдатлар туктаттылар. Тикшерү, сорашу китте. Баксаң, инде ике-өч көн бу якларда солдатлар ияртеп өлкә комитеты вәкиле Сәгыйтов дигән кеше йөри икән. Дәүләтьяров батыраеп совет йортына үтмәкче иде, өйалды тулы хатын-кыз күреп тукталып калды. Алар коралы кешене күргән унайга куркышып, түр стена янына сылаштылар. Үзләре мышкылдап елашалар да иде.

—Ни хикмәт монда?—дип сорады ул үзен озатып кергән солдаттан.—Бу хатыннар ни эш кыралар монда?—Өшәрдәге хәлләрдән соң ул хатын-кыз затыннан шүрли дә төшкән иде.

Солдат артык жәелмичә:

—Вәкил иптәш чакыртты аларны,—дип, өй ишеген ачып жибәрде. Тупсаны атлап кергәнче үк Әхмәтсафаның йөзенә кызу һава бөркелде. Лампа яктысында күн пәлтә кигән берәү кәперәеп йөренә, үзе өй уртасына баскан чәчләре-башлары тузгыган ике хатынга карап туктаусыз жикеренә иде:

—Сук, сук, жәлләмичә сук, ул сине жәлләп тормады бит, ә? Катырак тамыз, катырак дим!

Әхмәтсафаның абайлап алганы шул булды: хатыннарның кулында кыска таяк, алар «сук» дигән саен, бер-берсен кизәнгән булып кыланалар, һич кенә дә ныклап сугарга кыймыйлар иде.

Бу кешенең тавышы бик таныш иде. Әхмәтсафа ныклап танып өлгергәнче, теге кеше ишектән тартынусыз килеп керүчеләргә кисәк адым ясап, шып туктап калды. Әхмәтсафа аның кулындагы наганның нәкъ үзенә төбәлгәнен генә чамалап өлгерде.

—Үзебезнекеләр!—Солдат аңлашылмаучылык килеп чыкмасын диптер инде, кисәтүне кирәк тапты.

—Кемнәр ул «үзебезнекеләр»?

Әхмәтсафа каршысындагы кара тут йөзле, күзләре калайланып янган, авыз читләреннән күбек бәреп чыккан кешенен Фатыйх Сәгыйтов икәнен танып өлгергән иде инде, жинел сулап:

—Мин әле бу, Дәүләтьяров...—диде.

Сәгыйтов баштарак аптырап калса да, үзен тиз кулга алды

—Нинди жилләр ташлады сине монда?—диде ул.

—Өлкә комитеты вәкиле итеп жибәрделәр. Колхоз төзү эшләре буенча.

—Төзисез пычагым,—дип, ачу белән кычкырып жибәрде Сәгыйтов.—Аның хәл-әхвәл сорашып, сөйләшеп торасы килмәгәне сизелә иде.—Менә ничек төзиләр ул колхозны!—дип әйткән унайга хатыннарның өлкәнрәгенә аяк тибеп кычкыра-кычкыра, өстенә килә башлады.—Нәрсә бәбәгенне киереп торасың? Сук дим мин сина, сук ахирәт абыстаена! Колхозны таратырга өндәгән чакта кыланган сыман, жәһәт бул!

Хатынның йөзеннән тир катыш яшь ага иде, сулкылдый-сулкылдый Сәгыйтовка ялына башлады:

—Нишләп мин кеше котыртыйм ди? Жә инде. Кеше кайгыларымы миндә, иремне төрмәнгә алып киттеләр, өйдән куып чыгардылар, балаларым ач, ялангач, кеше абзарларында кунып йөрибез. Зинһарлар өчен жәфаламагыз ла...—Ул күз яшьләренә буылып, Сәгыйтовка табан бер адым атларга өлгермәде, өйне наган тавышы яңгыратты. Хатыннар гына түгел, монарчы ишек төбендә утырган адәм дә идәнгә лапылдап аудылар.

—Базда катырып үтерәм мин сине, хәшәрәт!—дип Сәгыйтов өй базын ачарга азаплана башлады.

Болай карап тору мөмкин түгел иде, Әхмәтсафа шактый кискен итеп Сәгыйтовка эндәште:

—Житте, Фатыйх! Нәрсә кыланасың, понимаешь, кем сина рөхсәт бирде халык белән болай эш итәргә? Хәзер үк кайтарып жибәр бу хатыннарны!

Сәгыйтов калтырана-калтырана әле генә кесәсенә салып куйган наганын кармалый башлады. Әмма Әхмәтсафаның да кулында наган күреп, нигәдер чүгә төште.

—Син нәрсә-ә, Дәүләтьяров, миннән үч алырга килденме монда? Элеккеләрне искә төшерәсенме? Унай вакыт таптың... Мина боерык бирергә кем әле син ул хәтле?

—Беренчедән,синең кебек үк өлкә комитеты вәкиле, икенчедән партиянен кантком работнигы. Менә син үзең ничек килеп чыктың монда, кем жибәрде?

—Партия жибәрде!—дип кәпрәеп маташса да, инде Сәгыйтовның кикриге шиңгән иде. Ул арыган тавыш белән хатыннарга эндәште.—Аунамагыз, анагызны...—Аяк өстенә күтәрелгән адәмгә әмер бирде.—Олактыр боларны, күзем күрмәсен.—Аннан Әхмәтсафага борылды.—Синең белән дә сөйләшербез... Мин ал-ял белми таралып беткән колхозларны кире жыеп, укмаштырып йөрим, син өлкә комитеты мандатын калкан итеп, астан ут өертәсең икән. Аңлашылды...—диде ул, теш арасыннан.

—Куркытма, Фатыйх, бер-беребезне куркытышлы уен уйнар чак түгел. Хәлләр житди. Син килгәнгә ике-өч көн, ни өйрәнден, ни белден ул арада? Коралл солдатлар белән килеп, халыкны куркытып колхозга куып кертергә булыр да булуын, иртәгесе көнгә нәрсә булыр монда? Мина бу төбәктә хәлләр яхшы таныш, һаман да халыкны көчләп колхозда тотуны дәвам итсәк, ахыры хәерле бетмәячәк. Аң бул, ут белән шаярасың!

—Ни кылырга кушасың инде? Күрә торып колхозларны таратып бетерикме? Өлкә комитеты, кантком шуның өчен жибәрдеме сине монда?—Сәгыйтов һөжүмгә күчеп маташа иде.—Мин шушы ике көн эчендә Түбән Яхшыйда, Табанлыкүлдә, Мәчтидә таралдып беткән колхозларны кире торгыздым. Кире уйлап карасыннар...

—Ничек тиз генә жыясы иттен аларны?—Әхмәтсафаның тавышында ирония сизелеп китте.—Шулай абыстайларны бер-берсе белән сугыштырыпмы?..

—Анысы да булды.—Сәгыйтов тагын кәперәеп сөйләнә башлады.—

Өлкә комитеты белешмәсендә ачык язылган—минем вәкаләтләр чикләнмәгән. Бездән барысы да дер калтырап торырга тиеш! Нигә әле без җыен кулак, мулла-мунтагай хатыннарын колхоз төзү эшенә җикмәскә тиеш? Ничек эшлим дисенме? Килеп керәм авылга. Совет аша бөтен ирләрне җыеп келәткә яптырам. Куркыту өчен солдатлардан бер-ике мәртәбә залп бирдертәм келәт төбендә, шыр җибәрәләр инде, малай. Кстати, сыналган ысул бу, күп җирләрдә шулай эшлиләр. Аннан җыям совет йортына хатыннарын. Кулак, мулла хатыннарын башкалар алдында бер-берсе белән сугыштырам, талаштырам, тынламаска маташсалар, колак төпләрендә генә наган гөрселдәтәм, шуннан китә эш хутка. Кем кире колхозга керә, алар гаризаларын калдырып кайтып китә, каршы килүчеләрне базга ябып куям. Минем һәр авылда ун-унбиш кешем базда ята, уйланып...—Мактанганда Фатыйхнын авыз читеннән күбек бәреп чыкты.

—Да... Ишкәнсен икән ишәк чумарын...

—Син моның ишегә каршы инде, әйе бит.—Сәгыйтов ачыктан-ачык үчекләшә иде.—Вчүтеки, сине бу эшкә җибәреп ялгышкан өлкә комитеты. Кемнен кем икәнен белми торып...

—Әйдә сүз көрәштереп вакыт үткәрмибез. Бәхәсләшеп тә торасы юк—халыкны судсыз-нисез келәткә, базга ябып кую өлкә комитеты вәкиле эше түгел. Без урыннардагы партия оешмаларына ярдәм күрсәтергә тиешбез. Менә бу эштә безнең вәкаләтләр чикләнмәгән, әлбәттә. Нигәдер монда ни партия оешмасы сәркатибен, ни башка активны күрмим.

—Халыкны җыярга куштым мин аларга. Берәр буш келәткә кертеп тутырырга...

—Менә ничек! Хәзер үк син кыланганнар буенча ашыгыч чаралар күрергә, вәзгыять контрольдән чыкканчы хәлне төзәтергә кирәк. Беләсенме, авылларда каршылык нинди төс алып бара? Безнең ялгыш адым ясаганны көтеп торучылар юк дисенме?—Ул ишек төбендә тавыш-тынсыз утырган кешегә дәште.—Сез кем буласыз?

—Кумхуҗ рәисе идем лә...

—Ничә әгъза калды кумхуҗда, таянырлык кешеләрең бармы? Чыгасы килгәннәр, әгәр инде үгет-нәсихәтләр ярдәм итмәсә, чыга бирсенәр, ә үзәкне, умыртка баганасы булырдай көчләрне сакларга кирәк. Менә шундый дуамаллык күреп, барысы да качышып бетмәсен күмәк хуҗалыктан.

—Егермеләп хуҗалык нык тора әле, колхоз кирәк дип йөрүче кызыл партизаннар күпчелеге.

—Шуларга таянып эш йөртегез.—Дәүләтъяровнын тавышы йомшара төште.—Халыкны тынычландырырга кирәк беренче чиратта. Чәчүлек орлыгы салынган келәтләрне туздырта күрмәгез, көн-төн саклау оештырыгыз. Яз көне чәчүлек орлыксыз калсагыз, эш мөшкелләнер. Язгы чәчү күрсәтергә тиеш күмәклек көчен, шуна кадәр сабыр итәргә кирәк.—Ул кисәк Сәгыйтовка борылды.—Сиңа Фатыйх теге авыллардан кабат үтәргә туры киләчәк. Анда хәзер нинди хәлләр икәнлеге мина карангы, йоклап ятмый торганнардыр. Инде кыланып күрсәткәнсен, хәвеф-хәтәрсез Минзәләгә кайтып керүенә ышаныч юк, ал минем биш кораллы җайдакны, тоткыннарынны азат ит һәм күп сүзгә житми авыллардан чыгып сыз. Мин моны сиңа канткомнын җаваплы работнигы буларак әйтәм.

—Ә син?.. Без бергә китмибез мени?—дип сорады Фатыйх куырыла төшеп.—Мина бит Минзәләдән йөз кешелек кораллы отряд җибәрәбез дигәннәр иде ярдәмгә. Алар килмичә мин беркая да китмим. Көтәргә вакытым бар әлегә.

—Кабатлап әйтәм, кантонда хәлләр катлаулы, беркем дә менә бүген сиңа ярдәм кирәк дип, отряд җибәрмәячәк. Алар хәзер һәркайда кирәк.

Сәгыйтов нигәдер Дәүләтъяровка каршы төшәсе итмәде. Әллә чынлап та ныклап арыган идеме, әллә үзе тынычлыгын алган авыллар аша кабат үтү кирәклегенен котылгысызлыгы яна башына барып житте, мич янындагы чиләктән чумырып су алды да чапыр-чопыр эчә башлады...

...Әмәкәйгә икенче көнне төш турысында килеп керде алар. Әхмәтсафа

туры каравыл өенә китте. Анда, ул көткәнчә, халык төркеме шәйләнмәде күзенә. Авыл үзе дә ничектер тыныч, нindidер бер жинеллек белән язгы кояш астында сизерәп утыра иде. Каравыл йортына ни кергән, ни чыккан кеше күренмәгәч, күнеле тынычсызланып куйды Әхмәтсафаның. Хәвефләнеп, әле гаскәриләр атларыннан төшәргә өлгергәнче, ашыга төшеп эчкә үтте.

Йортның сынар тәрәзәсе янындагы япмасыз өстәл янында нидер язып Габитов утыра. Ул керүчегә бөтенләй игътибар итмәстән, аның кычкырып биргән сәламен дә алып тормыйча, өстәл астыннан кәгазь белән яртылаш тулган иске кәржинне тартып чыгарды да, аягы белән ишек ягына шудыртып жибәрде.

—Гаризанны шунда ташла, апай—диде ул искитмәгән кыяфәт белән.—Хуш, фамилиян ничек димме инде...

—Дәүләтъяров...—Габитовны исән-имин күргәч, тын алуы иркенәеп киткән сыман тоелды. Ул-бу юк бугай монда...

—Дәүләтъяров... тәк-тәк...Дәүләтъяров дисең инде син... Эзләп тап инде менә шушы мунчаладан Дәүләтъяров дигән кешене...—дип сөйләнә-сөйләнә Габитов тәрәзә ягына авышып бер учма кәгазь актара башлады. Ул әле һаман Әхмәтсафага күтәрелеп тә карамый иде.

Аның бу хәлгә ачуы чыгасы урынга, шаяртасы килеп китте.

—Эзләмә иптәш Габитов минем фамилияне, ерак яшеренгән ул.

Габитов ялт башын күтәреп карады, кантком вәкилен төсмерләп, утырган эскәмиясеннән сикереп торды.

—Карале, апай, бөтенләй эшкә мавыгып киткәнмен...—диде ул түче тавыш белән.—И-и, иптәшкәй Дәүләтъяров килеп чыккан икән бит безгә. Ничекләр киләсе иттең, әле үзем утырам, үзем ямансулыйм, колхозны шартлатып төзеп куйганда зур-зур кешеләр килде Минзәләдән, мин әйтәм, күмхуж таралганда бер ялгызым утырам кангырап. Менә сине күргәч күнелләр күтәрелеп китте бит әле, иптәш Дәүләтъяров...

Әхмәтсафа сакланып сорау бирәсе итте:

—Ничек, әллә колхоз таралып та бетте мени?.. Бик тиз...

—Бетте, иптәш Дүләтъяров, бетте күмхуж,—диде Габитов пошмас тавыш белән.—Күмхуж менә шушы кәржиндә инде хәзер. Каршы төшеп булмый, иптәш Дәүләтъяров, килгән берсе иптәш Сталин мәкаләсен күтәреп керә гаризасы белән. Иптәш Сталинга каршы килеп булмый гына бит, апай, сәяси ялгыш китмәсен дип, башны да күтәреп карамыйм, исемлеккә язып куям да, вәссәлам.

—Чынлап та бер кеше дә калмады мени колхозда?—дип аптырап сорамый булдыра алмады Әхмәтсафа.—Инде шул кадәр макталып, телгә кергәч, аз гына да саклап калу хакында уйламадыгызмы күмәк хужалыкны?

—Берәү калды исемлектә...—диде Габитов теше сызлаган кешедәй йөзен жыерып.—Йөз процент таралды дип булмый булуын.

—Кем ул?

—Сөләйман карт,—диде Габитов ыңгырашкан тавыш белән.

...Әмәкәйдән ул янә туры Суыксуга юл тотты, ана курсларны дәвам итү йөкләнүе хакында фәрман килеп ирешкә. Егерменче мартта аны Минзәләгә чакырып алдылар. Партиянең кантком конференциясе булып, аны пленум составына керттеләр. Пленумда исә тагын да югарырак күтәрелде, ул бюро әгъзасы, агитация-пропаганда бүлеге мөдире итеп сайланды. Авылларда колхоз төзү икенче төс алды. Әле февраль ахырында ук Минзәлә кантномы Казанга йөз процент күмәкләшү турында рапорт биргән иде, март ахырына бу сан күпкә ким иде инде...

Әхмәтсафа конференциядән соң атналар буе авыллардан кайтып кермәде. Бу көннәр хакында киләчәк буыннарга көндәлектәге язмалар гына сөйләр инде: «Утызынчы мартка кадәр көн-төн, армый-талмый, ташка куйсаң таш ватарлык көчләр биреп, кантон конференциясе установкасын «ни один колхозник не должен выйти из колхоза»—диелгән директивасын үтәргә тырышабыз-тырмашабыз.

Колхозларга каршы хәрәкәтнең иң күтәренке вакыты егерме икенче марттан утыз беренче мартка кадәр булып, аның күп урыннарда советларга каршы хәрәкәт төсен алуы, шуның нәтиҗәсендә авыл советлары, хәтта волостьның вәзгыятьне кулдан ычкындыру күренешләре сизелде. Менә шушы тынычсызлыклар, переживаниеләр бервакытта да онытылмаслар. Нервларга ясаган эзләре мәңге калыр, сакланырлар...»

...Ничек кирәк алай күмәкләшүне нигездән җимерми саклап калып, язгы чәчүләрне үткәреп җибәрделәр. Әхмәтсафа инде язмышына буйсынып, шушы якларда төпләнү ягын да уйлый башлады. Җәй урталары җиткәч, Рабиганы да монда алып килү иде исәбе.

Шул уйлар белән фатирга кайтып барганда аңа Шәмтиев очрады.

—Ни хәл, иптәш Дәүләтъяров, колхозларны җимереп бетерәсенме әле, үгет-нәсихәт мөдире?—дип, шаярта төшеп, асылда, мыскыллаган кебек сөйләнә-сөйләнә кул бирде ул Әхмәтсафага.

—Колхоз төзү эшендә кимчелекләр булган икән, анда барыбызның да гаеп җитәрлек,—диде Әхмәтсафа, тегенең шаяртуын өнәмичә.

—Серкәң су күтәрми икән, дус кеше,—дип, Шәмтиев борын җыерды.—Болай гына әйтү, авылларда синнән дә күп йөрүче булмады бит ул чорда. Шул искә төште. Менә син турыдан-туры шул ялгышларны җибәрдең дә инде. Алай да сине пленум бюросына сайлап куйдылар...—Шәмтиевнең тавышы рәнҗүле иде.—Мин дүрт-биш авылга барып кайттым, арттан бер җалу килмәде, тора салып пленум составыннан чыгарып аттылар. Гаделлекме бу, тик торганда урыннан төшерүне әйтәм?..

—Үзең үк әйттең, тик торганга төшкәнсең дә инде,—дип, көләсе итте Әхмәтсафа.—Түрдән төшү гүргә төшү түгел әле ул, аптырап йөрмә юк өчен.

—Сина көлке,—дип, һаман үпкәләвен сиздереп, сөйләнде Шәмтиев.—Сина җайлы, тиз онытасың авырлыкларны. Бер малай әтәсенә: «Сугыш бетте, әтәй, сыерны суеп сатыйк та, гармун алыйк, мин уйнармын, син җырларсың,»—диеп әйткән ди. Үпкә саклап та йөрмисең, сүзне уен-муенга әйләндерергә һәвәс, ачуланышыр чакта...

—Аңламыйм, нигә, кем белән ачуланышып йөрим ди?—дип, чынлап сорады Әхмәтсафа.—Болай да башлар катып бетте. Бер сүз сөйлибез, икенчесен эшлибез...

Шәмтиев, шуны гына көтеп торган диярсең, йөзе ачылып китте. Ул сынаулы караш ташлап, пышылдап диярлек, сорау бирде:

—Нәрсә, иптәш Дәүләтъяров, партиягә ышанып бетмисенме әллә?

—Каян алып әйтәсен?

Шәмтиев каш сикертеп, алды.

—Икеле-микеле сөйләшәсен... Шуна әйтәм...

—Төрле вакыт була торгандыр инде.—Әхмәтсафа сүзне озынга җибәрми, китеп бармакчы иде, Шәмтиев аны туктатты.

—Мин бит болай гына, иптәш Дәүләтъяров. Синең кебек укыган кеше түгел шул без, кайбер нәрсәләрне аңлап та бетми торганбыздыр. Сорыйсы гына килә, шулай да, дөресен генә әйт әле, колхозлаштыруны дөрес дип табасынмы син?

—Дөресен әйт дисеңме?—Әхмәтсафа тын калып, Шәмтиевкә сынаулы караш ташлады.—Нигә кирәк соң сина аның дөресе?

Шәмтиев авыз читен кыйшайтып, елмайгандай итте.

—Авыллар нык каршылык күрсәттеләр бит, шуңа гына әйтүем...

Әхмәтсафа, үзе дә сизмәстән, ачылып китте.

—Дөресен әйткәндә, күмәкләштерүне яклаган хәлдә, мондый ашыгуны хупламыйм. Кулак дигән булып, авыллардан иң тырыш, булдыклы кешеләрне сөреп бетерүгә дә каршы идем. Авыл фәкать шундый кулыннан килә торган кешеләре булганда гына күтәрелә ала. Кайбер хәлле кешеләрне кулак дип, колхозга алмый, хәлне кискенләштерү ягында да түгел идем. Ни эшлисең, фирка карары һәр коммунистка канун, үз-үземне җинеп, карарларны кулдан килгәнчә үтәргә тырыштым...

—Вәт, әйтәм бит, укыган кеше бөтенләй икенче төрле сөйли шул...

Шәмтиевкә шул гына кирәк иде, ахры, саубуллашмый да китеп барды. Бу сөйләшүне Әхмәтсафа тиз онытты, моны еллар үткәч исенә төшерәчәкләрен дә чамаламый иде әлегә...

Фатирга кайтып, ашарга өлгермәде, олы конвертка салынган хат китереп бирделәр. Айхенвальд аны университетка кайтып, аспирантурада укуын дәвам итәргә үгетләп хат юллаган. Тәкъдиме коры сүз генә түгеллеген раслагандай, хат белән бергә ТКУ директоры Вольфович имзасы белән ныгытылган чакыру да җибәргән иде. Өстәвенә, партия өлкә комитетыннан да ризалык язуы алынган, анысы да конверт эчендә. «Хәзер фәнгә яшьләр кирәк. Синең кебек тәҗрибәле, белемле яшьләргә мохтаҗ ил. Икеләнмә, эшләргә өлгерерсең, мин Ишков, Разумовский, Слепков, Эльвов иптәшләр белән дә киңәштем, барысы да синең кандидатураны яклыйлар. Тулай торактан гаиләлеләр өчен бүлмә бирербез. Хатының белән бергә яши башларга кирәк бит инде, наконец!»—дип, егетнең күңелен канатландырган сүзләр дә теркәлгән иде хатта. Өлкә комитет исеменнән җибәрелгән юлламага кем каршы килсен?! Җәй башында район (канткомнар бетерелеп, районнар төзелә башлаган иде) үзәгеннән аны ат белән Курья пристанена китереп куйдылар...

Аны Минзәләдән озатып калучылар арасында Габидулла Такташев та бар иде. Ул март аенда гына килеп житте. Урыс мәктәбендә укыта башлады. Шагыйрь абыйсы кебек үк кешеләр белән тиз аралашучан, ачык йөзле егет. Чәчен кыска итеп алдырган, бусы Мәскәү модасы инде. Ул килгәч, бераз күңелле булып китте, чөнки тулай торакта Габидулла Әхмәтсафаның күршесе булып яши башлады. Озатканда Габидулланың күзләреннән яшь сыпылып чыкты, бары тик бер үк сүзләрне кабатлады: «Безнекеләрне күрсәң, сәлам әйт. Берүк күрергә тырыш...» Ул кабатлаган саен, Әхмәтсафа әманәтнең үтәләчәгенә ышандырды... Әмма көн артыннан көннәр агылып кына торды, уку, гаилә мәшәкатьләре белән айлар, ел үтеп китте һәм, Ходай насыйп итмәгәч, Казанда Такташ белән кабат очрашырга язмаган икән аңа. Аның җәсадына гына килде ул утыз беренче елның кышкы көнендә... Еш кына күз алдына Габидулланың өтәләнеп, абыйсына сәлам юллавы исенә төшә дә, күңеле сискәнеп куя иде, күрәсең, энесе абыйсына киләсе фаҗигане алдан ук сизеп, тоеп яшәгәндер, шуңа өзгәләнгәндер...

...Казан Әхмәтсафаны якты йөз белән каршы алды. Алда яңа тормыш көтә аны; яңа дуслар, яңа омтылышлар, яңа ачышлар кочагында нинди биеклекләргә күтәреләсен Әхмәтсафа Дәүләтъяров әле күз алдына да китерә алмый иде. Әлегә Рабигасы янына ашкынып кайтып жите дә, гомеренең иң татлы мизгелләре өерәмәсендә эреп, югалып калды. Ниһаять, ничә еллардан соң алар бергә, алар бәхетле, йолдызлар төнге күкне алар өчен генә бизәп калкалар, ай аларның сәгадәтле минутлары сагында тора, кояш аларга гына елмая иде...

Шундый нурлы, якты төннәрнең берсендә Рабига Әхмәтсафаның колагын кайнар сулышы белән өтеп алды:

—Мин сиңа бер малай алып кайтам...

—Чынлапмы, сөеклем?! Болай булгач, яшибез! Дәүләтъяр нәселе исән, яши дигән сүз! Рәхмәт, кадерлем!

Әхмәтсафа үзен-үзе белештермичә урыныннан сикереп торды, Рабиганы көчле кулларына күтәреп алды да бүлмә буйлап зыр китереп әйләндереп йөртә башлады. Бәхете ташыган Рабига иренең муенына сарылды, аның керфек очларына эленгән күз яшьләрен иксез-чиксез күктә йөзгән тулган ай гына шәйләп алса алгандыр... Бу төндә меннәрнең бәхеттән очынуларына, меннәрнең бәхетсезлектән канатлары каерылуына шаһит иде ай. Бәхет белән бәхетсезлек, шатлык белән хәсрәт, табу белән югалтуның гажәп дәрәҗәдә янәшә барулары дөньяга адәм баласы яралган көннән барлыкка килгән һәм һичнинди үзгәреш кичермәгән хакыйкать бит ул.

*Икенче китап тәмам.*

*Бәйрәмгә шигъри бәйләм*

## Илдар Юзеев

### Татар бугазында–циклон...

Сахалинда татарларның
Бик азы гына калган,
Тарихи атама булып,
Бугазы гына калган.
Үткәнне искә төшерү
Гүя бик авыр аңа...
Әллә шуңа инде циклон
Котыра, давыллана.
Еракта калган зурлыкның
Дулкыны ярсып килә.
Кечкенә татар иленең
Йөрәге әле тибә.
Башы-бугазында–циклон.
Кыйтганың бу ягында–
Давылның тик кайтавазы–
Татарның аягында.
Циклонга хәлсез татарның
Йөрәк тавышы кушылган,–
Аякта басып торса да,
Бугазыннан кысылган...

## Равил Фәйзуллин

### Тагын килде язлар...

*Үткән гомерләрне еллап түгел,*
*гашыйк язлар белән исәплим.*

Сау кеше өчен тагын язлар килде–
бар назлары, дәртләре белән.
Кемнең анда шатлык яше чыккан
ак каенның күкрәкләреннән?

Кемнәр өчен икән тел апкайткан
очар кошлар озын юл узып.
Учларында гөлләр шытар кебек,
ләйсәннәрдә торсаң кул сузып.

Кем күзләре бүген зәңгәр күктә?
Гөрләвекләр кемгә ашыга?
...Кичен кәрәз карда нур үткәреп,
чигү чигәр өчен ай чыгар.

Кемнәр быел сөю ялкынында
җаны белән җанга бәйләнер?
Ә кемнәрнең җуйган сөйгәннәре
рәшәләргә кереп тибрәнер...

...Зәңгәрәйде күкләр. Ачыклана төште
төсләр, югалтулар, табулар...
Тургай хыял булып өскә әйдәсә,
үткән еллар тарта чабудан...

Һәр иртәдә әле туа тора
куанырлык мең-мең сәбәпләр.
Күңелдә әле, яз басымын тоеп,
бар өзгәләнә алыр күзәнәкләр!

Җан түрендә әле урыннар бар
яңа шатлык, яңа газапка.
Тик, алдашмый, җырларыңда кара-
гел кешеле якка, яз якка!

...Сау кеше өчен тагын язлар килде-
бар гамьнәре, дәртләре белән.
Кемнең анда сагыш яше чыккан
ак каенның күкрәкләреннән?..

## Әхсән Баянов

### Йоклый кошлар

Йоклый кошлар. Алгы зур очышлар
Сыйган бүрек хәтле дөньяга:
Йоклый кошлар төнге тын ояда,
Оядагы йомыркаларда.

Нәни тормыш, сары томшык, каурый
Яфрак шавы төсле сизелә.
Атылыр моннан күпме яңа гомер
Зәңгәр океан чиксезлегенә!

Йоклый өмет, җил һәм күк ләззәте,
Кагынышып сайрар шатлыклар,
Офык алсулыгы, зәңгәрлеге...
Алар әле ләкин сак йоклар.

Килеп иртән монда сузылса кул?
Давыл купса шушы минутта?
Барысы чыгар юкка. Җирдә өмет
Валчыклары- юеш бер нокта...

Әй, кем анда, тукта! Ә юк, Җир дә,
Күк тә тыныч- бары уй курка.
Кошлар белән йоклый Җирнең, синең
Киләчәгең- шушы тынлыкта.

## Марс Шабаев

### Май кызлары

Май кызларың,
Казан,
һай, кызларың!
Якты кызлар—
Шәһәр гөлләре.
Озын кышлар буе сагынам шул
Май айларын,
Шушы көннәрне.
Май башында кызлар ачылалар.
Соңдырмы бу,
Әллә иртәрәк?—
Әйтә алмыйм.
Алар исертәләр,
Яшьлекләре белән иркәләп.
Май җилендә,
Комач алсуында
Атлап килүләрен күр әле!
Алларына төшеп,
Шаян сүзләр кушып,
Ияреп китте инде йөрәгем...
Казан!
Гомер агышлары бигрәк җитез:
Язлардан соң шаулап җәй үтәр.
Ә җыр һаман-һаман чыңлап торыр,
Ул җырга соң, әйтче, ни җитәр?

«Май кызлары килә,
Май кызлары!
Безне сөяр икән
Кайсылары?»

## Ренат Харис

### Табын

Ничәнче тапкыр тагын
дусларны җыйды табын.
Бер сөйләшик—искә төшсен
гомернең төрле чагы.

Бер көлешик—күңелләрне
йолдызларга күтәрик,
борчуларны, болыт итеп,
диңгезләргә түнтәрик!

Сагыну нурына чумыйк,
бераз яктырып калыйк—
бер генә мизгел булса да
саф сабый булып алыйк!

Жырлашыйк—жырлый белсәк тә,
белмәсәк тә жырлашыйк,—
жыр бит эчкәре дөньядан
тышкарыга нур ташый.

Бизик әле дөньяны бер
табыннар яме белән—
күктән йолдыз тел шартлатсын,
җирдән үрелеп—үлән!

## Гәрәй Рәхим

### Әниләр зары

Ирләр ул гел шулай:
Чәй кайнап чыкканчы гына, дип китә дә...
Югала.
Һәм еллар хәбәрләр китерә:
—Билгесез югалды...
—Приказны үтәгәндә...
—Батырлык күрсәтеп...

Малайлар гел шулай:
Чәй кайнап чыкканчы гына, дип китә дә...
Югала.
Һәм көн дә газеталар хәбәрләр китерә:
—Тайгада шәһәрләр төзелә.
—Чирәм җир сөрелә.
—Космостан әйләнеп кайттылар.

Көненә ничәмә мәртәбә куела самовар.
Көненә ничәмә мәртәбә әйтелә:
—Чәй кайнап чыга бит,
Кайтырлар...
Кайтырлар...

## Шамил Маннап

Түгеләсе килә күңелнең бер,—
Дөнья ташы баскан чишмәсен.
Коры җилләр бәгырьләргә үтә,
Нишләселәр икән, нишләсе?

Син шулчакта, хатирәмнән калкып,
Кузгатасың мүкле ташларны.
Чишмә ачыла.
Шиңеп барган гөлләр
Күтәрәләр кабат башларын.

Гаҗәп тоелмасын,
Бар кешегә
Була икән күңлем пакь кенә,
Кемнәргәдер күпне кичерәм икән,
Болар бар да—синең хакына...

Вакыт, ара, үлем аерса да,
Күңелемнән, эни, китмәссең.
Син булганда чәчәк-гөлләрем сау,
Имин тора күңлем чишмәсе.

## Рәдиф Гаташ

*

Әй-йа, Күңел! Тәүбә кыйл: кайт
Хакка– Аллаһу!– диген.
Хуҗа Ясәвичә, син дә
сәҗдә кыл һәм: «Һу!»–диген.

Шагыйрь рухы, сүнмәс хисе
сыяр шул иҗеккә дә!–
Валлаһи, ике дөньямда
чын ихлас сүз–бу!–диген.

Бөек мәүланадән васыять!–
мең еллык изге аять!
Бүген дә син, денсез гавам,
кальбең-рухың ю!–диген.

Тән белән пакьме без, Мәүләм?!
Кичмәде кемнәр Җирдән...
Саф иман! Гөнаһ-языкны
уйларыңнан ку!–диген.

Бакырганига рәхмәт әйт,
Ясәвигә кайт кабат!–
(Бул шигъреңә тугры ләкин,
янам, Ләйләм, су!–диген.)

Тәүбә кыйл, тәүбә: нәфсем, Син–
гел чәчләр тозагында...
Ә ул гөнаһмыни? Сөю–
мәңге яшь калу!–диген.

## Роберт Миңнуллин

### Шундый минем туган ягым

Ак чәчәкләр чыңлап тора,
Җырлап тора әйләнәдә.
Аккаеннар сылу-сылу
Яшь кызларга әйләнә дә.

Җыйнаулашып, тезелешеп,
Төшеп китә Сөн буена,
Яп-ялангач калып кына
Су керергә төн буена.

Ә малайлар шундый монда:
Хикмәт кенә уйлап йөри,
Ять-яшь кенә яшеннәрне
Камчы итеп уйнап йөри.

Шул камчыны шаяртып бер
Шарлатсалар болгый-болгый,
Баш очында утлар уйный,
Күкләр күкри ургый-ургый.

Тайлар монда бер урында
Чыдый алмый биеп тора.
Ә басулар шундый биек—
Офыкка ук тиеп тора...

Менә шундый инде минем
Туган җирем, туган ягым.
Мин төзәлә алмам, ахры—
Мактанылды менә тагын!

## Зиннур Мансуров

### Кош очар биеклек

Бер дә өстән карама, дип,
намус гел тыеп тота.
Ә үземне тоям кайчак
кош очар биеклектә.

Пеләшемә чия төше
төкерер, диеп көтмә.
Мондый уйны алып менмим
кош очар биеклеккә.

Һәм уйлама: башыбыздан
йөрмәсме биеп, дип тә.
Түбән җанлы булып кара
кош очар биеклектә.

Чүп кой, имеш, шул ләйсәнле
болытка тиеп кит тә...

Сөю яши, җыр туадыр
кош очар биеклектә.

Җир белән күк арасында
илаһи бөек нокта!..
Җир—балалар рәсемедәй—
кош очар биеклектән.

Дөрес, тормыш ваклыклары
чабудан бик еш тота.
Ничек булса да калырга
кош очар биеклектә!

Җир белән күк арасында
илаһи бөек нокта!..

## Мөдәррис Вәлиев

### Сулыштан—сулышка

Хыяллар рәшәсе
Тирбәлә дөньяда.
Офыктан-офыкка—
Ир бала,
Ир бала...

Үләннәр таҗыннан
Кайта нур югала.
Чәчәктән-чәчәккә—

Кыз бала,
Кыз бала…

Җир-әнкәй… Нур белән
Керфеге чылана.
Сулыштан-сулышка—
«И бала…»
И бала!

## Рашат Низами

### Кызыл җәй

Печәннәре уңган каерылып,
Җиләк исе аңкый җилләрдән…
Михнәтләргә сал син безне, язмыш,
Тик аерма туган илләрдән.

Кыштыр-кыштыр үбә карабодай,
Туган туфрак—серне, хикмәтле:
Кочагына алып тибрәтә дә,
Суза бер көн хәләл икмәкне.

Кояш байый. Офыклар ут яна—
Кызыл шәүлә бии алмада.
«Янгын!»—диеп дәртле чикерткәләр
Берөзлексез кырда чаң кага.

Офык яна… Мәшәкатьле көннең
Итәгенә гүя ут капкан!
Сүндермәсме яңгыр—болытларны
Җыеп йөри җилләр еректан.

Тарала да бетә вак болытлар,
Тынып кала дөнья берзаман.
Кызыл ялын шулай җилфердәтеп,
Кая табан оча бу заман?

## Наис Гамбәр

### Әрем

*(Х. Туфан белән сөйләшү)*

I

«Түзәрсең— егет ләбаса,
Гәрчә бик ачы мәең;
Ташландык йорт ишегалды
Тоташтан, энем, әрем.

Әрем—дару, җыеп апкер
Дәвага учма әрем;
Әрәмгә хәрам килешә,—
Йә, ничек хәзер хәлең?»

II

«Мең яшә, мең ел өйрән», ди,
Бик әйбәт, абый, хәлем;
Тереләсем килә, түзәм—
Ашадым ачы әрем.

...Авыр әкият шикелле
Авыргач күргәннәрем;
Хәзер бер чир дә кагылмас—
Мин үзем тоташ әрем.

## Нияз Акмал

### Учак

Без кузгалсак, соңгы уты сүнәр,
Яңгыр юар көлен, җил алыр.
Үзең яккан булгач, учакны да
Ташлап китү, бәгырь, бик авыр.

Туңган юлчы, юл читенә чыгып,
Учак ягар, учак көйрәтер.
Тәнең түгел, җаның туңганда да
Учак ягып карау кирәктер.

Без бик белеп яктык бу учакны,
Кирәкмәстән түгел, кирәктән!
Без дәшмичә йөргән күпме сүзне
Сөйләп бирде бит ул берррәттән.

Сүрелгәннәр үзен сүгә белми,
Яманлыйлар һаман ятларны.
Беркем белми менә, безнең нигә
Монда килеп учак якканны.

Ә ул яна!
Яна, күрәсеңме,
Безгә карап, безне җылытып!
Үрсәләнеп яна, аерылышасы,
Хушлашасы барын онытып.

Ашыктырма, әйдәмә дә мине,
Син кагылма миңа бу чакта,—
Күмер түгел, гомер яна, бәгырь,
Гомер яна бүген учакта!

Без калдырсак, соңгы уты сүнәр,
Яңгыр юар көлен, җил алыр.
Үзең яккан булгач, учакны да
Ташлап китү, бәгырь, бик авыр...



Халисә Мөдәррисова

# БӘЙГЕ ХАКЫ

ПОВЕСТЬ

Баеп баручы кояшның кып-кызыл итәге инде офыкка кагылды. Зариф уйнап торган яхшы атта, тояк күмәрлек тузанлы юлдан кара тиргә батып, җан-фәрман офыкка табан чаба да чаба. Ничек тә куып тотарга кояшны, якынаерга тиеш ул ана. Кояш аның саен тизрәк түбәнәя, кайнар хәнҗәр баткан май кебек шуып инә бара. Менә аны уратып алган алтынсу-сары балкыш куелана, кара кан төсенә керә.

Никадәр шәбрәк чабарга тырышмасын, ниндидер куәтле көч аны туктатырга тырыша, бар авырлыгы белән ат күкрәгенә, инсәләренә баса, күзгә күренмәс көч аны кирегә тарта, аты-ние белән артка каера. Зариф ике яктан үскән куакларга, агач кәүсәләренә тотынып алга ыргылырга азаплана. Аты бар куәтенә омтыла, ләкин көче житми. Йөрәк дөп-дөп килә.

Менә кояшның яртысы офыкка инде, менә ул чирек кенә, аннан урак нечкәлеге генә калды. Зариф никадәр чапмасын, житешә алмый кояшка, ул якыная барган саен офык арткарак чигенә. Бу бәйге мәңге бетмәс кебек, гажизлектән, көчсезлектән аның сулышы кысыла...

Зариф кара тиргә батып уянып китте. Тагын шул бер үк төш. Үз гомерендә бу төшне ул әллә ничә тапкыр күрде инде.

Зал түрендәге пианино өстендә электрон сәгатьнең яшел утлары төнге өчне күрсәтә. Фатирда кабер тынлыгы. Альбина әле кайтмаган. «Банкет бетмәгәндер»,—дип уйлап куйды Зариф, шулай дип үзен юатырга тырышты. Тик күпне күргән, үз гомерендә күп премьералар, күп банкетлар үткәргән карт режиссер бу вакытта инде мәҗлесләрнең таралганын белә, белсә дә күңел төбендәге шигенә, күнләшүенә ирек бирмәскә, горурлыгын, мин-минлеген алдарга тырыша.

Халисә МӨДӘРРИСОВА—*шагыйрә, башкорт һәм татар телләрендә дөнья күргән шигырь китаплары авторы. Башкортстанда яши.*

Ул күзләрен йомды. Йокы һәм уяулык арасындагы битараф халәтне уң кабырга астындагы астыртын сызлау акрынлап уяулык ягына авыштыра башлады.

Авырту мәкерле ерткыч кебек акрын гына, шуышып кына башта аркасына, аннары сыртына, аннары күкрәгенә якынлаша. Ул тере җанвар кебек башта йомарланып һәм салмак якыная, аннары торган саен оятсызрак һәм рәхимсезрәк була бара, аннары көчле һәм озын тешләрен бавырына батыра, умыра, чәйни, аяусыз рәвештә тәндәге һәр әгъзага, һәр күзәнәккә күчә, ул гына да түгел, мәрхәмәтсез рәвештә җанны ботарлый башлый.

«Уколның көче бетте»,–дип уйлады Зариф. Таңга кадәр әле озак. Ул, көч-хәл белән генә үрелеп, тумбочка өстендәге төнге лампаның төймәсенә басты. Күзләрне камаштырып ялтлап ут янды. Авыртуны баса торган даруын сәрмәнеп тапты, су эчәргә теләп чынаякка үрелде, савыт буш иде.

Зариф, коры сөяккә калган аякларын көч-хәл белән идәнгә төшереп, йомшак башмакларын киде, калтыранып торып басты, стеналарга тотына-тотына кухня ягына юнәлде. «Рәт бөтенләй беткән бит»,–дигән ачы уй миен сызып үтте. Ерагайды шул залдагы диваны белән кухня аралары, бетмәс-төкәнмәс чиксез юл кебек.

Их, хәзер янында җәлләүчесе, күңел тынычландыручысы, юатучы кешесе булсын иде аның. Шушы даруны йотып җибәрерлек хуш исле үләннәрдән пешергән төнәтмә бирсен иде ана берәрсе.

«Зарифкаем, ят, нигә тордың, сиңа сакланырга, ял итәргә кирәк, хәзер үзем дару бирәм»,–дип әйтүче, култык астыннан тотып акрын гына бәдрәфкә илтүче, аннан соң йомшак түшәккә салучы, чуалып бетсә дә һаман әле куелыгын югалтмаган, кайчандыр дөм кара, хәзер ап-ак булган дулкынлы чәчләреннән сыйпап юатучы, иң мөһиме–аны яратучы кешесе булса иде яннарында. Юк шул, юк. Ул көч-хәл белән генә урынына килеп ятты.

Ул эчкә баткан күзләрен караңгы түшәмгә юнәлдерде. Гаҗәп, авыруы көчәя барган саен аның күрү сәләте дә сизү сәләте дә көчәя бара иде. Йокысыз, сызланулы төннәрдә, ул уты сүнгән караңгы бүлмәдә, һәр әйберне күрә, ә караңгы түшәмнең һәр сызыгын яттан белә. Бу караңгылыкны җинә ала торган ак түшәм үзе бер дөнья икән бит. Иң яхшы рәссам дә шулай төгәл, тоташ бер дөнья, гаҗәп образлар тудыра алмас гади түшәмдә. Текәлеп караганда алар бер төрле, икенче караганда икенче төрле. Менә салмак, сыгылмалы гаҗәп камил эшләнгән сылу кыз сурәте, менә чабып килгән чаптарлар, аларның җилгә тузган яллары шулкадәр нечкәлек белән эшләнгән.

Тышкы ишекнең өч йозагы да шалтыр-шолтыр ачылды. Өйгә ияреп кергән затлы хушбуй исләре арасыннан Зарифның сизгер борынына ят ирләр исе дә килеп бәрелде.

«Әминә булса, шулай озакка берүземне калдырып китәр иде микән?»–дип аянды Зариф. Кереп хәлен белүен, премьераның, банкетның ничек үтүен, күргән-ишеткәннәрен сөйләп чыгуын өметләнде Зариф яшь хатынның. Ләкин ваннадан чыгу белән йомшак халатка төренгән Альбина, зал ягына башын тыгып кына карады да, үзенең бүлмәсенә кереп бикләнде. Зарифның күңеленә, утлы дулкын булып, Альбинага карата рәнҗү хисе килеп бәрелде.

Каты авырып түшәккә егылуына елдан артык вакыт үтте аның. Альбинага ул һич көтелмәгән бәхетсезлек булып төште. Диагноз ачыклангач, бер кайгысыз, мәшәкатьсез яшәргә өйрәнгән яшь хатын югалып калды. Иренең киң күкрәге артында җил-яңгырдан сакланып, байлыкка, дан-шөһрәткә күмелеп, затлы балдакның асыл кашы булып яшәгән Альбина үзен киң сәхрәдә япа-ялгыз калган бала хәлендә хис итте.

Аның ире–халык артисты, атаклы режиссер, үз илендә генә түгел,

бар төрки дөньясы сәхнәләрендә шөһрәт казанган, әллә ничә дистә спектакльләр сәхнәләштергән, сәнгать дөньясында гына түгел, республиканың бар булган сәяси форумнарында президиумның алгы рәтендә утырган, чит илләргә баручы рәсми делегацияләр составында, иң дәрәҗәле даирәләрдә һәрвакыт игътибар үзәгендә булган Зариф шундый яман чиргә юлыксын әле!.. Альбина моны башына сыйдыра алмады. Нәрсә булыр хәзер аның белән? Җәннәттә яшәп өйрәнгән хатын иреннән бигрәк, үзен жәлләп елады.

Яшь аралары зур булуга карамастан, җиде ел бергә яшәп, ул аңа өйрәнгән иде инде. Яхшы фатир, чит ил машинасы, затлы киемнәр, иң шәп курортлар, яшь егетләрнең игътибары белән беррәттән карт ире дә Альбинаның аерылгысыз чолганышына әйләнгән иде.

Зариф хатыны булганы өчен генә дә бар булган тылсымлы «сим-сим» ишекләрнең ачылуы, байлык белән шөһрәт янына яшьлек һәм матурлыкның килеп кушылуы нинди көчкә ия булганын инде аңлап өлгергән Альбина өчен бу көтелмәгән сынау иде.

Бар булган танышлыклар аша дәрәҗәле табиблар, тәҗрибәле профессорлар карады, төрле-төрле консилиумнар үткәрелде. Ил башлыклары чит илгә чыгарып операция ясау турында да фикерләр әйттеләр. Ләкин Ходай биргән чир кеше кодрәте белән генә китә торган нәрсә түгел иде. «Метастазалар киткән, операциягә соң инде,»—диделәр. Зариф берничә ай больница койкаларында аунаганнан соң, өенә, сөекле Альбинасы янына кайтырга теләк белдерде. «Үз кешем, үз ярым бәлки аякка бастырыр әле, Алла боерса,»—дип өметләнде ул. Ләкин эшләр башкачарак килеп чыкты. Башта яхшы гына тәрбияләде Альбина ирен. Үзебезнең һәм чит ил даруларыннан файда булмагач, халык табиблары, өшкерүче-төкерүчеләргә чират җитте.

Ләкин «чир кочаклап керә, мыскаллап чыга»—дигәннәре дә Зарифка туры килмәде—хәле алга түгел, гел артка китте. Нәрсә генә эшләп карамадылар, бернәрсә дә файда бирмәде. Альбина моның ни белән бетәчәген аңлаган иде инде. Ай ярым өйдә ирен караганнан соң, янадан эшкә чыкты. Репетицияләр, спектакльләр китте, ул торган саен өйдә азрак була, соңрак кайта башлады, Яктырак та күңеллерәк тә булыр, дип урын-җирен үзләренең йокы бүлмәсеннән залга—диванга күчерде. Баштарак, соңга калып кайтуы өчен акланса, аңлатырга, алдашырга тырышса, Зарифның хәле начарлана барган саен, моны кирәк, дип тә исәпләмәде. Ашамлыгын пешереп плитә өстенә, яки суыткычка куя да чыгып китә торган булды.

Көндезләрен әле ул ялгызлыкны бик тоймады. Урам шау-шуы, машина тавышларын тыңлап ятты, сирәк-мирәк, бик сызланганда телевизорын да кабызгалады, радиодан концерт тыңлады. Еш кына дусишләре, бергә эшләгән иптәшләре кереп хәл белеште, үзе дә акрын гына торып бүлмә буйлап йөрештерде, телефон аша да хәлен белүчеләр, кинәш-фәләнен биреп, нинди дару, нинди үләннең үтә дә шифалы икәнен өйрәтүчеләр күп булды. Бигрәк тә аскы катта яшәгән яшьлек дусты Бари аның күнелен күтәрергә тырышты. Карт артист, пенсиядә булуына карамастан, әле берничә спектакльдә уйный иде. Анын кергәнен Зариф түземсезлек белән көтә, бу дөньяда аннан да якын дусты калмаганын аңлый иде.

Бари театрда, республикадагы яналыкларны, артист халкы арасындагы гайбәт-мазарны да кереп сөйләп чыга. Труппадагыларның: «Атаклы режиссер, театр патриархы Зариф Хәсәнович әле бер генә спектакль куеп шатландырмас халыкны»,—дигән сәламе Зарифның күнелен күтәрергә тырышу гына иде.

Ә бит заманында халыкны таң калдырып ул—Хәлил, Бари—Исмәгыйль рольләрен ничек башкаралар иде. Аларның үзара барган монологларын вакытлы матбугат тәнкыйтьчеләре урысчалатып: «Великолепный дуэт двух будущих гениев»,—дип язып чыккан чаклар да булды.

Бер ятакханәдә, бер бүлмәдә яшәделәр, бер икмәкне икегә бүлеп ашадылар. Бари яшь чагында сәхнәдә Зарифка караганда өметлерәк артист иде. Аларның студент еллары иде. Театрның гастрольгә киту көне килеп җиткәч, Исмәгыйль ролен башкаручы ике артист та кинәт кенә авырып больницага эләкте. Театрның башка чарасы калмагач, рольне Барига тәкъдим иттеләр. Әй шатланды Бари. Иртәгә юлга, ләкин кесәдә бер тиен акча да юк.

Таныш-туган тиешле кешеләренә акча юллап Зариф шәһәрнең бер башына чыгып китте, ә Бари икенче якка чапты. Кичкә кирәк кадәр акча җыелган иде инде. «Ярый, берәр бүләк алып кайтырмын үзенә»,— диде Зариф.

Чыннан да гастрольдән ул Зарифка Әстерхан чикләвеге зурлыгындагы яшел эмальгә гарәпчә хәрефләр белән язылган бик матур медальон алып кайтып бирде. «Һе, диде, Зариф, эчтән генә, берәр китап-фәлән алып кайтсаң, лутчы буласы иде.»

—Бик кыйммәтле медальон ул, дускаем, мин аны базардан бер ак сакаллы, чалмалы карттан алдым. Бу медальон кешегә бәхет китерә, әгәр югалса, бәхете дә югала, анда бик кирәкле дога язылган, югалтма,— диде Бари медальонны Зарифның муенына кидергәндә. Зариф бу сүзләргә әллә ни игътибар итмәде, медальонны киеп куйды да онытты, комачауламагач, йөри шунда эленеп.

Кухня краны ябылып бетмәгән күрәсең, тып та тып, тып та тып су тама. Их, бер генә тамчы гөлҗимеш төнәтмәсе йотарга иде, бәлки ут булып янган эчләренә хәл керер, ялкыны басылыр иде. Әминәсе—яшьли кавышкан, бергә картайган хатыны булса икән янында. Ул кайгыртыр иде аны. Терсәк якын да тешләп булмый шул. Ул авырлык белән генә торып салкын чәй йотты, чак-чак атлап барып кранны япты һәм тагын урынына килеп ятты. Көчле дару үзенекен итте. Бөтенләй басылып бетмәсә дә авырту ераккарак чигенде. Сырхау дигән «ерткыч» йомарланып, күзләрен зәһәр ялтыратып, өненә посты. Зарифның зиһенен томан каплады, төш дисәң төш, өн дисәң өнгә охшамаган уйлар өермәсе аны үз кочагына суырды.

Бердәнбер бала булды ул гаиләдә. Әтисе авыл Советы рәисе, әнисе фельдшер иде. Үзсүзле, чая егет булып үсте. Үскәндә үк, әтисе биләгән вазифаның кешеләр өстеннән нинди хокук һәм хакимлек биргәнен күреп, тоеп үсте ул. Әнисе сабыр һәм басынкы, сизгер күңелле гади хатын иде. Зариф әтисе кебек ихтыярлы булырга теләсә дә, әнисенә сыена төшә иде. Шул йомшаклыгын сиздермәскә тырышып ул үзен дорфалык һәм кирәгеннән артык чаярак тотарга тырышты.

Ходай аңа тарих китапларында сурәтләнгән борынгы грек Аллаларын хәтерләткән килеш-килбәт, мөлаем йөз биргән иде. Атлетларча буй-сын, кара дулкын куе чәч, кап-кара зур күзләр, куе кара керфекләр, ак текә маңгай, каракучкыл сыгылмалы тән—болар барысы да сәхнә өчен генә яратылган кебек. Җитмәсә Ходай аны матур тавыш белән дә бүләкләгән иде. Артист булыр бу, диләр иде авылдашлары. Әнисенең аны юрист яки инженер итәсе килсә дә ул урта мәктәпне тәмамлагач сәхнә юлын сайлады. Башкалага килеп укырга керде. Чибәр, талантлы егетне тиз күреп алдылар. Укуы белән бергә ул театр сәхнәсендә рольләр дә уйный башлады. Башта массовкалар, аннары эпизодлар, аннары дублер, геройсөяркә рольләре дә бирә башладылар. Халык, бигрәк тә кызлар аны күрер өчен генә йөри иде театрга. Ул тудырган образлар йөрәкнең түрләренә үтеп кереп күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтә, елата һәм көлдерә, уйландыра һәм юата, нәфрәтләндерә һәм сокландыра иде.

Чыгарылыш елында, диплом спектакле итеп, «Галиябану» белән туган районына кайтып төштеләр алар. Менә-менә печән өсте башланырга тора. Колхоз үзенең машина-трактор, чапкычларын барлый. Агай-эне ел буе якты дөнья күрмәгән «ватык» дип йөртелгән «муравей», «матай», «сәпит»ләрен такта гаражлардан чыгара, арба-мазарын тазарта, чалгы

яный, тырма саплый, гомумән мәш килә; ә авыл, көннәр чабыш аты шикелле ярсу булуына карамастан, зур бәйге алдыннан гына була торган киеренке тынлыкка чумган.

Менә-менә старт бирелер дә халык алны-артны, уңны-сулны күрми яуга ташланыр... Һава кызган тимер кебек, ник бер җил иссен. Хәтта күк йөзе дә куе зәңгәр түгел, кояшта унган аксыл-зәңгәр пәрдә төсендә.

Авыл халкы күләгәдәрәк. Һавада ялан-болыннарда–яңа чәчәк ата башлаган мәтрүшкә, кыргый кәнәфер, клевер исләре. Үзләренең зур мәшәкатьләре белән, беркемгә игътибар итмичә, урман-болын белән авыл арасында эшлекле кыяфәттә бал кортлары оча. Бакча артындагы көмешсу елгасы чирәмлегендә яңа язылган сары май йомарлагы шикелле бәбкәләрен ияртеп, аталы-инәле усал казлар хәтәр ысылдашып, үлән чемчи. Күктә, бик биектә, шырпы башы кадәр генә тилгән каз саклаган малай-шалайның тизрәк салкын суга чумганын көтә.

Артистларны йортларга бүлеп алырга теләүчеләр күп булса да, кая ул, Зариф барысын да ияртеп әтиәнисе йортына кайтып төште. Артистлар верандага, җәйге йортка, өйгә урнаштылар. Әтисе печән өстенә тәгәенләп аерып ашаткан ажгырып торган тәкәне иртә таңнан егып суйды да, эшенә китте.

Йокылары туюдан бигрәк, туяр-туймас ризыкланып йөргән артист халкын тәмле шулпа исе уятты.

«Хәлил, Галиябануың үзенә булсын, әниен бер тәлинкә шулпа ашатса, дип Бари–Исмәгыйль, Зариф–Хәлилнең кабыргасына төртте. Зариф көлеп җибәрде, сикереп торып казанлыкта булышкан әнисе янына килде.

«Улым, иптәшләреңне уят, торсыннар, юынсыннар, хәзер ашарга әзер була»,–диде әнисе.

«Тагын аз гына йокласыннар инде, әни, артист халкы соң ята, соң тора ул»,–дип, өстәл башындагы урындыкка утырды Зариф. Сагынган иде Зариф әти-әнисен, сирәк кайтыла шул туган якка. Әле

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ
## «QAZAN UTLARI»NA 80 YIL

**Ислам Әхмәтҗанов,**

*«Идел-Пресс» Дәүләт унитар предприятиесенең генераль директоры.*

## ТОРМЫШ КИТАБЫ



***Гасырга якын дәвер эчендә «Казан утлары» журналы халкыбызның рухи көзгесенә, әдәбимәдәни энциклопедиясенә әверелде, дисәм, хакыйкатькә һич кенә дә хилафлык китермәмен.***

***Гаҗәп бит, бүгенгесе көндә Мәскәүдә бөтен Рәсәй өчен урыс телендә чыгарыла торган калын журналларның тиражы 5-6 меңнән артмый, ә шул ук вакытта мәркәзебездә «Казан утлары» журналы 9-10 мең тираж белән чыгып ята. Бу, минемчә, халыкның үз журналына, мәдәни энциклопедиясенә ихтирамы ни дәрәҗәдә булуын күрсәтә. Бүген бөтен җирдә дә тормыш гөрли–чәчәк ата, дип әйтә алмыйбыз. Икътисадтагы, сәясәттәге авырлыклар яшәү рәвешебезгә китереп суга, әмма шуңа да карамастан, татар халкы укымышлы халык, ничә гасырлар дәвамында китаптан аерылмаган халык, авызыннан өзеп булса да, акчасын җәлләмичә (хәер, «Казан утлары» әбунә бәясе иң арзан журналлардан санала), яраткан басмасына язылырга тырыша. Ул шул рәвешле рухи ихтыяҗына азык таба.***

***Мин журналны даими рәвештә алтмышынчы еллар азагында укый башладым. «Казан утлары» белән кызыксынып китүемнең үзенә күрә бер тарихы да бар. Казан дәүләт университетында укыган дәвердә***

менә Мәскәүгә ГИТИСка укырга җибәрү турында сүзләр бар, димәк Мәскәүгә китсә, тагын да сирәгрәк кайтачак ул.

Нинди рәхәт туган өйдә, кадерле әнисенең житез хәрәкәтләр белән аш-су әзерләгәнен карап утыру нинди күңелле...

Ләкин күңелен нәрсәдер айкап тора иде Зарифның. Нниндидер тынгысызлык, шом, сагаю бар иде күңел төбендә. Зариф үткән һәм булачак көннәрдәге вакыйгаларны барлап, чамалап чыкты. Юк, алай-болай күңелсезлек сизелми кебек. Кинәт «шылт» итеп хәтеренә төште аның: төш, бүген күргән сәер төш—баеп баручы кып-кызыл кояшны куып атта чаба да чаба, чаба да чаба ул.

Кояшны куып житешүгә бик күп нәрсә бәйле аның тормышында, нәрсәләр икәнен тезеп-тезеп әйтә алмый, тик бу—бик әһәмиятле юрау. Нинидер күзгә күренмәгән көч артка тарта иде аны, тик ул үҗәтләнеп алга барырга тырыша, бар көчен биреп алга ыргыла, кояш аның саен ерагая, байый бара, байый бара иде.

Ул төшен әнисенә сөйләде. Әнисе шомланып китте. Улы янына килеп утырды. Куллары белән ике янагыннан тотып күзләренә карады һәм шомлануын сиздермәскә тырышып: «Дөнья алдаткыч ул улым, булдыра алмаганыңны булдырырга, туктата алмаганыңны куып җитәргә тырышма, булганына канәгатьләнеп, кадерен белеп яшәргә тырыш, төшенне хәерлегә юра, ни юрасаң шул була»,—диде.

Хафалану катыш яратып, улының сөйкемле йөзенә, баһадирдай ныклы гәүдәсенә горурланып карады ул. «Әтисенең яшь чагы»,—дип уйлап алды, улы өчен сөенеп, юньле кешеләргә очрасын, бәхетле булсын иде улы—бердәнбере.

—Нинди хәбәрләр бар авылда әни, нинди яңалыклар?—дип сораша башлады Зариф.

—Яңалыклар... Үрге оч Мөхәммәтзариф бабаң гүр иясе булды, үткән җомга җирләдек, урыны җәннәттә булсын. Кәҗә урам Нәкыя апаң ире үлеп бер ел торгач, күрше Сарыкүл авылына бер тол иргә кияүгә чыккан иде, торалмады,

*сабакташым Эдуард Мостафин белән бергә журнал редакциясенә аның шигырьләрен китергән идек. Эдуард миңа журнал хезмәткәрләренең исемнәрен әйтә, таныштыра, ә мин исә: «Карале син, ә, шушындый кеше шушы микәнни инде ул?!» дип, исемнәре дөньяга танылган олпат шагыйрь, әдипләрне күреп, эчемнән генә тел шартлатып куям. Соңрак безнең тулай торак бүлмәсе үзе дә шагыйрьләр бүлмәсенә әверелде. Журналның соңгы санында дөнья күргән әсәрләр хакында һәм, гомумән, әдәбият тирәсендә бәхәсләр дә куба торган иде.*

*Шәхсән үзем дә, дистә еллар журналистикада эшләү дәверендә, тел-стиль җәһәтеннән уй-фикерләрне гади һәм төгәл итеп укучыларга җиткерүдә Г. Бәширов, Ә. Еники, С. Хәким, М. Мәһдиев, Г. Ахунов кебек өлкән әдипләребездән күп нәрсәгә өйрәндем. Алар иҗаты минем өчен үзенчәлекле зур бер мәктәп булды.*

*«Казан утлары» журналы үзенә кайсы ягы, сыйфаты белән җәлеп итә соң? Әлбәттә, бу сорауга кистереп кенә җавап бирү мөмкин дә түгелдер. Минемчә, безнең бу журналыбыз үзенә күрә бер Тормыш Китабы ролен үти. Анда дөнья күргән әсәрләр безне алга күз ату—фаразлары аша, бәхәсләре аша яшәргә өйрәтә. Ул бит сине: «тегеләй, яисә болай бул!»—дип өйрәтми. Әсәрдәге язмыш борылышларын күздән, күңелдән үткәреп, гыйбрәт алып, анализ ясап, әсәр каһарманнары кичергән халәтне үзең аша кичереп, чагыштырып өйрәнәсең бу тормыш китабыннан!*

*Һәр санны түземсезләнеп көтеп алуымның янә бер сере-хикмәте бар: журнал яңа авторлар белән таныштыра. Алар исә һич көтмәгән җирдән чишмә кебек тибеп чыга, дөньяга аваз сала. Әнә шул чишмә башында аркылы яткан авыр ташларны алып, чишмәне карап-чистартып, тәрбияләп торучы 80 яшьлек нык, таза бәдәнле ил агасы—авыл аксакалы белән чагыштырам мин татар әдәбияты чишмәсе сагында торучы олпат «Казан утлары»н. Соңгы елларда журнал үзенчәлекле әдип Р. Сибатны ачты; һич көтмәгәндә Т. Ахунҗановның (әдәби тәхәллүсе Т. Таһиров, заманында зур түрә—өлкә комитеты секретаре булган бу кешенең шундый каләме бардыр дип,*

кайтты, бичара. Тын алулары, исләре чит, үз Хәмзәмнең өемдә,исләре сенеп калган, шуларны булса да иснәп яшим, ди бахыр. Урман башы Җәннәт әбинең үткән шимбәдә мунчасы янып китте. Бик кызу яга иде шул мунчасын, чабынырга ярата иде. Авылда күнелсез хәбәрләр йөреп тора әле улым. Фатыйма әбиеннең оныгы–дивана Зәбирә кемнәндер алданып, кыз бала тапты. Кайсы явызы шул бахыр Ходай бәндәсенә бәгыре житеп кул сузды икән?!–диде, әнисе авыр сулап.

Зариф дертләп китте. Үзе дә сизмәстән:

—Кемнән икән?–диде.

—И-и-и, улым, акылы тулы түгел бит аның, бичараның, житмәсә теле юк, ни сөйләсен, дәшми. Баласы тугач үзе гел елмая, нарасыен күкрәгенә кысып алга-артка бәвелеп тик утыра иде, диләр.

Тагын шуны сөйлиләр: имештер, Зәбирә бахыркайны, теге йөзе кара ир, бәдбәхет, бер муен чылбырына алдатып алган имеш, диләр. Карт нәнәсенең үзенең бер аягы жирдә, берсе гүрдә, бу кайгыга түзәлмичә түшәккә егылды, районнан килеп Зәбирәнең баласын балалар йортына алып киттеләр.

Бик тарткалашты диләр, бик дулады, ди, Зәбирә, телсез авызы белән өч көн әллә елады, әллә улады, безгә чаклы ишетелеп торды тавышы, бахырның.

Баланы алырга килгән шәфкать туташы, жәлләп, инәсе муенындагы чылбырны баласына алып кидергән, бәлки берзаман, миһербаны килеп, атасы үз нарасыен килеп алыр, билге булсын дип әйткән, ди.

Өч көннән сон, тагын да хәле начарая башлагач, Зәбирәне диваналар йортына озаттык. Бөтен авыл елап калды.

Зариф башына таш ишелеп төшкәндәй хис итте үзен. Эчке халәте тышка чыкты, тамак төбенә йодрык хәтле төен килеп тыгылды, күз аллары карангыланды. Ул тизтиз атлап бәрәнге бакчасы аша елгага төшеп китте.

Чынмы бу? Булырга мөмкинме? Бер мизгелдә мен сорау үтеп китте башыннан...

***халыкчан телгә ия, дип уйламаган идем) журнал аша шәп әсәре укучыларга барып ирешә. Факил Сафин романнарын да кызыксынып укып барам.***

***Кайчак, дөнья булгач, төче, ялтыравыклы сүзләр дә сөйләргә туры килә. Ә «Казан утлары» хакында сүз чыкса, һич кенә дә ялтыравык сүз түгел, ә бәлки күңелең түреннән чыккан ихлас сүзне сөйлисең. «Казан утлары»ның иң тәүге, иң беренче укучылары–безнең «Идел-Пресс» басмаханәсе хезмәткәрләре! Әле басылып кына килә торган, яңа «табадан төшкән» журнал битләрен (аны әле кисәргә дә, төпләргә дә өлгермәгәннәр, йә ул берәр повесть, поэма йә хикәянең бер кисәге була) станок артында ук укып торалар. Журналга, туган телебезгә булган мөнәсәбәтне ап-ачык күрсәтүче күренеш бу. «Болай булгач, яшибез, милләт буларак яшибез!»–дигән сүз бу!***

***«Казан утлары»–мөхтәрәм журнал, аны бар итүчеләр дә–мөхтәрәм коллектив. Биредә эшләүче хезмәткәрләрнең һәркайсының тормышта, әдәбиятта үз урыны бар, яшьме ул, инде буын ныгыткапмы, йә булмаса аксакал булып киләме, «Казан утлары» дигән олуг исемне, символны үз җилкәсендә йөртә торган олпат затлар, каләм осталары алар. Журнал янә бик күп еллар халкыбызга хезмәт итсен, яңа иҗат җимешләре белән сөендерсен, Тормыш мәктәбе, Тормыш Китабы дигән исемгә киләчәктә дә лаек булып калсын, бәрхеткә төреп йөртерлек журналыбыз ул!***

Былтыр, гастрольдән соң, берничә көнгә ялга кайткан иде ул.

Җәй ахыры, тик күз башы түгел әле. Дөнья—бала тапканнан соң рәхәтләнеп йокымсырап изрәп ял итүче ана шикелле. Сулар тын инде, тыныч, ләкин җып-җылы. Агачларга бераз сары иңгән, тик табигать әле яшьлеген югалтмаган. Анда-санда куакларда кара, кызыл бөрлегән шаян кыз шикелле күз кысып үзенә чакыра, инде таҗларына тимгел төшә башлаган ромашкалар, кыргый клевер чәчәкләре рәхәт ял итә, сукмак читләп бар куәтен, җанын биреп шайтан таяклары йодрык хәтле ал чәчәкләрен «менә мин нинди», дигән төсле масаеп кояшка сузган. Көмешсу өстендә буй җиткән каз-үрдәк канат кагына, кырчын таш арасында энә буе вак балыклар җил чемчи.

Зариф тынычланып ял итәр өчен икенче ярга йөзеп чыкты. Әнисе дә: «Шунда елгага якын гына гөлҗимеш куаклары бар иде, иренмәсән әзрәк җимешен җыеп алып кайт әле, улым, кыш көне үзе бер дару ул»,— дип әйтеп калды. Зариф ялангач тәнен кояшка куеп, комга күмелеп, рәхәт изрәп озак ятты.

Җылы, алтынсыман елга комы аның кайнар тәнен рәхәт иркәләп аякларыннан, янбашларыннан, күкрәкләреннән, эченнән җиргә коела. Күңел әллә нинди тауларны җимереп, кыялар актарырлык дәрт һәм киеренкелек белән каядыр ашкына, тынычсызлана, талпына иде.

Бу халәттән аны кинәт су чәчрәгән тавыш уятып җибәрде. Ул башын күтәреп аргы якка карады. Елга аша кемдер бу ярга йөзә иде.

Зариф аптырап калды, җәй ахырында аннан башка тагын кем җөрьәт итеп су керә икән? Бала-чага түгел, колачы киң, ныклы беләкләре су өстендә ялтлап-ялтлап китә, ялангач янбашлары, ныклы аяклары хәрәкәт унаена ак балык сырты шикелле янып-янып су өстендә чагылып ала.

Йөзүче бу якка чыкты, яр буена аяк басты. Бу шәп-шәрә хатын-кыз иде. Хәзер генә танып алды Зариф аны. Зәбирә. Дивана Зәбирә, әпә Зәбирә дип тә йөртәләр иде аны авылда. Әти-әнисеннән яшьли ятим калып, Фатыйма әбисе кулында тәрбияләнгән бу кыз, бала чакта телсез дә, исәр дә түгел иде.

Зарифтан өч сыйныфка түбәнрәк укыды ул. Шулай да олырак егетләр ана игътибар итәләр иде инде.

Дулкын-дулкын булып иңнәренә таралган житен төсле чәчләре, кара куе керфекләр белән уратылган күкчәчәкләр шикелле зур зәңгәр күзләре, яшь булса да инде билгеләнеп килгән зифа буе күпләрне җәлеп итәчәк иде, үсеп җиткәч.

Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас, дигәннәр. Бәхетсезлек аяк астында икән шул. Көз көне мәктәп балалары колхоз бәрәңгесен чыгарырга барганда, «Беларусь» кинәт тарттырып җибәрә һәм арбага төялгән балалар арасыннан Зәбирә егылып төшеп аның югалта.

Озак ятты ул район һәм шәһәр хастаханәләрендә. Кайтканда ул элеккеге Зәбирә түгел иде, әйтерсең, алыштырып куйганнар. Ул телдән язды, хәтерен югалтты, сөйләшмәс һәм кеше белән аралашмас булды, алмашына башлады.

Шул Зәбирә йөзеп чыкты елганың бу ярына һәм ул шәп-шәрә иде. Зариф торып басты. Матур иде кыз, ап-ак шикәр шикелле зифа тәненнән энҗе-энҗе тамчылар тәгәрәп аяк астындагы алтын комга төшеп югала. Бәллүр шикелле ике тамчы тулы күкрәгенең пешкән чия төсле бүртеп торган очларына кунган, чәчләре дулкын-дулкын чуалып ачык иңнәрендә ята. «Горгона» кебек, дип, ирексездән соклануын яшерми уйлап алды Зариф.

Кыз башта куркып киткән кебек булды, ләкин аның игътибарын шунда ук Зариф муенындагы медальон җәлеп итте. Ул тартынмый-нитми якын ук килеп шул медальонга үрелде. Зарифка әйтерсең ут капты, аның тыны кысылды, йөрәге күкрәк читлеген җимерердәй булып дөп-

дөп тибә башлады. Ул бер кулы белән кызны биленнән кочып алып үзенә тартты.

«Ошыймы?–дип сорады Зариф аннан, калтыранган тавыш белән,– миңа гөлҗимеш жыешсаң, бүләк итәм үзеңә».

Кыз су буен яңгыратып көлеп җибәрде, нәрсәдер әйтергә теләгәндәй өн ишеттерде. Зариф аны биленнән кочаклап урман арасына алып кереп китте...

Икенче көнне Зариф, ашыгыч эшем бар, дип, ялы беткәнне дә көтмичә, тиз генә җыенды да иртә таңнан шәһәренә тайды.

* * *

Төн тынычлыгын тыңлап ятудан да серлерәк, гаҗәбрәк нәрсә бар микән авыру кеше өчен бу дөньяда.

Менә ул–син яшәгән, яраткан, нәфрәтләнгән, шатланган, кайгырган, өметләнгән һәм өметләреңне җимергән, ләкин бик кадерле булган дөнья. Ул якын гына кебек, синең күз алдында гына, синең янында гына, сине уратып алган, сиңа таныш та, үз дә, ләкин шул ук вакытта инде ул читтә, ифрат еракта, ул инде сиңа ят та, дошман да, сиңа битараф та, салкын да кебек. Бу дөнья үлем түшәгендә ятканнарга бөтенләй икенче үлчәүләрдә үлчәнә, икенче яссылыкта ята икән.

Ә монысы хәзергесе–ач күзләре белән сине үтәдән-үтә тишеп караучысы, очлы озын тырнакларын күкрәгеңә батырырга әзер торганы дәһшәтле дә, шул ук вакытта серле дә иде. Ул аяусыз һәм куркыныч, шул ук вакытта аны аңларга, төшенергә тырышу, тиздән, бик тиздән үзеннең инде аныкы булачагыңны тою хисе кире этәрә, һәм шул ук вакытта котылгысыз рәвештә үзенә тарта. Зариф, авыртулары вакытлыча булса да поскан арада, эчке бер кызыксыну белән бу ике халәт–ике дөнья арасындагы аермалылыкны аңларга тырышты.

Менә аның куллары, кайчандыр җимертеп эш эшләрлек булган ныклы мускуллары, күпме хезмәт иткән–язган, исәпләгән, аш-су җыйган, күпме гүзәл хатын-кыз тәненә, чәчләренә кагылуын калтыранып көткән озын көчле бармаклары... Беләкләре хәзер тиресе бушап–буш оек кебек сәлперәеп калган, сары, зәңгәр тырнаклары тырпайган, бармаклары калаклар кебек шыксыз һәм кансыз...

Тегесе–исән-сау чактагысы–ваемсызлык, мәгънәсез максатлар артыннан чабу, дан, шөһрәт, байлык, казанышлар эзләү, үз фикерләреннән дөреслегенә инанырга тырышу һәм башкаларга да шуны исбатларга омтылу, вак күңел ачулар белән урап алынган, соңгы чиктә өч тиенлек дөнья мәшәкатьләре эчендә эрү, юкка чыгу, көлгә әйләнү. Бик кирәкле нәрсәләргә юлыгып аймылышта калмады микән, күрмичә, сизмичә үтеп китмәде микән ул аларны, кул сузымы арада гына калмадымы икән ул яшәү мәгънәсе дигән нәрсә Зариф өчен?

Нигә монысы–бу халәте, бу дөньясы, ягъни әҗәл якасындагысы шомлы әйдәү, серле пышылдау, кайдадыр каерылып, газапланып ашкыну, алгысу һәм гаҗизлек белән тулы?

Ул күзләрен зур ачып, Европа стилендә эшләнгән затлы йорт җиһазлары өстендә тәрәзә аша төшкән тәүге нурлар яктысында акрын гына, сизелер-сизелмәс балкыш булып тибрәлгән тузан бөртекләрен, мен тапкыр күреп тә игътибар итмәгән тәрәзә төбендә балкып чәчкә аткан кактус гөлен, нигәдер кыш уртасында уянган чебеннең пыялага бәргәләнүен, ябылып бетмәгән краннан тамган суның яшәүне исбат итеп тып та тып, тып та тып тамуын–кинәт бар күзәнәкләре белән тойды. Нәкъ менә шушылар яшәү сере, яшәү мәгънәсе икән! Менә нәрсәләрне ишетергә, күрергә вакыт җитмәгән... Һәр мизгелнең кадерен белергә кирәк булган... Мәңгелек алдында барыбыз да тузан гына... Уйлары аны янадан хатирәләрен барларга, һәрберсенә соңлап булса да үз бәясен бирергә чакырды.

Әминәгә ашыгып өйләнде ул. Зәбирә белән булган хәлдән соң, нык курыкты егет, вөҗданы җәзалады, нигә кагылды ул ана, нигә Ходай колын-гөнаһсыз кызны нәфесен тыя алмый файдаланды? Мәскәүгә укырга китәр алдыннан, психик авыруларны дәвалау больницасына барып, Зәбирәне эзләп табарга булды ул, аны вөҗдан газабыннан бигрәк тә бу хәлгә ышанмау этәрде. Дежурда торучы шәфкать туташы журналдан карап Зәбирәнең ничәнче палатада икәнен әйтте: «Буйный түгел, очраштыра алабыз»,–диделәр. Ерак туганы дип таныштырды ул үзен.

Төрмәдәге кебек рәшәткәле һәм тимер ишекле кысан гына бүлмәгә керттеләр Зарифны. Артыннан шалтыр-шолтыр ишек бикләнде. Күп тә үтми әзмәвердәй санитар чандыр гәүдәле, ап-ак йөзле, Зәбирәгә бер җире белән дә охшамаган кызны алып килде. Өстендә соры килешсез халат, дулкынланып иннәренә таралган чәчләре урынына кырып алдырылган такыр баш. Кочагына тастымалдан бәби шикелле нәрсә төреп күтәргән.

Зариф куркып китте, танып килеп ябышса? Санитар Зәбирәне Зариф каршындагы урындыкка алып килеп утыртты. «Менә бу, синең брат, Забирочка»,–диде ул ана. «Ныклабрак кара әле, таныйсыңмы?» Зәбирә күзләрен күтәреп Зарифка карады. Йә, Хода, шул ук күзләр, ләкин алар буп-буш. Аларда котып салкынлыгы, алар хиссез һәм хәрәкәтсез. Күзләр Зарифка бактылар, бер генә мизгелгә аларда нидер уянгандай булды, ниндидер киеренкелек белән күз каралары кинәйде. Ләкин шул ук секундта алар тагын сүнде, тагын куенындагы төргәккә юнәлде. Зәбирә алга-артка чайкала-чайкала «бала тибрәтә» башлады. Санитар: «Сезне танudымы? Бахыр көне-төне шушы төргәкне бала урынына тибрәтә, кулыннан да төшерми, юньләп ашамый да, эчми дә, хәле бер дә яхшыру ягына түгел»,–диде.

Зариф, алып килгән күчтәнәчләрен калдырып, авыр күңел белән чыгып китте. Артыннан тимер рәшәткәле авыр ишек шалтор-шолтыр ябылып Зәбирәне мәңгелеккә үзенә йотты.

Кайгысын һәм үкенүен басар өчен эчеп тә карады Зариф, ләкин файдасы тимәде. Күз алдында боз шикелле хәрәкәтсез күзләр генә иде. Колагында гел шалтырап ябылган ишек тавышы чыңлады.

Мәскәүгә китәргә бер атна калуга ул Әминәне очратты. Китапханәчеләр әзерли торган техникумда укый иде кыз. Үзеннән ике яшькә генә кече. Басынкы авыл кызы, үскән чагында чама белән дөнья көтүче тәртипле гади колхозчы гаиләсендә гөнаһ һәм савап, яхшы һәм яман, бар һәм юкның нәрсә икәнен аңлап үскән кыз иде. Бер күрүдә ошатты аны Зариф. Җыйнак кына урта буйлы, тотышы гади һәм оялчан. Инде күп кызларны күреп, аларга үз бәясен биреп өйрәнгән егет, Әминәдән яхшы хатын һәм кайгыртучан ана чыгасын чамалады.

Зәбирә хакындагы газаплы уйлар да ераграк яшеренгән шикелле булды. Алар ашыктырып кына ЗАГСка керделәр, кызның әниләренә кайтып тиз генә никах укытып алдылар. Әминә укуын дәвам итеп калды, Зариф Мәскәүгә очты.

Мәскәүдәге уку Зарифка күп нәрсә бирде, зур киңлекләр ачты, кызыклы шәхесләр, өр-яңа дөнья белән таныштырды. Фикер һәм хис офыклары киңәйде, белем сандыгы баеды.

Ул арада Әминә Азат исемле малай табып үстерә торды. Мәскәү матур һәм шаукымлы дөнья, ул үзенә әйди, йота, күзләрне камаштыра, кыйблаларны саташтыра. Әз-мәз «шаярулары» булмады түгел Зарифның Мәскәүдә, ләкин Зәбирә белән булган хәл аның баш очында утлы кисәү кебек гел кисәтеп торды. «Шашма», «шашма», «шашма»...

Укудан соң үз шәһәре аны көтеп һәм киң колач җәеп каршы алды. Түрә абзыйлар да ана зур игътибар бирделәр, ярдәмнәрен җәлләмәделәр, чөнки Зарифка зур өметләр багланган иде, милли театрны дөнья киңлегенә чыгарырга кирәк иде. Үзе дә әллә яшьлеге, әллә тәвәккәллелеге аркасында моңарчы кулланылмаган сәнгать ысулларын, яңалыкларын кулланып,

кыю экспериментлар кертеп, иске сәхнә әсәрләренең дә миллилеген һәм халыкчанлыгын югалтмыйча тамашачыга янача ачты, көтелмәгәнчә эзләнүләр белән көне-төне эшләде. Тәүлегенең унбиш-егерме сәгать вакыты эш белән үтте.

Инде картаеп, катып, теше-тырнагы белән яналыкка карышкан «иске гвардия»нең күбесеннән җайлап-майлап, исем-фәлән, персональ пенсия-мазар бирдереп, бенефисларын үткәреп котылырга тырышты. Театр труппасына күбрәк яшьләрне җәлеп итәргә омтылды. Аның девизы: «Сәхнә–яшьлек өчен!», «Картлык чама белән, яшьлек чамасызлыгы белән шәп!»–иде. Күп тә үтмәде ана театрның баш режиссеры вазифасын йөкләделәр. Ат кебек эшләүләр һәм республика җитәкчелегенең ярдәме белән театр ил күләмендә игътибар казана башлады. Бигрәк тә төрки дөньяда даны күтәрелде. Эш булгач аны күрсәтә белергә дә кирәк иде, катлаулы декорация, кыйммәткә төшкән костюмнар дип тормадылар (хөкүмәт алар өчен акча җәлләмәде), бөтен Урта Азия, Себер, Кавказ, хәтта Балтыйк буе шәһәрләренә дә гастрольләргә йөрделәр. Шулай театрның бәһасе күтәрелде, республиканың даны артты. Зариф өстәлендә мактау грамоталары, дипломнар, күкрәгендә медаль-орденнар, яхшы һәм иркен фатир, кыйммәтле йорт җиһазлары артты.

Тик бәхет дигән нәрсә генә баеган саен кими барды. Гаилә учагы сүрелә, Әминә белән аралар салкыная төште. Уллары Азат әтисе тәрбиясенә түгел, подъезд дуслары карамагына күчә барды. Зариф күп вакытларын эштә, командировкаларда, гастрольләрдә үткәргәнгә, ялгызлыктан газапланган Әминә бар назын малаена бирергә тырышты, тик «Ана күнеле балада, бала күнеле–далада»,–дип халык юкка әйтмәгән шул. Иркә һәм үзсүзле булып үсте уллары. Мәктәпне тәмамлагач, нефтьчеләр әзерләү институтына керде, дуслары артты, эчкәләп кайта башлады.

Инде куып чыгарабыз, дигәндә әтисе аркасында тагын укуында торып калды. Наркотиклар куллана башлады Азат. Гаилә һәлакәткә табан тәгәрәде. Ике арага эремәслек салкынлык керде. Әминәнең сарыф ителмәгән мәхәббәте, күнел җылысы аяусыз ут кебек сиздермичә эчтән генә үзен-үзе ашады. Җыелган байлык та, туклык, дан да инде аны кызыксындыра алмады. Чамадан тыш кулланылган наркотиктан соң уллары бу дөньядан китеп өч ай үтүгә, өендәге бернигә дә кагылмыйча, бер тиенгә дә тимичә, бары тик өс киемнәрен генә алып, инде пенсия яшендәге Әминә, авылына–картаеп барган ялгыз әнисен карарга кайтып китте. «Мине эзләп йөрмә, безнең арада берни дә калмады. Мина синнән берни дә кирәкми, пенсиям җитә, аерылышу гаризасын язып киттем»,–дигән иде ул соңгы язуында.

Зариф аптырап калды. Бу аның өчен яналык иде. Әминә!? Әллә читтә күнел ачулары, хатын-кызлар белән шаяргалауларын белгәнме ул?! Хәер, белмәгән дип уйларга мөмкин түгел иде, чөнки ул алардан әллә ни сер ясамады, чөнки боларның берсе дә чын нәрсә түгел икәнен үзе дә, Әминә дә анлый дип уйлый иде ул. Әминә беркайчан да әр яки битәрләү сүзе катмады ана, бигрәк тә соңгы елларда шуклыкларын күрмәмешкә салышты. Үзенең инде Зариф өчен карт икәнен анлый иде ул. Сәнгать дөньясында, сихри әкият дөньясында яшәгән Зарифның күнеле мут икәнен белсә дә әрнүләрен сиздермәде. Гомер буе икәү яшәп тә, ялгызлыктан көл булган күнел төбендәге соңгы кузлар уллары үлү белән бөтенләй сүнде. Улын күмеп кайткач бер генә сүз әйтте Әминә ана: «Син гаепле!». Кайгыдан бөгелеп төшкән Зариф дәшмәде. Алар бөтенләй сөйләшмәс булдылар. Бары эштә генә юаныч таба иде Зариф. Көне-төне эштә янды, кайгысын шунда басты.

Бүлмә җыештыручы, какча буйлы, ап-ак, чирләшкәгә охшаган идән юучы кыз Зарифның башын тотып, бертуктаусыз тәмәке көйрәткән чагында кереп, сүзсез генә юыштырып-җыештырып йөри дә, ишек төбендә тукталып озак-озак карап тора иде.

Театрда Зарифның кайгысын барысы да беләләр. Хатыны киткәч

бигрәк тә авыр икәнен аңлап торалар иде. Идән юучының: «Зариф абый, сезнең өчен нәрсәдер эшләргә түгелме, бәлки берәр ярдәм кирәктер?»—дигән сүзенә Зариф башын күтәрде. Ул сигаретын көл савытына басты да: «Кем сез, ә, әйе бит әле, юк, сеңлем, кирәкми, рәхмәт, миңа көл савытын гына юыгыз да...» Ул урыныннан торып көл савытын кызга сузды. Зәп-зәңгәр күкне хәтерләткән күзләр—бу ап-ак ябык биттә ике зәбәрҗәт кебек күзләр генә яна иде. Яулыкны күтәреп колак яныннан бер дулкын кара чәчләре килеп чыккан. Бик таныш һәм бик якын кебек тоелды Зарифка бу күзләр. «Чирләмәсә, чибәр генә буласы икән бу бала»,—дип уйлап алды ул.

«Сез кайчаннан бирле эшлисез биредә, сеңлем, мин сезне беренче күрәм, исемегез ничек?

«Әй, Зариф абый, мин бит инде театрда ярты ел эшлим, Нәҗибә минем исемем, сезнең бүлмәне җыештыручы хатын декретка киткәч, мина юарга куштылар. Иренмим, җыештырам, акчасы күбрәк булыр. Сезнең бүлмәне мин инде ике атна юам, сез генә гел эш белән мавыгып, мине күрмисез, чүп савытын аягыгыз белән генә этеп куясыз. Шуңа күрә бүлмәгезне, йә сез кайтып киткәч, йә сез килгәнче иртән юып алам.»

«Алай икән, гафу ит сеңлем, бик мәшәкатьле чагым, кайгылы вакытым. Улымны җирләдем, хатыным миннән китте.»

Аның бу кызның күкрәгенә сыенып туйганчы елыйсы килде. Ирексездән күзләренә килгән яшьләрне сиздермәскә тырышты.

Зариф тукталып калды, ни өчен әйтте әле ул кайгысын беренче күргән кешегә?

«Абый, хәлегезне аңлыйм, авыр икәнен беләм, Ходай ярдәм бирсен, бик бетеренмәгез, Коръән күп еларга кушмаган, күп еласаң мәет су эчендә ята, ди иде минем Галимә апам. Мәчеткә барып хәер бирегез, кайгыгыз басылыр.»

Бу инде күпләр кебек күнел булсынга әйтү генә түгел, чын йөрәктән әйтелгән, гади генә, кешеләрчә юату сүзләре иде.

«Ярый, сеңлем, барыгыз, ишекне ябып чыгыгыз», диде Зариф һәм берүзе калып, улын җирләп, хатыны киткәннән соң беренче тапкыр ана кешеләрчә якты, җылы итеп дәшүдән күңеле тулып, елау урынына яралы ерткыч кебек ыңгырашып өстәлгә капланды.

Ничек болай булды соң бу? Кайда хата җибәрде ул? Бердәнбер улының фаҗигасендә дә, Әминә әйтмешли, ул гына гаепле микәнни? Ә гаилә җимерелүгә?

Дөресен генә әйткәндә, артык яратып яшәмәде ул Әминәне. Ләкин күңеле тыныч иде. Гаилә, кайтып керер өй, өйдә сине көтүче кемдер бар, җитмимени шул? Җитмәгән икән шул. Ул роль алыр өчен, зур сәхнәгә аяк басар өчен барысына да әзер иде. Яшь артисткалар белән рестораннарда, су буйларында, сауналарда типтергәндә, аның гаиләсе, иң якын кешеләре фаҗига кичергән. Әминәсе барысын да белеп, аңлап торган, бала атасыз үскән. Аның җылысы җитмәгән иң якын кешеләренә. Димәк, ул гаепле булып чыга.

Икенче көнне ул хатынын алырга авылга кайтып китте. Бәбкә үләне баскан ихата, ап-ак итеп кырып юылган күтәрмәдә ак ситсы күлмәктән бәләкәй генә калган әбисе утыра. Әминә аның ап-ак чәчләрен тарап үрә иде. Ничә еллар ялгыз калган әбисен дә кайтып күргәне, игътибар биргәне юк икән бит аның.

Әминәсе дә әнисенә ошап бара икән. Кайгыдан бәләкәй генә калган, бөрешкән. Ул күзләрен күтәреп Зарифка карады. Сүзсез дә барысы аңлашыла иде. Чакматаш кебек каткан иде Әминәнең күңеле. Ике генә сүз әйтте ул: «Юк! Йөрмә!» Бу ике сүздә тыгызланып йомарланган тау шикелле рәнҗеш тә, үпкә дә, нәфрәт тә бар иде.

Авыр уйлар белән кайтты Зариф шәһәргә. Ул туры театрга китте. Сәхнәдә спектакль бара. Театрда спектакль барган чакта гына була торган

киеренке тынлык, ул бүлмәсенә үтте. Бүлмә ачык иде. Нәҗибә бүлмә идәнен юа, һәрбер хәрәкәте, гәүдә йөреше эшенә шулкадәр тач туры килә, ул бер дә кирәксез һәм артык хәрәкәт ясамый, «лентяйка» биюче җитезлеге белән бүлмә почмакларында, кәнәфи, өстәл асларында «биеп» ала да, чиләк тулы суга чума. Өйрәнеп беткән оста куллар җәһәт кенә чүпрәкне чайкап боралар да янадан эшкә тотыналар. «Чын мәгънәсендә һәр эшнең остасы булырга кирәк, ул үзенчә бәхетле»,—дип уйлап алды Зариф Нәҗибәгә сокланып. Аңа бу дөньяда җан кыеп көрәшергә, җәмгыятьтә үз-үзеңне, вазифаңны, дәрәҗәңне югалтмас өчен бар көчеңне биреп эшләргә, теш-тырнак, терсәк белән төртешергә, интригалар белән шөгыльләнергә, «зур» абзыйларга ярарга тырышырга кирәкми. Аның тормышында, эшендә яман да, мәкер дә, алдау һәм алдану ачысы да юк, дип ирексездән көнләшеп куйды Зариф.

Нәҗибә чүпрәк борган җиреннән башын күтәрде, турайды:

«Зариф абый, кайттыгызмы, ничек?»

«Берничек тә түгел, сеңлем, апаң кире кайтмады.»

«Яхшы түгел, алай олыгайган ирне ташлап китү, минә минем якын кешем булса, мәңгегә дә ташламас идем. Сез кайгырмагыз, әгәр кирәк икән мин сезнең йортыгызны җыештырырмын, ашарга пешерермен, керегезне юармын, миңа бу эшләр һич кенә дә авыр түгел, көндез мин барыбер бушмын»,—диде Нәҗибә чын күңелдән.

«Рәхмәт, сеңлем, гаиләгездә ачуланырлар бит?»

«Минем беркемем дә юк, абый, мин бит детдом баласы. Әнием үлгән, әтием бөтенләй булмаган, мине башта күкрәк балалары йортында асраганнар, аннары үсә төшкәч, детдомнан детдомга күчереп йөрттеләр. Бер генә якын кешем бар иде минем, тәрбияче Галимә апай. Мәктәпне тәмамлагач һөнәр училищесында пешекчелеккә укытып чыгарды, аннары үзенең бәләкәй генә коммуналка фатирына прописка кертте. Олыгайган иде инде, беркеме дә юк, авырый иде, һөнәрем буенча эш булмады, урам себерүче булып эшкә урнаштым, көндезләрен-төннәрен авыру Галимә апаны карадым, иртәле-кич урам себердем, подъездларны юдым. Галимә апа дөнья куйгач, үзем дә кар көрәп, суыкларда урам себереп сәламәтлегемне югалта яздым, шуннан соң бәхеткә каршы, шушы матур, җылы театрга эшкә урнаша алдым.

Әй, матур да инде монда, әкият дөньясы кебек, их минем дә әтием-әнием булса, мине укытып чыгарган булсалар, мин шушындый сәхнәләрдә уйный алсам... Юк шул, андый бәхет миңа эләкмәде. Нинди каты бәгырьле әти мине ташлап киткәндер инде, нигә әнием үлеп калгандыр, нигә әтием мине эзләп тапмаган икән, кем икән ул? Бик зур генерал микән, начальник микән? Яхшы кеше булса, мине ташламас иде, әллә берәр эчкече, я берәр бомждыр әле.

Мин барыбер ялгыз түгел, абый, өемдә песием бар, «Йомшак» атлы, бик акыллы, паласны пычратмый, тартма белән ком куям да, мин өйдә юкта, шунда утыра, ә кайткач тышка чыгып керә, шулай булгач мин ялгыз түгел. Минә хәзер сез бар, сезне тәрбиялим. Тартуны ташларга кирәк сезгә. Беләсезме, сезгә витамин җитми, мин сезгә үләннәр кайнатып алып килермен, бу «Боржоми»—фәлән агу гына ул, аларны эчмәгез башка».

Зарифның күңеленә инде олыгаеп барган Нәҗибәнең бала кебек беркатлы самими такылдавы сары май кебек рәхәтлек бирә, тынычландыра, юата, кадерле әнисе кебек иркәли, кайгырта сыман тоелды аңа.

Тормыш үзенекен итте. Яралар төзәлә, югалтулар әкренләп онытыла барды. Дүрт айдан соң алар Әзәрбайҗанга гастрольләргә очтылар. Шунда танышты якыннан Зариф Альбина белән. Сәнгать училищесын яңа бетереп, массовкаларда уйнаучы кыз үтә дә үткер һәм чая иде. Ә көлүе чишмә чылтыравы шикелле. Ирексездән шул көлүе җәлеп итте Зарифны. Талант ягы чамалы булса да буй-сыны зифа иде Альбинаның. Альбинага ул үлеп гашыйк булды.

* * *

Пианино өстендәге сәгать иртәнге алтыны күрсәтә. Зариф дарунын көче бетә башлаганын тойды. «Ерткыч» өнендә кыбырдый, үрсәләнә башлады. Менә анын өн авызыннан ин беренче йонлач аяклары белән озын кәкре тырнаклары күренде, менә әкренләп жанвар дисән жанвар түгел, куркыныч тәмуг женнәре шикелле ямьсез борыны, ыржаеп торган тешләре күренә башлады.

Зариф көч-хәл белән күтәрелеп чираттагы даруын капты. Йокылыуяулы халәт аны акрын гына тагын томанга урый башлады.

Кинәт телефон шылтыравы аны уятып жибәрде. Күзләрен ачуга тан яктылыгы сызылып кына тәрәзә аша бүлмәгә үтә башлаган иде. Тән берни дә сизми. Чирнен көн-төн буе котыргыч эшеннән арып-алжып торган иртәнге ял вакыты иде.

Тагын телефон чынлады. Зариф авыр гына үрелеп янындагы тумбочка өстеннән трубканы алды. Ул арада күрше йокы бүлмәсендә Альбина да трубканы күтәрде. Зариф трубканы кире салырга теләде, ләкин телефоннын икенче башында ир-ат тавышы ишетеп сөйләшүгә колак салды.

—Привет.

—Привет,—диде Альбина,—нигә өйгә шалтыратасын, мин бит сина үзем хәбәр бирермен, дидем, нәрсә булды?

—Дорогая, поездканы тизләтергә кирәк, дача хужалары бүген кич юлга кузгалырга булганнар, ниндидер ашыгыч эш бугай. Сәгать өчтә сөйләшенгән урында бул. Мин сине шуннан алып китәрмен.

—Нигә алай, син бит икенче атнада барабыз, дигән иден. Мин бит теге картны больницага урнаштырып китәргә тиеш идем. Нәрсә эшләргә сон?—диде Альбина.

—Берни дә булмас әле ул үләтенә бер атна эчендә, калдыр да кит, ашарына хәстәрлә дә. Әле үз аягында йөри булса кирәк бит.

—Шулаен-шулай да...

—Ярар, пока, жду, целую.

—Бу атнада нотариусны чакыртып завещаниесен дә алдырырга иде бит әле. Әллә үлеп китәр... Теге карчыгы судлаша башласа?!

—Ну ладно, икенче атнада эшләтерсен әле, аңынчы гына үлмәс, витаминнар бир...

Зариф бу кадәр оятсызлыкны көтмәгән иде. Бу—үзе укытып, үзе артист ясаган, герой образларын уйнаучы егет иде. Ул акрын гына трубканы куйды.

Картлыкны алдатып, батып барган кояшны куып тотарга тырышып, ашкына-ашкына яратты бит ул бу кызны. Бар булган чәчелми-түгелми калган хисләрен, жылылыгын, сонгы ин мөкатдәс гыйшкын биреп яратты ул аны. Сонгы юанычым, аккош жырым, син, дия иде ул ана.

Яшьлегендә үз хатынына, баласына бирә алмаган назны, хәстәрлекне биреп бетерәсе килде анын Альбинага. Анын сыгылмалы назлы кайнар тәне, озын нечкә куллары кагылу белән эреп китә иде ул. Шуна да берни дә жәлләмәде ул аннан. Ин беренче итеп Альбинадан театрнын примадоннасы ясады. Чибәр иде кыз, ә талант урынына режиссер осталыгы, үз-үзе өстендә эшләү, ирнен даны, шөһрәте дә килеп кушылгач егерме биш яшьлек сылудан менә дигән сәхнә гүзәле килеп чыкты.

Танылган режиссерның һәм артистның яшь хатыны булып сыйхөрмәттә яшәү бик ошады Альбинага. Ин беренче итеп ул ЗАГСка керү мәсьәләсен куйды. Зариф бу хәтлесен үк көтмәгән иде.

«Яшәп карыйк әле, гүзәлем, мин бит синен өчен карт инде, бераз көтик»,—дисә дә, ай-ваена карамыйча, Әминә белән аерып, үзе белән никах теркәде. Ин якын дусты булган Бари гына:

«Зариф дус, ашыкма әле, бу чибәркәен чабыш аты кебек уйнаклап тора, тәртәгә кертә алмассын моны тиз генә, өйрәт, үзе дә ияләшсен»,—диде.

Халык әйтә: «Төнге кәккүк көндезге кәккүктән уздырып җибәрә»,–ди. Альбина барыбер үзенекен итте. Хатыны китеп, ярты ел үтүгә, өйгә ять-яшь, янып торган хатын кереп хуҗабикә булды. Ләззәтле иде төннәр, таннар балкып ата, кичләр сызылып үзенә чакыра иде, ялкынлы, шул ук вакытта күңел тынычлыгы бирә торган мәхәббәткә сусаган иде Зариф.

«Мин дә яшәгәнмен хатын белән»,–дип уйлый иде ул Әминә турында. Гомер буе тәне тартынды, оялчан, кыюсыз булды шул Әминә. Зариф арттырып җибәрә башласа, шундук бөрешеп, куркып, оялып кала иде. «Тун тәпәч»,–дип сүгә иде Зариф аны эченнән генә. Шуна да аны тәртәләре еш кына читкә каерды. Чит кызлар кыю, оста, усал иделәр. Ләкин алар белән Зариф бушану сизсә дә күңел тутырырлык хисләр таба алмады.

Менә, ниһаять, таптым, дип уйлады ул Альбина турында. Олыгайган көнемдә Ходай мина олы итеп бәхет бирде, барлык бушка үткән елларын, юкка янган хисләрең өчен мә сина, мәхәббәт, дип, китереп тоттырды... Ин затлы туннар, бизәнү әйберләре, кыйммәтле йөзек, алка, беләзекләр алып кидерде, күлмәк-костюмнарын шәһәрнең иң яхшы тегүчеләрендә генә тектерде. Кеше арасында Альбинаның үзен култыклап узуы, уйнаса–сәхнәдә, башкалар уйнаса–янында, затлы яшь хатын белән спектакль премьераларында бергә утыру Зарифка искиткеч горурлык, күңеленә канәгатьлек бирә иде. Мин-минлеген назлый иде. Кулуарларда Зарифка бертөрле елмаеп, артыннан мыскыллы ыржаеп калган яшь артистларның Альбина тирәсендә бөтерелгәннәрен дә күрмәде түгел, күрде, ләкин игътибарга алырга тырышмады, ышана иде ул хатынына. Нәҗибә генә яратмады Альбинаны. Аларның өйләнешкәнен ишеткәч, өйләренә дә килмәс булды. Зарифка арты беләнрәк борылып җыештыра башлады бүлмәсен дә.

«Нәрсә булды, Нәҗибә сенлем, ни өчен үпкәләден мина, хәлләренне дә сөйләмисен, песиен

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ

## «QAZAN UTLARI»NA 80 YIL

**Фатих Сибагатуллин,**

*Нурлат районы һәм шәһәренең хакимият башлыгы, Татарстанның халык депутаты.*

# МИЛЛӘТНЕҢ ЙӨЗЕК КАШЫ



***Мин шәхсән үзем «Казан утлары»н алтмышынчы еллардан ук, әле ул «Совет әдәбияты» дип аталган чордан ук даими укып барам. Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев кебек әдәбиятыбызның алтын баганалары белән, аларның әсәрләре белән мин иң әүвәл шушы журнал аша таныштым. Нәкъ менә «Рәшә» кебек, «Өч аршын җир» кебек кызыксынып укыла торган, яңалыкка, фәлсәфи тирәнлеккә, әдәби кыйммәткә ия әсәрләр җитенкерәми хәзер. Детектив белән генә әлләни ерак китеп булмый. Әхлакый-тәрбияви мәсләкне дә күз уңыннан ычкындырмаска иде. Һәрхәлдә, мин «Казан утлары» битләрендә яңа заман, яңа чорның чагылышын да көтәм. Бүгенге көндә, ни кызганыч, татар язучысының матди хәле, язган әсәрләре өчен түләнә торган каләм хакы бер дә мактанырлык түгел. Матди этәргеч булмаса, кызыксыну тумаса әдипнең язу стимулы да шактый кечерәя. Күп миллионлы татар өчен «Казан утлары»ның 10 меңгә якын гына данәдә таралуы да милли җанлы һәр җитәкчене борчый торган күренеш, дип исәплим. Гомумән, хөкүмәтнең әдәбиятка, милли матбугатка булган карашы тамырдан үзгәрергә тиеш.***

***Тиздән олуг юбилеен уздырырга җыенучы яраткан журналым — «Казан утлары»ның укучылары күп булуын телим.***

ничек? Әллә гөлҗимешең беттеме, күптән эчергәнең юк»,—диде ул, елмаеп, ни өчен Нәҗибәнең үпкәләгәнен чамалап.

«Яшь хатыныгыз эчерсен әнә, сез инде ятим дә, бахыр да түгел, алтын баганагыз бар»,—диде ул Альбинага ишарәләп.

Нәҗибәнең бу сүзләреннән Зариф көлеп җибәрде.

«Нәҗибәкәй, сеңлем, хатын—хатын урынында, син бит минем дустым, серләремне сиңа гына сөйлим бит, ташлама олы абыеңны»,—диде ул уены-чыны белән.

Уйлар-уйлар. Менә аның бар ышанычы, күңел юанычы булган җиде ел бергә гомер кичергән хатыны. Чит ирләр белән сөйләшә, кайдадыр барырга сүз куеша икән, димәк, инде эшләр еракка кергән.

Зариф яңаклары авыртып чыкканчы тешләрен кысты, әчкә баткан күзләреннән ике бөртек рәнҗү яшьләре сакал-мыек баскан ач яңакларына тәгәрәп төште. Күрше бүлмәдә Альбина утны кабызды, ефәк халатларын кыштырдатып юыну бүлмәсенә үтеп китте, кранны ачып дүрт кеше сыярлык «джакузи»га су агыза башлады. Ярым ачык ишектән ваннага салган хуш исле өстәмәләрнең исе Зариф яткан бүлмәгә үк житеп борынына килеп бәрелде. Ул ап-ачык итеп хатынының сылу сыгылмалы тәненең ничек итеп кайнар ванна кочагына чумуын, югалуын күз алдына китерде, йөрәге әрнеп алды. Үзәкләргә үтәрлек ялгызлыктан, әч пошуыннан ул ыңгырашып куйды.

Нигә Ходай аңа һаман үлем бирми икән, нәрсә өчен аны шулкадәр каһәрләде икән, нинди гөнаһлары өчен? Һәм аның алдына аермачык булып тагын бер ялангач сын пәйда булды—Зәбирә—сабый Зәбирә...

Ул алдады бичара Зәбирәне, Зариф һәлак итте бахыр кызны. Ташкенттан кайткан яшел медальонга алыштырып алды ул аның яшьлеген. Яшьлеген генә түгел, гомерен дә алды. Бер генә гомерме әле, ә аның кызы? Яңа туган сабые? Димәк, Зарифның да сабые, балада аның да каны ага түгелме соң? Тагын кемнеке булсын. Август киче, гөлҗимеш кызарган вакыт. Май аенда Зәбирәнең кызчыгы дөньяга килә, вакыт шуңа ишарәли. Зәбирә үзе ике айдан тиленәр шифаханәсендә, бала сагышына түзә алмый, чире көчәеп һәлак була.

«Нинди кеше булдым соң мин,—дип уйлап куйды Зариф.—Мин әзмәвердәй, хатын-кызның һушын алырдай егет, үз илемнең горурлыгы, сүзе дә, зиһене дә үткен сәнгать арсланы, театр йолдызы—үземне яраткан бер генә кешене дә бәхетле итә алмадым?!.»

Кемгә тисәм, кемгә кагылсам да миннән соң учак урыннары, бер уч көл генә кала дип ачынып уйланды ул. Зәбирә, Әминә, улы, менә хәзер Альбина. Үзе гаепле түгелме соң Альбинаның шулай булуына? Кайда үрелде ул олы башы белән. Яшь аермасын белми идемени?»

Кайнар ваннада рәхәтләнеп ятты Альбина. Һич кенә дә шушы ваннадан, инде кабер исе килеп торган карт ире кырына чыгасы, икесе өчен дә ялган булган кәмитне уйныйсы, дәвам иттерәсе килми иде аның. Иртә әле, тагын ярты сәгать вакыт бар, дип, вакытны сузды ул.

Кияүгә чыгып, театр йолдызы булып, бар хыяллары тормышка ашу белән, Альбина үзенең ялгышканын аңлады. Карт иде аның ире, төнлә йоклаганда авыр итеп тын алулары, чыңгылдап йөткерүләре, Альбинага кызык һәм күңелле булган табын, яшьләр арасында күңел ачышларда ачыктан-ачык әч пошулары, кайнар тәнле, ярсу йөрәкле, уйнап торган яшь хатынның нәфесен баса алмавы, житмәсә, ярарга, ошарга тырышып килешсез, корсаклы гәүдәсенә яшьләрчә модный футболка, джинсы киеп куюлары аны тагын да көлкерәк, кызганычрак итеп күрсәтә иде.

Альбинага күз ташлаучылар күп булды. Башлап сәхнәгә аяк баскан, герой-любовник образын тудырырга ашкынучы, аннан да бигрәк Альбина аша режиссерның үзенә тезген салырга теләүче кешеләр дә аз булмады. Кайберләре теләгенә дә иреште.

Ә тезген бушау һич көтмәгәндә, бөтенләй көтелмәгәнчә булды.

Бергә яши башлауларына ике ел узуга Зарифның алтмыш яшьлек юбилеен бөтен республика бәйрәменә әйләндерергә булдылар.

Театр труппасы кичәгә әзерләнә башлады. Иң беренче Альбина катнашындагы спектакльләрдән өзекләр әзерләнде, соңыннан калган спектакльләргә чират житте, кичәнең сценарие төзелде, афишалар, чакыру кәгазьләре басылды. Зарифның тормыш юлын, иҗатын чагылдыручы буклетлар, «Театр һәм режиссер» дигән төсле фотолар белән альбомнар эшләнде, ил житәкчеләре, күрше республикалардан күренекле шәхесләр, якын дуслар, хезмәттәшләр кунакка чакырылды.

Кичә грандиоз итеп әзерләнде, көтелгәнгә караганда да мәртәбәлерәк үтте. Зарифны чәчәк бәйләмнәре, Почет грамоталары күмеп китте, хәтта «Халыклар дуслыгы» ордены белән дә бүләкләнде. Һәр килгән кунак, берсеннән-берсе арттырырга тырышып, Зарифны мактады. Затлыдан затлы бүләкләр биргәндә: «Хөрмәтле хәләл җефетегез белән буш вакытта укырсыз, яки, хатыныгыз—гүзәл Альбина ханым белән кара-каршы утырып чәй эчкәндә...»—дип котлау сүзләре язылган папкалар, затлы сервизлар, тун-бүрекләр, ат бүләк итәбез, дип асыл бизәкләр белән нәкышләнгән йөгәннәр чыгарып бирделәр.

Зарифтан бигрәк Альбина арыды. Чөнки ирен котлыйлар, ә аннан күзләрен дә алмыйлар. Асылташ кебек үзенә жәлеп итә иде шул күпләрне Альбина.

Тик ул сер бирергә тырышмады. Ниһаять, алар соңгы кунакны—Ташкент театрының режиссерын аэропортка кадәр озатып, самолетка утыртып жибәргәннән соң кайтып ял итәргә булдылар. Өйдә Альбина ваннага су агызды, ә Зариф бардан алып бәллүр рюмкаларга затлы коньяк салды.

«Матурым, әйдә, бу жиңү хөрмәтенә берәрне эчеп куйыйк та ятып ял итик.»

Алар эчеп куйдылар, арыган тәнгә рәхәт жылы йөгерде. Кунак озата-озата шактый йомшарган Зариф тагын берәрне салды.

«Житәр, жаным, күп була, мин хәзер, ванна кереп чыгам да, синең янга чумам, кара аны, йоклама»,—дип Альбина ваннага кереп китте. Зариф чайкала-чайкала йокы бүлмәсенә юнәлде.

Хуш исләр бөркеп Альбина ваннадан чыгуга, ире берни белми йоклый иде инде. Альбина аны иркәләп уятырга тырышты, тарткалап, селкеткәләп карады, ә Зариф, чалкан төшеп, ачык авызы аша авыр тын алып берни белми, сизми йоклап ята иде.

«Нинди ямьсез һәм карт син»,—дип уйлап алды ул.

Альбинаның күзләренә яшьләр килде. Аның дәртле, яшь, кайнар тәне дер-дер калтырана, йөрәге ярсып-ярсып тибә, рәнжегән һәм үпкәләгән жаны өзгәләнә иде.

«Нишләдем мин, нигә кирәк булды бу карт миңа. Әнә тигез парлар күңел ачалар, дискотекаларда бииләр, тиргәшә-талашалар, аннары кочаклашып яратышалар, балалар үстерәләр. Ә бу, хөрәсән, ичмасам, бер бала да таптыра алмады»,—дип өзгәләнде ул.

Авыр уйларыннан аны ишек кыңгыравы айнытып жибәрде. Ул шәрә тәненә кыска ефәк халатын элеп билбау белән генә бәйләде дә ишеккә юнәлде. Ишек тишегеннән аңа ак тешләрен күрсәтеп елмаеп, инде бер ай буена котлау телеграммалары ташучы егет карап тора иде.

Альбина ишекне ачты. Егет елмаеп:

—Сезгә тагын телеграмма,—диде.

Альбина егетне өйгә чакырды.

Егет:

—Менә шушында кул тамгагызны салыгыз»,—дип, каләм сузды.

Ул ямьсыйый иде. Альбина елмаеп куйганын сизми дә калды:

—Ах, карасы беткән бит моның, әйдәгез кухня ягына үтәбез, көн бик эссе, бәлки сусагансыздыр?!

Егет кыюсыз гына хуҗабикә артыннан иярде. Ирексездән Африка

кызлары шикелле кояшта янган, ялтырап торган озын аякларга, йомры янбашларга, атлаган саен сыгылып торган нечкә билләргә, дулкынланып иннәренә төшкән куе бакыр төсендәге чәчләргә, шома матур беләкләргә күзе төште. «Нинди гүзәллек, иблис ич бу хатын»,—дип уйлап куйды егет.

—Уз, үскәнем, исемең ничек була, утыр азрак, арыгансыңдыр.

Альбина суыткычтан «Боржоми» алып, нечкә бармаклары белән нәзакәтле тотып, су тулы бокалны егеткә сузды.

—Радик булам мин, ягъни Родион чын исемем, рәхмәт!—диде егет.—Студент мин, каникул вакытында телеграммалар ташып акча эшлим. Альбина телеграммага игътибарсыз гына күз йөгертте дә өстәлгә ыргытты.

Чибәр иде егет, яшь иде, унтугыз-егерме яшьләр тирәсе генә. Ап-ак шома маңгай, «ежик» стилендә алынган көлсу чәчләр, зәп-зәңгәр күзләр, елмайган чакта алсу иреннәре арасыннан тезелеп торган ап-ак тешләре күзгә ташлана. Тәненә сыланган ак футболка аша ныклы тыгыз мускуллары кабарып тора.

Альбинаның кинәт башы әйләнеп китте, бу егет алдында үзен бик бәләкәй, көчсез, яклауга мохтаж кеше итеп сизде. Шушы мускулларга сыенасы, башны шушы яшь күкрәккә куеп берегеп йоклыйсы, ныклы мускулларның көчен тоясы килү теләге биләп алды аны.

—Радион, телисезме, бераз коньяк бар?—Ул җавап та көтмичә йокы бүлмәсенә коньяк алырга юнәлде.

Зариф, берни тоймыйча, гыр-гыр килеп йоклап ята иде. Альбина йокы бүлмәсенең ишеген ныклап ябып кухняга узды. Чайкатып та тормыйча рюмкаларга коньяк салды. Хатынның үзенә чакырып торган гәүдәсеннән гаҗиз булып калган егет бер сүз дә әйтмичә коньякны эчте. Альбина ана якын ук килеп басты, халатының билбавын сүтеп җибәрде, аяк астына елан кебек бөтерелеп ефәк халат шуып төште. Кайнар иреннәр, тотып тыялмаслык теләк, чакыру аларны үз упкынына суырып алды.

Альбина егеткә елышкан җиреннән, шәрә ботын егетнең янбашы аша сузып, аяк очы белән кухня ишеген дә ябып куйды.

* * *

Кайнар ваннадан соң Альбинаның салкын душ астында коенганын ишетеп, аның һәр хәрәкәтен белеп-тоеп ятты Зариф. Тик аның күзләрен ачасы килмәде, телефон аша таңгы сөйләшү аның миен айкый, йөрәген кискәли иде. Хәтта тән сызлавын да басып китте бу газап.

Зариф Альбинаны кайчандыр югалтасын белеп тора. Тик болай ук тиз, үзенең күз алдында булыр дип һич кенә дә уйламый иде ул. Үзе үлгәч Альбина аны җәлләр, сагыныр, оныталмас, газапланыр, бик озак еллар үткәч кенә кемне дә булса табар, тик үзен барыбер оныталмас, дип уйлый иде ул.

Ә дөнья—бөтенләй башка, дөнья шулкадәр көтелмәгән, шулкадәр шәфкатьсез, мәрхәмәтсез икән.

—Хәлләрең ничек,—дип янына килеп утырды Альбина Зарифның,—врачлар кичә укол кадап киттеләрме сиңа? Мин хәзер профессор Аскат Нуриевичка шалтыратам, бүген үк сине дәваханәгә салып бераз дәвалап алсын, авыртуларың басылыр—дип «гөрләде» ул ире янында берни дә булмагандай.

«Оятсыз»,—дип уйлады Зариф эчтән генә. Тик үзе:

—Юк, минем хәлем яхшы, мин беркая да бармыйм, беркая да!—диде, күзләрен ачмый гына. Күзләрен ачса, Альбина барысын ла аңлар, дип курыкты ул. Иң курыкканы үзенең йомшаклыгын күрсәтү иде аңа.

—Но, Зариф, син бит инде бала-чага түгел, лечиться итәргә кирәк ич, бәлки терелеп тә кайтырсың!

—Юк, кирәкми, мин үземне яхшы хис итәм, юкка тырышма мине больницага салырга!

Альбина гаҗәпләнеп калды, аскы иренен тешләп ачуын көч-хәл белән басты:

—Миңа, берничә көнгә авылга кайтырга, әниләрнең хәлен белергә кирәк, гел сине генә саклап ята алмыйм бит инде мин.

—Бар, теләсә кая кит, мин сине тотмыйм, хәлем әйбәт, минем өчен хафалана күрмә...

Альбина кулына тоткан чәйле бокалны бармак очлары агарганчы жан ачуы белән кысты.

—Ярый алайса, үзеңә кара, мин сиңа яхшылык теләп кенә...

—Рәхмәт. Тик бер үтенечем бар, минем эш бүлмәсен җыештыручы кыз Нәҗибәне театрга кереп эзләп тап, монда килергә куш, бер данә ишек ачкычларын аңа бир. Шул булыр миңа синнән зур ярдәм...

—Ну, Зариф, ничек итеп чит кешегә өй ачкычын бирмәк кирәк?

—Бир, мин әйткәч, курыкма, урларга һәм урлатырга бур йә тауар булырга кирәк, ә ул—кеше!

Альбина бер сәгать эчендә киенеп, төзәнеп-ясанып, хуш исләр чәчеп чыгып китте. Артыннан авыр корыч ишек өч йозак белән дөбер-шатыр килеп бикләнде.

Зарифны хатирәләр дөньясы тагын үз эченә алып китте. Менә улы Азатның тугыз яшь вакыты. Улы әтисенә: «Әти, мине «Луна-паркка» алып бар әле, анда карусельләр бар, минем шуларда йөрисем килә»,—диде беркөнне.

Зариф ял көне паркка алып барырга вәгъдә бирде. Шимбә көнне репетицияләрдән соң район башлыгы урман өендә мунча ягып кунак итәргә чакырган иде. Анда, билгеле инде, эчемлекләр, кызлар, шашлык, уха, мунча. Зариф ял көне, кичке унберләрдә генә ушына килеп, өенә кайтып керде. Ишектән кергәч кенә ул бүген улын ял паркына алып барырга вәгъдә иткәнен исенә төшерде. Азат йоклый иде инде.

—Сине көтә-көтә йоклап китте,—диде, үпкәле һәм рәнҗү катыш тавыш белән Әминә.

—Эш бит, эш,—дигән булды ул.—Икенче атнада барырбыз инде.

Атракционның бүген соңгы көне иде,—диде Әминә һәм сүзсез генә үзенең бүлмәсенә кереп бикләнде.

Мәктәпне тәмамлагач улының чыгарылыш кичәсенә дә килә алмады ул. Чираттагы командировкасыннан «кайтып җитешергә тырышырмын» дисә дә тагын нәрсәгәдер соңлады.

Азатның күзе аттестат кәгазе алганчы актлар залының ишегендә булды. Унышларын атасына күрсәтәсе, атасының үзе белән горурлануын тоясы килде аның. Тик бу юлы да әти кеше өлгермәде.

Ах, ул ялгышларны төзәтеп булса икән?! Нигә кирәк булды миңа бу дан, бу байлык, бу шөһрәт, үлем якасында әргәдә бер якын җан иясе дә булмагач, дип әченеп уйланды ул. Театрда инде яңа кешеләр, үзе исән чакта да үкчәгә басып, колак артында кычкырып тын алып торучы яшь режиссер. Яшьләр заманы хәзер бу дөньяда. Аларның үз дөньясы, үз репертуарлары, үз актрисалары, үз тәкәбберлекләре, үз көрәшләре.

Зариф кебек тешсез патриархларны инде алар чынга кабул итмиләр. Театрга килгән чакта ихтирам йөзеннән генә игътибар һәм нәзакәтлелек күрсәткән булалар да, берәр сәбәп табып, тизрәк алар яныннан таю ягын карыйлар. Озак авыргач, дуслар, танышлар башта хәл белергә килгәләделәр, аннан алар да онытты. Шулай, гомер сүнә, гомер дәвам итә, дип ачынып уйланды Зариф.

Җилгә очкан еллар, көлгә калган гомер. Бу гомернең театр гына икәнен аңласа иде кеше яшь вакытында. Кулыннан килсә Зариф та яшьлек таныпа барыр, шул иртәнге чык бөртеге шикелле чиста, гөнаһсыз, әпә, дивана Зәбирәне үзенең яры итәр, кадерләп дәвалар, карар, аннан туган кызчыгын карап үстерер, тәрбияләр, кеше итәр, кияүгә бирер,

оныкларын тәрбияләшер иде. Хәзер кызы яки оныгы ана су эчерер, дару бирер, тузгыган чәчләрен тарар, бәлки ваннага салып юындырыр да иде әле. Кеше күтәрәлмәс газаплардан арынган тәне дә, жаны да чистарыну, пакьлек сорый иде Зарифнын.

Наркотиклы көчле препаратлар да бик азга баса иде инде анын газапларын, дару алып эчкәннән сон Зариф, тагын күзен йомып, тынгысыз йокыга талды. «Кеше гомере тузан гына, жилләргә туза гына».

Зариф төшендә әнисен күрде, менә ул ап-ак алъяпкычын киеп, ак яулыгын чөеп бәйләп ап-ак мичтән кабарып алсуланып пешкән пәрәмәчләр чыгара имеш. Пәрәмәчләрдән чыккан ис анын борынын кытыклый, тәме авызга сизелә, төкерекләр китерә, хуш исе жаннарга чаклы үтеп керә кебек.

Зариф күзләрен ачты, кухнядан чыннан да тәмле булып пәрәмәч исе килә иде. Альбина ялгышын анлагандыр, кире кайткандыр. Зарифнын гафу итүен телидер, дигән уй яшен кебек өмет уятты анын зиһенендә.

Кухнядан ак яулыгын чөеп бәйләп, поднос тотып Нәжибә килеп чыкты. Кызарып-алсуланып пешкән бәрәңге пәрәмәчләре иде подноста.

—Зариф абый, йоклап та карыйсыз икән әй, мин кергәнне дә, дөбер-шатыр йөргәнне дә ишетмәдегез! Саумысыз, әйдәгез әле, калкыныгыз, йомшак пәрәмәчләр ашап, гөлжимеш төнәтмәсе эчеп жибәрегез, чиргә бик килешә ул,—дия-дия, диван янындагы бәләкәй өстәлгә табын әзерләде.

—Хатыныгыз эшемә килеп, Сез чакыра, дигәч, кибеттән кереп әзер камыр гына алдым да монда чаптым. Сез йоклаган арада пешеп тә чыкты.

—Рәхмәт, Нәжибә сенлем, менә гөлжимеш суын сагындырды, шуна чакырырга булдым,—диде Зариф һәм авырлык белән генә урыныннан күтәрелде. Чыннан да тәмле иде пәрәмәч, ярты пәрәмәч ашап бетерә язды ул. Тәмендә балачак, үсмер, яшьлекнең гади нигъмәтләре, әнисе сауган жылы сөт, төйгән бәрәңгенең ләззәтле тәме бар иде. Мона кадәр гомер буе ашаган кызыл-кара уылдыклар, затлы ашамлыклар, кыйммәтле балыклар, кырлап-сырлап эшләнгән салатлар берни булмаган икән, алар бернигә дә тормый иде бу пәрәмәчләр алдында. Кеше үләр алдыннан гына яшәүнең чын мәгънәсен, анын асыл бәясен анлый икән, дип уйлады Зариф.

Нәжибә ялт итеп тиз генә иданнәрне юып чыгарды, тәрәзәләрдәге кормаларны ачып жибәрде. Форточканы ачты, мебельләрдәге тузаннарны сөртте. Үзе бертуктаусыз сөйләнде:

—Зариф абый, сезгә бирешергә ярамый, сез бит талант иясе, бөек шәхес, сез әле яна спектакльләр ижат итәргә тиешсез. Нәрсә ул хәзерге яшь режиссерлар?! Ни куйганнары да, нәрсә әйтергә теләгәннәре дә анлашылмый. Житмәсә гел урысча гына сөйләшәләр. Артистлары да сәхнәдә Голливудныкылар кебек бөтен кеше алдында чат-чот үбешәләр, кочаклашалар, кочаклашалар да үбешәләр, оят, прәме...

«Галиябану»да сез беркемне дә үбештермәдегез дә, барыбер Хәлил белән үлгәнче яратышулары анлашыла иде...

Зариф Нәжибәнең беркатлы тыкылдавын рәхәт изрәп тынлап ятты. «Бәхетле ата булган булыр иде Нәжибәнең атасы кызын ташлап китмәсә»,—дип уйлады ул.

—Зариф абый, сезнен урын-жирне алыштырырга кирәк, үзегезне юындырырга да, кырындырырга да вакыт житкән,—диде Нәжибә.

—Шулаен шулай да сон, сенлем, Бари абыен янына кереп чыксан, ул ярдәм итмәс микән мина юынырга?—диде Зариф хәлсез тавыш белән.

—Ничава, Зариф абый, сез минем атам яшендәге кешесез, эчке ыштаныгызны салдырмый гына әйбәтләп үзем юындырам мин сезне. Һич кенә дә тартынып тормагыз, аркаларыгызны ышкырмын, чәчләрегезне юармын, калган жирләрегезне үзегез дә юасыз инде...

—Кыен бит әле, Нәжибә сенлем.

—Бер дә кыенсынмагыз. Минем әти булып, малайлары булмаса, мин аны да шулай юындырган булыр идем,—диде Нәҗибә.

Зарифны иплэп кенә култыклап тотып ванна бүлмәсенә алып килде. Зариф чишенгәч Нәҗибә коты очып куркып китте. Кайчандыр баһадир гәүдәле ир, өстенә тиресе эленгән сөяктән генә тора иде. Ул, Зариф үзен-үзе күрмәсен дип, гәүдәсе белән көзгене каплап басарга тырышты. Күзләренә яшьләр килде. Сабынлап юганда тәненә кагылып та булмый, авырта иде Зарифның. Нәҗибә ничек кенә булса да йомшаграк кагылырга тырышты. Аннары сабынлап сакал-мыекларын кырды, чәчләрен юды, коендырды, алмаш киемнәрен бирде. Саклык белән генә ваннадан чыгарып чиста урын-жиренә яткырды.

—Рәхмәт, кызым, үз балаң да болай кадерләмәс, бәхетле бул,—диде Зариф.

—Бәхетле мин Зариф абый, болай да бәхетле! Бәләкәй генә фатирым бар, Аллага шөкер, эшләп торырга эшем бар. Кияүгә чыгып булмады булуын, алмадылар мине егетләр, матур булмагач, ләкин минем янда тере җан иясе песием «Йомшагым» бар, картаюын-картая инде, ләкин тугры дус, мине ташламый.

Чынлап та, бәхет өчен күп кирәкми, шул да житә бит, шөкранә итә белгән кешегә, дип, бу гади хакыйкатькә бар булмышы белән төшенде Зариф.

Нәҗибә диван янында идәнгә төшкән сөлгене алырга дип иелде. Шулчак аның гади генә итеп тегелгән күлмәге изүеннән Әстерхан чикләвеге зурлыгында эмальле медальон шуып чыгып муенында асылынып калды. Зариф «аһ!» итте... Аның Зәбирәгә кидергән медальоны иде бу... Ак йөзенә кинәт кан йөгерде, күзләре зур булып ачылды.

—Зариф абый, нәрсә булды сезгә, ни булды, хәлегез начармы әллә?—дип өзгәләнергә тотынды Нәҗибә.

—Бу, бу, медальон кайдан синдә?

Нәҗибә аптырап калды.

—Медальон? Белмим, ул туганнан бирле минем белән. Тәрбияче Галимә апа әйтүе буенча, ул әнинеке булырга тиеш. Мине детдомнан детдомга күчереп йөрткәндә тәрбияче апалар бу медальонны миңа кушып жибәрә торган булганнар, үскәч бәлки ярдәме тияр, бәлки берәр сере бардыр, бәлки кем дә булса шуның аша эзләп табар үзен дигәннәрдер инде. Аны бер дә муенымнан салмадым. Миңа бәхет китерә ул медальон.

Зарифның күзләреннән ике бөртек эре яшь агып төште:

—Кызым!—диде ул ишетелер-ишетелмәс кенә.

Ләкин Нәҗибә аның сүзләрен аңламады, тиз генә 03 не жыйды. Ашыгыч ярдәм машинасы килгәндә Зариф аның югалткан иде инде.

Үләр алдыннан Зарифка шул ук күренешләр, төшләр керде: зур алма кебек кояшның кып-кызыл итәге офыкка төшә, якыная, сүнә бара. Зариф кояш артыннан атта чаба да чаба, чаба да чаба. Кояш аның саен тизрәк югала, жәһәтрәк офыкка күмелә, инә бара, инә бара иде.



## Фәнис Яруллин

### ТАУЛАРГА КАРАП

Заманалар тиз үзгәртә безне,
Алмашына хәтта кыйблалар.
Таулар гына һаман беркемгә дә
Баш имичә горур торалар.

Кылыч кисәр диеп куркабыз шул
Башкайларны түбән имәсәң.
Дөнья ныграк бөгә барган саен
Шул таулардан күбрәк көнләшәм.

### Авылга кайткач

Исән-саумы, туган Кызылъярым,
Исәнмесез, дуслар, якташлар.
Сез дә инде әби буласыздыр,
Безне сөйгән кызлар-туташлар.

Язмыш чәчте безне төрле якка,
Тамыр җәйдек төрле җирләрдә.
Туган җирдән өстен булып булмый,
Әверелсәк тә әллә кемнәргә.

Авыл безнең күзебезне ачты,
Тел ачкычы бирде кулларга.

Югалмадык, адашмадык җирдә
Шул тылсымлы ачкыч булганга.

Рәхмәт, авылым, рәхмәт, туган ягым,
Яшә шулай үсеп, яңарып.
Урамыңда бала-чага чапсын,
Ипи пешсен мичтә кабарып.

Яңа матур йортлар калкып чыксын
Көндәш булып биек тауларга.
Авыл кирәк безнең үткәннәрне
Киләчәккә илтеп ялгарга.

Киткәннәргә рәнҗемә син, авылым.
Агым кирәк һәрбер елгага.
Ерак очыш кирәк кошларга да,
Биеклекләр кирәк җырга да.

Гөлләр шиңә өзүләрен көтеп,
Сабагында шиңә, тамырда.
Ярдәм итә алмый назлы кояш,
Ярдәм итә алмый яңгыр да.

Вакыт узган, ак күлмәкләр тузган,
Гөлләр карашында моң, үпкә.
Керфекләргә кунган чык суларын
Кул аркасы белән җил сөртә.

## Терәүсез дә тора биеклек

Урманнарга керсәң, никадәрле
Корыган агачларның кәүсәсе.
Үрә катып басып тора алар
Сукмакларга сузып шәүләсен.

Шул шәүләләр, кара күләгәләр–
Алардан тик калган шул гына.
Яфрак ярмый, хәтта чыпчыклар да
Кунып сайрамыйлар очына.

Элек «кагылгысыз» булгангамы,
Утынга да кисми бер кеше.
Пеләш түбәләрен әкрен-әкрен
Ашап килә кояш эссесе.

Без күкләрнең баганасы диеп
Саный алар һаман үзләрен.
Күрми алар җиргә сузылып яткан
Үзләренең кара эзләрен.

Ә күккә бит терәү кирәк түгел,
Терәүсез дә тора биеклек.
Яши бу агачлар–бер-берсенең
Авып төшүенә сөенеп...

Тамыры белән йолкып атты давыл
Тау өстендә үскән имәнне.
Тау булып тау түбәнәеп калды,
Тау булып тау хәтта имгәнде.

Нинди генә ачуы булды икән
Давылларның мәгърүр имәндә.
Көнләштеме әллә җил-давыллар
Имән биек тауда үскәнгә?

Табигать тә бәлки безнең кебек
Үчләшәдер күңеле тарлыктан.
Хәтта яшен агачларның биеген
Эзләп йөри
Болыт арасыннан, ярыктан.

Ярларның да биекләрен ишә
Елгаларның ярсу дулкыны.
Текә ярлар ишелеп кенә төшсен,
Колач җәеп тора упкыны.

Җирдә мәңге шундый көрәш бара,
Бу көрәшнең юктыр ахыры.
Мәкер-үчнең, зурлык-биеклекнең
Бер үк җирдә яши тамыры.

Рәнҗеткәннәр сине, рәнҗеткәннәр,
Бик тә рәхимсез шул бу дөнья.
Көлә-көлә йөгереп барган чакта
Үсеп чыга юлга зур кыя.

Башың белән килеп бәреләсең,
Челпәрәмә килә өметләр.
Өметеңнең ватыкларын хәтта
Таптап китә усал көчекләр.

Кайда соң сез ватык хыялларны
Ялгый белә торган кешеләр?
Миңа гына нигә очрый, дисең
Үзләре зур, җаны кечеләр.

Әллә миңа бәхет чишмәсеннән
Ятып су эчүләр хараммы?
Кайсы агачлардан яфрак өзим
Каплар өчен канлы ярамны?

Рәнҗеткәннәр сине, рәнҗеткәннәр,
Бик усал шул бездә кешеләр.
Үч сакламыйк ләкин без аларга,
Көчле була алмый үчлеләр.

## Сорау билгесе

Син барасың, мин барамын,
Йөрәк яна, көн эссе.
Икебезнең арабызда
Бик зур сорау билгесе.

Сиңа карый—син дәшмисең,
Миңа карый—мин телсез.
Аралар якын булса да
Сүзсез бару күңелсез.

Икебездән җавап көтә
Олы сорау билгесе.
Баш очыннан выжлап үтте
Кызган сөю сөңгесе.

## Үзем дә аңламыйм бугай

Истә әле үкенечләр,
Аем урланган кичләр,
Иясез калган мәхәббәт,
Җиргә тапталган хисләр.

Истә өзелгән өметләр,
Ялгызым түккән яшьләр.
Ничек онытылсын, мең тапкыр
Өн дип алданган төшләр.

Истә—чәчәксез язларым,
Истә җимешсез көзләр.
Истә—керфек очларымда
Боз булып каткан сүзләр.

Ә бит һаман «син» дип яна
Мең кат өтелгән йөрәк.
Күрәсең минем йөрәккә
Һаман алдану кирәк.

Әллә шушы алданулар
Бирәме миңа ләззәт?
Ачы язмыш калачымны
Кимерәм әзләп-әзләп.

Канатларымны көйдереп
Ташланам утка һаман.
Үзем дә аңламыйм бугай,
Нәрсә—чын, нәрсә—ялган.

Хыялым белән бутадым
Мин, ахры, сине үзем:
Йөрәк сиңа бәрелеп каный,
Хыялны күрә күзем...

## «Сагындым» дигән сүзең

Җаным дөньядан сүрелеп,
Нуры сүнгәндә йөзнең—
Канат куеп өметләргә,
Күтәрә мине күкләргә
«Сагындым» дигән сүзең.

Соңгы пәрәвезен җилләр
Өзеп киткәндә көзнең—
Бер тал була тотынырга,
Упкыннардан котылырга
«Сагындым» дигән сүзең.

Арага гөнаһ кермәгән.
Күңелләр чиста безнең—
Йөрермен бәхеткә юрап
Кабатлансын гына ешрак
«Сагындым» дигән сүзең.

Әйтәләр: ул бит шаяра,
Ышанма шул сүзләргә.
Ышанам әле чыннан да
Соң түгел бит беркайчан да
Өметләрне өзәргә.

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



**Зиннур Хөснияр**

## АЙНЫҢ ТУГАН-ТУМАЧАСЫ ЮК

хикәя

Тege китте. Сөт машинасына утырып. Райүзәккә, судка, дип. Ул калды. Кузгалып китәм дигәндә генә, машинадан сикереп төште дә, капка төбендә үскән кәкре агач артына ышыкланды. «Районга нишләп бу хәерче киемнән барырга тиеш әле мин!—дип, сукранды ул үзалдына.— Өстендәгесе матур бит, үзе барсын! Аерылышу кәгазен дә үзе алып кайтсын!..»

Сорады бит иртә белән: «Яңа күлмәк-ыштан әзерләп бир»,—диде. Җавапка: «Аерыласы хатыннан кием сорамыйлар! Яшь хатынын табып бирер, җәме!»—дип кенә кычкырды.

Ул, аягын көчкә сөйрәп, түбән очтан югарыга—өенә таба атлады. Шулчак кылт итеп башына мондый фикер килде: яз көне аерылышу килешәме соң ул? Ахыры хәерле булырмы? Шуны Хәбибә карчыктан кереп сораса? Әнә генә бит аның йорты! Ул өшкереп имләгән хатын бәбигә уза, кысыр сыер бозау алып кайта, дип юкка гына сөйләмиләрдер?

«Кермим әле! Чуртымамы соң?! Яз көне аерылыштың ни дә, кыш көне ни... барыбер күнелле нәрсә түгел инде»,—дип кире уйлады да, иренеп кенә өенә таба атлады. Уйлары аякларына чолгана, шуларга мәнә-мәнә сөртенеп егылыр төсле. Авыл урамында эт тә юк. Бик иртә әле. Хуҗалык сөтен сәгать биштә үк җыеп озаталар. Урамда—уйлар гына. Уйлар басуга җим эзләп очкан каргаларга ияргән, алар ерганаклар булып агалар, алар капка төбендәге шәрә агач ботакларына эленгән, беришесе сөт машинасына төялеп китте. Кичәге, бүгенге көн турындагы уйлар... Ә иртәгә?.. Аерылышкач ничек булыр икән соң, ә?..

Бала-чагалары юк-югын да... Армиядән соң дүрт ел өйләнмәскә кушканнар иде аңа. Хезмәтен тутыргач, каты итеп, кисәтеп әйттеләр: дүрт елсыз өйләнмә, балаларың гарип туачак! «Туачак! Тумаячак!»—дип сөйләнә-сөйләнә ул капка келәсенә басты.

Фәгыйлә—армиягә озатып калган күрше кызы—йә өйләнәсен, йә мин

---

Зиннур ХӨСНИЯР *(1961)—прозаик, «Таң ата да кич була», «Тәгәри китте язмышлар» һәм башка китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

башкага чыгам, дигәч кенә, солдаттан кайтуына өч ел дигәндә генә кушылганнар иде алар. Беренче балаларын Аллаһы Тәгалә ничек бирсә, шул рәвешле үз катына алып та куйды.

Икенчесенә үзләре җөръәт итмәделәр. Күтәргә булганнар иде. Хәер, армиядән кайтканына дүрт ел да ике ай була икән бит инде. Күрәсең, аларга бәби язмагандыр. Инде менә аерылышуга да барып життеләр...

Чү, нидән чыкты соң әле алар арасындагы бу ызгыш? Юк, юк, үзеннән гаеп эзләргә, яисә акланырга түгел иде аның исәбе. Болай гына... Уйлар өермәсе алып кереп китте аны бу тарафларга. Чынлап та, нидән килеп чыкты соң әле бу хәлләр?

Бая, хатынының бертуган апасы яшәгән йорт яныннан узганда, аякларын көзән җыера язды, әйтерсең, баганалары тимер торбадан утыртылган бизәкле капкадан бозау кадәрле, саллы колаклы астыртын эт чыгар да, аңа ташланыр күк иде. Тизрәк, тизрәк! Җәһәтрәк инде!

Монда хатынның апасы яшәп ята. Гаиләсе белән.Гаилә дигәнең: хатын да—ир, тракторда эшләүче исерек малайлары гына.

Тимер баганалы капканың келәсе «чык» итте дә, аннан чуар яулыклы бер баш күренде. «Кая чабасың бу хәтле? Сөртенеп егыласың бит инде! Ташка егылып тез капкачынны ярсаң! Бульнискә эләксәң!..»

Хатынының апасы Фатыйма бу. Өйрәтә. Яшәргә өйрәтә. Ни ашарга, ничек йокларга... Кияүгә чыкканына байтак булса да, сеңлесе бала тапмый. Баланы каян аласын гына өйрәтеп житкерә алмый Фатыйма. Ирек куйсаң, урталарына кереп ятарга да күп сорамас иде кана...

«Фатыйматын-тайбатын—минем әни бай хатын», дип мыгырданды Хәмит, капкада хатынның апасы күренгәч.

—Кая болай чабасың, дим бит! Ни булды?—дип төпченде Фатыйма.

Хәмитнең аның белән сөйләшеп торырга ни теләге, ни кәефе юк иде. Әмма сорау шундый итеп бирелде ки, һич кенә дә җавапсыз калу мөмкин хәл түгел иде. Кияүнең гәүдәсе бишек сиртмәсе кебек җыерылды, тамак төбенә вак бәрәңге сыман төер тыгылды. Барыннан да бигрәк аның үз-үзенә, җавапсыз торуына ачуы килде һәм, ниһаять, әлеге хис тамактагы төерне этеп төшерде дә, акылы белән киңәшеп тә тормастан, хәерсез теле:

—Фәгыйләне районга илтеп куйдым. Бәби апкайтырга!—дигән яналык әйләндереп чыгарды.

Капылт кузгалудан Фатыйма чайкалып китте, җәһәт кенә капка баганасына ябышты.

—Нинди бәби булсын ди!

Үз ялганы үзенә дә ошап китте Хәмитнең. Хатыны белән ачуланышканнан бирле ягылмаган тимер мич шикелле суык җанына җылы йөгерде.

—Корсагы да беленми ие бит әле аның!? Шул арадамы? Бигрәк тиз бит!?.

—Тиз шул! Космос гасырында яшәгәненне белмисеңмени?

Күрәсең, Фатыйма һушына килеп өлгергән иде инде.

—Кай жирендә йөрткән ул аны! Алдыйсыңдыр ла! Миңа әйткән булыр ие!

—Төнлә участкауайны алып кайтканыем инде мин. Икәү булырга тиеш, ди. Игезәк! Берсе—кыз...

Хәмит телен тешләде. Арттыра бит! Артыгын шыттырып җибәрсә, мәңге ышанмаячак тегe! Бу рәвешле хатынның апасыннан үч алуы рәхәт, жан рәхәте иде. «Мокыт!—дип уйлады ул, авызын колакларына тиклем җәйде.—Атлаган саен акыл саткан була. Яшәргә өйрәтә. Үзе шуна да ышанды тагын! Мокыт.. Бәби дә алып кайтмаган килеш, Фәгыйлә синен аркада гына китә! Соң, бала тапкач кына китсә? Малаем яки кызым ятим үссә?..»

Чү!.. Кызулык белән... ачуланышу кайнарлыгы белән уйлап та, уйланып та караганы булмаган икән ич—хатынсыз ничекләр итеп яшәр икән соң ул? Монарчы алай талашып тормады ич алар. Яшь, матур хатынның итәк жиле кагылып узганда да каны шундук кайнарлана, ана буйсынырга теләмәгән

чуар көнеле һәм дуамал башы «Нигә яшим?» дигән мәңгелек сорауга гади генә җавабын табып, урынына кире утыра торган иде.

Һаман да шул Фатыйма: «Бәби апкайтмыйсыз!»—дип тинтерәтә торгач, алар икесе бер авыздан: «Балалар өчен яшәргә өлгерербез! Әүвәл үзебез өчен яшәп калыйк»,—диярләр иде.

Фатыйманың бертуктаусыз өйрәтүеннән, тормышларына кысылуыннан гарык булган Хәмит кияү көннәрдән беркөнне: «Синең дә балаң бераү генә. Нигә тагын апкайтмыйсыз!»—дип үртәгән иде, аңа мәчегә ташланган эт кебек ябышты. Бераз сүрелә төшкәч, акланганмдаймы, әллә үз-үзен юатырга теләпме: «Көтү көткәндә яр буенда утырып салкын тигезде бит бажан!..»—дип, башка балалары юклыгын әллә ире өстенә, әллә язмышка аударып калдырган иде. Шулчак беренче мәртәбә кызганып куйган иде Хәмит хатынының бертуган апасын. Адәм баласының күнелендәге кызгануны шундук этлек хисе алыштырды: «Нәрсә, чыбыркысы шартламый башладымы әллә?»

Бу ямьсез сөйләшү Хәмитләрнең ишегалдында бара иде. Әлеге сүзләрдән соң Фатыйма түтиебез бер агарды, бер күгәрде дә, нидер әйтмәкче булып авызын ачкан иде—сүзе чыкмады, аннан аңлаешсыз ымлыклар гына коелды. Гаярь хатынның мона тагын да ачуы килде һәм ул, Хәмитләрнең салпы колаклы ялкау эте арт аягын койма култыксасына күтәреп кире төшергәнче, җәһәт кенә өенә кайтып, аннан иренең иске чыбыркысын өстерәп килде. «Нәрсә! Шартламыймы?! Хәзер шартлатып күрсәтәм мин сиңа!»—дип, ишегалды буйлап Хәмитне куып йөри башлады. Ире белән апасының дорфа сөйләшүеннән кәефе киткән Фәгыйлә, моны күреп, эчен тота-тота көләргә кереште. Апасы белән ире ишегалды буйлап куышуларын дәвам иттеләр. Ишегалды хәйран зур булса да, качып котылыр урын юк иде. Фатыйма шарт та шорт чыбыркы шартлата. Коты табан астына тәгәрәгән кияү балакай качарга урын эзли, үзе: «Кара, ничек шәп шартлата икән!»—дип уйлый. «Шартламыймы! Шартламыймы! Менә сиңа, менә сиңа, мә!» Бер-ике мәртәбә чыбыркы очы кияүнең колак яныннан да сызгырып узды инде. Ул чарасызлыктан лапаска чумды. Печәнлеккә качып котылу иде исәбе.

Тегесе Хәмит артыннан үрмәләде. Бәхеткә, печәнлектә чыбыркы шартлатып булмый иде. Шулай да Фатыйманың ачуы һаман да яман иде әле. Ул абынып печән өстенә ауган Хәмиткә ташланды. Буып үтерергә... борынын тешләп өзәргә диптер инде. «Борынсыз калсам, бетте баш!» дигән уй Хәмитнең миен көйдереп узды. Һәм ул өстенә ауган Фатыйманы, тыпырчынмаслык итеп, үзенә таба тартты. Хатынның кайнар сулышы битенә бәрелде, дәү имиләре күкрәгенә басты. «Йа, бу хәтле булса да булыр икән!—дип уйлады ул хатынының апасын кочаклаган килеш.—Нәкъ Фәгыйлә! Кайнар сулышына тиклем! Имиләре генә бушрак. Ишегалды буйлап чаба-чаба тирләгән үзе. Фәгыйлә исе килә! Йа, Раббым, булса да булыр икән!..»—дип, уйлап ятты ул аста килеш...

Эшнең болай килеп чыгуына Фатыйма үзе дә аптырап, хәтта каушап калды. Бу рәвешле кияү өстендә ятуына и/ояллды, и/ унайсызланды хатын. Әмма хатын-кызның эчтәге зәһәрлеге көчлерәк булып чыктымы, йә инде әлеге хәленнән котылуның берданбер юлы, чарасы диптерме: «Каяле, каяле! Синең чыбыркың шартлыймы икән! Тикшереп карыйм әле!—дип, тез башы белән җинелчә генә бот арасына төртеп алуга, үзен салам көлтәсе астында калгандай хис иткән Хәмит, җәһәт кенә кочагын бушатып, «чүмәлә» астыннан шуышып чыгып, аска сикерде.

Печәнлектә кичергән иләс-миләс хисләр икенче көнне үк юкка чыкты. Икенче көнне үк Фатыйма тагын килеп, аларны янә яшәргә өйрәтә башлады.

Инде берничә ел бергә яшәп, Хәмит белән Фәгыйлә бер-берсенең гадәт-холыкларына тәмам ияләшеп бетә яздылар, әмма кияү балакай хатыны апасының «диктатурасын» күнеле белән дә, акылы белән дә кабул итеп, килешә алмады.

Беркөн шулай Хәмит такта ярдырып кайтты да, ишегалдына бушатты. Мунчаны бәрәңге бакчасына табарак дәвам иттереп, шунда ян корылма

төзү иде исәбе. Бәлкем, келәт булыр. Ишегалдындагы тактага Фатыйма да игътибар итте.

—Келәтегез бик тузгание, яңасын саласыңмы әллә?—диде ул эссе каккан тавыш белән.

«Барысын да каян белеп тора бу, зәхмәт!»—дип сукранды Хәмит.

—Нинди келәт! Нәрсәгә кирәге бар аның! Бассейн төзим!—диде ул киреләнеп.

—Бассейн?! Авыл җирендәме? Мунчаң була торыпмы?

—Мунча үз урынына, бассейн үзенә!

Шулай иттереп, бер дә уйламаганда-көтмәгәндә, келәт урынына бассейн пәйда булды.

Тора-бара боларның аралары тәмам бозылышу чигенә җитте. Кияү хатынның апасын өнәмәс булды. Моны Фатыйма, күрәсең, үзе дә сизенеп йөрде микән, беркөнне ул аларны кунакка дәште. Итләре бетте. Ат алып суярга булдылар. «Килегез!» дип, бажа үзе чакырып китте. Фатыйманың бусагасыннан атлап керергә бер дә күңеле тартмаса да, бажасы килеп әйткәч, карышырга яхшысынмады.

Ат дигәннәре айгыр өммәтеннән иде. Аны чалырга күрше-тирәнең бар ир-аты җыйналды. Гадәт буенча, Фатыйма сугымчы ир-атларга киңәш-табыш итәргә үзе алынмакчы иде, арадан берәү ярым чын, ярым шаяртып:

—Монда йөрмә инде син, Фатыйма килен. Җә балаң гарип туар,—дигәч тә исе китмәгән иде. Ә төп сугымчы Гарәфи карт:—Йөрмә дигәч, йөрмә инде, килен. Борчылма, әгъзасын сиңа кисеп бирербез,—дигәч кенә, оялып, өйгә кереп китте.

Ир-ат тыныч кына, мәдер-мәдер сөйләшә-сөйләшә үз эшен эшләде. Нәрсәгә тотынса, кулыннан шул шөгыль килә торган күрше Гарәфи—алтмыш яшьләрдәге, колгадай озын буйлы, чандыр кеше—сүзнең тәмен белеп, сөйләр урынын белеп сөйли.

—Берзаман шулай күрше мари авылында Үзәкәйгә тәкә суйдым. Урманда агач тарттыра идек. Трактор ватылды да, бер көн ял бирделәр. Иптәшләр өйләренә кайтып китте. Мин кайтмадым. Гәүһәр апагыз белән дә талашып чыгып киткән ием. Сагынсын әле, мин әйтәм, кайтмыйм. Икенче көнне тагын билдән кар җырып кире киләсе бар, мин әйтәм. Үзәкәйнең ире, Иванның дим, чыбыркысы шартламый ди бит. «Трайной» эчеп янган да... Химия бит инде. Нефтедән эшләнгән.

Шулай кичтән Иван белән самагун чөмердек-чөмердек тә, чирмешем өстәл астына ук тәгәрәде. Тере кешеләрдән Үзәкәй белән икәү генә. Мин дә үз урыныма барып яттым инде.

Хикәянең нәкъ шушы төшенә житкәч кенә Фатыйманың бертуган энесе—колхозның бердәнбер «КамАЗ»ында шофер булып эшләп, салган баштан күптән түгел идарә каршындагы баганаларны рәттән кырган өчен эштән чыгарылган Хатыйп, салкын тигән юеш тавышы белән:

—Үзәкәй янына чумдым, диген инде, ичмасам,—дип, Гарәфи абзыйны «төзәтәсе» итте.

—Син нәрсә, энекәш! Кеше хатынына кул саламмы соң!—диде тегесе ачу белән.

—Үзәкәйнең шәп чаклары барые бит, дип кенә әйтүем.

Хатыйпның ялгыш сүзләре өчен үкенүе булдымы бу, акланууымы, әмма ул барыбер үчекләвен дәвам иттерде.

—Кеше хатынының йөзенә туры караганым да юк минем, энекәш! Үзәкәй яныма үзе килеп ятты беләсең килсә!..

Гарәфи сөйләвеннән капылт кына туктап калды. Сүзнең иң кызык җирендә генә өзде дә куйды, хәйләкәр. Хатыйпның борынына янадан су җыелган иде, ул тынкыш тавышы белән:

—Әйттем бит, әйттем бит!—дип кабатлады.

—Әйттең пычагым! Беләсең килсә, арканы куйдым да яттым. Һаман китми әкәен. Шуннан юри киерелгән булдым да, артны тункайттым, караватта урын калмагач, Үзәкәй лап итеп идәнгә егылды да төште.

Иртәсен үлеп баш авырта гына бит. Үзәкәең самагунын җәһәннәм тишегенә үк яшереп куйган. Бирми. Иван эзләп тә карады. Үч ала янәсе. Әүвәл тәкәне суеп бир, аннан соң бирермен, может, ди. Нишлим инде? Тәкәсен чалдым. Кулына табак тотып Үзәкәй басып тора. Канын шушы табакка агыз әле, ди. Минем ишеткән барие инде—алар свежий канны куырып ашый икән. Ярар, мин әйтәм, китер табагыңны. Үзәкәй кереп киткәч, аяк тотып торырга да ярамаган Иван үзе мина күз кыса, үзе тәкәнең җомыркасын йолкый. «Моны да табакка салырсың әле, бүтәкә дип әйтерсең»,—ди. «Кит, мин әйтәм, ул җирен бездә килмешәк этләргә генә ташлыйлар», дим. «Жук, жук! Турап сал инде табакка!—ди.—Хатын-кыз шуны ашаса, дәрте кузгала ди. Андый хатын үлгән кешене дә терелтә алырлык гайрәтле була»,—ди. «Синең хатын болай да кимен куймый бит инде»,—дип әйтеп булмый ич инде чирмешкә. Ялына гына бит. «Утын әрдәнәсендә яшереп куйган бер чирек самагуным бар, шуны алып чыгарыем»,—ди. Дустың гозерен аяк астына салып булмый бит инде. Шулай эшләдек тә.

Хатыйпның борынына бу юлы су бик тиз җыелды, авызын ачып, сүз әйтә алмады. Беренче булып Хәмитнең баҗасы телгә килде:

—Алайса, айгырныкының да көче бардыр бит инде? Кемгә ашатыйк икән?..

Ул сүзен әйтеп бетерергә дә өлгермәде, кулына җылы су салынган комган күтәреп Фатыйма күренде. Икенче кулында зур сары табак иде. Күрәсең, аларның сөйләшүен дә ишеткән...

Ул комганны кар өстенә утыртып, кул сөртергә дигән тастымалын айгыр түшкәсен асарга әзерләгән киштәнең ботагына элде дә, җаен туры китереп, Хәмит янына килде. Фатыйманың йөзе гадәттәгечә түгел иде, тавышы да йомшак, үзен беренче көнне кияү куенына керергә әзерләнгән яшь бичә кебек тота, оялчан, кыюсыз. Бит очлары—салкыннан түгел, җылы өйдән генә чыгып килеше бит—алсуланган, күзләре утлы күмер кебек яна.

«Хатын-кызның холкы юк дип әйтмәс идем, бар аларның холкы, тик ул көн саен үзгәреп кенә тора»,—дигән бер шагыйрь. Фатыйманың да моңарчы ала-колалы чуар холкы бүген үзгәргән, йомшарган, үзе тыйнак кына бер мөлаем хатынга әверелгән дә куйган!.. «Хәерлегә булсын!»—дип шомланып уйлады Хәмит. Хәер, вәсвәсәсе юкка булган, Фатыйманың кияү балакайга үтенече бар икән.

—Хәмит, дим, энем-җаным, кеше күрмәгәндә шыпырт кына ат җомыркасын менә шушы табакка салырсың әле, пожалысты!

Тегесе, аптырап, күзләрен шарландырды:

—Ә-ә?..

Фатыйманың тавышы сүнеп бетә язды.

—Беләсең бит инде, баҗаена, баҗаена...—диде ул ярым пышылдауга күчеп.—Пешереп ашатмакчы булганыем... Чыбыркысы бит...

Хәмитнең аптырау-гаҗәпләнүдән оешып каткан йөзе яктырып китте.

—Була ул! Айн-момент!

Кичен Фатыйма сугымчыларны, авылдагы якын-ерак туган-тумачасын, күршеләрен кунакка чакырды. Сыйландылар, бик күңелле утырдылар. Төнгә чаклы дәвам итте бәйрәм. «Ат чалу шәп нәрсә икән!»—дип уйлады Хәмит кияү. Өйләренә төн уртасында гына кайтып яттылар. Авыл күгендәге ялгыз ай аларны капка төбенә кадәр озата барды. «Айның туган-тумачасы да юк. Безнең кебек кунакка да йөри алмый, бахыр...» Башына әллә ниткән фәлсәфи уйлар килә. Хатын белән тору зур тормыш мәктәбе ул, ир-ат шул мәктәптә гап-гади бер укучы гына. «Әйтелеп бетмәгән бу, фикер китек әлегәсен. Өстәргә кирәк моңа: «Ул мәктәптә хатын-кыз да укый. Ир арткы партада, хатын иң алда утыра».

Хәмит, колак төбендә безелдәгән черкине куганда итеп селтәнде дә: «Нәрсә, фәйләсүфләнгән булам соң әле! Вакытымыни!»—дип, үз-үзен җинелчә генә шелтәләп алганнан соң, шартлатып, өйалды ишеген бикләп куйды.

Хатыны инде юрган астына ук чумарга өлгергән. Кич буе кешесез

торгач, өй эче суына төшкән: күлмәкне салуга чытайтып җибәрде. Ул, киемнәрен аннан-моннан гына урындык өстенә өеп, тизрәк юрган астына... хатынының җылы кочагына ашыкты.

Тәрәзәдән өй эченә үтеп кергән ялгыз ай күпме генә тырышып күзәтсә дә, караваттагы икенче кешене һич кенә дә эзләп таба алмады, кат-кат җентекләп исәпләсә-санаса да, очына чыгарлык түгел, юрган астында бер генә кеше ятадыр сыман иде. Хисап дигән фәнне каян белсен инде ул мескен ай! Санаган була тагын...

Иртәгесен кибет артында баҗасы белән күрешкәч, тегесе барлык шартын туры китереп, ат ите кысылган саргылт тешләрендә сынык шырпы белән казына-чокына:

—Ну, ничек сун?—дип куйды.

Үзе чабатадай авызын тагын да җәя төшкән, куе сары кашлары арасына яшерелгән бәләкәй күзләре ниндидер сер белгәндәй тәмам кысылып беткән. Ут чыбыгында тезелешеп утырган чыпчыкларның һәммәсен берьюлы баҗаның авызына җыеп тутырасы килде Хәмитнен—чүпләнсеннәр иде рәхәтләнеп. Сүзен әйткәндә дә шырпысын теш арасыннан алып тора алмый, ичмаса.

—Нәрсә, ничек сун?

Сары каш астындагы күзләр урынында ике нечкә сызык кына калды, алар тагын да озынайдылар һәм колакка тиклем сузылып, нәкъ шул урыныннан бу баш бүреге-ние белән кырт киселеп төшәр күк тоелды. Киселер, пычагым! Бажа кеше, әнә, рәхәтләнеп ыржая. Ө нигә дип ыржая соң әле? Ул һаман аңламый, яна капкага кайтып кергән сарык бәрәнедәй тик аптырап карап тора. Бажасының карт алаша ите кебек кызыл йөзендә баягы серле-сәер тантана ничек тиз кабынган булса, шулай ук сүрелде дә; шырпы сыныгын чиртеп җибәреп, башын чайкап куйды.

—У-уу! Фатыйма апагыз... ат күкәен генә түгел... хәленнән килсә... Бертуган сеңелемнең кияве дип тормасые!..

Бажалар тиз аңлаштылар, чөнки Хәмит тә ана кичәге серне чишеп ташлады. Әлбәттә, бу хәлгә бажаларның бик тә ачулары килде. Гарьләнделәр, хурландылар. Икесе дә чыгырларыннан чыктылар. Әмма күтәрелеп бәрелмәделәр, икесе ике якка—өйләренә ашыктылар.

Кайткач та, бажасының лапаста маллар карап йөргән Фатыйматтәйне шунда ук салам чүмәләсе өстенә төртеп екканын Хәмит бажа күрмәде, әлбәттә. Моңа кикриге өшесә дә, әле бик гаярь булган кызыл читекле әтәч кенә шаһит булды. Әмма бу хакта ул кунакчада бөрешеп утырган тавыкларына да сөйләмәде. Әтәч кенә булса, да сер тота белә икән тагын үзе...

Хәмит бажа нишләде дисезме? Иң башта урам капкасын иңсәсе белән генә төртеп ачты, аннары тибеп япты да ишегалдына аяк басуга: «Фәгыйлә! Ананны!..»—дип кычкырмакчы, аны үз янына чакырып чәчеп-туздырып ташламакчы иде, дыңк иттереп капка ябылган тавыш ис-һушына китерде бугай, бермәлгә туктап калды: үзе еш-еш сулый, буылган кеше кебек әледән-әле изүләрен тарткалый. Беравыктан суына төште. Шулай итми нишләсен, ул хәтта хатынына нәрсә дип әйтергә кирәклеген дә, башлап ни дип авыз ачасын да белми, белү генә түгел, башына да китерә алмый. Чарасызлыктан интегүе әллә каян күренеп тора. Шулай шул: апаң мина айгыр җомыркасы кыздырып ашаткан, дип әйтеп булмый бит инде!..

Дуамалланып кайтып килүче ирен Фәгыйлә тәрәзәдән үк күреп, болдырга чыкты. Әнә шулай каршысына чыгып басуы белән Хәмитне «аяктан екты» да инде. Әүвәл тез аслары хәлсезләнеп, аннары теле көрмәкләнде—сүзен әйтә алмас булды. Яшь хатынның иннек-кершән белән каешланмаган, табигый төсен җуярга өлгермәгән ак, чиста йөзе, аптыраулы гөнаһсыз коңгырт күзләре Хәмитне каушатты.

—Хәми-и-ит! Ни булды-ы?—диде яшь хатын чак кына сузып.

Тавышының мөлаемлылыгы, күнелгә ятышлылыгы ирне икенче мәртәбә җиргә чүктерде. Ләкин җанындагы үпкә-ачу алай гына басылырлык түгел иде, һай, түгел иде шул.

—Фатыйман бүтән монда аяк басмаячак!

Хәмитнең кызган күкрәгеннән әнә шул җөмлә генә сытылып чыкты. Кем әйтмешли, хатын-кыз ир-аттан акыллырак, чөнки алар азрак белә, ә күбрәк аңлый. Фәгыйлә дә иренә каршы капылт кына сугылып бәрелмәде, сәбәбен дә сорашмады—апасы белән ире арасында игълан ителмәгән сугыш барганын күреп тора, ләкин ана һич кенә дә игътибар итми, бу аяк астында буталып йөргән вак-төяк ызгышлар дип кенә уйлый иде. Шулай да ул бу юлы:

—Нигә? Тагын нәрсә булды инде?—дип сорап куйды.

Мондый сорау һич кенә дә кирәкми иде Хәмиткә: Нәрсә дип җавап бирсен соң ул ана? «Ярар» дип мыгырданды ул авыз эченнән генә һәм лапас алдына «кикрикүк!» дип аваз салган ак әтәчкә хатынының көтү куа торган юан таягын алып тондырды.

* * *

...Әбүген алар аерылышалар. Фәгыйлә район үзәгенә гариза илтә китте. Судка икесе барырга тиешләр иде дә бит... Ул качып калды, кузгалам дигәндә машинадан сикереп төште. Хатын-кыз алай сикереп йөри алмый бит. Хәмит төшеп калгач, яшь хатынның ачуы отыры кузгалган иде. Юл шактый сикәлтәле, сөт бидоннары төягән машина әрҗәсендә дөбер-шатыр сикерә торгач, тынычланды тагын үзе.

Дөресен генә әйткәндә, хатын белән аерылышу җиңел эш түгел икән. Хәмитнең җаны уйный башлады. Шуны басар өчен диптер инде, ул кибеттән аракы алып кайтырга уйлады.

Аракы—арыш мае,
Эч әле, карышмале.
Бушат калын кесәне,
Җанга дәва булале,
Әй, аракы, аракы...

Ул, каяндыр ишеткән әлеге такмакны көйләп, урамга чыкты. Баш комбайн кебек эшли, җан уйнаклый, күңел әсәренә. «Усал аракысы усал хатыннан яхшырак!»—дип сөйләнде ул үзалдына. Уйлап тапкан шәпкә әлеге тапкыр җөмләсе бик акыллы, үткен булып тоелса да, кибет янына якынлашкан саен, ул бу сүзләрнең үзенә һәм хатынына бик үк туры килеп бетмәгәнлеген чамалады. Усал түгел бит аның хатыны. Тик нигә аерылышырга җыенганнарын аңлатып кына бирә алмый ул. Беркөнне,—ат суйганнан соң атна да узмагандыр,—Фатыйма килеп киткән, Хәмит шуна дулады. «Сезнең нәсел белән араны өзәм!»—дип җикеренде ул хатынына. «Өзәм!»—«Өз!» И шуннан бетте-китте, вәссәлам!..

Кибет алдында җигүле ат тора. Ат хәтта бәйләнмәгән дә, тезгене чишелгән, ул, башын төрле якка йөртә-йөртә, кар өстеннән азык эзләгәндәй итә, борыны үз нәҗесенә төртелгәч, чирканып, кинәт башын күтәрә, арткарак чигенә. Аннары кибет алдындагы рәшәткә башына таба сузыла. Кимереп алырга исәбе. Ул шатыр-шотыр агач кимерергә керешкәч, кайдадыр чәнчәң эт өргәне ишетелде. Хәмит шуннан соң гына чанадагы салам арасыннан этнең башын күреп алды. Колхоз электригы Ярулла абзый кибеткә тукталган икән. Бар тирә-юнь белә: Ярулла абзый дөм исерек хәлдә чанасында йокласа да, нинди генә буранда яки ерак юлда калмасыннар—бу кызгылт ат белән Бурзай кушаматлы нечкә сыйраклы чәнгелдек эт хуҗа кешене капка төбенә хәтле алып кайтып җиткерәчәкләр.

Кибет эченнән тавыш-гауга ишетелә. Нindидер шәп тауар кайтып, шуның өчен ызгышалар кебек. Баксаң, анда, кибетче Солтан кызы, Ярулла абзый белән хатыны Мөштифәдән гайре эт тә юк. Мөштифә уң кулындагы бер чәки аракыны баш өстенә күтәргән, икенчесе белән үзенә ташланырга әзер торган Яруллага кизәнә.

—Тагын бер генә адым атлап кара менә! Атлап кына кара, бәрәм дә ватам! Ике дә уйлап тормыйм менә!

Ярулла абзый бик ярсулы, шулай да үзен тыеп тора, күрәсең, хатынының холкын күптән өйрәнеп бетергән: чәкине ваттырасы, әрәм иттерәсе, «зәм-зәм» суыннан колак кагасы килми. Солтан кызы, кайсысын якларга да белмичә, аптырап, үлчәү артына поскан да, шуннан тыныч кына күзәтә.

—Ватып кына кара менә! Бакча җимеше түгел ул сиңа, акча җимеше!

—Бер генә адым атлап кара менә! Ике дә уйламыйм, белдеңме!

Солтан кызы, яңа гына кияүгә чыгып, ир куенында берәр атна чамасы гына төн уздырган бала, кайсысын якларга да белми. Дөресрәге, бу мизгелләрдә болар урынына ире белән үзен куеп карап, шуннан нәтиҗә чыгарырга азаплана бугай. Ләкин бернинди дә нәтиҗә чыкмый. Чөнки тормыш тәҗрибәсе бик сай әле, чыпчык тезеннән генә. «Вата бит хәзер, Мөштифә апа! Батырлыгы җитмәячәк! Кара, Ярулла абзыйның кыяфәтен, котырган үгез кебек!» Кызның уенда әнә шундый ике фикер тарткалаша-ярыша.

—Ватып кына кара менә! Мин сине бүген үк аерып җибәрәм!

Һай, Ярулла абзый! Шушы сүзеңне әйтмәгән булсаңчы, хатын-кызның холкын белмәгән кеше кебек! «Аһ, син шулаймы! Аерасыңмы! Сиңа аракы кадерлерәкме?!» Чәки ишек төбендә торган ябык кильки мичкәсе кырына очты һәм чык иткән тавыш кына ишетелде. Мөштифә үз кыюлыгыннан үзе дә коелып төшеп, аптырап-югалып калды һәм котырган аю кебек алпан-тилпән өстенә килә башлаган иреннән качып, ишеккә йөгерде. Аның артыннан—Ярулла абзый...

Кибет эче тынып калды, урамда ярсып-ярсып эт өргәне генә ишетелде. Солтан кызы да, Хәмит тә җинел сулап куйдылар. Икесе дә белә: чәки өчен генә аерылыша торган гаилә түгел инде болар. Өйгә кайтуга, Ярулла абзыйны әзмәвердәй ике малае караватка бәйләп салачак, ә иртәгесен Мөштифә Ярулласына—махмырдан интегеп яткан иренә, сөтле аш пешереп, аны кашыклап үзе ашатачак. Авылда белмәгән кеше юк: электрик Ярулланың сөтле аштан соң эче йомшарып, махмыры да юып алгандай юкка чыга. Ә кичен алар атка утырып, парлашып, күрше авылга һинд киносы карарга барачаклар. Моның шулай буласын авыл белеп тора. Чөнки беренче мәртәбә генә түгел. Өстәвенә Ярулла абзыйның олы кызы килеп, кибет идәнен дә юып-себереп китәчәк әле. Төштән соң. Моны кибетче Солтан кызы да белә. Шуна күрә хәзергесе вакытта почмакта таралып яткан шешә ватыкларына тамчы да исе китми аның. Кибет эченә таралып өлгергән аракы исе генә күнелне болгатып, күзләрне әчеттерә.

Хәмит тә, Солтан кызы да, тегеләр чыгып киткәч, бу хакта бер сүз дә алышмадылар. Кибет түренә нәрсәдер алып кайтып өйгәннәр. Хәмит, аракы дип авыз ачасы урынга, кияге белән шунда таба ымлады.

—Әллә мебель апкайттыңмы?

Әлеге сүзләрдән Солтан кызы җанланып китте.

—Ие шул, Хәмит абый, сафа ул. Двухспальный карават. Агачтан, мендәрләре дә бик йомшак.

Хәмит әүвәл караватның бар җирен җентекләп тикшереп чыкты, аннан соң кибетчегә күтәрелеп карады. Аның ни әйткәнен дә көтмәстән, Солтан кызы кызу-кызу тезеп китте:

—Без үзебез дә районнан яңа гына кайттык әле. Сиңа хәбәр салырга өлгермәгәнием. Фәгыйлә апа белән районда күрешкәниек. Бульнискә кереп барадырие. Күренергә килдем, ди. Хәмит абыеңа әйттер, карават безгә бик кирәк, дигән ие. Менә хәзер берәрсен сиңа йөгертергә дип торадырыем.

—Ие шул, ие,—дип мыгырданды Хәмит.—Алам мин моны. Ошады бу. Карават кирәк безгә. Бик кирәк...

❀

## ҮҖӘТ ЯУГИР, САМИМИ ШАГЫЙРЬ

КАВИ ЛАТЫЙПКА 75 ЯШЬ

*Кави Таһир улы Латыйпов—Кави Латыйп—малай гына көе сугыш җәһәннәменә кереп тә, аннан—кырык үлем күреп, ысланып, мең тетрәнү кичереп, әмма чын ир-егет булып чыга алган милләттәшебез. Димәк, исән-сау калган, чыныккан яугир буларак илхалык, зур максатлар өчен янып, озак «яшәргә хөкем ителгән» кешедер, бәлки. Уйласаң, шагыйрь Нажар Нәҗми әйткәнчә, «җитмеш биш яшь яши алган кеше—болай да бит бөек, үлемсез»дер. Шулайдыр ул.*

*Күрше Чувашстанның Батыр районы Татар Тимәше авылында туып (1927 ел, 1 май) үсә ул. Педучилище тәмамлап, укытучы була. Аннан—сугыш; 1944 елдан махсус гаскәрләр сафында хезмәт итә: Полесье сазлыкларын кичеп, Карпат тауларын үтеп, әле сугыш беткәч тә, махсус батальонда диверсантларга каршы сугыша... бу турыда әдип, журналыбызда дөнья күргән «Ур арты ур» (2000) исемле автобиографик повестында сурәтли. (Укучылар һәм тәнкыйть тарафыннан җылы каршыланды бу әсәр—монсын да әйтү урынсыз булмастыр...) Язмышлар документы ул! Хәрби училищеда укып, офицер булгач, чит илдә тышкы разведкада хезмәт итә. Аннан—Казанда хезмәт... Ниһаять, хәрби дөнья белән саубуллашып, 1955 елдан журналист, педагоглык эше: телевидение, мәгариф министрлыгы, фәнни институт, газета мәйданнарында сыналу... Инде чынчынлап иҗат, язу белән янып яшәү юлы. Беренче китабында әле (1960 елда басылган шигырьләр җыентыгы)—шул ук «Солдат эзләре»... Аннан—башка эзләр, эзләнүләр... Шигырь һәм проза китаплары. Алар инде—унбиштән артык. Урысча да басылды. Чуваш телендә дөнья күргәннәре дә бар (Космонавт А. Николаев турында повесть; шигырь китаплары). Кави Латыйп—Чувашстанның И. Яковлев исемендәге милли премиясе лауреаты да әле. Әдип эзләнүдән һич туктамый, армый. Бигрәк тә шигырьдә. Сиксәненчетуксанынчы елларда ирекле ритмлы, ак яки нәсергә якын торган үзенчәлекле формалы шигырьләр иҗат итә башлады К. Латыйп. «Вакыт канатында» (1983), «Хәтер йомгагы» (1987), «Иркен сулыш» (1991), «Иман кәрваны» (1997) исемле китаплары әнә шундый тәҗрибәләр һәм табышларны эченә ала. Аларда рухы белән оптимист, шат, самими хисле, садә рухлы, өлкән яшьтә булуын да сизмәгән, яшьлек омтылышларына тугры шагыйрьнең бай күңел дөньясы: кызыклы, кайчак сәер, сискәндерә торган, әмма һичшиксез үзенчәлекле дөнья. Аның бу чор иҗатын хуплап, байтак каләмдәшләре язып чыкты: И. Юзеев, Г. Рәхим, Р. Мингалим, Зөлфәт һ. б. Р. Мостафин да русча, татарча мәкаләләр бастырды. Р. Фәйзуллин исә «Һәркем җирдә бер бизәк» исемле шактый әтрафлы эссепортретын журналыбызда чыгара (1997, май саны), А. Хәлим Кави Латыйп шигъриятен бездәге ирекле шигырь тарихы, аның эволюциясе белән бәйләп, аңа зур күләмле эссетрактатын багышлады («Мирас» журналы, 2000 ел.). Шулай ук шагыйрь иҗатын, бигрәк тә аның ирекле шигырьдә эзләнүләрен танымаган, яки тәнкыйть иткән чыгышлар да булгалады—әдәби процесста бусы да табигый күренеш иде... Әмма К. Латыйп үзенең иҗат активлыгын арттыра бара: соңгы елларда гына Сөембикә ханбикәгә багышлап язган поэмаларын бастырды ул, кызыклы истәлекләрен дөньяга чыгарды... Инде яңа XXI гасырда яшибез. Сугышта, узган XX йөзнең, шагыйребез әйткәнчә, «Бөек Афәт»ендә катнашкан әдипләребез дә бармак белән генә санарлык инде хәзер. Кадерләре дә арта булыр аларның...*

*Котлыйбыз, Кави абый!*

**Рәдиф ГАТАШ**



# Кави Латыйп

## КАНАТЛЫ АЛМАЛАР

❁

«Түгел, түгел тирәктә,—
үзем китсәм,
үзем үлсәм, җаным калыр шигърияттә».—
Күңел шулай әйтә.

Шигърият—оҗмах-җәннәт тә,
шигърият—тәмуг-кыямәт тә.
Шигырь язганда,
җәзаланганда
шуны мин белдем:
бер мизгел—мин рәхәттә,
мең мизгел—мин михнәттә...

❁

Ишелеп-ишелеп кар ява...
Ап-ак кар.
Ак дөнья,
пакь дөнья бар.
Күңел сорый яр!
Саф,
пакь күңеллене.

Кышкы ак көннәр,
кышкы төннәр,
безгә—чистарыну,
пакьләнү өчен килде түгелме?..

❁

Корбаннар, туганнар,
сугыш кырында ятып калганнар,—
сезләрне без онытмадык.
Киләчәктә дә онытмабыз.

... Алар истәлегенә, Аллаһыбыз,
без-исәннәрнең күңелендә
Үзең ут кабыз.
Сүнмәс ут кабыз!

۞

Без—маңкортлар,
маңкортлык безне кыл өстендә тота.
Кандаладай сыта,
еландай йота.
Маңкортлыгыбыз аркасында
тираннарга баш иябез.
Кулларын үбәбез,
юлларына гөлчәчәкләр сибәбез.
Ә үзебез канлы яшь түгәбез.
Әйтербез күк:
«Күз яшьләре өчен булса да,
тиеннәр түләгез...
Терeләй җиргә күммәгез!»

۞

«Курск» атом су көймәсенең батуы
Чечня өчен Аллаһының<u>дыр</u> каргышы.
Шулдыр
«Без—бөек держава!»—дип масайган,
мактанган Русия язмышы.
Шәхсән мин шулай уйлыймын.
Ә үзем—үлүчеләр өчен
зар елыймын.

۞

Җәйге чиллә
бигрәкләр дә хәтәр тәэсир итте:
Җан җегәрлеге дә,
тән җегәрлеге дә бетте.
Тәмам талдым.
Кыл өзә алмаслык хәлгә калдым.
Җиһан дигәне дә гүя таш капчык.
Бәреләм-сугылам
бер почмактан икенче почмакка.
Ташланмасам гына иде—
төнге күбәләктәй—утакка.

## Канатлы алмалар

Биек алмагачта алмалар
канатлы кошлар сыман
очарга торалар...
Алмалар, алмалар, алмалар—
җанымдагы җыр алар.

۞

Һәрнәрсәне эшләргә кирәк
тирән уйлап, алга карап,
китмәсен дисәк су астына Ил-Кораб!

❁

Мәскәүләрдә шартлаталар,
Казаннарда шаккаталар
Геннадийлар, Гаталар...

❁

Курай моңнары–
тургай моңнары,
тугай моңнары.
Сәйдәш, Тукай моңнары...
Олы бер бәхет
курай тыңлавы.
Мәхәббәтем курайга
бер мизгел дә суынмады.
Суынмас та:
ул моңнарны
курайчы әнием
гүрдә тыңлап ята...

❁

Шигърият корбаны мин:
Шәрекъ вә Гаребкә
догалар кылганмын мин.

❁

Гомер буе кайнадым мин
татар казанында–
Казан казанында.
Шунда булыр азагым да,
соңгы азаным да.

❁

Югалган көн табылмас,
ул бердәнбер,
аңа юк алмаш.
Югалган көн елап китәр.
«Бәхил!»–диеп касә күтәр!

❁

Чал чәчле дип тормыйлар,
картларның түземлелеген сыныйлар.
Әмма сулар кичкән,
утлар үткән агайлар сынмыйлар.

Сынаучыларга үч итеп,
авыр халәттә дә,
фронттагыча, алар–
үз өсләренә ут ачуны,
туптан атуны сорыйлар...



# Рим Идиятуллин

## ШУЛ БЕР ГОМЕР ЭЧЕНДӘ

Килер буын сүз кузгата калса
Мин яшәгән дәвер хакында,
Белегез сез, кайгы күлен кичеп,
Күрсәтмәдем зарның затын да,—
Шул бер гомер эчендә.

Атсагыз да, ассагыз да риза,
Мин гөнаһлы Вакыт каршында:
Җаһил булып тумасам да җиргә,
«Җиттем җиде патша башына»,—
Шул бер гөмер эчендә.

Кояшларың сүнсә, хәсрәтләрең
Сүрәнәйми икән кичен дә:
Мин яшәдем яуда янган эткәм,
Суга баткан улым өчен дә,—
Шул бер гомер эчендә.

Шул бер гомер эчендә,—
Тәүдә—дәһри, соңра диндар итте,
Кертте заман төрле сурәткә,
Фанилыкта тәмуг утын татып,
Юл яралмый калдым җәннәткә.

Әрвахларым—дуслар, туганнарым,
Сезне дәшеп, кордым зур табын;
Рухыгызга атап яздым менә
Бу гасырның сагыш китабын,—
Шул бер гомер эчендә.

## Булсачы...

Бәхетне без умырып тотар идек,
Тик кайда соң аның кулчасы?
Җырлап кына яшәр идек тә бит,
Җырлап кына яшәп булсачы!

Рим ИДИЯТУЛЛИН *(1940)— шагыйрь, башкорт һәм татар телләрендә «Хәерле иртә», «Хәерле көн» исемле китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Уфада яши.*

Нигә шулай ис-төтенгә тула
Ак дөньяның кара мунчасы?
Елап кына яшәр идек тә бит,
Елап кына яшәп булсачы!

Их, кояшта җылынмый да калдык,
Җитеп беткән энә кичләр дә;
Өннәрендә рәхәт күрмәгәннәр
Ләззәт кичерсеннәр төшләрдә!

Без, бәндәне, нинди омтылыш соң
Алга әйди, алдап көн-төнен?
Челпәрәмә килгән өмет белән
Бәхетләрнең көтә бөтенен.

Елап туйгач, кинәт җырлый башлый,
Башкалардан кимен куймый ла,
Теткәләнгән йөрәк типкән чакта
Яшәүләрдән беркем туймый ла!

Баемаган кояш, җырлыйк әле,
Елап кына яшәп булмый ла!

## Гомер тоташ хушлашудан тора

Сагыш йөзе таныш түгел чакта
Туган ягым белән хушлаштым,
Һәм каланың салкын ташларына
Тузган чабатадан мин бастым.

«Хуш!» дидем мин зәңгәр күзле кызга,
Җиңнәремә сөртеп яшемне,
(Их, кайсыбыз гына булды икән
Тәүге мәхәббәттә бәхетле.)

Яшәп көйгән әнкәм белән салкын
Кабер өсләрендә хушлаштым:
Ыңгырашкан зират капкасын да,
Шатлык капкасын да шап яптым.

Түз йөрәгем!—аһ, нинди терәгем!—
Күмелде лә калды чоңгылда,
Син яшисең кебек, улым, кичер,
Һаман хушлашалмыйм чынында.

Бик вакытлы, бик вакытсыз киткән
Күпме җан дус белән хушлаштым,
Бар гомерем хушлашудан торгач,
Кадерләрен беләм сау башның.

Әйт, нәрсә ул яшәү?—безнең язмыш—
Соңгы шәме сүнгән мәгарә;
Үзем белән үз аңымда чакта
Хушлаштырсын Ходай Тәгалә!

## Кайткан кошлар белән сөйләшү

«Кайттыгызмы тагын ил-оягa,
Кичеп чүлләр, кочып диңгезләр?
Нишләп әле канат җилпегәндә
Көек исе килә сезләрдән?»

«Җир өстендә ялкын, шәйләү кыен,
Ул үлеме, әллә тереме?
Ут-очкыннан канатыбыз көеп,
Күзебезгә тулды сөреме;

Томан булып Җирне кайгы сарган,
Йөрәк җитми ярсып сайрарга...»

«Күкләрдән күп нәрсә күренгәндер,
Сугышлар соң дөрли кайларда?»

«Бәндәгә хас-мәңге бетмәс бәхәс:
Кайсы кавем, кай дин иң өстен?—
Аешалмый шуны кан коеша
Яһүдиләр илә фәләстин».

«Раббым бәндәсенә» ни җитми?!»
«Күккә күчәр өчен җир җитми».

«Канатыгыз талган, кыйтталарның
Төягәнсез, ахры, аһ-зарын,
Сулышыгыз капмадымы,—кыеп
Очкан чакта Кавказ сыртларын?»

«Биек таулар боек күренделәр,
Күз яшедәй ачы кар суы—
Үксеп ага-ага үзәннәрдә,
Хасил иткән хәсрәт дәрьясы.

Чечен иле—Кавказ итәгенә
Җәеп салган канлы намазлык,
Иблис әйтер күрсә: «Кодрәтемнән
Килмәс минем мондый явызлык!»

«Чеченына тагын ни җитми дә
Урысына анда ни җитми?!»

«Бераүсенә—ярымайлы ирек,
Бераүсенә—майлы җир[1] җитми».

«Туган җиргә кайтып җиттегез бит,
Аһ-зарыгыз, кошлар, ник бетми,
Сез бит гелән күктә, гел ирекгә,
Йә, сезләргә тагын ни җитми?!»

«О, кешеләр, безгә күп җитми,—
Җирдә барган зәһәр алышлардан
Каралмаган зәңгәр күк җитми!»

---

[1]Майлы җир—нефтьле җир күз унында тотыла.

## Грозный хәрабәләре өстендә гәп

Урам-урам күмер йортлар
Пыскып утыра;
Ике чукрак чечен карты
Кайнар гәп кора.

«Ай-вай, кар мул диләр, кордаш,
Быел Аргында».
«Әйе, бахыр, булып калдык
Кяфер алдында».

«Сугыш посты, ахры, кордаш,
Салкын тауларга».
«Китте урыс танк менеп
Бүре ауларга».

«Күче белән күсе үрчи,
Үлә сабыйлар».
«Русьне басып алалмастыр,
Ай-вай, Шамилләр».

«Тере микән, ишетелми
Терек шарлавы».
«Ичкер–Камыр баһадирның
Чәнчә бармагы».

«Җаен тагын сугыш җиле
Төшәр үзәнгә».
«Кайчан басар әсир Кавказ
Богау өзәргә?»

«Каф тау...»–ауды гәптәш нокта
Куймый сүзенә;
Карап катты сукыр пуля
Тишкән күзенә
(Ятим карт).

## Аптыраганнан язылган шигырь

*Сөеклеләргә*

Патшаларны барлап чыктым бүген
Дәверләрдән, барча илләрдән:
Сугышлар ул шуңа тынмыйдыр да,–
Бит патшалар гел дә ирләрдән.

Тәхетләргә чат ябышкан алар,
Берсе–исәр, берсе–башкисәр,–
Җанлы курчакмыни! Арт санына
Шәпләп типсәң генә ул төшәр.

Ә шулай да тәртип-кагыйдәдә
Булмый калмас бер-бер искәрмә:
(Искәрмәне искә ал да–тубал
Башларыңны ташка бик бәрмә).

Әнә ерак, әнә якын тарих,–
Әби патша, Тэтчер, башкалар...
Исләп торсаң, шулар какимендә
Күп хыяллар чынга ашканнар.

Кызыл йөзле әрсез узаманнар
Тәхет өчен һаман өзешә;
Әнә шуңа ирлек горурлыгы,
Күрәсездер, көннән-көн төшә.

Исми яңа җилләр, шуңа тынчу
Без яшәгән тап-тар бу читлек.
... Юл бирик без Әби патшаларга,
Күрсәтикче, ирләр, егетлек!



## Радик Фәизов

## РӘХИМ ИТЕГЕЗ, СЭР!

ФАНТАСТИК ХИКӘЯ

Скат балыгы сыман ялпак, уктай очлы гигант космоплан, биниһая куәтле двигательләрен гөжелдәтеп, урыныннан ук җәһәт кузгалды. Озатып калучыларның елмаюлы йөзләре, ялтырап торган бетон полоса, Җир үзе дә минут эчендә артта, хисапсыз еракта, түбәндә калды. Космоплан, гайре табигый бер куәт чөеп җибәргән сөңгедәй, Җир шары атмосферасын бер селтәнүдә тишеп үтте.

Тизлек—адәм баласының фикере иярә алмаслык иде.

Һәм менә—иксез-чиксез кара бушлык—Галәм иркенлеге.

Бу тиклем куәтле, унайлы һәм акыллы очкычны Галәмгә ничәмә тапкыр күтәреп тә, Райт әле һаман да шул гадәти бер тойгыдан котыла алмый... Кулларына космоплан штурвалын кысып, Җирдән Галәмгә сикереп кенә үткәндә аның күкрәгенә сулышын тарайтып, дулкынлану, соклану, горурлык хисе кереп тула. Мондый искитмәле машина штурвалы янында, Галәм киңлегенә чыккач, Америка Кушма Штатлары гражданины Джеймс Райт шәхсән үзен бу дөньяда иң куәтле, бәйсез, барыннан да өстен бер зат итеп, Пентагонның тәкәббер генералларыннан, хәтта инде президентның үзеннән дә кодрәтлерәк бер кеше итеп тоя.

Һәм шушы очкыч күтәрелгән саен, әлеге тойгы үсә торды, билгеле бер юнәлеш ала барды. Акрынлап эш шуна барып җитте ки, утыз ике яшьлек, физик һәм акыл ягыннан да сау-сәламәт Райтның күнелендә бер уй яралды. Дөньяда монарчы күрелмәгән дәрәҗәдә зур, кыю һәм хәтәр уй. Һәм менә Райт ныклы карарга килде. Бүген! Барысы да бүген хәл ителәчәк!

Райт үзенең ярдәмчесе, икенче пилот Питер Яаррау ягына күз төшереп алды. Питер искитмәле күркәм, чибәр егет. Көнбагыш чәчәгедәй сап-сары чәчле, зәңгәр күзле блондин, бернигә исе китми торган, тып-тыныч күңелле, гризли аюыдай куәтле яшь пәһлеван.

Радик ФӘИЗОВ *(1931)—прозаик һәм публицист. «Бәхет», «Дусларым», «Галәм кызы», «Адымнарым», «Ак каз» китаплары авторы. Арчада яши.*

Яррау әлегә Райтның уйлары турында берни дә белми, абайламый да. Әмма мондый карусыз бер бозауны күндерү әллә ни авыр булмас. Идарә итү кабинасыннан артта урнашкан, зал кебек иркен пассажирлар салонында Джоанни–Райтның ярәшелгән кызы–дөньяда иң гүзәл һәм искитмәле кыз берүзе утыра. Ул да берни белми әле. Аларга барысын да соныннан гына төшендереп бирәчәк Райт. Дөньякүләм мәхшәр кузгалып киткәч, инде чигенергә урын калмагач. Хәер, нигә әле аңлатып, үгетләп маташырга, вакыт әрәм итеп. Ул аларга әмер генә бирәчәк һәм вәссәлам!

Әйе, әлегә беркем бернәрсә белми. Бөтен Җир шары, кешелек дөньясы, президент үзе дә белми. Һәм алар, бик ихтимал, хәлнең асылын, мәхшәрнең нигә һәм ничек башланып киткәнен тәки төшенми дә калыр. Бәлки бу шулай кирәктер дә.

Түгәрәк тәрәзәләрнең теге ягында коточкыч салкынлык, дегеттән кара, адәм баласын секунд эчендә боз кантары итәргә сәләтле галәм бушлыгы, ә космоплан кабинасында җып-җылы, плафоннардан йомшак яктылык коела, бернинди калтырау яисә зыңгылдау юк, тыныч һәм рәхәт. Райт корабльне бары тик космоплан пилотларына гына каралган эшелонга, төрле иярченнәр һәм космик станцияләр комачауламый торган биеклеккә күтәрде. Моннан инде Җир шары өстендәге материкларның чикләре генә шәйләнә, офыкның түгәрәк икәне ап-ачык беленә. Үзенә әмер ителгән биеклеккә корабль шулкадәр тиз һәм ансат күтәрелде ки, Райт үзалдына елмаеп утырды. Шайтан алгыры! Очкыч кына түгел, дөньяда монарчы бөтенләй күрелмәгән могҗиза бу! Һәм бу могҗизага ул–Джеймс Райт хуҗа!.. Тиздән, бик тиздән шушы могҗиза аны бөтен дөньяның хакиме, хөкемдары итеп куячак.

Аэрокосмоплан «Х-31» дөрестән дә искитмәле очкыч иде. Проектның башлангычында аны пассажирлар йөртү өчен билгеләделәр. Һәм «Көнчыгыш экспрессы» дигән романтик исем дә бирделәр үзенә. Иң соңгы ясалган һава лайнерларын да уздырып бу очкыч берничә дистә километр биеккәрәк күтәрелә алды һәм искитмәле тизлек күрсәтте. Аңа утырган пассажирлар ике минут эчендә бөтен Җир шарын әйләнеп чыга ала иде. Американың калын кесәләре, билгеле инде, шушы очкычта гына сәяхәт итәргә теләделәр.

Ләкин тиз арада мондый космоплан белән Пентагон үзе кызыксынды. Кызыксыну белән генә чикләнмәде, проектның туксан процентын финанслауны үз кулына алды. Дөресе, тулаемы белән кабып йотты. Шулай булмыйча! Аэрокосмоплан «Х-31» яманаты чыккан «Челленджер»ларның һәм бөтен «Шаттл» программасының борынына чиртте. Аның ярдәмендә орбитага файдалы йөк чыгарып кую егерме тапкыр арзангарак төште! Өстәвенә, хәрбиләр аны тагын күп нәрсәләргә «өйрәтте». Космоплан, Галәмгә күтәрелеп, теләсә кайсы ясалма иярченгә якын килә, махсус җайланмалары белән аны әсир итә ала. Үз бортына алып аның эчен актара, ватып тимер-томыр итә, үзгәртеп яисә төзәтеп кире орбитага чыгара. Үзенең шлюз камерасы ярдәмендә теләсә кайсы космик станциягә килеп ялгана, аның экипажын алыштыра, азык-төлек, ягулык, почта китерә. Хәтта астронавтлар тар станциядән вакытлыча космопланның иркен салонына чыгып, анда ял итеп, кәеф-сафа кора алалар.

Әлбәттә инде, хәрбиләр космопланның гади йөк ташучы, хезмәт күрсәтеп йөрүче генә булып калмавын кайгырта белделәр. «Х-31»нең гади кешеләр абайламый торган яшерен «кесәләре» бар. Һәм ул кесәләргә кайбер нәрсәләр салып Галәм киңлекләренә алып чыгарга мөмкин. Менә бүгенге күтәрелү дә гади рейс кына түгел. Командир буларак, Джеймс Райт берүзе генә белә: бу рейска космоплан кесәләренә салып нәкъ әнә шул «кайбер нәрсәләр»не алып чыкты. Шушы йөк белән командир очкычны төрле режимда, төрле эшелонда сынап карарга тиеш. Һәм бөтен нәрсә аның үз карамагында. Җир белән турыдан-туры элемтәгә керү катгый тыела. Барысы турында да базага кайткач кына сөйләп бирергә.

Бүген—Джеймс Райт көне! Ул әллә кайчаннан бирле күпме хыяллар корып әзерләнгән, гасабиланып көткән көн! Үзе күтәрелеп киткән Ванден базасына космоплан инде кабат беркайчан да әйләнеп кайтмаячак.

Америка Кушма Штатлары Хәрби Һава Көчләренең сынаучы-очучысы полковник Джеймс Райт, күз иярмәстәй тизлек белән кара бушлыкны тишеп барган космоплан штурвалын тоткан хәлдә, котылгысыз уйларыннан арына алмады. Ул әле рухи яктан һаман соңгы хәлиткеч адымга әзерләнә иде. Ул үзенең бар тәвәккәллеген бер йодрыкка төйнәп, барысына да төкереп кенә карарга омтыла кебек, ә күңеле түрендә исә ниндидер намус, кешелеклелек дигән төшенчәләр баш калкытып маташа, зиһенен бер ноктага юнәлтергә ирек бирми иде. Райт шунда Питер Яарраугa күз төшерде һәм ирексездән елмаеп куйды. Менә сина, кирәк бит, әй! Икенче пилот, бөтен эшне командирына ышанып тапшыргандай, рәхәтләнеп гамьсез йоклап утыра. Иптәшенең нәкъ сабыйларча самими йөзен, янакларына чыккан нәфис алсулыкны, күзләрен каплаган озын керфекләрен күргәч, Райтның йөрәген ниндидер унайсызлануга охшаган нәрсә тырмап алгандай итте. Тик Райт бу тойгыдан җәтрәк качарга тырышты.

—Чәнчелеп китсеннәр! Ник бөтен дөньясы җәһәннәмгә олакмый!

—Нәрсә бар, командир?—диде Яаррау күзләрен ачып.

—Берни дә юк. Курста нәни генә хата. Хәзер төзәтәм,—диде Райт.

—Ә-ә,—диде Яаррау һәм тагын күзләрен йомды.

Райт Галәмгә чыгу һәм ана бәйләнешле мөмкинлекләр турында хыялланып үсмәде. Гомумән, хыялый кеше түгел иде ул. Аның әтисе һәм аннан соң Райт үзе дә мастерской хуҗасы иде. Велосипедлар төзәтә торган нәни генә бу алачык ач та итми—тук та итми, дигәндәй, азмы-күпме капитал китерсә дә баеп югары җәмгыятькә үрләү мөмкинлеге бирмәде. Монда үз-үзенне аямыйча, көнне төнгә ялгап күпме генә азаплансаң да әллә ни алга китә алмыйсың.

Хәер, егет зур капитал туплауга омтылмады. Аны иң борчыганы—күңеленә яшьтән төзәлмәслек җәрәхәт булып уелып калганы—үзе яшәгән җәмгыятьтәге коточкыч тигезсезлек иде. Ни өчен берәүләр гомерләре буе бил бөгеп тә, якты дөньядан шул бөгелгән хәлдә китеп баралар? Ни өчен икенчеләр бернинди көч, сәләт сарыф итмичә дә хисапсыз байлыкларга, чикләнмәгән куәткә ия? Ә Табигать анабыз тарафыннан барлык кешеләр дә тигез итеп яратылган лабаса... Бу аяусыз гаделсезлеккә, бу тигезсезлеккә ничек итеп чик куярга? Егет менә шушы четерекле сорауларга җавап эзләде. Тик ана—азмы-күпме милек иясе булган адәмнең башына, җәмгыятьне, социаль җирлектә, революция юлы белән үзгәртеп кору уе килмәде. Аныңча, барысы да бик гади: бу җәмгыятьне, коточкыч усал, мәкерле, аяусыз, төрле алдаулар һәм юньсезлекләр белән тулган җәмгыятьне, юк итеп ташларга кирәк! Бер селтәнүдә! Ә аннары... исән калган азчылык белән яңа җәмгыять төзергә—үзара тулы тигезлек хөкем сөргән җәмгыять. Ул яңа җәмгыять, аның барган юлы нинди булыр, нинди кытыршылыклар, янтаюлар килеп чыгар? Болары хакында инде Райт баш ватып тормады. Иң мөһиме—социаль гаделсезлекне юк итеп ташларга! Аннан соң күз күрер.

Асылы белән соң чиктәге реакцион, хәтәр мәсләк иде бу. Вак буржуа мәсләге. Нәкъ менә шушы мәсләк кайчандыр Германиягә Гитлерны бирде. Дөнья өстенә, халыклар өстенә коточкыч афәтләр иңдерде.

Тырыш һәм эшчән әтисеннән үзгә буларак, Райт велосипед мастерское хакында юньләп кайгырта белмәде. Вакытында өйләнмәде, үз тормышын кормады. Көнкүреш ыгы-зыгысы эчендә әйләнүдән тәмам туйды да барып армиягә ялланды. Ә биредә аны—артык нечкә хисләргә бирелми торган, физик яктан бик таза боксчы егетне, тиз күреп алдылар. Аның белән Хәрби Һава Көчләре кызыксынды. Әле кайчан гына велосипедлар төзәтеп көн күргән, тыйнак егет салкын канлы, салкын акыллы, куркуның ни икәнен дә белмәгән кыю йөрәкле очучы булып

китте. Инде Пентагон аны үз канаты астына алды. Берничә елдан ул беренче классны очучы, ә аннары иң яңа хәрби техниканы сынаучылар арасында иде. Ул аэрокосмоплан «Х-31»гә, техниканың өр-яңа, иң куәтле казанышына хуҗа булу бәхетенә иреште.

Иң куәтле техника! Чикләнмәгән мөмкинлекләр! Менә шунда инде Джеймс Райтның күңелендә соңгы еллардагы уңышлар юшкыны астында күмелә килгән теге уй баш калкытты. Аяусыз һәм хәтәр уй... Ул үзе үзгәргәнгә, үскәнгә, югары күтәрелгәнгә карап кына җәмгыять бер тамчы да үзгәрмәде бит. Киресенчә, әнә, җәмгыять тагын да түбән тәгәри. Ә ул үзе, асылда, әле һаман доллар бәрабәренә ялланган бер ялчы бит. Нигә мондый җәмгыятьне юк итеп ташламаска?! Бу эш хәзер аның кодрәтеннән килә.

Америка Кушма Штатлары гражданины Джеймс Райт аз да түгел, күп тә түгел, өченче Бөтендөнья сугышын башлап җибәрергә җыена иде. Атом-төш коралы сугышы!

...Райт приборларга күз төшерде. Космоплан тиешле эшелонда бара, гаять зур радиус белән тын океан өстендә әйләнә. Барысы да тәртиптә. Райт аркасын креслога терәп, уңайлап утырды.

Әйе, барысы да тәртиптә, инде барысы да хәл ителгән. Менә ул тиздән космопланны каршы яктагы бөек держаканың һава чикләре янына алып киләчәк. Шуннан торып Кушма Штатлар территориясенә ракета залпы бирәчәк. Әйе, нәкъ менә үз Ватаны өстенә! Моның сәбәбе һәм мантыйгы да бар. Әгәр дә залпны руслар ягына күчерсәң, аларның әле бу залпның гади бер провокация икәнен төшенеп алулары, хәтта җавапсыз калдырмаулары ихтимал. Ә менә Пентагон генераллары исә, аны-моны абайлап өлгермәячәк. Аларның НОРАД һәм САКлары[1], бүген искәртү системалары хаталанудан айный алмый. Әле үткән гасырның илленче елларында ук, алдан искәртү системасы, Америкага атом бомбалары төялгән совет очкычлары якыная дип коткы салды. Чынлыкта исә бу кыр казлары көтүе булып чыкты. 1980 елның 3 июнендә НОРАД системасы компьютерларының берсе сөрән салды: русларның континентара баллистик ракеталары якынаеп килә! АКШның атом-төш коралы төялгән йөзгә якын бомбардировщигы һәм президентның һава идарәсе пункты һавага күтәрелергә әзерләнде. Һәм ни сәбәптән? Компьютердагы бәясе 44 цент торган бер чипның бозык булуыннан.

Руслар чиге ягыннан залп бирәсең икән, Пентагон ике дә уйлап тормаячак. Шунда ук җавап залпы бирәчәк. Ул тәкъдирдә инде руслар да кул кушырып тора алмас. Димәк ки, атом-төш сугышы! Һәм бу сугышны ул—Джеймс Райт башлап җибәрә. Ә нәрсә? Мондый хокук ни өчен президентларга гына бирелгән ди әле?

Аннан соң Джеймс космопланны мөмкин булган иң югары эшелонга күтәрә. Шуннан торып каршы якларның бер-берсен юк итүләрен көтә. Барысы да җәһәннәмгә олаккач, космопланны Тын океан уртасындагы утрауларның берсендәге запас базага утырта. Бу утрауда җирле халык та аз калган, гарнизон да кечкенә генә. Полковник Райт дәрәҗәсе белән анда иң зур кеше булып калачак һәм, билгеле инде, властьны да үз кулына алачак.

Джеймс Райт күкрәген тутырып, тирән итеп бер сулады да штурвалны кысып тоткан хәлдә, корабльне Россия һава чикләре зонасына юнәлтте. Уңайлы квадратка җитү өчен нибары сигез секунд вакыт китте. Хәзер, хәзер! Райт космопланны текә борып алды, сөңгедәй очлы борыны белән штатларга төбәде. Аның уртасы батынкы ияге алга чыккан, калын иреннәре нык кысылган, эре сөякле йөзендә тәвәккәллек иде. Инде уянып приборларга текәлгән Питер Яррау, шактый сәерсенеп, командирына карап алды.

—Өйрәнү атакасы...—диде Райт.

[1]НОРАД һәм САК—Американың ракеталар һөҗүмен алдан искәртү системалары.

Яррау «анладым!» дип ым какты.

Шунда Райтның күзе сул яктагы тәрәзәгә төште һәм... ул дерт итеп куйды. Очу курткасы астында аркасы шау тир булды. Космопланга бөтенләй таныш булмаган бер орбиталь станция якынлашып килә, инде сиздермичә генә шлюз камерасына тоташыр дәрәҗәдә якынайган иде! Бу ни хәл тагын?! Бернинди очу планында каралмаган, бернинди кисәтүсез, әллә акылдан язганмы алар анда?

—Мин хәзер, хәлне ачыклап киләм,—диде Райт, Ярраунга анлаешлы итеп идарә приборларына ымлап һәм үзе, урыныннан торып, корабльнең арткы өлешенә, шлюз камерасына юнәлде. Берәрсе шаяртадыр әле, муенастына килгере!

Хәзер, командир алар белән сүзне кыска тотачак. Иркен һәм буш пассажирлар салонында, болындагы ялгыз чәчәккә охшап, Джоаннинын тузгак башы күренде. Райтның күнеленә җылылык дулкыннары үтеп керде. Кадерлесе Джоанни аның белән бергә! Ул зур түрәләр каршысында ялынуга, кимсенүгә чаклы барса барды, ә менә бу рейска кызны үзе белән алып чыгу бәхетенә иреште. Райт, ерактан ук үзенә омтылып торган кыз янында тукталып, аның иреннәренә иренен тидереп кенә алды да алга ашыкты. Бу көтелмәгән тоткарлыктан тизрәк котылырга кирәк иде.

Ул арада инде теге станция космоплан бортына килеп ялганган, ә автоматлар шлюз камерасы ишеген киң итеп ачып куйган иде. Әйтерсен, космоплан командиры Джеймс Райтны ниндидер тантана, олылау көтә. Чыннан да, камерадан кемдер чыгып ишек янына басты һәм... Райт тагын имәнеп китте. Гаҗәеп серле, гаҗәеп сәер бер зат иде бу «кемдер». Бик озын буйлы, чандыр, бастырып куйган такта төсле төз һәм ялпак гәүдәле бер... карачкы иде бу! Аның идәнгә кадәр салынып төшкән плащы бу охшашлыкны тагын да көчәйтә иде. Бу затның озынча башында чәч дигән нәрсәнең әсәре дә юк, бөтен битен, түм-түгәрәк дәү күзләре тирәсен эре-эре, тирән җыерчыклар сарган иде. Райтны бигрәк тә карачкының күз карашы тетрәтте. Райт монарчы Җир шары кешеләренен берсендә дә күрмәгән тирән акыл, рухи көч, сабырлык бар иде бу күзләрдә. Аларның карашы астында Райтка, ни өчендер, бик тә унайсыз булып китте. Әлеге зат, әлеге кеше таяктай озын кулы белән шлюз камерасының түренә күрсәтте.

—Вилкәм, сэр, рәхим итегез!—диде ул инглизчә, бик нәзакәтле итеп.

Райт тумыштан бернинди куркуны, каушап калуны белми торган адәм иде. Тик бу хәлләрдән ул да югалып калды. Хәтта борылып китәргә талпынды. Ләкин нәзакәтле гозер әмер рәвешендә тагын кабатланды:

—Вилкәм, сэр, рәхим итегез!

Һәм Райт ирексездән атлап камерага керде. Үзен ул ниндидер бер реаль булмаган, сихри, хыялый дөньяда дип хис итә иде. Һәм шунда!.. Шунда, нәкъ әкияттәгечә, аның каршысына, аның... копиясе, игезәге—ул үзе атлап чыгып килә иде! Әйе, әйе—ул үзе! Уртасы батынкы киң ияк, туры борын, аз гына турсаеп торган калын иреннәр—барысы да тәнгәл киләләр, хәтта очу курткасы җиңендәге сан да «12» иде. Райт тораташ булды да катты. Ә Райт-II исә, хәрбиләрчә атлап, аның яныннан үткәндә, хәтта дусларча елмаеп, күз кысып өлгерде. Аның нык атлап космопланга кереп китүе иде. Шул мәлдә үк Райт-II артыннан камера ишеге чыжылдап ябылып та куйды.

—Вилкәм, сэр!

Ниндидер бер көч Райтны шлюз камерасыннан станция эченә тартып алды һәм Галәмдәге ике объект бер-берсеннән аерылып та китте. Ике карачкы Райтны култыклап алды, ишек ачып каршылаганы алдан атлады. Райтны озын коридор буйлап алып киттеләр һәм ул, Галәм техникасы белән бик таныш кеше, аңлап алды: бу бернинди орбиталь станция түгел, бу космик корабль, космопланның үзеннән дә әллә никадәр

куәтле Галәм сәяхәтчесе иде. Америка гражданины Джеймс Райт хәзер инде үзе идарә иткән космопланнан колак каккан, аннан бик еракта, бөтенләй икенче дөньяда,ниндидер явыз кешеләр, ә бәлки башка планета, бүтән цивилизация вәкилләре кулында иде. Тик менә ул аларга ни пычагыма кирәк булды икән?

Аны түгәрәк бер бүлмәгә алып керделәр. Бу бүлмәдә бернинди кресло яисә урындык күренми, бирелдәге жан ияләре барысы да аяк өстендә. Уртадагы калкулык кебек урында тагын бер карачкы басып тора, аның йөзендәге, күз тирәсендәге җыерчыклары бүтәннәрнекеннән дә тирәнрәк иде. Командирлары күрәсең. Түгәрәк бүлмәнең стеналары буенда тагын күп карачкылар басып тора. Райтны уртага, командир каршысына чыгарып бастырдылар. Барысы да кызыксыну һәм игътибар белән аңа текәлгән иде. Бу тирән акыллы карашларда Райт үзенә карата ниндидер шелтәләү чалымнары күргәндәй булды.

—Зәңгәр планета кешесеме?—дип сорады тегеләр командиры.

—Әйе, мин—Җир планетасы кешесе!—диде Райт горурлык белән.—Ә менә сез... кайдан килгән карачкылар? Кемнәр сез?

—Без Галактика үзәгеннән. Без—гел сәяхәттә!—диде командир.

—Чәнчелеп китегез! Кайдан килсәгез дә, минем барыбер сезне күрәсем дә килми. Хәзер үк үз кораблемә кайтарып куегыз. Мин моны таләп итәм!—диде Райт.

—Хәзер сез, сэр, Зәңгәр планета кешесе түгел!—диде командир искиткеч тыныч һәм нык итеп.—Сезнең, гомумән кеше итеп, гакыл иясе итеп саналырга хакыгыз юк. Чөнки сез бөтен бер планета халкына куркынычлы индивидум. Бу—Бөек Галәм Тынычлыгы Законына каршы килә. Без сезнең уйларыгызны укыдык, планнарыгызны белеп алдык. Алар тормышка ашмасын өчен, без сезне үз карамагыбызга алырга карар иттек. Зәңгәр планетаны, Галәмдәге иң матур планеталарның берсен, сез саласы афәттән саклар өчен. Без сезне хәзер үк үз планетабызга озатабыз. Анда тәрбия кылачакбыз. Вилкәм, сэр!—диде командир.

—Шайтан алгыры, соң озата бирегез, тәрбияли бирегез!—диде Райт зәһәрле тантана белән.—Тик минем планнарым барыбер тормышка аша. Анда, космопланда, минем игезәгем...

—Ә ул без җибәргән робот кына. Штурвал артында утырган җиреннән үк тере булмаган материя хәленә күчте,—диде командир Райтның зәһәренә һич кенә дә илтифат итмәстән.

—Сез!.. Кеше үтерүчеләр сез!—диде Райт.

—Бер индивидум ике кабыкта яши алмый. Бигрәк тә ул бөтен бер планета өчен куркынычлы шәхес булганда. Монысы да Бөек Галәм Законы!—диде командир тантана белән. Стена буендагы барча карачкылар командирлары фикерен хуплап аяк express кактылар.

Командир кулын күтәрде. Райтның ике ягына ике карачкы килеп басты.

* * *

Тагын ярты сәгатьтән Джеймс Райтның тирән анабиоздагы гәүдәсе салынган капсула Галактика үзәгенә оча иде инде. Кеше акылы иярмәслек тизлек белән.



**Миркасыйм Госманов**

# ЯҢАДАН ТАНЫШУ ЯКИ ФИДАКАРЬ ХӘЙРИЯЧЕЛӘРЕБЕЗ ХАКЫНДА

1959 елның 23 ноябрендә уздырылган бер әдәби кичә хәтеремдә нык уелып калган.

СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы конференц-залында (Лобачевский бакчасы янындагы бинада) булган иде ул кичә. Тыштагы җепшек, салкынча көзге һавадан соң монда әллә ничек ягымлы җылылык хөкем сөрә иде. Әйтерсең лә, шыксыз һавалы көннәр артта калган да, алда исә шушы шыгрым тулы зал кебек якты, нурлы, җылы киләчәк көтә...

Кичәгә җыелган халык та үзенчә аерылып тора иде: бәйрәмчә киенгән зыялы кыяфәтле агайлар, ханымнар; олыгайган, чал чәчле олпат картлар, апалар—моннан 40-50 еллар элек үк иҗтимагый тормышка, әдәби хәрәкәткә катнаша башлаган кешеләр иде алар.

Нигездә әдипләрдән, галим-голәмә һәм артистлардан, кыскасы, интеллигенциядән, шулай ук беркадәре студентлардан тупланган халыкта бәйрәмчә хис хөкем сөрә: таныш кешеләр бер-берсе белән кул алышып күрешәләр, котлашалар. Олы яшьтәгеләре мәгънәле рәвештә ым кагышып елмаеп куялар. Тыгыз итеп тезелгән кәнәфиләргә барып утыралар. Кайбер олы яшьтәге кешеләрнең үз оныкларын да алып килгәнлеге күренеп тора: әби-бабайлары янында әле генә буй җиткергән кызлар, мыеклары төртә башлаган үсмер егетләр шәйләнә. Залга соңрак керүчеләрне алданрак урын алучылар кул изәп сәламлиләр; якын тирәдә буш урын булса, ишарәләп яннарына чакыралар. Һәрхәлдә, теләктәшлек һәм чын бәйрәмчә атмосфера хөкем сөрә монда...

Ул кичәдә туган, дөресрәге, хәтеремдә оешып калган тәэсирләр хакында хәзер төптәнрәк уйлап карасам, андый атмосфера урнашуның җитди сәбәпләре, зур иҗтимагый мәгънәсе булган икән. Мәшһүр егерменче съездан соң туган (бүген ни өчендер "Хрущев җепшеклеге" дип авыз кыйшатыбрак әйтелә торган, чынлыкта күпләр өчен сүнеп барган өметләргә яңа рух өргән) мәгълүм

елларның берсендә уздырылган һәм чын мәгънәсендәге олы вакыйга булган икән ул кичә. "Халык дошманнары" дип тамгаланган, төрмәләрдә утырып тап алган Галимҗан Ибраһимовлар, Кәрим Тинчуриннар әле генә "кайтарылган" еллар бит. Бу кичә исә татар халкының иң күренекле шагыйрьләреннән берсе булган Дәрдмәнднең—күп еллар буена "буржуаз эстет", гади халыкны изүче "миллионер" сыйфатында сүгенеп кенә телгә алына торган Закир Рәмиевнең 100 еллыгына багышланган тантаналы җыелыш иде. Дөресрәге, элек гел читкә тибәрелгән, хәтта хурланган иҗатның әдәби һәм мәдәни хәятыбызга яңадан кайтарылуын рәсмиләштерә торган тарихи вакыйга!

Сәхнә түрендә затлы кыяфәтле шагыйрьнең фотосыннан эшләнгән зур сурәт тора. Докладны ул чакта әдәбият буенча берданбер профессор булган Мөхәммәт ага Гайнуллин укый. Зал тып-тын; докладны йотлыгып тыңлыйлар. Кешеләр гүяки докладчының һәр сүзен, хәтта һәр авазын да отып калырга телиләр...

...Бүген исә, әлеге кичәдә яңгыраган докладны, дөресрәге, аның басылып чыккан тулырак текстларын укысаң, сәер генә хисләр туарга мөмкин. Бер яктан, тирән фикерле шагыйрьнең гаҗәеп осталыгы, намуслыгы хакында шактый җылы сүзләр әйтелгән; икенче тарафтан аның дөньяга карашы, тоткан юлы "буржуазлыкта" һәм нindидер аңлаешсыз "чикләнгәнлектә" гаепләнә. Аның "Вакыт" газитәсе, "Шура" журналын чыгарудагы эшчәнлеген, тырышлыгын да кыскача беләбез. Ә чын буржуйның һәм иҗтимагый аңы чикләнгән кешенең күп еллар дәвамында андый басмалар өчен үз акчасын түгеп ятуы—моның сәбәпләре аңлашылмый кала. Мин үзем Дәрдмәнд дигән бер шагыйрьнең "Кораб" исемле шигырен элек тә яттан белә идем (мин туып үскән якларда аны җыр итеп тә башкаралар иде бугай...). Ләкин ул шигырьдә тирән мәгънә, чишелмәс "каршылык" булуы хакында ишетмәгән идем әле. Һәрхәлдә, әлеге кичә минем өчен үзенә күрә бер ачыш—билгеле дип исәпләнгән шагыйрь белән яңадан танышу булды.

Соңрак уйлап карасам, ул кичә совет чорында дөньяга килгән яки шул заманда тәрбия алган урта һәм кечерәк яшьләрдәге буын вәкилләре өчен, хәтта илленче еллар ахырындагы әдәби, мәдәни тормыштан азмы-күпме дәрәҗәдә хәбәрдар булган киң җәмәгатьчелек өчен дә Дәрдмәнд дигән олы шагыйрь белән яңадан танышуның бер рәсми акты булган икән.

Мөхәммәт ага Гайнуллинның, уңга-сулга карый-карый дигәндәй ташламалар ясап, саклык белән язган доклады, аның "Совет әдәбияты" журналында һәм шагыйрьнең 1959 елда чыккан "Сайланма әсәрләр"ендә кереш мәкалә буларак басылган текстлары—алардан бүген нинди генә кимчелекләр эзләп тапсаң да—үз вакыты өчен билгеле дәрәҗәдә кыюлык, актуаль яңалык булган лабаса. Гомумән, Мөхәммәт аганың ул елларда һәм аннан соңрак та 1917 елга кадәр иҗат иткән әдипләрнең исемнәрен кайтару юлындагы эшчәнлеге, әгәр төптәнрәк уйласаң, үзенә күрә бер фидакарьлек тә иде. Әлбәттә, ул елларда тоталитар хәлдә хөкем сөргән рәсми идеологияне, аңа хезмәт итүче "чын партияле" тәнкыйтьчеләрнең арка терәкләре (дирижерлары) ныклыгын, Йосыф Акчура, Риза Фәхретдин, Фатыйх Кәрими ише зыялыларның исемнәре генә дә аталуның "зур политик хата", дип игълан ителүен исәпкә алганда...

Әйе, беркадәрле соңрак без, яшьрәк каләм ияләре, М. Гайнуллин хезмәтләренә хасрак "өстән-өстәнлекләр" күреп, аның үзеннән дә "каршылыклар" һәм "чикләнгәнлекләр" эзләсәк тә (хәтта олы кешенең рус телендә үзенчәлекле сөйләшүеннән көлебрәк йөрсәк тә), 50 еллар ахырында аның зур кыюлык, хәтта фидакарьлек күрсәткән шәхес булуында хәзер минем берниндu шигем юк. Чөнки аның белән чагыштырганда, "теоретик җәһәттән" күпкә әзерлеклерәк, күпкә кыюрак, дип исәпләсәң, иң мөһиме, "партия өчен ышанычлырак" дип саналган тәнкыйтьчеләрнең һаман ажгырып торган чаклары иде. Алар тагын күп еллар дәвамында Дәрдмәндне "символист" булуда, буржуаз "эстетлыкта" гаепләүләрен дәвам иттерделәр.

Фидакарьлек хакында сүз чыккан икән, тагын бер мәсьәләгә махсус тукталу кирәк булыр дип исәплим. Бер иҗат хакында кыю сүз әйтүне

фидакарьлек дип бәяләп, әмма шул иҗатның үзе турында шома гына узып китү бик үк дөрес булмас иде, әлбәттә. Чөнки зур иҗатлар хакында авыр шартларда дөреслекне ярып әйтүчеләр берләтә батырлык күрсәткән булсалар, андый мирас калдырган шагыйрьләрнең үз фидакарьлекләре, һичшиксез, икеләтә, өчләтә кыйммәткә иядер. Мәсәлән, теге яки бу иҗат хакында әйтелгән теләсә нинди кыю фикер вакыт узу белән үзгәрергә, ягъни киңәйтелергә, үстерелергә яки төзәтелергә—"үз урынына" утыртылырга мөмкин. Дәрдмәнд иҗатына карата әйтелгән күп фикерләр белән дә шулайрак килеп чыкты. Әмма аның үз әсәрләре—заманында әдәби хәрәкәтебезгә керткән бәхәссез өлеше, соңрак чор эстетик фикеребезгә ясаган тәэсире—үзгәрмичә яши бирә, һаман тәэсирен арттырганнан арттыра бара. Башка олы шагыйрьләребез, язучыларыбыз белән дә шундый ук хәл. Мисал кирәк икән, аның Кол Гали мирасы, Гаяз Исхакый иҗаты һәм төрле елларда аларга карата булган мөнәсәбәтләрнең язмышлары.

Шулай итеп, 1959 елда уздырылган әлеге кичә Дәрдмәнд белән яңадан чын-чынлап танышу акты булды, дөресрәге, аның әдәби тормышыбыз кочагына кайтуы рәсми рәвештә гамәлгә ашырылды. Нәтиҗәдә, аның мирасына карата игътибар көчәйгәннән-көчәйде. Әгәр 1966 ел башында, Уфада Диния нәзаратында беренчеләрдән булып Ризаэтдин Фәхретдин архивы, "Асар"ның кулъязма томнары белән танышкан чагымда, төп игътибарны андагы Дәрдмәнд биографиясенә караган материалларга, аның моңарчы билгесез булган шигырьләренә юнәлткән булсам ("Казан утлары", 1966, 7 сан, 118—123 б.), моның өчен мин, һичшиксез, әлеге 23 ноябрь кичәсендә алган тәэсирләремә бурычлымын.

Өр-яңа чор шигъриятебездә советча шома такмазалар урынына мәгънәле кыска шигырьләрнең активлашуы да (әйтик, Р. Фәйзуллин, Р. Харис һ. б. иҗатларында) шулай ук Дәрдмәнд мирасының тәэсире иде. Әдәбият белгечләреннән Н. Хисамовның зәвык белән язылган мәкаләләре барлыкка килү, Р. Даутов тарафыннан сыйфатлы итеп "Исә җилләр" җыентыгы төзелү дә (1980) шул ук тәэсирнең дәвамы. Ниһаять, иң характерлы совет чоры тәнкыйтьчесе булган Гали Халитның элекке социологизм схемаларыннан баш тартып, шагыйрь иҗатына яңача бәя бирергә омтылуы да, шагыйрь эстетикасының тантанасы булган кебек, тәнкыйтьченең дә гражданнарча батырлыгы—фидакарьлеге иде.

Ләкин мин бу урында Дәрдмәнд поэзиясенең кабатланмас әһәмияте һәм аның иҗаттагы гражданлык дәрәҗәсе хакында артык сөйләп тормастан (бу турыда без бүген кичәгегә караганда күбрәк беләбез инде), шагыйрьнең зур фидакарьлектән гыйбарәт булган икенче бер сыйфаты хакында махсус әйтүне кирәк табам. Сүз Дәрдмәнднең, дөресрәге, бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләрнең хәйриячелек, химаячелек, хәтта олы меценатлык юнәлешендә күрсәткән бәхәссез зур фидакарьлеге хакында булыр.

* * *

ХӘЙРИЯЧЕЛЕК, меценатлык турында сүз чыккач, бу төшенчәләр хакында, теманы киңәйтебрәк дигәндәй, мәсьәләгә төрле яктан карап, махсус аңлатмалар бирү кирәк булыр. Мондый төпченүгә, тәфсиллеккә җитди ихтыяҗ бар. Чөнки коммунистик идеологиянең большевистик варианты хөкем сөргән тоталитар совет чынбарлыгында хәйрия эше, хәйриячелек дигән күренеш "буржуаз мөкерлек" сыйфатында тулаем кире кагылган, хәтта каһәрләнгән иде. Мәсәлән, хәйриячелек хакында махсус гыйльми эзләнүләр булмау, бу күренешкә объектив бәя бирелмәү бер яктан, бәлки шул чорда рус телендә чыккан төрле характердагы сүзлекләрдә әлеге атаманың эквиваленты булган "благотворительность" сүзе йә бөтенләй юк, яки гаделсез рәвештә иске буржуаз тормышының зарарлы галәмәте сыйфатында аңлатыла килде. Хәтта С. И. Ожеговның сәясәт белән әллә ни бәйләнмәскә тиешле (шундый хокукка хаклы) булган гап-гади максатлы "Словарь русского языка" исемле лингвистик сүзлегендә дә аңа "одно из средств маскировки эксплуататорской

природы буржуазии" дип, үтергеч, ләкин яла табигатьле хөкем чыгарылган.

Татар теленең өчтомлы аңлатмалы сүзлегендә (1981) хәйриячелек, химаячелекнең берсе дә юк. Мәгәр "хәерче, хәер-сәдака, хәер-фатиха" ише тар мәгънәле төшенчәләр бар. Әмма 1966 елда Мәскәүдә чыккан татарча-русча сүзлектә "хәйрия, җәмгыяте хәйрия" төшенчәләре, мәгънәләре махсус ачылмаган хәлдә, кыскача гына теркәлгән. Ниһаять, Меценат дигән тарихи кеше исемен белсәк тә, шул исемнән ясалып, төгәл бер иҗтимагый күренешне белдергән меценатлык хакында да сүзлекләрдә ләм-мим...

Мондый хәлнең килеп чыгуы, минемчә, тарихи чынбарлыкка концептуаль мөнәсәбәт белән бәйле. Мәсәлән, ул хосусый, ягъни, русча әйтсәк, частный милекнең табигыйлеген танудан баш тартуга, хәтта аның барлыкка килүе, урнашуы кануный (бүгенгечә әйтсәк, легитим) икәнлеген инкяр итүгә барып тоташа.

Ярар, шул концепциягә таянып, милек ияләренең мохтаҗ кешеләргә яисә җәмгыять хаҗәтенә үз ихтыярлары белән ярдәм итүләрен инкяр иттек, ди. Әмма шул милекне көч белән тартып-талап алуны, ахыр чиктә әрәм-шәрәм итүне гаделрәк гамәл дип әйтеп буламы? Моның өчен, дөресен әйткәндә, бездән язмыш бүген "кычкырып көлде": бөтен XX йөз буена диярлек хосусый милекчелек белән көрәшкән, большевистик шартларда туып үскән, тәрбияләнгән җитәкчеләребез, шул гасырның ахырында ук, яңа битлек кигән хәлдә (янәсе "демократлашкан рәвештә"), өскә караган уч төпләрен алга суза-суза Җир шары буенча хәер соранып йөрделәр бит!

Әлбәттә, мондый хәлнең идеологик банкротлык нәтиҗәсе икәнлеге, аның хурлыклы күренеш булуы ап-ачык иде. Шуңа күрә, хурлыкны үз-үзеңнән яшерү чарасы буларак, "благотворительность", ягъни "изге эш эшләү" дигән гап-гади, җиңел аңлаешлы сүз урынына "бөек һәм кодрәтле рус телендә" спонсорише серлерәк яңгыраган чит сүз дә кулланыла башлады. (Мәсәлән, 1989 елда чыккан "Словарь иностранных слов" сүзлегендә аны табып булмас.)

Хәйриячелекне буржуаз эксплуатациянең мөкерле төре, явыз коралы, дип casларга маташкан коммунист җитәкчеләребез үзләре дә, яшерен-батырын түгел, халыкны социаль, икътисади изүчеләр катламына әверелеп беткән иде. Ил-дәүләт "хуҗасы" саналган колхозчылар бушка дигәндәй эшләгән, эшчеләр исә сөт-катык, икмәк, арзанлы "чәй" колбасасы өчен чират торган шартларда, түрәләребез, үз дәрәҗәләренә карап, конвертларда исәпкә керми торган өстәмә акча алып яттылар, кибетләрнең арткы ишекләреннән кереп, чит илләрдән китерелгән затлы сервилат колбасасы һәм кош-корт итен ташыдылар, ягъни бал белән майда йөзделәр. Әллә мондый хәлләр булмадымы бездә?.. Булган булса, аны өстенге катлам тарафыннан оештырылган эксплуатация төре димичә, ничек атарга? Яки үз халкы авызыннан тартып алынган милекне бүтәннәргә (чит ил баш күтәрүчеләренә, социализм төзибез дигән яланбот африкалыларга, коммунистлыкны дәгъва кылучы башка ил сепаратистларына) "интернациональ ярдәм", дип бушлай һәм үз халкыннан яшерен рәвештә өләшүләре белән совет җитәкчеләре үзләре үк төпсез һәм законсыз хәйриячелек эше белән шөгыльләнмәделәрме соң?.. Яисә үз илендәге халыкларның милли, рухи ихтыяҗларына кирәкле чыгымны бөтен ил милкен талап алып үзләштергән Мәскәү һәм җирле түрәләренең, кул сузып, үтенеп сорагач кына, тамчылап-тамызып дигәндәй "бүлеп" бирүләре шул ук хәйриячелек күренешенең бер төре булмадымы икән?!.

Шулай итеп, төптән һәм әтрафлырак рәвештә уйлап карасак, эксплуатацияне бетерү дигән талпынышның тормышка ашмый торган, һәрхәлдә бездә чынбарлыкка аша алмаган буш хыял—утопия, ә хәйриячелек дигән нәрсәнең исә реаль милек хөкем сөргән шартларда котылгысыз күренеш икәнлеген белербез. Теләсәк тә, теләмәсәк тә... Шулай булгач, элекке милекле кешеләрне, аларның хәйрия юлындагы гамәлләрен кире кагуның яки хосусый хәйриялекнең әһәмиятен күрмәмешкә салынуның үзе үк тормышчан һәм тарихи гаделсезлекнең бер чагылышы, дөресрәге демагогик алдашуы була икән.

Ике чордагы ике төр (дәүләти һәм хосусый) хәйриялек арасында уртаклык бар, һичшиксез. Ул бер нәрсәгә—кешеләр һәм халыклар эшләп тапкан милектән, байлыктан "башкаларга" өлеш чыгаруга кайтып кала. Аерма да бар, әлбәттә. Хакимият иясләре, хөкүмәт вәкилләре, ягъни чиновник-түрәләр законлы (тиешле һәм гадел күләмдә салым җыю), яисә законсыз, ягъни экспроприация юлы белән тартып-талап алу юлы белән тупланган байлыктан күп очракта үз өстенлекләреннән, үз кәнәфиләреннән колак какмас өчен генә милексез калган, "хәерчелектә тигезләнгән" халыкка мәҗбүри рәвештә, тамчылап-тамызып дигәндәй, "сәдака" бүлү белән шөгыльләнгән. Җылы урыныннан "очу", яки "өстән" шелтә алу куркынычы булмаса, гадәти чиновник халык ихтыяҗына бармак аша карый, хәтта төкерә генә аңа! (Дәүләтнеке дип исемләнгән байлыкның зур өлеше, безнең тарихта йөз биргәнчә, иң элек түрәләр катламын туендыруга, сугыш кораллары ясауга, яки, югарыда бер әйтелгәнчә, "интернациональ ярдәмгә" китеп бетә иде.)

Ниһаять, чиновник-түрәләрнең, шулардан торган хөкүмәт-дәүләт аппаратының халыкның рухи һәм мәдәни ихтыяҗларына бик өстән карауларын, аларны сәяси һәм идеологик мәнфәгатьләргә буйсындыруларын, кирәге чыкса, корбан итүләрен татар тарихы яхшы белә. Әйтик, без тарыган, төмен мул татыган "дәүләт хәйриячелеге" булмаса, бер гасыр эчендә ике-өч тапкыр язу алмаштыру ише фаҗигагә дучар булырмы идек? Яки XVIII—XIX гасырларда татарларның үзләре тарафыннан андый "герostратлыклар" башкарылу мөмкинме иде? Димәк, чиновник-түрәләр матди байлыкны гына түгел, рухи-мәдәни хәзинәне дә туздырырга сәләтле икән. Чөнки алар бер нәрсәгә дә чын хуҗа түгел. Алар вакытлы арадашчылар гына...

Хосусый милек иясләре, чиновниклардан башка буларак, үзләре тырышып-тырмашып, әлбәттә, башкаларны да эшләтеп, ягъни эксплуатацияләп туплаган, яки аталарыннан мирас итеп калган, мәгәр Нух пәйгамбәр заманыннан бирле законлы дип исәпләнгән үз милегеннән аерым мохтаҗ кешеләр яки җәмгать-халык ихтыяҗы өчен үз ихтыярлары белән өлеш чыгарып торган. (Эксплуатация мәсьәләсенә төртеп, "мәгънәле" авыз ермыйк: совет чорында да, күргәнебезчә, ул күренеш гамәлдә булган иде.) Әлбәттә, монда да чама хисе хөкем сөргән. Ләкин эш урыныннан, түрәлек өстенлегеннән колак кагу куркынычы астында түгел, бәлки "яхшылык эшлим әле" дигән ихтыяри теләкләр белән "үз авызыннан" бүлеп бирелгән. Димәк, хосусый һәм шәхси хәйриячелек дәүләти һәм рәсми кайгыртучанлыктан, әхлак җәһәтеннән караганда, бер башка биегрәк, өстенрәк булып чыга.

Дөрес, милекне кешеләр, байлар дөньясында, кем әйтмешли, котсыз саранннар, оятсыз жуликлар, гомумән, намуссыз бәндәләр житәрлек булган шикелле, түрә-чиновниклар арасында да ихлас күңелле халык-кавем, кешеләр мәнфәгате алдында үз бурычларына тугърылыклы игелекле затлар очрап торгалаган. Шулай ук, соңгыларында купчелекне мөкерле карьеристлар, туң йөрәк формалистлар тәшкил иткән кебек, байлардан да башкаларга карата рәхим-шәфкатьле һәм юмарт, үз кавеменә ихлас теләктәш, аның мәнфәгате өчен янып-көйгән асыл затлар, затлы нәселләр дә чыкканлыгы бәхәссез...

Бу юлларны күздән кичергән укучыда шундый сорауның тууы ихтимал: гап-гади хакыйкатьне раслар (әйтик, байлар арасында да әйбәт кешеләр булгалый, дип әйтер) өчен нигә шулкадәр уңнан-сулдан мисаллар китереп, бер теманы тәфсилләп торырга?

Хикмәт шунда ки, мәсьәләнең күп очракта без уйлап житкерми торган катлаулырак яклары да бар. Мәсәлән, без иң элек хәйриялекне, хәйриячеләрне күрәбез һәм аларга бәя бирәбез. Ләкин үзебезне яхшылап белеп, үзебезнең аларга карата булган мөнәсәбәтләребезне объектив рәвештә бәяли алдыкмы, алабызмы? Әгәр беләбез дисәк, безнең узган тарихыбызда күпме эре хәйрияче, меценат булган, аларның саннарын, конкрет эшләрен, исемнәрен төгәл атый алабызмы? Ниһаять, хосусый хәйриячелек дигән күренешнең иҗтимагый җәһәттән төп эчтәлеге, фәлсәфи асылы, әһәмияте һәм кыйммәте нәрсәдән гыйбарәт?!.

Сорауларның беренчесенә карата шуны әйтергә мөмкин. Безнең хәзерге җәмгыятебездә хәйриялеккә һәм гомумән милекле кешеләргә карата шактый каршылыклы мөнәсәбәт яшәп килә. Бер ишебез бай кешеләрне гомумән яратмый, күрә алмый һәм элекке түрәләрнең "гаделлекләрен" сагынып яши, (тик хәзерге яңа байларның күп очракта шул ук түрәләрнең үзләре яки якыннары, балалары икәнлеген уйлап тормый!. Икенчеләребез исә һәр "яңа урыс" белән "яңа татардан" әллә нәрсәләр өмет итә, аларның барысыннан да киң юмартлык, гализат меценатлык көтә.

Чынлыкта чиновник-түрәләр сүзнең төп мәгънәсендәге хәйриячеләр булмадылар, була да алмыйлар. Алар бары дәүләт кулында тупланган милек белән халык ихтыяҗы арасындагы арадашчылар гына (зур хәйрияче байларның да шундый ук функцияне үти торган махсус хезмәтчеләре булган).

Яңа байларга килсәк, аларның да зур күпчелеге өчен хәйриялек—кул җитмәслек биеклектәге серле төшенчә. Аларда, байлыкны эшләп һәм эшләтеп тапмыйча, бары Ельцин—Гайдар, Чубайс—Кириенколар уздырган "реформалар", дефолтлар чорында финанс махинациясе яисә дәүләтнекен юк бәягә үзләштерү юлы яки аракы сәүдәсе белән кинәт баеп калган кешеләрдә һәм, иң мөһиме, үзләре туйса да, күзләре һаман туймаган рухи люмпеннарда—хәйриячелек дигән күренешнең фәлсәфи мәгънәсен, иҗтимагый әһәмиятен аңларлык зиһен, интеллект, эчке культура җитеп бетми әлегә. Бик азлары гына, караңгыда капшанып дигәндәй, әлеге биеклеккә таба елышырга тырыша... Монысына да шөкер итик...

Сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәк, соңгы елларда бездә гамәлгә азлап-азлап керә башлаган хәйриячелек фактларына карата болай икеләрәк бәя бирүнең үз сәбәбе бар. Әйтик, төрле авылларда, аерым шәһәрләрдә яңа мәчетләр салыну, моңа киң җәмәгатьчелекнең катнашу фактларын алыйк. Ярдәмгә кайбер оешмаларның, зур предприятияләрнең җитәкчеләре дә катнашуы мәгълүм. Болар, һичшиксез, күңелле күренеш. Әмма ләкин мәчет, салынып беткәч, аңа фабрика яки башка бер икътисади кодрәтле оешманың тере җитәкчесенең—түрәнең исеме бирелүе (әйтик, "Альберт мәчете", "Хәйрулла мәчете" ише) гаҗәбрәк күренеш. Беренчедән, ул җитәкчеләр мәчет салдырыр өчен үз акчаларын түгел, бәлки оешма-предприятие милкендәге кирпеч, цемент һәм такта ише материалларны җибәртеп, хәтта төп эш урыннары шунда булган эшчеләрне күндереп ярдәм иткәннәр. Димәк, авылдагы ялгыз мәчеткә исем кую шарт булса, тере чиновникларның түгел, бәлки завод-фабриканың исемен бирү дөресрәк булыр иде. Соңгы вакытларда кайбер зур, икътисади көчле предприятияләрнең махсус ярдәм фондлары оештыруы, аңа битарафрак рухлы исем куюлары гаделрәк, дөресрәк алым. Икенчедән, бөтен җәмәгатьнең, төгәл бер мәхәлләнең иман йорты булган урынга аерым бер, кайбер очракта шөбһәле шәхеснең исеме бирелү, дөресен әйткәндә, мәкруһ (начар, кире кагыла торган) күренеш. Мисал китереп маташмыйк: "Мәрҗани мәчете", "Әҗем мәчете" ише исемнәр, соңрак, мәчетләр күбәйгән чакта стихияле рәвештә барлыкка килгән тарихи исемнәр. Ниһаять, өченчедән, гыйлем һәм уку йортларына, завод-фабрикаларга исем кую гадәте иң элек Алманиядә барлыкка килгән, аннары Русиядә, бигрәк тә СССРда киң таралган, күп очракта мәгънәсезлеккә китерә торган гадәт (бездәге һәр егерме-утыз ел саен исем алмаштыру "бизгәгенә" игътибар итегез).



*Закир Рәмиев*

Гомумән, хосусый милекчелек гадәти хәл булып исәпләнгән элекке чорларда да, чын хәйриячеләр, дәвамлы меценатлар саннары буенча әллә ни күп булмаган. Бу әйтелгәннәрнең дәреслеген татар чынбарлыгы тулысынча раслый. Мәсәлән, XVIII йөзнең икенче яртысыннан, ягъни татарларга үз диннәрен тоту, сәүдә итү, эшкуарлык белән шөгыльләнү өчен чикләнгән хокук бирелгән чордан алып, XX гасырның башына кадәр безнең халыкта меңләгән дип әйтерлек хәлле, милекле кешеләр яшәп узган. Ләкин алар арасыннан чыккан хәйриячеләр, дәресрәге шундый шәхесләрнең иң күренеклеләре бик аз иде (русларда да шундый ук хәл).

Тарихыбызда менә шундый бармак белән санарлык хәйрияче һәм тагын да азрак сандагы меценатларыбыз арасында беренче бишлеккә керүчеләр исәбеннән бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләрне атарга кирәк. Ләкин бу мөхтәрәм затларның хәйрия-химаяче буларак башкарган эшләрен, әдәп-әхлак җәһәтеннән бөеклекләрен чын-чынлап аңлар, объектив рәвештә бәяләр өчен тарихыбызның башка сәхифәләренә дә күз салып узу зарур.

* * *

МОХТАҖ КЕШЕЛӘРГӘ, ярлыларга, ятим-толларга һәм авыру-зәгыйфьләргә хәйриялек юлы белән рухи һәм матди ярдәм күрсәтү гамәле, фикер вә идея буларак, бик борынгы заманнарда ук барлыкка килгән. Кешелек җәмгыяте цивилизацияле тәрәккыят, үсү юлына баскач, бигрәк тә китаби диннәр оешып киң таралгач, хәйриялек идеясе дә билгеле бер әхлакый норма, дини тәгълимат күренешенә әверелгән. Кайсы гына диннең өйрәтүләренә мөрәҗәгать итсәк тә, ярдәмчелекнең, ягъни химая-хәйрия эшенең изгелек, иманлылык галәмәте, хәтта хәлле кешеләр тарафыннан эшләнүе зарури бурыч сыйфатында тәкъдим ителүен күрербез. Кайбер дини тәгълиматларда хәйриячелектән баш тарткан сараннарга, каруннарга төрле куркыныч җәзалар вәгъдә ителүе дә диннәрнең шул мәсьәләгә зур әһәмият бирүен күрсәтсә кирәк.

Гомум тәгълиматы, конкрет мәсьәләләр буенча өйрәтүләре бик җентекләп, төрле яклап, тәфсилләп эшкәртелгән Ислам дине дә хәйриячелекне шул диннең үтәлүе һичшиксез тиешле, зарур бер таләбе дәрәҗәсенә күтәргән. Моңа "з ә к я т" дигән бик борынгылыктан килә торган махсус исем беркетелгән. Милекле мөселманнар (бары мөселманнар гына) мондый бурычтан качмасын өчен зәкяткә в а җ и б, ягъни үтәлүе һичшиксез тиеш дигән, ф а р ы з д а н кала икенче урында тора торган дәрәҗәдә бирелгән. Бары зәкят дөрес һәм тиешле кешеләренә, ягъни ярлыларга, тол-ятимнәргә, мохтаҗ илгизәрләргә һәм гариб-горабаларга бирелгән очракта гына мөселманнар өчен милек һәм аннан килгән конкрет керем "пакьланган, аруланган", ягъни хәләл дип исәпләнгән.

Зәкятның кагыйдәләре барлык нечкәлекләре белән бик җентекләп эшкәртелүе, соңгырак чорларда кайбер мөселман илләрендә зәкятның дәүләт файдасына җыела торган мәҗбүри салымга әверелүе аның башта җәмгыять тормышында мөһим функция үтәү көченә ия булганлыгын күрсәтә (дәүләт файдасына алына торган башка төр салымнар—г о ш е р, х ә р ә җ һ. б. да булган, әлбәттә). Шулай ук татарларда зәкяткә карата "ф а р з ы с ә д а к а" төшенчәсенең кулланылуы, ягъни дәрәҗәсе күтәрелүе, әлеге фикерне тагын да куәтли төшә. Ниһаять, зәкят, аның "ф ы т ы р з ә к я т е" дип атала торган бер төре елның билгеле бер вакытында (рамазан гаете алдыннан) милек һәм керемнең мәгълүм бер күләме (мәсәлән, уннан яки егермедән бер өлеше) бүленеп бирелә торган хәйрия чарасын аңлата. Г а д ә т и с ә д а к а исә күләмен һәм вакытын күрсәтү мәҗбүри булмаган, ягъни теләсә кайчан һәм күпме күләмдә ихтыяри рәвештә бирелә торган хәйрия актын белдергән.

Хәйрия эшләренең дини тәгълиматка кертелеп, житди контроль астына алынуы аларның җәмгыять тормышындагы функциясен көчәйтә. Милекле гади кешеләр генә түгел, бәлки эш-дәүләт башында торган хакимият вәкилләре дә, ү з м и л е г е н н ә н зәкят һәм башка рәсми

салымнарны түләүдән тыш, хосусый хәйриячелек, ягъни үз милегендәге байлыктан мохтаҗлар һәм җәмгыять файдасына ихтыяри өлеш чыгару, бигрәк тә галим-голәмәгә, шагыйрь һәм әдипләргә, рәссам һәм музыкантларга меценатлык ярдәмен күрсәтү белән актив шөгыльләнгәннәр. Хәтта бу юнәлештә үзара ярыш та оештырганнар. Мондый күренешнең заманында шактый киң таралган булу фактларын төрле мөселман илләре тарихында күргән кебек, Болгар дәүләте, Җучи Олысы империясе һәм Казан ханлыгы чорларына караган язма истәлекләрдән, бигрәк тә әдәби әсәрләрдән мул табарга мөмкин. Мәсәлән, мәчет-мәдрәсәләр салыну, әдәби әсәрләр иҗат ителү, галим-голәмәләр тәрбияләү фактлары. Шулай ук дәүләткә бернинди салым түләми торган **вакыф** милегенең киң таралган күренеш булуы да характерлы. Вакыфларның бары хәйрия юлы белән шәхесләрдән җыелган милек нигезендә генә барлыкка килгәнлеген, яши алганлыгын онытмыйк. (Бездәге вакыфлар тарихы үз алдына мөстәкыйль тема.)

Әмма Казан ханлыгы яулап алынгач, мәчет-мәдрәсәләр җимерелеп, татар вакыфлары туздырылгач, социаль тормышта шәригать кануннары Русия дәүләте законнары белән алмашынгач, ниһаять, ике-өч гасыр дәвамында татарның милекле өлеше, ягъни аксөяк катламнары, җир биләүчеләре кырып-себереп дигәндәй юк ителгән иде. Мондый шартларда, вак-төяк сәдака бирүләрне исәпкә алмаганда, дәвамлы һәм күләмле хәйрия эшләре белән шөгыльләнү турында уйларга да урын һәм мөмкинлек калмаган иде. Бары XVIII гасырның икенче яртысыннан алып, дөресрәге "Әби патша" чорында, Русиядә элекке кыргыйлыктан китәргә омтылып, аурупача цивилизацияле идарә итү алымнары күренә башлагач, җөмләдән татарларга дин тотуда, икътисади тормышта да беркадәре ирек бирелгәч, хәйриячелекнең кайбер күренешләре барлыкка килә башлый. Әйтик, байлардан җыелган иганә исәбенә яңа мәчетләр салыну, алар янында ачыктан-ачык эшли торган мәдрәсәләр тәрбия ителү фактлары. Бу күренеш, әлбәттә, иң элек сәүдәгәрләр катламы оешып, халыкның бер өлешендә хосусый милек—капитал барлыкка килүнең, шуннан хәйриялек максатына өлеш чыгарылуның нәтиҗәсе иде.

Татар сәүдәгәрләрендә милли капиталның барлыкка килүе, үсүе иң элек руслар үтеп керә алмый торган Шәрекътәге мөселман регионнарына юл ачылу белән бәйле иде. Шәрекъ илләре белән сәүдә эшләрен җайга салу өчен татарлардан файдалану мөмкинлеге идеясен XVIII йөзнең урталарында патша хөкүмәте дә танырга мәҗбүр була. Оренбург янында махсус Сәгыйт бистәсе салыну, кайбер салым төрләреннән азат ителгән татар сәүдәгәрләренең казакъ сахраларына, "кяферлар" өчен ябык Урта Азия ханлыкларына, "серле" Шәркый Төркестан шәһәрләренә, ерак Иран, Әфганстан, хәтта Һиндстан җирләренә дә үтеп керә башлау фактлары, тәфсилләп өйрәнелмәгән булса да, фәндә яхшы ук мәгълүм.

Русиядә капиталистик мөнәсәбәтләрнең урнаша башлау процессында татарларда тукымачылык, тире эшкәртү (күнчелек), сабын кайнату, шәм кою, милли кием-салымнар тегү эше җиңел сәнәгать төрләренең яралгылары, кайбер очракларда куәтле генә учаклары барлыкка килгән иде. Бу процесс та милли капитал үсүдә, ныгуда мөһим роль уйнаган иде, әлбәттә.

Татарда милли капиталның чын-чынлап оешкан, ныгый барган чоры Русиядә крепостнойлык (ярым коллык!) системасының җимерелүенә туры килүе бездә электән үк аерым фикер рәвешендә яшәп килгән **мәгърифәтчелек идеясенең** иҗтимагый хәрәкәт дәрәҗәсенә күтәрелүен тәэмин иткән иде. Татар мәгърифәтчелегенең дәвамы, югары этабы булган **җәдитчелек** хәрәкәтенең киң колач җәюе, кайбер сыйфатлары белән милләтне оештыручы, хәтта аны "яңадан тудыручы" кодрәтле көчкә әверелүе дә, әгәр төптән уйлап карасак, шул милли капитал—татарның хосусый милеге **химаясендә** (ярдәмендә, канаты астында!) тормышка ашкан казаныш иде.

Әгәр егерме-утыз ел эчендә генә Русиядәге татарлар яшәгән төрле җирләрдә йөзләгән-йөзләгән яңа типтагы яки яңартылган мәктәп-мәдрәсәләр

барлыкка килүен җентекләп тикшерсәк, алар арасында "Мөхәммәдия", "Хөсәения", "Мәрҗания", "Госмания", "Галия", "Касыймия", "Әмирхания", "Рәсулия", "Мотыйгия" кебек шәһәр уку йортларын, шулай ук Иж-Буби, Кышкар, Каргалы, Эстәрлебаш, Бәрәскә шикелле бер-берсенә охшамаган дистәләгән-дистәләгән авыл мәктәп-мәдрәсәләренең тарихларын өйрәнә башласак, без күплөгән химаячеләр, хәйриячеләр белән очрашыр идек.

Әгәр "Тәрҗеман" гәзитенең ничек, кемнәрнең идеясе һәм матди ярдәмнәре белән чыгу, озак яшәү фактларын барлап, 1918 елга кадәр чыккан башка дистәләгән татарча гәзит-журналларыбыз язмышларында да актарынсак, тагын милли хәйриячеләребезнең исемнәрен телгә алыр идек.

Игътибар итик: боларның барысы дүрт йөз елга якын дәүләткә барлык салымнарны түләп килгән, солдатка газиз балаларын биргән (башта һәммә җир милекләре дә "казнага күчкән"), ләкин үзенең рухи, мәдәни ихтыяҗлары өчен шул дәүләттән бер тиен дә алмаган, ала алмаган татарларның үз омтылышлары, үз аң-белемнәре, үз тырышлыклары, үз матди көчләре белән барлыкка китерелгән казанышлары—милли хәзинәсе иде.

Нәкъ шушы урында укучыларның бер сорау куюы ихтимал: кемнәр соң ул йөзләгән мәктәп-мәдрәсәләрне тәрбияләп, әлеге чагыштырмача аз тиражлы, димәк, файда китерми торган гәзит-журналлар чыгаруга матди җирлек тудырган фидакарь затлар?

Дөресен әйткәндә, бу сорауга без бүген (бәлки хәзергә) барлык төгәллекләре белән, эшчәнлекнең төрле якларын чагылдырган хәлдә, тулы җавап бирә алмыйбыз. Нибары шул юнәлешләрдә актив һәм эзлекле рәвештә эшләгән бер уч фамилияне генә атый алырбыз. Образлы итеп әйткәндә, хәзергәчә үзебез анык белгән олы затларның фамилияләрен санап чыгар өчен дә бер кешедәге кул-аяк бармаклары артыгы белән җитәр иде. Мәсәлән: Алкиннар, Апанаевлар, Акчуриннар, Баязитовлар, Борнаевлар, Галиевләр, Дибирдиевләр, Кәримевләр, Насыйровлар, Нигъмәтуллиннар, Рәмиевләр, Сәйдәшевләр, Хөсәеновләр, Юнысовлар, Яушевлар...



*Шакир Рәмиев*

Тагын күпме исем өстәп булыр боларга? Ә инде һәр авыл саен диярлек үз чыгымнары белән мәчет-мәдрәсәләр салдырган, дәвамлы рәвештә аларны тәрбияләгән яки мәхәллә инициативасы белән җәмәгатьчелектән хәл кадәри һәм чамалы гына акча җыелган шундый эшләргә үзләреннән зур өлеш керткән "урта кул" хәйриячеләребезнең исемнәрен" йөздән унын гына булса да, санап чыга алабызмы, Юк, әлбәттә. Бигрәк тә аерым-аерым рәвештә фикер йөртеп, бер-ике кешенең "хәтер янчыгында" гына казынган чакта...

Элекке чор химая-хәйриячеләребез хакында бүген шулай аз белүебезнең объектив сәбәпләр дә бар, билгеле. Шулардан берсе, югарыда күрсәтелгәнчә, совет чорында хәйриялек идеясен тулаем кире кагудан, хәйриячеләрнең үзләрен исә мәкерлелектә гаепләүдән гыйбарәт иде. Әйтик, татар әдәбияты белемендә китап чыгаручы наширләрне, мөхәррирләрне урыны килгән-килмәгән саен эксплуататор сыйфатында тамгалау гадәткә кергән иде. Хәтта зур хезмәт хакы, шигырьләре өчен тәшкә керми торган гонорар вәгъдә итеп, Габдулла Тукайны Оренбургка эшкә чакырганы өчен Рәмиевләрнең гайбәте дә шактый чәйнәлде. 1920—1930 еллардагы иҗтимагый агым, тупас социологизм шаукымына бирелгән Мәҗит Гафуриның "Шагыйрьнең алтын приискасында" исемле, нигездә саерак фикерле язмасы мәктәп дәреслекләрендә урын алып килде. Шул рәвешчә "миллионер шагыйрь"

Дәрдмәнднең—Закир Рәмиевнең—зур эксплуататорлардан булуы хакындагы фикер яшьтән үк башка сеңдерелде.

* * *

ЭКСПЛУАТАЦИЯ мәсьәләсе кузгатылган икән, ул чакта бу күренешне тулаем кире кагу идеясен гел алга сөргән, СССРда аны "бөтенләй бетердек", дип игълан кылган совет чынбарлыгына да мөрәҗәгать итеп карыйк. Ләкин мин бу урында халыкның хосусый милеге тартып алынуы яки туздырылуы, игенче халыкның бушлайга диярлек эшләве, завод-фабрика эшчеләренең ачка үлмәслек хәлдә генә хезмәт хакы алулары, ачтан үлүчеләрнең сөякләре өстендә Беломор каналны, ГЭСлар, Магнитогорск, Чиләбе комбинатлары ише башка йөзләгән-меңләгән "гигантлар" төзелүе хакында махсус сөйләп тормыйм. Шулай ук "башкача социализм төзеп булмый иде" дип, ул социаль изүләрне, чын эксплуатацияне, ягъни яңартылган крепостнойлык шартлары белән килешкән, матур вәгъдәләр хакына аларны акларга теләүче кол психологияле люмпеннарга да җавап биреп торуны кирәк тапмыйм... Мин бары конкрет кешеләрнең, бигрәк тә иҗат ияләренең конкрет хезмәтләре өчен нинди бәя, "өҗер" бирелүне күрсәтә торган бер-ике хосусый мисалны китерү белән чикләнәм. Тик рубльдә бирелә торган гонорарның да күләменә, реаль кыйммәтенә кагылмыйча, чөнки "күпме бирә", кем әйтмешли, бу "хуҗаның үз ихтыяры". Мин бары совет кешеләренә чит илләрдә сирәк эләккәләгән премия һәм гонорарлар тарихыннан гына фактлар китерәм.

Беренче мисал. XX гасырның 60 еллары ахырында, Иран дәүләтенең ике мең еллык юбилеен уздырган чакта, совет галимнәреннән Эрмитаж музееның ул чактагы директоры, атаклы археолог Б. Б. Пиотровскийга (хәзерге директорның әтисенә) һәм Ташкенттан иранчы галим Шаһислам Шаһмурадовка Шәрекъ илләренең тарихлары, мәдәниятләрен өйрәнүгә керткән зур өлешләре өчен Фирдәүси исемендәге премияләр бирелә. Һәр бүләкнең күләме 150 мең туман тәшкил итә. Бик зур сумма! Ике галим кичен кунакханәдә бу кадәре акчаны илгә ничек алып кайтырга, ничек тотып бетерергә, дип баш ваталар. Шаһислам агай "Волга" машинасын сатып алу ниятенең тормышка ашуы хакында хыяллана. Тик акчаның артып калганын кая куеп бетерергә, дип борчыла ул. Әмма юкка гына була бу җәфаланулар. Мәсьәлә гаять җиңел хәл ителә: иртәгесен аларны совет илчелегенә чакырып алалар да, премия акчаларын СССРдагы фәлән-фәлән шәһәрләрдә салыначак музыка мәктәпләре өчен бүләк итәбез, дип гариза язарга кушалар. Үзләре ихтыяри язмасалар, партбилетларын чыгарып салырга кирәк буласын да белдерәләр. Дөрес, үз илләренә кайтып житәр өчен бераз сумма б ү л е п б и р ә л ә р. Ачуы чыккан лауреат, Ташкентка кайткач, бурычка алып булса да, бер иске "Москвич" сатып ала алуын... (Бу вакыйга хакында Шаһислам әкәдән хикәятне үзе ишеткән Җ. Зәйнуллин сөйләде; аның үзенең дә Гыйракта шундыйрак хәлгә эләккәне булган икән.)

Икенче мисал. Татар әдибе Җәвад Тәрҗемановның "Шуктуган" исемле кечкенә генә китабы, белгәнебезчә, бик күп телләргә тәрҗемә ителгән. Бельгиядә чыккан басмасы өчен автор исеменә ике мең доллар чамасы кыйммәткә ия әллә ничә мең франк гонорар килеп төшә. Мәскәүгә, әлбәттә. Гонорарны алыр өчен чакырталар үзен. Ичмасам, пенсиягә генә тилмермичә яшәп, иркенләп бер иҗат итәрмен дип хыялланган Җәвад аганың кулына Мәскәүдә, барлык "законлы исәп-хисапны" күрсәткәч, 186 рубль тоттыралар. (Бу хакта автор миңа үзе сөйләгән иде. Әсәрләре чит илләрдә еш басыла торган кайбер мәскәүле язучыларның гонорар исе чыгуга үзләре шунда барып, акчаларының бер өлешенә булса да, киенеп кайтулары гадәткә керүе очраклы булмаган, димәк.)

Сәламәтлекләрен җимерү исәбенә халыкара ярышларда беренчелекне, икенчелекне яулаган совет спортчыларының гонорарларыннан җиңү казанучыларның үз кулларына күпме тию фактларын саный башласаң, сүз артык сузылып, әңгәмәбез дә төп темадан читкәрәк китәр иде. Ләкин

китерелгән хәтле һәм житди, һәм көлкеле мисаллардан да шул нәрсә яхшы күренә: совет чорындагы безнең элекке эксплуататорларны гаепләвебез угрының күз буяу, башкаларны ялгыштыру өчен акырып каравыл кычкыруына охшаган икән, ләбаса!

Эксплуатация мәсьәләсенә житдирәк мөнәсәбәт белән карасак, матди житештерү, эшкәртү һәм эшләп чыгару мөнәсәбәтләре хөкем сөргән, кешелек җәмгыятен хайванат дөньясыннан аерып тора торган шартларда аның котылгысыз, хәтта зарури күренеш икәнлеге бәхәссез. Ул булган, бар һәм булачак. Чөнки хезмәт нәтиҗәсенең бер өлеше икенче кешеләр тарафыннан үзләштерелүе, ягъни эксплуатация дигән нәрсә ахыр чиктә эш мәйданын булдыручының, анда мөмкинлек һәм тәртипләр урнаштыручыларның шул оештыру, оештыра белү, оештыра алу хезмәтләре өчен эш хакы алуыннан гыйбарәт бит. Киресенчә булса, оештыру дәрәҗәсе, хезмәт буларак тиешлечә югары бәяләнмәсә, завод-фабрика, колхоз-совхоз җитәкчеләре, төрле мөдир-директорлар гади эшче, гади хезмәтче белән гадәти колхозчыдан түбәнрәк эш хакы алган булырлар иде. Ә менә милек иясенең оештыру сәләте, тырышлыгы, белеме хезмәт түгелме соң? Әллә хосусый милек иясе аз эшләгән кешегә күп хак биреп, җыелган милекне туздырырга тиешме, һәм шундый "тәртип" урнашканда гомумән милек җыелып, халык, ил-дәүләт байлыгы барлыкка килеп, аннан башкалар өчен өлеш чыгар идеме. Әгәр Рәмиевләрнең еллар дәвамында тырышып оештырылган алтын приискалары, анда куплләгән эшчеләр эшләве булмаганда, ун-унөч ел дәвамында өзлексез чыгып торган, узгандагы мәдәни тарихыбызның йөзек кашларын тәшкил иткән "Вакыт" газете, "Шура" журналы барлыкка килерме иде? Ниһаять, шул газит-журналдан ахыр чиктә татар халкы, аның, хезмәт ияләре зарар күрдеме, әллә файда алдымы?! Мондый сорауларга ниндирәк җавап бирелү ул конкрет шәхеснең иҗтимагый аңына, эчке культурасы белән интеллектуаль ихтыяҗларына бәйле булса кирәк...

Дөрес, кешеләр арасындагы икътисади мөнәсәбәтләрдә эксплуатациянең кыргый, оятсыз төрләренә чик куя торган чараларга да ихтыяҗ булды, бар һәм булачак. Әмма аны хәл итәр өчен башкаларны талауның, экспроприацияләр оештыруның, ягъни мәсьәләнә бер кизәнүдә "хәл кылуның" яраксыз, ялгыш гамәл булганлыгы тулысынча расланды инде. Дөньядагы иң бай илләрнең беренчесе булган СССРдагы халыкның гомум ярлылыкта яшәве ("хәерчелектә тигез" булганы өчен үзен "бай" дип исәпләргә, алданырга күнегүе...), ниһаять, "явызлык империясе" булган, иң кодрәтле илләрдән саналган милитаристик дәүләтнең бер Әфган сугышы нәтиҗәсендә тезләнүе, шартлап җимерелүе, хәтта бөтен социалистик лагерьның таркалуы моны артыгы белән раслады.




*«Вакыт» газитәсенең титул бите*

Димәк, яңадан утопиягә бирелмәсәк, хезмәт өчен гадел рәвештә түләү мәсьәләсе, бүген дә актуаль булганы кебек, киләчәктә дә үз көчендә калачак. Минемчә, гаделлек мәсьәләсе бары чама хисе һәм законлылык таләпләре белән билгеләнеп, аның урнашу юлы чагыштырмача дәрәҗәдә генә хәл кылыначак. Шулай икән, киләчәктә дә (әгәр ул киләчәк гомумән реаль нәрсә булса) халык, милләт тормышының, рухи һәм мәдәни ихтыяҗның күп мәсьәләләре милек ияләренең аңнарына, конкрет гамәлләренә бәйле булачак. Чөнки нормаль хәлдә яшәп, нормаль рәвештә тәрәккый итә торган социаль-иҗтимагый шартларда халык, милләт үз ихтыяҗлары өчен үзе эшләргә, үзенең киләчәген үзе кайгыртырга тиеш. Ә "үзе" булып

беренче планга, кырыс тарих кат-кат күрсәтә килгәнчә, милек ияләре, ягъни мөмкинлекләре булган кешеләр чыга икән. XIX йөзнең икенче яртысы белән XX гасырның башында, ягъни "үз буржуйларыбыз" аякларында нык басып торган чорда, халкыбыз ирешкән рухи-мәдәни казанышлар моны артыгы белән раслады. Бөек фикер иясе, атаклы галимебез Ризаэддин Фәхретдин хәзрәтләре кат-кат әйткәнчә, халык милләт буларак нормаль яшәсен, нормаль тәрәккый итсен өчен, ул бай булырга тиеш.

Милләт байлыгын исә җыеп алып, бер җиргә өеп куйган, шуннан булдыра алган теләсә кем "чөлдереп"", ягъни урлап-ташып әрәм-шәрәм итә торган конкрет хуҗасыз "уртак мал" түгел, бәлки аерым шәхесләр, традициягә ия нәселләр кулында бөртекләп җыелудан тупланган, яхшы саклануы, үстерелүе тәэмин ителә торган хосусый милек—хосусый капитал тәшкил итә. Мондый байлыкның ничек җыелуын һәм ничек әрәм-шәрәм ителү ихтималын үзенең бер шигъри парчасында Дәрдмәнд дә образлы итеп тасвирлаган:

Әгәр илгә таратсаң бер хәзинә,
Бер акчадан төшәр һәр өй беренә.
Бер акчадан әгәр алсаң алардан,
Булыр һәр көн дә хасил бер хәзинә.

Димәк, эш оештыра белүләре белән "һәр өйдән" (эшләгән кешедән) берәр тәңкәдән файда алып капитал туплаган Рәмиевләр "тамыры" белән халыкныкы булган шул капиталны, миллионнар килеш халыкның үзенә кайтарган булып чыга. Шулай булгач, Рәмиевләр башкарган хәйриячелек иҗтимагый аңлылык нәтиҗәсе булган икән.

Шул ук вакытта, киләчәк өметләр бары милек иясләрендә, аларның хәйриялек эшендә дигәч тә, башкаларга ярдәм итүнең кирәкле гамәл икәнлеген аңлаган белемле, юмарт бер байга утыз-кырык аңсыз, ачкүз саран бәндәләрнең туры килүен дә онытмаска кирәк. Халык, милләт мәнфәгатен тирән аңлаган, үз кавеменең гомум тәрәккыяте өчен гомер буе хезмәт иткән олы хәйриячеләр, чын меценатлар тагын да азрак очрый. Шулай булгач, бертуган Рәмиевләр—үз замандашлары булган Хөсәеневләр, Нигъмәтуллиннар, Акчуриннар кебек үк—сирәкләрнең сирәкләреннән булган икән.

Әмма ләкин Рәмиевләрнең хәйриялек өлкәсендәге эшчәнлеге кинәт туган вә кыска вакыт кына гамәлдә булган гадәти юмартлык галәмәте дә булмаган. Дәрдмәнднең бертуган агасы Шакирның 1881 елда Истанбулда укып яткан энесе Закирга язган бер хатыннан күренгәнчә, ул яшьтән үк халык өчен кирәкле китаплар чыгару, басмаханә, ягъни нәшрият булдыру идеясе белән яшәгән, үз ана телендә газит-журнал чыгару хакында да хыял иткән. Башка чыганаклардан беленгәнчә, аның Гыйльман ахун Кәримигә нәшрият оештыруга, Исмәгыйль Гаспралыга "Тәрҗеман" газитен чыгаруга матди ярдәм күрсәтүе мәгълүм. Шулай ук аның үз акчасыннан татар мәдрәсәләрендә, рус мәктәпләрендә укучы яшьләргә даими стипендияләр биреп торуы, берничә шәһәрдәге хәйрия җәмгыятьләрендә гамәли яки шәрәфле әгъза булып, аларга да дәвамлы рәвештә матди ярдәм күрсәтүе дә билгеле.

Димәк, кайчандыр олы бабалары нәселле морзалардан булган, соңрак буыннарда сәүдәгәргә әверелгән Габделкәрим Рәминең уллары бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләрнең "Вакыт", "Шура"ларны өзлексез чыгарып ятулары аларның гомум хәйриялек эшчәнлегенең бер конкрет өлеше генә булган икән. Без моңарчы, Дәрдмәнднең әдәби мирасы хакында бераз белгәнебез хәлдә, аның туганы Шакирның әхлакый йөзен, кешелек сыйфатын, кыскасы, сирәк очрый торган асыл кеше булуын, кызганычка каршы, җүнләп аңлый, бәяли алмадык, күрсәтә дә белмәдек. Бу җәһәттән без заманында Риза казый Фәхреддин ирешкән әхлакый биеклектән күпкә түбән тәгәрәп төштек...

* * *

ЧЫН ХӘЙРИЯЧЕ олы затларның аз булуыннан гаҗәпләнмик. Монда үзенә күрә бер закончалык хөкем сөрә. Әнә бит "халык властенең" гәүдәләнешенә, гомумән гаделлекнең "соңгы инстанциясенә" дәгъва иткән совет чорында да ачык бюджеттан халыкның мәдәни ихтыяҗына бүленеп бирелә торган өлеш өч-дүрт процентган артмый иде. Әмма дәүләт бюджетының җәмгатьчелеккә игълан ителмичә (хәрби һәм сәяси ихтыяҗлар өчен аерым тотылган) яшерен тармакларын да кушып исәпләсәң, әлеге өч-дүрт процентның гомум чыгымга нисбәтән тагын да азрак булганлыгы беленә. Шул ук вакытта совет власте чорында рухи-дини ихтыяҗлар өчен бер тиен дә бирелмәвен, мәгәр гыйбадәт йортларыннан салым алынуын да яхшы беләбез...

Һәрхәлдә, минем кара исәбем (бәлки капшанып кына ясаган фаразым) буенча, реаль хәйрия эше белән шөгыльләнүчеләр хәлле милек ияләре катламының, ягъни бай кешеләрнең дүрт-биш процентын гына тәшкил иткәнгә охшый. Ләкин шул дүрт-биш "бөртекнең" фидакарьлеге аркасында XX йөз башында татар мәдәниятенең нинди казанышларга ирешүен, шул казанышның соңгы чор язмышыбызга да нинди тәэсир ясавын күрүе артык кыен булмаса кирәк. Әлбәттә, болай раслаганда, мин күңел күзләре ачык, реаль белемле кешеләрне күз уңында тотып фикер йөртәм...

Җыеп әйткәндә, аңлылык һәм эчке культура байлыгына химая-хәйриячеләрнең барлыкка килүе ул очраклылык галәмәте яки примитив юмартлык күренеше генә түгел. Бәлки ул хәйриячелек эше милек җәһәтеннән мөмкинлекләре булган шәхесләрнең, олы затларның, үзләрен конкрет бер халыкның, милләтнең аерылгысыз өлеше икәнлеген аңлаган хәлдә, шул бөтеннең дә, өлешнең дә хаҗәтләрен бергә үз өстенә алып, үз җилкәсендә күтәрүеннән гыйбарәт. Дәрдмәнднең: "Аһ, туган каумем газиз!"—дип гомумиләштереп ялкынлы күрсенүе очраклылык түгел иде. Димәк, чын хәйрия эше формасы буенча аерым кешеләрнең игелек гамәле булса, эчтәлеге, функциясе ягыннан ул халыкның милләт-кавемнең тәрәккыять юлындагы үзенчәлеге икән. Ә мондый үзенчәлек җәмгыятьтә гражданлык мөнәсәбәтләренең яки аның элементлары барлыкка килүнең күрсәткече иде. XIX йөзнең икенче яртысы белән XX гасыр башында, ягъни җәдитчелек чорында безнең тормышта чыннан да гражданлык җәмгыятенең кайбер сыйфатлары гамәлгә керә башлаган иде. Шунысы да мәгълүм булсын: гражданлык мөнәсәбәтләре бары кешеләрдә—милеклелеккә, халыкта исә милли байлыкка хокук булганда гына мөмкин. Белгәнебезчә, 1917 елдан соң мондый шартлар Русиядә тамырдан юк ителде. 20 елларның икенче яртысыннан соң исә үзе хакында кайгырта, тырыша ала торган милләт урынына ата баладан курыккан, бала атасыннан йөз чөергән, шәхси һәм хосусый милек түгел, хәтта шәхси фикергә дә хокукы булмаган—күпчелеккә буйсынган—яшәүчеләр, җан асраучылар барлыкка килгән иде.

Күренекле хәйриячеләрнең төрле ярдәм, хәйрия җәмгыятьләре, ятимнәр һәм картлар йорты, хастаханәләр, китапханәләр оештыруга якыннан катнашулары мәгълүм. (Бездә бу мөһим күренешнең тарихы һич тә өйрәнелмәгән, гәрчә ул бик актуаль, зарур мәсьәлә.) Ниһаять, милли-азатлык хәрәкәтенә, иҗтимагый оешмалар, сәяси партияләр оештыруга хәйриячелек эшләре белән мәгълүм затларның актив катнашулары да әлеге милли үзешчәнлек хакындагы фикерне артыгы белән куәтли. Бәс, шулай булгач, хәйриялекне гомумән һәм тулаем кире кагу—ул халык—кавем тарафыннан күрсәтелә торган инициативаны, аның үз ихтыяҗларын үзе канәгатьләндерү юлындагы үзешчәнлеген, ниһаять, бер кавемнең шундый гамәл вә хокукка, ягъни гражданлык хокукына ия икәнлеген инкяр итү булып чыга...

Милли-мәдәни мәнфәгатьләрне кайгырту юлында халыкның үзешчәнлеген булдыру өчен хосусый милекнең әһәмиятен күрсәтә торган тагын бер гыйбрәтле мисалга мөрәҗәгать итик. Шәркый Төркестанда, дөресрәге андагы Голҗа һәм башка шәһәрләрдә яшәгән татарлар тормышына

багышланган "Ябылмаган китап" исемле әсәремдә мин андагы хосусый милеккә ия татарларның чит ил, ят җирләрдә дә үз көчләре белән озак еллар буе алдынгы рухтагы мәктәп-мәдрәсәләр ачып, үзешчән сәнгать түгәрәкләре, мәчет-зиратлар тәрбияли алуларын беркадәре тасвирлаган идем. Балалар, яшьләр үз ана телләрендә укып, белемле һәм нормаль рухлы кешеләр булып үсәләр иде...

XX гасырның урталарына, Кытайда коммунистлар хакимияте урнашканга кадәр. Аннары, мәгълүм булганча, хосусый милекне бетерү «культура революциясе» хөкем сөрде...

2000 елның көзендә, ягъни кырык биш елдан соң, миңа Өремче һәм Голҗа шәһәрләренә барып кайту, татар кешеләре белән аралашу насыйп булды. Урамда һәм эштә генә түгел, хәтта гаиләдә дә үзара ата-бабалары телендә нормаль сөйләшә торган яшьләрне күрергә туры килмәде диярлек. Берәүләре уйгырча гәпләшә, икенчеләре казакъча сөйләшә, өченчеләре исә үз яшьләрендәге милләттәшләре белән дә кытайча аңлашуны өстенрәк күрә. Милли мәктәп турында хыял итү дә мөмкин түгел. Биш меңнән артык кешедән торган зур гына кавемгә. Ә элек илле-алтмыш баланың башы кушыла алган җирдә дә кавемнең үз мәктәбе барлыкка килә иде...

Бары олы яшьләрдәге кешеләр генә, утның карая башлаган күз-күмерләренә өрә-өрә дигәндәй, сүнеп бара торган учакның очкын-өметен сакларга телиләр сыман...

Шулай, хосусый милек бетү белән кешеләрдә үзләренең рухи-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек мөмкинлекләр дә юкка чыга, кеше буларак мөстәкыйльлеген саклардык ихтыяр көче дә калмый икән.




«Шура» журналының титул бите

Узган чор социаль-иҗтимагый хәятыбызда мөһим роль уйнаганлыгы бәхәссез булган халык—милләтнең үзешчәнлеге, аның җәмгыять тормышындагы активлык тарихын моңарчы без, кызганычка каршы, җүнләп өйрәнмәдек, яхшылап белмәдек, белә алмадык. Бәлки "сыйнфыйлык" дигән булып, социаль табигый катламнарның берсен генә мактау, икенчеләрен таптау, иң киме хурлау белән шөгыльләндек. Сыйнфыйлык дигән фәнни, танып-белү өчен кирәкле принципның асылда җәмгыятьтәге һәр катламның табигатен, функциясен махсус өйрәнү, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне, табигый каршылыкларны күрә белү, аңлау өчен кирәкле гыйльми алым икәнлеген онытып бетерә яздык—бер яккарак, дөресрәге шөбһәле тарафкарак чалулап киттек. Нәтиҗәдә вульгар социологизм сазлыгына баттык. һәм хәзер бу гамәлнең кайтарып суккан җәзасын алып ятабыз.

Җәмгыять нормаль яшәсен өчен элек көч белән юк ителгән сыйныфларны кайтарабыз дип, ашык-пошык кылану нәтиҗәсендә дәүләт һәм кеше малын талауга, шул юлда кан коюга сәләтле бандитлар өерен барлыкка китердек, аларны бөтен ил буйлап диярлек таратып җибәрдек. Үзебездә исә өметсезләнгән, пассивлашкан күпчелек белән бергә сөт-икмәк алырга да акчалары җитмәгән, бушаган шешә җыярга мәҗбүр ителгән миллионлаган картлар, урамга сөрелгән ятимнәр, сәрхушлыкка сабышкан гарип-горабалар утырып калды. "Юрганны" башка тартсаң, аяк ачыла, ертыкны җөйләсәң, тишек ырҗая дигәндәй...

Шулай да, кыенлыкларның күләмен һәм табигатен аңлаган хәлдә, мондый ямьсез, авыр күренешләрнең вакытлы икәнлегеннән өмет итәргә кала. Ике-өч буын алмашынгач, ягъни аталарының ертлачлык, жуликлык юлы белән баюларын белмәгән, ләкин аларга караганда белемлерәк тәрбиялерәк, инсафлырак булган яңа буыннар үсеп чыккач, ихтимал,

вәзгыять беркадәре үзгәрер, дип уйларга урын бар. Чөнки матди мөмкинлекләрнең аң-белем үсүгә, мәдәният тәрәккыять итүгә җирлек тудыруга сәләтле икәнлеге мәгълүм факт.

Белемлелек, тәрбиялелек төшенчәләре хакында сүз чыккач, андый сыйфатларга ирешү өчен нинди чаралар кирәклеге хакында да уйлану зарур. Күп төрле чаралар арасында, минемчә, тарихны объектив яктырту, җәмгатьчелекне узган тормышыбызның гыйбрәтле фактлары—һәм казанышлары, һәм югалтулары белән якыннанрак таныштыру да үз урынын алырга тиеш. Узгандагы хәйриячеләребезнең эшчәнлекләрен барлау, аларга объектив бәһа бирү киләчәк бурычларыбызның берсе булырга тиеш. Чөнки без алар алдында һәрвакыт бурычлы.

* * *

Сүзне шагыйрь Дәрдмәнднең мирасы белән яңадан танышу фактыннан башлап, бертуган Рәмиевләрнең хәйриячелек юнәлешендәге конкрет эшчәнлекләренә тукталудан бигрәк, гомум мәсьәләне төрле яктан ачыклый-ачыклый фикер йөртүем, узган тормыш сәхифәләрен мул актаруым шундый тарих белән танышуның бер юлы, чарасы дип исәплим. Һәрхәлдә, хосусый милеккә, элекке чорларыбызга хас булганча, хәйриялек эшенә күз йомудан тормыш чынбарлыгына кырын карау гадәтеннән арына башларга вакыт инде безгә.

Бу мәсьәләгә, сүзне кабатлап дигәндәй, махсус игътибар итүнең үз сәбәбе бар. Соңгы елларда ашык-пошык башкарылган вульгар реформалар һәм дәүләт милеген талаудан барлыкка килгән капиталны чит илләргә чыгару нәтиҗәсендә, әле генә әйтелгәнчә, халыкның зур өлеше икътисади җәһәттән авыр хәлдә калды. Мондый аптырашка дучар булучыларның зур өлеше, бигрәк тә олы яшьтәге кешеләр, узганындагы чагыштырмача тотрыклырак тормыш шартларын сагыналар. Аларны аңлап була: бөтен гомере совет чорында узган, башкача яшәү шартларын күрмәгән, белмәгән картлар асылда узганның бетмәс-төкәнмәс чиратларын, хәерчелектәге "тигезлекләрен" сагынмыйлар (үткәннең начарлыклары тиз онытылучан була, гадәттә). Алар, бәлки, үзләренең сәламәт яшьлек һәм киләчәктән өметле чакларын, шулай ук нәрсәгәдер ышанып яшәгән, ышанып эшләгән, ягъни иманлы булган елларын да сагыналар. Димәк, аларның сугышчан рәвештә кирегә—совет чорына кайтырга чакырулары, реальлеге чамалы булса да, табигый һәм аңлаешлы күренеш икән.

Әмма соңгы вакытларда Сталин сурәтләрен күтәргән шундый сугышчан картлар арасында яшьләрнең дә арта баруы очраклы булмаса кирәк. Шәхесе булмаса да, шәхес культына таба елышу фактлары, Чечнядагы хәлләргә карата, 30 еллардагы репрессияләрне аклаган кебек, агрессив теләктәшлек барлыкка килүе дә шомландыра. Мондый процессның, әгәр Русиядә реформаларны гел контрреформалар белән алыштырылу гадәтен исәпкә алсаң, шактый реакцион нәтиҗәләргә китерүе ихтимал. Нәкъ шушы урында укучының: "Социализм идеясеннән баш тарту, капитализмга кире кайту үзе үк реакцион күренеш түгелме соң?!"—дип соравы табигый.

Әйе, XX гасырның беренче яртысында башкарылган талаулар өстенә тагын яңа (икенче төр) талаулар барлыкка килде, халыкның зур күпчелеге әйтеп бетергесез авыр хәлгә тарыды. Болар Ельцин—Гайдар—Чубайсларның икътисади "реформаларының" формасы буенча реакцион булуын раслый. Ләкин эчтәлеге һәм максаты буенча түгел. Чөнки социализм төзү эксперименты СССР җәмгыятен алды ябык тыкрыкка—тупикка китереп терәгәнлектән, артка чигенү, киләчәгә ачык "урамга" чыгарга юл эзләү котылгысыз һәм прогрессив омтылыш иде. Әгәр кайберәүләр өмет иткәнчә, яңадан социалистик юнәлешкә борылсак, минемчә, күнегелә язган кыенлыклардан котелмәгән катастрофаларга барып керәчәкбез.

Чөнки тарихи процесс дигән хикмәт иске юлны кабатлаганны белми, һичвакытта да андый чигенүләрне кабул итми.

...һәрхәлдә, яхшыдан өмет итик. Киләчәктә хосусый милеккә, гомумән милекчелеккә карата реалистик мөнәсәбәтләр урнашкан нормаль җәмгыять,

гражданлык җәмгыяте оешуны да беркадәре өмет итәргә мөмкинлек бирә торган дәлилләр бар кебек. Болай уйларга хәйриячелекнең безнең шартлар өчен хәзергә иң мөмкин, иң дөрес булган яңа формалары барлыкка килүе нигез бирә. Мәсәлән, берәр икътисади көчле хуҗалык, оешма һәм предприятие каршында шуларның керемнәреннән рәсми рәвештә бүлеп бирелә торган акча исәбенә эшли торган махсус фондлар—үзенә күрә цивилизацияле яңа заман вакыфлары оешып эшли башлау фактлары. Нәселдән килә торган байлыкка ия кешеләребез әлегә бөтенләй юк булган, яңа байлар исә интеллектуаль җәһәттән "өлгереп җитмәгән" хәзерге каршылыклы чорыбыз өчен мондый махсус үзәкләрнең эшчәнлеге, әһәмияте аерата кыйммәткә ия. Татнефть каршында оештырылган хәзергәчә берничә юнәлештә ярыйсы гына актив эшләп килә торган "Рухият" фондының шундый яңа һәм өметле үзәкләрнең берсе булуы миндә шик тудырмый. Мондый күптармаклы фондлар ишлерәк булып, дәвамлырак эшләсәләр, алар үрнәгендә хосусый хәйрия эшенең икенче буыннар килгәндә яңадан җанланып китүе, мәдәни-рухи тормышыбызда "яңа сулыш" ачылып, өметле киләчәк барлыкка килүе ихтималдан ерак түгел.

Икенчерәк итеп әйткәндә, һәр халык, һәр милли кавем үз ихтыяҗын үзе хәл кылырга, үз киләчәген гомум үзешчәнлек юлы белән үзе тәэмин итәргә тиеш.

Халыкның мәдәни-рухи тормышында шундый үзешчәнлек башлангычы бар һәм көчле булганда гына культура гомуммилли, димәк, чын мәгънәсендә халыкчанлык дәрәҗәсенә күтәрелә ала.

Бары шулай актив эшләгән халыкның гына киләчәге өметле.

* * *

Бертуган Закир һәм Шакир Рәмиевләргә—шагыйрь Дәрдмәнд белән агасы Шакирның хәйриячелек эшчәнлекләренә багышланган мәкаләдә еш-еш конкрет темадан читкәрәк китеп, гомумирәк мәсьәләләргә тукталу бер дә гаҗәп түгел. Болай эшләүнең үз сәбәбе бар.

Беренчедән, безнең элекке тормышыбызда (һәм гомумән һәр аерым этнос-халык, һәр милләт хәятында) хәйриячелек кебек халык-кавемнең үзешчәнлеге, тоткан урынын, аның әһәмиятен, нормаль тәрәккыять өчен зарурлыгын искә төшерү теләге. Октябрь инкыйлабына кадәр хәйриялек юлында зур активлык күрсәткән Рәмиевләр эшчәнлеге, аның эчтәлеге, интеллектуаль дәрәҗәсе, тарихи әһәмияте шундый теләккә иң әйбәт, иң ышанычлы мисал, үрнәк булып хезмәт итә.

Икенчедән, хәйриячелек хакында авыз ачып, бары Рәмиевләрнең генә эшчәнлекләре хакында кыскача сөйләү яки мәгълүм материалларның эчтәлекләрен кабатлау белән чикләнсәм, ягъни әлеге күренешнең асылына кереп, фәлсәфәсенә киңрәк тукталмасам, Рәмиевләр башкарган олы эшләрнең дә чын кыйммәте—иҗтимагый әһәмияте тулырак ачылмас, калкурак күренмәс иде. Бәлки аерым очраклы "яхшы кешеләрнең" игелекле эшләре кебек кенә тәэсир ясар иде. Шул ук вакытта Рәмиевләрнең иганәчелек, меценатлык гамәлләренең тарихы да хәзергә җентекләп өйрәнелүгә мохтаҗ.

Өченчедән, безнең алда торган иң зур бурыч — ул элекке мәдәни-рухи тормышыбыз тәрәккыятенә зур өлеш керткән хәйриячелек хәрәкәтен тулаем өйрәнү, башка күренекле шәхесләребезнең дә тормыш юлларын, игелекле гамәлләрен тулырак, төгәлрәк яктырту. Әйтик, шундый ук махсус хатирәгә, алфавит буенча санап чыксак, Акчуриннардан, Апанаевлардан алып, Хөсәеневләр белән Юнусовларга кадәрге атаклы фамилияләрнең, аларның күренекле вәкилләренең — барысының да бәхәссез хаклары бар...

Киләчәктә нормаль яшәү һәм алга таба үсүне теләсәк, яңадан-яңа хәйриячеләребез, чын меценатларыбыз җитлегеп торуын өмет итсәк, узган тарихыбызда халык, милләт мәнфәгатен иңнәренә күтәргән ил агалары алдында булган изге бурычларны онытмаска тиешбез.

## Солтан Шәмси

# НИЗАГЛЫ ЙОРТТА

АЛТЫН УРДА ДӘҮЛӘТЕНЕҢ
ТАРКАЛУ ЧОРЫННАН СӘХИФӘЛӘР

## КОНДЫРЧА СУГЫШЫ (1391 ЕЛ)

### «Төзеки-Тимер»

Тимер бәк (Аксак Тимер) заманы—сакланып калган тарихи чыганакларның муллыгы белән аерылып тора. Җиһангирның галим-голяманы якын күрүе, акыл ияләре, зыялы затлар белән аралашырга, әңгәмә корырга яратуы мәгълүм нәрсә. Сәркятибләре аның һәр сүзен, һәр боерыгын, теге яки бу мәсьәләгә карата әйтелгән һәр фикерен аерым дәфтәрләргә теркәп бара торган булганнар. Моннан тыш Тимер бәк үз хозурында махсус тарихчылар да тоткан. Бер сүз белән әйткәндә, Сәмәрканд әмире, кылган гамәлләре тарихка кереп калсын өчен, системалы эш алып барган, моны аңлы рәвештә эшләгән.

Ул заманның безгә килеп житкән иң гаҗәп документларыннан берсе «Төзеки-Тимер» дип атала *(Уложение Тимура.—Ташкент.—1904)*. Аны Тимер бәк дәүләтендә хөкем сөргән кануннар тупланмасы дип тә атап булыр иде. Документта Тимер бәкнең тормыш фәлсәфәсе дә, сыйныфларның җәмгыятьтә тоткан урыны, үзара мөнәсәбәте, гаскәр белән халыкны идарә итү ысуллары да чагылыш тапкан. Әлбәттә, Тимер бәк аны үзе язмаган, гаҗәеп бай эчтәлекле бу чыганак—коллектив акыл җимеше. Ләкин аның һәр җөмләсе Тимер бәк тарафыннан расланган дип ышанып әйтергә мөмкин. Бу кануннарны атаклы Рим хокукы кодексы белән чагыштырырга мөмкин булыр иде. Аның төрки халыклар тарихы өчен әһәмияте ифрат зур, чөнки аны өйрәнү безгә башка төрки дәүләтләр, шул исәптән Алтын Урдада хөкем сөргән кануннарны тирәнрәк күзалларга ярдәм итә. Алтын Урдадан алай бөтен килеш безгә килеп җиткән документлар азрак сакланган. Ә бу ике дәүләтнең тормыш-яшәешендә уртаклыклар гаять күп. Шуңа күрә әлеге чыганак безгә кайбер нәрсәләрне реконтрукцияләргә ярдәм итә.

«Төзеки-Тимер»нең беренче битендә үк аның төзелү максаты ап-ачык итеп әйтелә. Әлбәттә, сүз Тимер бәк исеменнән бара. Кануннарның язылу сәбәбен җиһангир болай аңлата:

«Дәүләтләр яулаучы бәхетле балаларыма, җиһанны идарә итүче бөек варисларыма. Аларга мәгълүм булсын, мин, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен өмет итеп, күбесенең минем бөек тәхетемә варис булып калуына ышанамын. Шушы хәл мине үзем кулланган кагыйдәләрне алар өчен теркәп калдырырга этәрә. Әлеге кагыйдәләргә таянганда, алар мина зур борчу-мәшәкатьләр, авырлыклар, хәтәр сынаулар белән күкләрдән һәм рәсүлемез Мөхәммәд (Аллаһы Тәгалә аннан разый булсын) диненең бәрәкәтле йогынтысы, аның нәселе, сәхабәләре аша ингән бәхет-сәгадәтне саклап кала алырлар. Мин васыять итеп калдырган

Дәвамы. Башы 1—4 саннарда.

дәүләтне саклар өчен шушы кагыйдәләр тормышта да, дәүләт идарәсендә дә аларга кулланма булсын».

Күрәбез ки, бу документны Тимер бәкнең варисларына атап төзегән үгет-нәсихәте, васыятьнамәсе дип тә кабул итәргә мөмкин икән. Ул җиһангир гомеренең соңгы елларында төзелгән булса кирәк, чөнки анда фани дөнья белән саубуллашу, тормышына нәтиҗәләр ясау төсмере нык сизелә. Кагыйдәләргә күчкәнче, Тимер бәк тагын бер-ике сүз әйтүне кирәк таба: «Барысы уникe кагыйдә. Аларның әһәмиятен минем файда күрүем исбатлап тора: алар мина хакимдар булырга, дәүләтләр яуларга, яулаганны ныгытырга һәм тәхеткә лаек булырга ярдәм итте».

Әйе, бу кыйммәтле һәм күләмле чыганактагы фикерләрне тагын да китереп булыр иде. Ләкин бу очракта безне Тимер бәкнең 1391 елда Туктамыш хан өстенә яу йөрүе кызыксындырганга, яуның ничек әзерләнүен күздән кичерик. Ә кызыклы өзекләрне шушы вакыйгага бәйле рәвештә китерербез.

* * *

Шик юк, Тимер бәк бу яуга бик ныклап әзерләнгән. Аның төрле ягын уйлаган. Җитди карарлар кабул итү алдыннан үзенең нинди чаралар күрүен ул «Төзеки-Тимер»дә әйтеп уза: «Мин алдан киңәшмичә бер эшне башламыйм, аны тормышка ашырганда, бер нәрсәне дә вакыйгалар агышына куймыйм: хәрәкәт итә башлаганчы мин аның ничек тәмамланасын уйлыйм һәм елгырлык-житезлек, төптән уйлау, ныклык, саклык һәм алдан күрә белү аркасында аны уңышлы рәвештә тәмамлап чыгуга ирешәм.

Тәҗрибә шуны күрсәтә: сүзе белән гамәле арасында каршылык булмаган адәмнәр генә яхшы план төзергә сәләтле, алар бер төрле карар кабул иткәннән соң бернинди сәбәпкә дә карамыйча моңарчы кире кагылган иске планга әйләнеп кайтмыйлар».

Әлбәттә, бу һәр эш-гамәлгә кагыла торган гомуми фикер. Ә сугыш башлаганда карар ничек кабул ителгән? Тимер бәк бу мәсьәләне дә игътибарсыз калдырмый. «Гаскәрне яуга озату мәсьәләсе алга килеп басканда мин башта төп нәрсәне–сугышны башларгамы, юкмы дигән сорауга җавап эзлим, шуны хәл итәм,–ди ул.–Башта әмирләрнең фикерен тыңлыйм. Әгәр дә алар тыныч тормышны, солыхны кулай күрсә, сугыш мәшәкатьләре белән чагыштырганда, аның өстенлеген төпченәм; әгәр дә алар сугыш башлау яклы булсалар, киресенчә, тыныч тормышның унайлыклары белән чагыштырып карыйм. Шулай фикер йөртә торгач, мин һәрвакыт иң отышлы якны сайлыйм.

Гаскәрне икегә бүлә торган карарны мин һәрвакыт кире кагам. Мин сүзен кыюсыз гына әйтүче киңәшчене дә, фикерен ныклы итеп дәлилләүчене дә бүлдермичә тыңлап бетерәм. Һәр киңәшчене ахырына кадәр тыңлыйм, тик әйтелгән һәр фикернең уңай һәм тискәре якларын аерам, ахыр чиктә акыллы һәм файдалы киңәшне генә кабул итәм»,–дип Тимер бәк сугышны башлау-башламау мәсьәләсенең ничек хәл ителүен аңлатып бирә.

Китерелгән өзекләр Тимер бәк дәүләтендә җитди карарларның капылт кына, хискә бирелеп кенә кабул ителмәвен күрсәтә. Шул сәбәпле Тимер бәкне Туктамыш хан өстенә яу белән барырга күндерү өчен Идегәй мирзага шактый күп көч түгәргә туры килгәндер, дип уйларга кирәк.

## Яуга әзерлек

*«Вакыйгалар агышының язмыш кулында булуын тормыш тәҗрибәсе раслап торса да, зирәк акыллы һәм төпле адәм планнар корудан, алдан күреп эш итүдән баш тартырга тиеш түгел».*

(Тимер бәк)

Тимер бәк уйлаганын тартып-сузып йөрүче адәмнәрдән булмаган. Ул Туктамыш хан өстенә яу йөрү турында ныклы бер карарга килү белән эшкә керешә. Замана тарихчысы да шуны ук тәкъбарлый: «... Шуннан

соң Тимер (бәк) тиз арада Дәшти Бәркәне яулап алырга әзерләнде» *(Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов...,—т. 1,—С. 459)*. Бу очракта Дәшти-Бәркәнен—Бәркә ханнан мирас булып калган Дәшти Кыпчак дәүләте икәнен укучы беләдер.

Шулай яуга әзерлек башлана. Тимер бәк алдына яуны дошман өстенә нинди юлдан алып барырга дигән житди мәсьәлә килеп баса. Дөрес карар кабул итүнең булачак кампания барышында нинди мөһим роль уйнаячагын Тимер бәк яхшы аңлый. Шуңа күрә ул аны жентекләп тикшергән, үз кешеләре белән төрле ягын уйлагандыр. Әлбәттә инде, бу яуга илһамландыручы төп кеше буларак, Идегәй мирза да планны тикшергәндә читтә калмагандыр.

Мәвараэннәһердән Алтын Урда башкаласы Сарай шәһәренә таба картада туры сызык үткәрсәң, ул Арал дингезенең нәкъ уртасыннан узачак. Димәк, Алтын Урдага яуга жыенган Тимер бәк Аралны йә көнчыгыштан, йә көнбатыштан урап узарга тиеш була. Көнбатыштан узган очракта, ана Хәрәзем жирләре аша үтәргә туры киләчәк. Бер караганда, бу иң яхшы юл инде, борынгы Ефәк юлының бер тармагы. Дөрес, Тимер бәк, Хәрәземне яулап алып, Үргәнечне жимерткәч (1388), халкын үз башкаласы Сәмәркand тирәләренә күчереп утырткач, анда тормыш тәмам сүнә сүнүен, инде кеше-фәлән дә сирәк очрый. Әгәр дә ул яуга шушы юлдан чыгып китсә, дошманы Туктамыш ханны тиз эзләп табачак, әлбәттә. Ләкин болай ашкыну максатка ярашлы булыр микән? Араларның якын булуы ул бит ике яклы. Яу килү турындагы хәбәр дә дошманга тиз барып ирешәчәк. Ул аң булып, әзерләнеп көтеп торачак. Зур яу тиз йөри алмый, кызу барсаң, йөк төялгән хайваннар артта торып калачак. Шуңа жай белән генә хәрәкәт итәргә кала.

Кыенлыкның икенчесе шунда—Аралны узу белән үлән-суга бик тә фәкыйрь коры далага килеп керәчәксең. Анда ул кадәр малларны туендыру-сугару бер бәлагә әйләнәчәк. Ач килеш, сугарылмаган килеш йөк тартып бару аларны тәмам эштән чыгарачак. Димәк, коры даланы үтеп чыгып, сугышка кергәнче гаскәргә дә, атларга, йөк хайваннарына да ял бирергә кирәк булачак. Ә дошманның якын торуы исә мондый мөмкинлекне калдырмаска да мөмкин. Димәк, гаскәр сугышны арган-ялчыккан килеш башларга мәжбүр булачак. Табигый, арган яудан әллә ни гайрәт көтәргә туры килми. Ә Туктамышка шул гына кирәк тә. Ул үзенең Түбән Иделдәге нык тылларына таянып эш итәчәк. Сугыш барышында күргән зыянны да тиз каплаячак, чөнки артында халкы ишле бай ил жәелеп ята, мул үләнле далада меңләгән куй, елкы көтүләре утлап йөри. Ә Тимер бәк карамагында юлда өшәнгән гаскәр белән хәлдән тайган атлар гына булачак. Сугышны мондый шартларда башлау акылсызлык булыр иде. Яуларда зур тәжрибә туплаган Тимер бәк болай үзен андый авыр хәлгә куя алмый иде, әлбәттә. Шуңа күрә ул яуга Хәрәзем аша баруны башта ук яраксыз дип таба, аннан баш тарта.

Дөрес, Туктамыш хан өстенә икенче юлдан да барырга мөмкин. Анысы Аралны көнчыгыш тарафтан урап уза. Аннан барырга уйласа, Тимер бәккә көзен Ташкент яисә Отрар калалары тирәсендә гаскәр тупларга, кышны шунда чыгарга, ә яз житү белән юлга кузгалырга туры киләчәк. Бу юл беренчесенә караганда озынрак һәм, аны сайласаң, Мугоджар тауларына кадәр, хәтта Эмба елгасының башына житкәнче, комлы, үләнгә фәкыйрь, тозлы туреклы далалар аша узарга кирәк булачак. Димәк, монысы да шундый ук кыенлыклар китереп чыгарачак. Житмәсә юл беренчесенә караганда озынрак та.

Тагын нинди юл кала соң? Туктамыш хан өстенә нинди юлдан барачак соң Тимер бәк? Бар икән андый юл. Кыен да, бик озын да ул, тик уйлый китсәң, уңайлыклары да аз түгел икән аның. Бу юл Ташкенттән туп-туры төньякка юнәлә, Сары-су елгасын уза да Тургай капкасы аша Тубыл елгасына килеп чыга. Әйе, ул артык озын һәм әйләнгеч тә, әмма исәп-хисап йөртә торгач, аның уңай, имин яклары да күп икәне ачыклана. Әлбәттә, коры даланы үтеп чыгу монда да жиңел булмаячак, тик аның уңайлыгы шунда—ул дошман күзеннән бик ерак ята. Аны ашыкмыйча, күченеп йөргән кебек жай белән үтәргә мөмкин. Дошман сине күрми, берни белә дә алмый. Тагын бер уңай ягы—төньякка ераграк үтеп кергән саен дала һаман мәрхәмәтлерәк була бара. Олы Тауның көнбатыш итәгеннән мул үләнле көтүлекләр башлана, күлләр, кечкенә елгалар, инешләр күп. Әгәр дә Тимер бәк гаскәрен шушы юлдан алып китсә, ул үләнгә мул жирләргә барып ирешкәнче Туктамыш хан аңа берниндиi комачаулык та кыла алмаячак. Аннан

сон бит кеше яшәмәгән андый кинлекләрдә гаскәрнең кай тарафка хәрәкәт итүен кем белә алсын. Әгәр дә инде Туктамыш хан Тимер бәкнең яуга чыгып китүен ничек тә белеп алса, аны коры даладан чыккан чакта Олы Тау, Ишим елгасы тирәләрендә каршы алырга уйласа, үзенә дә үзәк олыслардан аерылырга, кыш көне Дон, Идел, Җаек буйларыннан халыкларны җыеп мәшәкатьләнергә туры киләчәк. Бу исә туган далаларыннан меңәр чакрымнарга китү, шул сәбәпле гаскәренне куркыныч астына кую дигән сүз. Әлбәттә, Туктамыш хан моңа бармас, дип фикер йөрткән булса кирәк Тимер бәк.

Әгәр дә ул Тубыл буйларына тыныч кына барып житә алса, ябыккан атларын мул үләнле тугайларда көрәйтсә, гаскәренә дә тиешле ял бирсә, ул чакта иркен сулыш алып куяр һәм хәрәкәт итә башлар иде. Шулай итеп ул юлның әйләнеч һәм урау вариантын сайлый. Аның иң ышанычлы һәм имин юл икәненә ышана.

Тимер бәк хакимият дилбегәсен үз кулында нык тотса да, дәүләт өчен әһәмиятле зур эшләргә керешкәндә корылтай җыйган, туган-тумачасы, әмирләр, шаһзадәләр фикерен дә тыңлаган, үзе өчен ачык мәсьәләгә киңәшеп эшләү төсе бирергә яраткан. Бу очракта да ул шулай итә. 1391 елның февраль аенда ул корылтай җыя, аксөякләр, хәрбиләр белән киңәшә. Табигый, корылтайда Туктамыш хан өстенә яу йөрү турында уңай карар кабул ителә. Күзгә күренә торган эшләр шуннан соң гына башлана.

* * *

Карар кабул итү әле бер хәл, аны тормышка ашыру исә бөтенләй башка нәрсә. Яу вакытында нинди кыенлыклар килеп чыгасын, нинди авыр мәсьәләләрне хәл итәргә туры киләсен Тимер бәк бик яхшы аңлый. Шуларның иң четреклесе– Дәшти Кыпчак халкының сугышларда чыныккан, теләсә нинди шартларда да орыша белүче үзе күчмә, үзе утрак халык булуында. Бу гайрәтле халыкка яу белән барсаң, бик уйлап эш иткәндә дә таманга туры килә. Соңгы вакытта, төрле низагларга кереп, бераз таркаулык кичерсәләр дә, илгә куркыныч килгәндә бу халык берләшергә, ватанын сакларга сәләтле. Өстәвенә тиз арада зур атлы гаскәр дә туплап өлгерә ала. Халкы ишле, ат көтүләренең анда саны-исәбе юк. Шуңа күрә бу халыкка яу йөри калсаң, шаярып кына, ярты көчкә генә орышырмын димә.

Аннан соң азык-төлек мәсьәләсе. Тимер бәк сайлаган әйләнеч юлда аны беткән саен өстәп торып булмаячак, юлның яртысыннан артыгын адәми зат яшәмәгән бушлыклар аша узарга туры киләчәк. Димәк, барын да үзең белән алырга кирәк. Яулар уйлаганнан озаккарак сузылса, гаскәр азык-төлек ягыннан авыр хәлдә калачак. Шуңа барысын да алдан күрәсе, ихтимал кыенлыкларны да исәпкә аласы иде. Ачтан интекмәс өчен ул хәтта, алдан кешеләр җибәреп, барыр юлда игеннәр дә чәчтереп куярга була. Яу килеп житкәнче күтәрелә торсыннар.

* * *

Тимер бәк яуга чыгып китәр алдыннан Яу багу йоласы үткәрергә бик ярата торган була. Аның гаскәре атлылардан һәм җәяүлеләрдән торып, ерак җирләргә йөргәндә җәяүлеләр дә ат белән тәэмин ителә. Кирәк чакта иярдән төшеп тә сугыша белсеннәр өчен, атлылар да җәяүләп орышырга өйрәтелә. Әлбәттә, алар ияр өстендә остарак эш итә, тик җәяүле күнекмәләре алу да кайчак бик ярап куйгалый.

Атлылар, Дәшти Кыпчактагы кебек, ике төргә бүленә–авыр һәм җиңел коралланган гаскәргә. Авыр коралланганына тәҗрибәле, иң оста орышучылар туплана, чөнки бәрелешнең язмышын еш кына алар хәл итә. Әлбәттә, Тимер бәкнең үзен саклаучы махсус баһадирлар да бар, алар киемнәре, затлы кораллары, ат өстенә ябылган кыйммәтле тукымалары, юлбарыс тиреләре белән башкалардан аерылып торалар. Моннан тыш гаскәрдә төрле һөнәр ияләреннән торган махсус бүлекләр дә бар. Мәсәлән, көймәчеләр елга-суларны кичкәндә күперләр суза, саллар бәйли; таш атучылар төрле җайланмалар ярдәмендә аларны дошман өстенә яудыра; рум уты осталары чүлмәкләргә тутырылган яндыргыч сыекча ата; арада диварларга менү өчен арканчылар, агачтан баскыч көйләүчеләр дә, гаскәрне

туендыручы ашчылар, чатыр-тирмә корырга маһир йортчылар да бар. Таулы якларда сугышканда андагы халыклардан махсус тәркемнәр туплана, кыя өсләрендә урнашкан нығытмалар алар ярдәмендә алына һ. б.

Ә гаскәр исә мондый тәртиптә төзелә. Һәр ун сугышчының берсе иптәшләре тарафыннан унбашы итеп сайлана. Ун унбашы арасыннан берәү йөзбашы итеп сайлана. Әлбәттә, ул иң акыллы-зирәк, булдыклы һәм батыр булырга тиеш. Ун йөзбашы үзен тәҗрибәле гаскәр башы итеп күрсәткән, батырлыклары белән абруй казанган мирзага яисә бәккә буйсына.

Унбашының үз кул астындагы сугышчыны алыштырырга хакы бар (үлгән, яраланган яисә качып киткән очракта). Моның өчен ул беркемнән дә рөхсәт сорамый, бары тик йөзбашына гына хәбәр итә.

Йөзбашы да унбашыларны үзе куя, үзе алыштыра.

Меңбашы да йөзбашыларны үзе билгели, бу хакта Тимер бәккә хәбәр итә.

Шулай итеп, хәрби бүлекчә башлыкларының тәртип бозучыларны җәзага тартырга, вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен хезмәттән куарга, алар урынына икенче кеше алырга тулы хокукы бар. Гомумән, һәр сафтан чыккан кешене бүлекчәнең башлыгы икенче берәү белән алыштыра тора.

Яуның аеруча кыен буласын белгәнгә, Тимер бәк бер нәрсәне дә игътибардан читтә калдырмаска тырыша, башкалардан да шуны таләп итә. Алдан хәстәрен күрсән, соныннан җинелгә туры килә шул. Анын уенча, һәр сугышчы үзе белән бер елга җитәрлек азык-төлек алырга тиеш. Әйтик, кеше саен дүрт карт сарык, киптерелгән ит, корт, бавырсак ише кайнар суда җебетеп тиз арада тамак ялгап була торган ризыклар. Кораллардан, сугыш кирәк-ярагыннан—җәя, кәкре кылыч, туры кылыч, чукмар, утыз ук сыешлы садак, калкан, һәр 2 кешегә 1 ат; 10 кешегә—1 чатыр, 1 көрәк, 1 китмән, 1 урак, 1 пычкы, 1 балта, 1 без; баулар, каешлар, арканнар; су салу, авызын бәйләп елга-сулар аша кичү өчен турсыклар, капчыклар. Моннан тыш 100 кешегә 1 казан, һәр 18 кешегә киез тирмә.

Авыр коралланган атлылар гаскәрдә аерым урын алып тора, анда һәр сугышчыга ике ат, 5 кешегә 1 тирмә тиеш. Атлы сугышчы анда үзенең корал йөртүче ярдәмчеләре белән куна.

Һәр унбашына аерым чатыр һәм 5 ат тиеш. Йөзбашының 10 аты, аерым тирмәсе, кораллардан—кылычы, җәясе, уклары, чукмары, тимер көбәсе, тимер туны булган. Меңбашының тирмәсе алдында күләгәдә кинәшү өчен җәймә тарттырылган. Ул шулай ук запас кораллар да тотарга тиеш булган: көбәләр, тимер туннар, шлемнар, сөңгеләр, садаклар, уклар, кылычлар һ. б.

Әмирләрнең дәрәҗәсе 12 баскычтан торган. Әйтик, 1 нче дәрәҗәле әмирнең ике тирмәсе булып, берсенә ике тент тарттырылган, ә икенчесе алтын белән чигелгән. Шулай ук ул шактый күләмдә запас кораллар да саклаган. Гомумән, барлык әмирләр дә үзләрендә запас корал сакларга тиеш булганнар.

Беренче дәрәҗәле әмир үзе белән 110 ат, икенче дәрәҗәлесе—120 ат йөртергә тиеш булган, атлар саны шулай 12 нче дәрәҗәгә кадәр үсә барган.

Яу башының атлары 300 дән дә ким була алмаган *(Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов..., т. 1,—С. 459; Тамерлан: эпоха, личность, деяния.—М.,—1992,—С 425—426).*

Дөресен әйтергә кирәк, яуга җыенганда, Яу багу йоласы уздыру Тимер бәк уйлап тапкан нәрсә түгел. Аңа хәтле Чыңгыз хан да бу йоланы катгый үтәгән. Тимер бәк исә борынгыдан калган йолага аеруча зур әһәмият бирүе белән генә аерылып тора. Йола вакытында гаскәрнең төзек сафларын, ялык-йолык итеп торган коралларны, сугышчылар күзендә чагылган яу дәртен күрү анын кәефен бик нык күтәргән булса кирәк. Шулай итеп, 1391 елның 21 февралендә булып узган корылтайдан соң Ташкент тирәсендәге киң яланда үткәрелгән йола вакытында Тимер бәк, 200 мең гаскәрен күздән кичереп, анардан канәгать кала.

Иртәгесен, таң атып, кояш күтәрелгәндә догалар укыла, сәедләрдән фатиха алына һәм яу юлга кузгала. Гаскәр сафларында Идегәй мирза да бара. Бу мәлдә үз ватаны Идел-Йорт өстенә нинди афәт, нинди һәлакәт килүен уйлады микән ул? «Тимер бәкне яуга үгетләп дөрес эшләдемме?» дип бер генә мизгелгә эче жу итеп куйды микән анын?! Әллә инде барысын да оныткан хәлдә Туктамыш ханнан үч алу турында гына уйлады, шуны күз алдына китереп, тантаналы ләззәт кичерде микән?!

## Далалар аша

**XX гасыр** кешесенә дала тутырып баручы 200 менлек яуны күз алдына китерүе жинел түгелдер. Үз халкынның үткәнен, гомумән, төрки бабаларының тормыш-көнкүрешен рәтләп белмәсән—бигрәк тә.

Тимер бәк сайлаган юл Алтын Урданың үзәк олысларыннан, хәтта Жаек буйларыннан да бик еракта узганга, аның гаскәре буш далада кинәт дошман белән очрашудан шикләнмичә, күчеп йөргәндәге кебек, жәелеп-иркенәеп хәрәкәтләнгән. Ул кадәр ишле халык төркеменен бергә укмашып баруын күзалдына да китереп булмый. Һәм бу мөмкин эш тә түгел. Табигый, яу йөзләгән төркемнәргә, отрядларга,колонналарга бүленеп барган, һәркайсы үз мәшәкатен үзе кайгырткан. Ә хәзер шушы массаның дала буйлап хәрәкәт итүен яисә ялга туктаган чагын күз алдына китерик.

... Иксез-чиксез гаскәр, менләгән атлар, дөяләр, куып алып барылган куй көтүләре, олаулар, яу белән баручы алыпсатарлар, хезмәтчеләр, төрле һөнәр ияләре... Шулар өстендә һавада жилфердәгән әләмнәр, буынчыклар, менләгән авазлар, сөнге очларында сызгырган дала жиле...

Аннан боерык яңгырый. Ул төркемнән-төркемгә күчә барып, ничәмә чакрымнарга сузылган шушы халыкны туктап калырга мәжбүр итә, шундук учаклар тергезелә, казаннар асыла, һавага меңнәрчә төтен путалары сузыла. Күп тә үтми борыннарга яна суелган ит шулпасы исе килеп керә, тирә-юньгә тарала.

Яу ял итә.

Сугыш хәрәкәтләре барганда, дошман якын торганда тәртипләр башкачарак булган. Төнгә каршы урда әйбәтләп ныгытылган, тирмәләр төзелеп божралар ясалган, кирәк дип табылса хәтта урданы канаулар белән дә уратып алганнар. Көтелмәгән һөжүмнән зыян күрмәс өчен, мәсәлән, Тимер бәк урдасын 12 мен атлы сугышчы саклаган (һәр тарафта 3000), урданы гына түгел, гомумән, гаскәр урнашкан лагерь да махсус отрядлар сагы астында торган. Ясауллар урда эчендәге тәртипне күзәткән—угры-караклар шаярмыймы, үзара сугышу, бер-беренә кул күтәрү юкмы, алыпсатарлар бәяләрне арттырмыймы...

Аурупа авторлары дала халыкларын күп заманнар кыргыйлар рәтендә йөрттеләр. Даланың үзенә хас тормышын, үзенчәлекле мәдәниятқә ия булуын күрмәмешкә салышып килделәр. Тик болай мәнге дәвам итә алмый иде. Ниһаять, боз кузгалды. Күчмәләр тормышын тирән аңлаган, аның үзенчәлеген күрә белгән хезмәтләр дә языла башлады. Бу яктан мәшһүр тарихчы Л. Н. Гумилев зур эш башкарды, гомере буе дала халыкларын төрле гайбәтләрдән яклап, аларның чын йөзен ачып күрсәтә торган тирән хезмәтләр язды.

Бу эш әле XIX йөздә үк башланган булган икән. Шушы уңайдан икенче бер урыс тарихчысының күчмәләр хакында әйткән соклану сүзләрен китермичә уза алмыйм. Аларны тәржемә итәргә ничектер кул бармый, нидер югалыр сыман тоелә, шуна күрә ничек язылган булса, шулай китерәм: «Но каким образом эти войска могли иметь с собой, при движении в военное время, эти огромные обозы, множество табунов, перекочевывать с своим имуществом и в то же время вести войну вдали от своих аулов и среди враждебных им народов? Хотя можно предпологать, что они большею частью имели значительное превосходство в силах против неприятелей и могли отделять часть войска для прикрытия обозов, однако, тем не менее надо удивляться умению кочевых народов пасти и перегонять свои многочисленные табуны лошадей, верблюдов, баранов, перевозить огромные запасы в землях неприятельских, часто при недостатке воды и корма и небольшом числе людей в сравнении с величиною стад и обозов, умению смотреть за ними, в случае опасности защищать их или укрывать в безопасные места и предохранять себы от нечаянных нападений. Это может объясниться только необыкновенною способностью кочевых народов к малой войне и истребительною, кровопролитною системой их войн» *(М. И. Иванин. О военном искусстве и завоеваниях монголо-татар и среднеазиатских народов при Чингиз хане и Тамерлане.—СПб.,—1875.—с. 129—237).*

Бу сүзләрне күчмәләрнен үтә кырыс шартларга жайлаша белүен, гажәеп чыдамлыгын, чыныкканлыгын, гадәти тормышны сәнгать дәрәжәсенә күтәрергә сәләтле халык булуын тану дип кабул итәргә кирәктер.

* * *

Шулай Тимер бәк явы Ташкенттан төньякка таба кузгалып киткәч, Күк Урданың борынгы калалары Сәүран, Карачык, Ясә аша уза, аннан байтак вакыт хәзерге Казакъстан жиреннән аккан Сары-су елгасы буйлап бара. Аннан, Олы Тауны унда калдырып, шушы тауларда тибеп чыккан чишмәләрдән туенучы Олы Жыланчык елгасына чыга. Монда гаскәргә бераз ял биргәч, Тургай инкүлеге аша Тубыл елгасының өске агымына юнәлә.

«Юнәлә» дип әйтүе генә жинел, чынында бу юл бик газаплы булган. Кышкы шартларда ташлы-комлы, үләнгә-суга фәкыйрь коры далалар аша узу гаскәрне бик нык йончыта, атлар, терлек-туар ябыга, хәлдән тая. Дөрес, юлның унай ягы да бар—төньякка тирәнрәк үтеп кергән, Тубыл буйларына якынлашкан саен табигать мәрхәмәтлерәк була бара, эчәргә су, терлекләргә үлән арта, гаскәрне тәмам эштән чыгудан шул коткарып кала. Хәер, Тимер бәк бит бу юлны шушы өстенлеге өчен сайлый да.

Тубыл буйларына килеп чыкканчы Тимер бәк явы Туктамыш ханның бер генә кешесен дә очратмый. Бу исә аның яуны бик оста яшереп алып баруы хакында сөйли. Шулай ярты юлны, гадәттәгечә күчереп йөргән кебек, хәвеф-хәтәрсез үтәләр. Тубыл буенда исә ул гаскәргә озакка ял бирергә була, чөнки хәл алмыйча, ныклап торып әзерләнмичә, атларны бераз симертмичә яуны дәвам иттерү турында уйлыйсы да юк.

Яуны жентекләп өйрәнгән авторлар күрсәткәнчә, Тимер бәк монда азык-төлекне сак тоту ягыннан да житди чаралар күргән. Дошман якын, яу килүне тиздән белеп алачак, ә сугышның күпмегә сузыласы әлегә билгеле түгел. Шуна күрә, кыен хәлдә калмас өчен, ул шундый фәрман чыгара: дәрәжәсе нинди булуга карамастан, барлык кешегә баллы-татлы ризыклар белән туенуны катгый тыя; көнлек азык күләмен киметә, барысына да он белән болгатылган киптерелгән ит кенә бирергә, аны үләннәр, тамырлар белән төрләндерергә куша. (Бүгенге күзлектән караганда, бу чаралар язгы авитаминоздан котылу, кешеләргә хәл кертү өчен эшләнгән дип кабул итәргә мөмкин.) Бирелә торган онның да күләмен киметергә боера, шулай 25 фунт онны 60 көнгә бүлә башлыйлар. Аннан соң яу белән баручы һәр кеше үзенең шәхси запасларын чыгарырга, бүлеп сугышчыларга таратырга мәжбүр ителә. Моннан тыш азык-төлек запасын арттыру өчен дә кайбер нәрсәләр эшләнә; әйтик, ашарга ярый торган үләннәрне, кош йомыркаларын жыю, жәнлекләр аулау, зур мәйданнарда камау аулары оештыру кебек чараларның барысы да эшләнә. Шулай яу белән алып барылган шактый азык-төлек янга калдырыла.

Шушы эшләр башкарылып, гаскәр бераз хәл алгач, ямасын-ямап, төзәтәсен төзәткәч, Тимер бәк кабат Яу багу йоласы уздыра. Шәрәфетдин Йезди язганча, ул ике көн буе дәвам итә. Тимер бәк ял иткән төзек сафлар буенча узганда һәр хәрби бүлекчәнең башлыгы, атыннан төшеп, жиһангиргә үз сугышчыларын тәкъдим итә, тегеләр үз чиратында сугышу алымнарын күрсәтә, ә командирлары, Тимер бәк каршында тез йөгенеп жирне үбә, Яу башы исәнлегенә дога кыла һәм гомерен кызганмыйча орышачагын белдереп ант итә. Әлбәттә, шундый анттан соң сафларда торган сугышчылар сөрән сала, тирә-юньне янгырата торган булган.

Шушы ук көннәрдә Тимер бәкнең хәбәргәрләре беренче тапкыр Туктамыш хан кешеләренә тап булалар. Эш шунда, Яу багу йоласын үткәрү белән Тимер бәк дошман турында берәр хәбәр алу өчен тирә-юньгә берничә отряд жибәрә. Һәм тегеләр берәр жан иясе эзләп табу эшенә керешә. Ниһаять, өченче көнне шактый алда барган хәбәргәр отряд учак төтеннәре күреп ала, тик кеше-фәлән таба алмыйлар. Тырыша торгач, постырмадагы бер төркем дошманның берничә сугышчысын кулга төшерәләр. Сорау алганнан соң Тимер бәк, ниһаять, Туктамыш ханның кайда икәнлеген белә. Бу вакытта инде Алтын Урданың сакчы отрядлары Тубыл елгасындагы кичүне бозып куйган була.

Бу урында шуны да әйтеп үтәргә кирәк. Әле 6 апрельдә үк, Идегәй мирзаның ике нөгәре, Тимер бәк гаскәрләреннән качып китеп, Туктамыш ханга зур яу килүе хакында хәбәр китерә *(Сафаргалиев М. Г. Распад Золотой Орды.—Саранск.—1960.-С. 152).* Шулай итеп, гади сугышчыларда ватаннары Идел-Йорт өчен борчылу, аны коткарып калу теләге көчлерәк булып чыга.

Әлбәттә, чыбык-чабыклардан көлтәләр бәйләп, аларны күп итеп түшәп, Тубылдагы кичүне ныгытырга туры килә, шуннан соң гына елганың каршы ярына чыгалар. Бу урында Алтын Урда отрядлары белән бәрелеш-фәлән булмый. Тимер бәк Җаекка юл тота. Бу мәсьәләне җентекләп тикшерүчеләр Тимер бәк Җаек кичүенә май ахырларында гына килеп җиткән булырга тиеш, дигән фикер әйтәләр. Күтәрелгән язгы сулар бу вакытта ярларына кире кайта икән. Елганы кичкәндә, үзенең Туктамыш хан һөҗүменә дучар буласын Тимер бәк яхшы аңлый.

Чыннан да, Туктамыш хан дошманын Җаек кичүендә, Кырык күл дип аталган җирдә каршылар өчен гаскәр туплый. Тимер бәкне шунда көтә. Дөрес, аралар ерак булу сәбәпле, билгеләнгән вакытка ни Болгардан, ни Азак далаларыннан ярдәм килеп җитми. Шулай да Туктамыш ханның гаскәре аз булмый. Ә Тимер бәк, аның ниятен аңлап алып, Җаекның өске агымына юнәлә, елганы дошман бөтенләй көтмәгән урында, тыныч-имин шартларда кичә. Моны белеп алган Туктамыш ханга, дошман аның артына төшмәсен өчен, тиз арада ил эченә таба чигенергә туры килә.

## Алдаучы хәрәкәтләр, беренче бәрелешләр

Гомумән, Туктамыш ханның планы нидән гыйбарәт булган соң? «Чүлдәге комнар белән агач яфраклары кебек хисапсыз» дошман явын ул ничек туктатырга, көрәшне ничек оештырырга уйлаган?

Идел буеның картасына күз салу үзе үк бу сорауга җавап бирергә ярдәм итә шикелле. Белгәнебезчә, Туктамыш ханның дошманны Җаек суын кичкән чакта каршы алу планы барып чыкмады. Тимер бәктән ул алданды, тегенең тактикасы өстенрәк булып чыкты. Туктамыш ханга ашыгыч рәвештә артка чигенергә туры килде. Ул кайсы тарафка чигенергә тиеш иде соң? Гомумән, чигенгәндә нинди тактика сайларга тиеш иде?Шик юк, Алтын Урданың үзәк олыслары урнашкан көньяк-көнбатышка таба чигенү аңа бер өстенлек тә бирмәячәген Туктамыш хан әйбәт белгән. Ул тарафта Каспий диңгезенә кадәр ачык дала җәелеп ята, һәр хәрәкәтенне-маневрыңны дошман күреп торачак, ышыклану өчен бернинди табигый киртә дә юк. Тимер бәк гаскәренең сугышларда нинди чыныгу алуы, яхшы идарә ителүе аңа мәгълүм. Шуна күрә Иделнең түбән ягына таба чигенүне ул кире кага. Дошманны үз башкаласына алып барырга башына тай типмәгән ич аның. Туктамыш хан башка тактика сайлый. Ул чигенә-чигенә дошманны дала белән урман зонасы чигендә сузылып яткан урманлы-кырлы җирләрдән ил эченә алып кереп китмәчке була. Монда сугыш алып бару өчен төрле уңайлыклар бар, гаскәренне берәр урманчык артына яшереп куеп, кинәт һөҗүм итәргә дә мөмкин, дошман синең яшерен хәрәкәтләреңне, ниятләреңне дә белмәячәк. Шулай итсән, Тимер бәк гаскәрен көтелмәгән хәл алдына куя-куя, акрынлап хәлсезләндерергә, тора-бара өстенлек алырга да мөмкинлек туачак. Иделгә аркасы белән торган Туктамыш хан шулай гаскәренең сул һәм уң канатларын җәеп җибәрә, ә үзәккә көчле кулларны урнаштыра.

Ләкин Тимер бәк тә туктаусыз дошманы турында уйлый, ул Туктамыш ханның тактикасын тиз аңлап ала. Дошман тәкъдим иткән ысулны сайласа, үзенең гаять авыр хәлдә калачагын ул күреп тора. Шуна күрә татар гаскәрен дала чигеннән узган урман-кырлар тасмасыннан ничек тә булса ачыклыкка кысып чыгару эшенә керешә. Ә Туктамыш хан аны төньяк-көнбатышка–Болгар җирләренә алып китәргә тырыша. Бу вакытта ара-тирә вак бәрелешләр дә булгалап тора. Ләкин ахыр чиктә Тимер бәк, татар гаскәренең сул канатына чыгып, аның төньяк-көнбатышка чигенү юлын бикләүгә ирешә.

Шушы уңайдан Туктамыш ханның кампания башында җибәргән бер стратегик хатасын да әйтеп үтәргә кирәктер. Ул берничә ай буе далалар аша узган Тимер бәк гаскәре юлда бик нык хәлсезләнгән, запас фуражлары беткән, арган-талган дип уйлый, шул сәбәпле дошманны ил буенча мөмкин кадәр озаграк йөртеп, тагын да эштән чыгарырга карар кыла. Тимер бәкнең әле Тубыл буенда ук гаскәргә әйбәт ял бирүен, азык-төлекне бик саклап тотуын, камаулы аулар

оештырып, запаслар туплавын, Яу багу йоласы үткәреп, сугышчыларының рухын күтәрүе хакында ул берни дә белми. Ягъни дошман ул уйлаганга караганда көчлерәк тә, туграк та, әзерлеклерәк тә булып чыга.

Өстәвенә, Тимер бәк дошман гаскәре арасында астыртын таркату эше дә алып бара. Әлбәттә, бу эшләр, Идегәй мирза кебек, Сарайдан качып киткән яисә, Туктамыш хан ягында булып та, күнеле белән ана оппозициядә торган кешеләр ярдәме белән эшләнә. Ягъни Алтын Урда гаскәрендә Туктамыш ханга каршы хыянәт әзерләнә. (Бу мәсьәләгә без әле иркенләбрәк тукталырбыз.)

Шулай итеп, Тимер бәк Жаекны кичә, чигенгән татар гаскәре артыннан юлын дәвам иттерә. Бу вакыт көтелмәгән хәл була–Туктамыш хан Жаекка чакыртып та, билгеләнгән көнгә килеп житмәгән кайбер олыс гаскәрләре Тимер бәкнен корбанына әвереләләр. Азак буйларыннан килгән гаскәр дә Тимер бәк ятьмәсенә килеп керә. Бу гаскәрнен башында мәрхүм Мамай мирза улы була. Сорау алганда хәлне ул болай анлата: «Мин Сарайдан ханым янына ашыктым, ләкин сөйләшенгән жирдә аны тапмадым. Башка берни дә белмим»,–ди *(Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов...,–т. II.–с. 164-165)*. Бу исә Туктамыш ханнын Жаекны ашыгыч рәвештә ташлап китүе турында сөйли. Ләкин тарихчылар, анын гаскәре моннан башка да житәрлек булган, диләр.

Тимер бәк, татар гаскәре эзеннән барып, очраган елгалардан Сакмарны, Самараны, Сокны кичә. Шулай хәлиткеч бәрелеш сәгате көннән-көн якыная бара. Моны ике як та сизеп тора. Ниһаять, Туктамыш хан дошманны Самара терсәгеннән бераз төньяктарак урнашкан Кондырча суы буенда каршыларга, орышка шунда керергә карар кыла.Бу көннәрдә анда, ике якны да исәпкә алсан, ярты миллионга кадәр гаскәр туплана. Монарчы Идел буе тарихында бу кадәр зур гаскәрнен тупланганы әле булмый. Кем өстен чыгар: чит жирне талау өчен килгән баскын жиһангир Аксак Тимерме, Әллә Идел буенын үз халкы–татармы?

## Кондырча сугышы (18 июнь,1391 ел)

Сугыш мәйданын фәкать шушы урында сайларга Туктамыш ханны нәрсә мәжбүр иткән? Бу хакта төрле фикерләр бар. Әйдәгез, картага күз салыйк та анын унай һәм унайсыз якларын ачыкларга тырышып карыйк. Шик юк, сугыш башланганчы ике яу Кондырчанын капма-каршы ярларында торган. Ун як ярда Туктамыш хан гаскәре, сул якта–Тимер бәк. Гаскәрләр болай урнашкан очракта Туктамыш хан, мәсәлән, һөжүм итеп алга гына хәрәкәт итә алган. Ни өчен дигәндә, анын артында Идел, чигенә башласа, гаскәргә бернинди маневр ясау мөмкинлеге калмый, ул елга ярына килеп терәләчәк һәм... бик авыр хәлдә калачак. Алай гына да түгел, Самара терсәгенә житәрәк Идел матур дуга ясый. (Бүгенге көндә анда Куйбышев сусаклагычы урнашкан.) Чигенергә туры килдеме–әлеге дуга эченә керәсен дә утырасын. Бу Туктамыш хан гаскәре өчен капчык. Бер кереп капсан, чыгу мөмкин түгел. Урын сайлаганда ул моны күрмәде, бу хакта уйламады микәнни сон?

Шулай да Туктамыш хан турында алай ук начар уйлыйсы килми. Бәлки ул махсус шушы урынны сайлагандыр. Ни өчен?

Әле сугыш башланганчы ук Тимер бәкнен Алтын Урда гаскәре арасында астыртын таркату эше алып баруын әйтеп үткән идек. Бу хәбәр чыганакларда да чагылыш таба. Әйтик, Тимер бәк Туктамыш ханнын төп байракчысы белән мөнәсәбәткә кереп, аны үз ягына аударуга ирешә. Сугышнын ин кызган чагында теге байракны төшерергә риза була. Орыш кызган чакта хан байрагынын кинәт юкка чыгуын күз алдына китерик. Димәк, монын күнелләргә күпме шик-шөбһә, шом саласын Тимер бәк алдан ук уйлап куйган һәм анын көчле бер отряды, чыннан да, татар гаскәрен ярып кереп, хан байрагын бәреп төшерә (әлбәттә, байракчы ярдәме белән!). Шулай ук Идегәй мирза да бу орышта Тимер бәккә зур ярдәм күрсәтә. Ул Алтын Урда ягында сугышкан үз ыруы мангытларга алдан кеше жибәрә дә аларны сугыш кырын ташлап китәргә күндерә. Килешенгәнчә, мангытлар орышнын ин кызган чагында, Туктамыш ханны ташлап, үз олыслары Мангышлыкка кайтып китәләр.

Бу хәбәрләр ни хакында сөйли соң? Алтын Урда гаскәрендә бердәмлек булмавы, Туктамыш ханны күпләрнең өнәмәве, аңа карата оппозициядә торуы хакында сөйли. Әлбәттә, хан үзе моны белеп-сизеп яшәгән. Һәм гаскәргә, аның бүлекчәләрен җитәкләгән бәкләргә, мирзаларга ышанычы әллә ни зур булмаган. Гаскәре җан-фәрман сугышсын, үзен кызганмасын өчен ул нишләргә тиеш иде? Әлбәттә, ул аны артка чигенә алмаслык шартларга куярга тиеш иде. Кондырча суының уңъяк ярында урын алуы, артында Идел булып, гаскәренә чигенү җае калдырмавы шушы сәбәпләргә бәйле түгел микән? Мондый шартларда гаскәр бары тик дошманга һөҗүм итеп, алга барып, аны кысрыклап, чигенергә мәҗбүр итеп, өстен чыгып кына үзен саклап кала алачак иде...

Туктамыш ханның сугыш мәйданы итеп Кондырча буен сайлавын башкача аңлатып булмый.

Ә Тимер бәк? Аның планы нинди булган? Ул сугышны ничегрәк алып барырга уйлаган? Табигый, ул беренче чиратта дошман позициясенең йомшак ягын үз файдасына җигәргә омтылган, ягъни Туктамыш хан гаскәрен Идел ярына китереп кысарга, «капчыкка» кертеп ябарга тырышкан. Шул ук вакытта, үзенең чигенү ихтималын да уйлап, артындагы Сок елгасында ныгытылган линия булдырган. Дошман бик нык кыса башласа, бу аңа шунда күчеп бераз хәл алырга, маневрлар ясарга, аннан кабат һөҗүм башларга мөмкинлек тудырачак. Кыскасы, аның өчен ике вариантның һәркайсы кулай, һәлакәт белән тәмамланмый торган итеп уйланган була. Ә Туктамыш хан исә бары тик алга барып кына хәлен яхшырта алган. Ике якның планнарын чагыштырып карасаң, Тимер бәкнеке уңышлырак икәне ярылып ята. Аларның принципиаль аермасы шунда.

Моннан тыш гаскәрне урнаштыру, сафларны төзү, аларны идарә итү дә бар бит әле. Дөресен әйткәндә, Туктамыш ханның бу сугышта нинди ысул-тактика куллануы хакында чыганакларда мәгълүмат күп түгел. Әмма Алтын Урдада чыңгызый ханнардан килгән традициянең нык саклануы, гаскәрнең уң кулга, сул кулга һәм урта кулга бүленүе билгеле нәрсә. Галәттә, гаскәр дошманны, сул һәм уң яктан

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ
## «QAZAN UTLARI»NA 80 YIL

**Рүзәл Юсупов,**

*Казан дәүләт педагогия университеты ректоры, академик.*

# МӨГАЛЛИМНӘР МӘКТӘБЕ



***«Казан утлары»— өлкәннәр дә, урта буын да, яшьләр дә яратып укый торган журнал, аң-гыйлем җыя торган, мәктәптә алган белемнәрне тирәнәйтә-киңәйтә торган журнал.***

***Казан дәүләт педагогия университеты укытучылар әзерли. Димәк, ул—мөгаллимнәр мәктәбе. «Казан утлары» журналы исә студентлар һәм укытучылар өчен нык рухи-мәдәни нигез, терәк булып тора, ул бик күп зыялы затларыбызның өстәл китабына әверелде. Бүгенге көндә журнал 9—10 мең тираж белән тарала икән, аның яртысын һичшиксез укытучылар алдыра. Димәк, «Казан утлары» да—мөгаллимнәр мәктәбе! Университетта биш ел белем алсалар, бу журналны исә гомер буе укыйлар. Шушы җәһәттән, КДПУны тәмамлаган һәм хәзер илебезнең төрле төбәкләрендә балаларга гыйлем эстәүче укытучыларга мөрәҗәгать-гозерем дә бар: языгызы «Казан утлары»на, акча ягыннан арзанлы, әмма рухи яктан бәһаләп бетергесез кыйммәтле журнал ул!***

***Шәхсән үзем яраткан журналымнан ниләр көтәм соң? Иң беренче чиратта—кыю публицистиканы, затлы-***

әйләнеп узып, ике яктан китереп кысып, тар-мар итә торган булган. Кондырча буенда да Туктамыш хан татарларының шушы ысулны куллануы шик тудырмый.

Ә менә Тимер бәкнең орышларда нинди ысул куллануы чыганакларда шактый ачык әйтелә. Ул тактиканы дошманның күләменә карап сайлый торган булган. Әгәр дә дошман гаскәре 40 меңнән артып китсә, идарәне һәрчак үз кулына алган. Кондырча буенда исә ул 200 мең гаскәрен җиде өлешкә бүлгән: үзәктә—урта кул, ике якта—уң кул белән сул кул, гаскәр алдында маңгай кул—авангард, моннан тыш дошманны уңнан һәм сулдан урап алу өчен ике өстәмә фланг гаскәре һәм резерв та булган. Соңгысы хәлләр бик авырга китсә генә сугышка кертелгән, ахырга кадәр запаста тотылган.

Телгә алынган «Төзек-и Тимер» чыганагында яуларда, аның төрле этапларында нинди кагыйдәләргә буйсынып эш итүе җентекләп тасвирлана. Кызыксынган кеше аннан гаҗәеп бай мәгълүмат таба ала. Шул исәптән анда сугыш урынын сайлау кагыйдәләре дә теркәлгән. Алар мина шул кадәр кызык тоелды ки, күчереп язмыйча булдыра алмадым.

«Сугыш буласы урынны сайлаганда яу башы түбәндәге дүрт шартны үтәргә тиеш: «1) суның якын булуы; 2) сугыш кырының гаскәрне урнаштыру өчен уңайлы булуы; 3)дошман гаскәрен сугыш кырында берьюлы күрә алу мөмкинлеге; бигрәк тә кояш гаскәрнең каршында булмаска тиеш, чөнки бу хәл сугышчыларның күзен чагылдыра, күрү сәләтен киметә; 4)сугыш кыры киң һәм тигез булырга тиеш».

Шушы дүрт шарт үтәлгәннән соң орыш барышында нинди тәртип-кагыйдәләргә таянып эш итәргә кирәклеге Тимер бәк исеменнән бик тәфсилләп бәян ителә.

«Иртәгә сугыш буласы көнне яу башы сафларны уйланган план буенча төзеп чыгарга тиеш; билгеле тәртип буенча төзелгән гаскәр алга барганда, уңга да, сулга да тайпылмыйча, сафларны сакларга тиеш. Дошман күренү белән сафлардагы сугышчылар «Аллаһу әкбәр!» дип сөрән салырга тиеш.

Әгәр дә гаскәрдәге төп күзәтүче берәр бүлекчә башлыгының үз вазифаларын үтәмәвен күреп алса, ул аны

*аналитик әдәби тәнкыйть мәкаләләрен һәм яңа әсәрләрне, яңа авторларны күтәп алам. Афәрин!—журнал өметемне һәрдаим аклый. Соңгы елларда үзем өчен Факил Сафин дигән бик тә кызыклы һәм үзенчәлекле әдипне ачтым. Эльмира Шәрифуллинаның шушы елның март санында дөнья күргән, бөек мәгърифәтчебез Каюм Насыйрига багышланган «Каюм коесы» исемле поэмасы да күңелне кузгатты. Үзебезнең университет галим-мөгаллимнәре Фәрит Хатыйпов, Рифат Сверигин, Фоат Галимуллин, яшьләрдән Әлфия Мотыйгуллина белән Ләйлә Минһаҗеваларның журналда даими рәвештә әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән катнашуы күңелдә горурлык хисләре уята. Бездә белем алган яшь әдипләр Зиннур Хөснияр белән Марат Закирның әсәрләрен дә кызыксынып укыйм.*

*Яңа әсәрләр дигәннән, бүгенгедәй буталчык-авыр икътисадый вәзгыятьтә язган әсәреңне китап итеп чыгару да үзе бер проблемага әверелде ләбаса. «Казан утлары» исә (9—10 мең данәдә!) аны бушка чыгара, хәл кадәри каләм хакын (гонорарын) да вакытында биреп барырга тырыша. Хәзерге шартларда монысы да зур гамәл.*

*Мөгаллимнәр мәктәбе дигәннән, без «Казан утлары» журналын өйрәнүне татар филологиясе факультетының уку программасына берничә дәрес буларак кертергә ниятләп торабыз һәм ул аңа бик тә лаек.*

икенче кеше белән алыштыра ала. Бу очракта ул мин биргән хокукка таянып эш итә.

Яу башы төп күзәтүче белән берлектә дошман явының күләмен ачыкларга, анын коралын үз сугышчыларының коралы, офицерларын үз офицерлары белән чагыштырып карарга тиеш. Шулай дошманның көчлерәк ягын белергә, ә үз кимчелекләренне төзәтергә кирәк. Отрядынның эшен гел күзәтеп торырга—акрынтигез баралармы, әллә тәртипсез рәвештә чабалармы. Шулай ук дошманның һәр хәрәкәтен күзәтеп торырга тиешле: һөҗүмгә барысы да күтәрелдеме, әллә аерым отрядлар гына орышамы.Бу очракта иң кыены—дошманның һөҗүм башлау һәм чигенергә җыену мизгелен тотып ала белү; ул кабат атакага ташланачакмы яисә элеккечә дәвам иттерәчәкме. Әгәр дә орыш шулай дәвам итсә, сугышчылар ныклык сакларга тиеш, чөнки батырлык бит ул барыннан да бигрәк хәтәр чакта түземлек саклый белү.

Яу башының вазыйфалары нәрсәдән гыйбарәт? Гаскәрне идарә итү һәм хәтәр килгәндә югалып калмау. Аның әмер-хәрәкәтләре кыю, тәвәккәл булырга һәм ул үз идарәсендәге хәрби бүлекчәләргә коралның бер төре итеп карарга тиеш: әйтик, ук, балта, чукмар, хәнҗәр, кылыч, сөнге,—һәркайсын кирәк чакта кулланасын. Яу башы үзен хәрби бүлекчәләрдән торучы, төрле әгъзаларыннан чиратлашып файдаланучы көрәшче-баһадир итеп тоярга тиеш: менә ул көрәштә аягын, кулларын, башын, күкрәген, гәүдәсенең башка өлешләрен эшкә җигә. Дошманны төрле ысул-корал белән кысрыклый торгач, ахыр чиктә теге бирешергә мәҗбүр булачак.

Яу башы сугышны башлаганда бәрелешкә иң элек үзәк мангай кулны кертә, аннан ярдәмгә уң кул мангае белән сул кул мангаен кертә. Шулай өч һөҗүм ясый. Әгәр дә бу чара уңышка китермәсә, ярдәмгә уң канатның беренче дивизиясен, аннан соң сул канатның икенче дивизиясен кертергә кирәк. Болай да тулы өстенлеккә ирешелмәсә, уң канатның икенче дивизиясе белән сул канатның беренче дивизиясен орышка ташларга. Нәтиҗәләрен мина житкереп торырга...

Шулай итеп, ана сугышта, мавыгуларга бирелмичә, житез һәм төпле эш итәргә кирәк, чөнки акылсыз кыюлык—шайтан кызына тиң. Яу башы үзен чыгып булмастай авыр хәлгә төшүдән сакларга тиеш *(Тамерлан: эпоха, личность, деяния.—М.,—1992.—с. 152—153).*

Бу өзектән Тимер бәк дәүләтендә хәрби мәсьәләләрнең нинди югарылыкта торуы, аларга бик зур әһәмият бирелүе ачык күренә. Башкача була да алмый, чөнки Сәмәрканд әмире төзегән дәүләтнең төп эшчәнлеге яулар алып бару булган, икътисады да чит илләрне талау, матди байлыкларны тартып алу, һөнәр ияләрен Мәвараэннәһергә куып китерү, алар көче белән үз тормышынны көйләүгә, матур калалар салуга, су үткәргеч каналлар казуга, гүзәл бакчалар утыртуга корыла.

Әмма вакыйгаларга әйләнеп кайтыйк. Татар йөрәгендә тирән җәрәхәт калдырган Кондырча сугышы 1391 елның 18 июнь иртәсендә башлана. Шушы иртәдә ике коточкыч зур яу йөзгә йөз килеп баса. Бу көн тарихыбызда зур фаҗига көне буларак искә алынырга лаеклы. Бу иртәдә ерак бабаларыбыз ватаннары Идел-Йортны килмешәк дошманнан саклап калу өчен рәхимсез орышка кергәннәр, туган ил туфрагына аларның изге каннары тамган.

Сугыш Алтын Урда гаскәренең көчле һөҗүме белән башланып китә. Күрәсең, күпме вакыт чигенеп, дошман белән очрашуны тартып-сузып килгән Туктамыш ханның илбасар Сәмәрканд әмиренә сабак бирәсе, үзен шундый хәлгә төшергәне өчен аннан тизрәк үч аласы килгәндер. Орыш башында ук татарлар, Тимер бәк явын ике яктан әйләнеп узып, аның артына төшәргә омтыла. Чыннан да, бераздан Туктамыш ханның сул кул көчләре дошманның уң канатын әйләнеп уза, Сәйфетдин хажи идарә иткән гаскәрнең артына төшә. Күп тә үтми Тимер бәкнең сул канатында да шушы ук хәл кабатлана. Татар гаскәренең һәр омтылышын Тимер бәккә житкереп торалар. Шулай ана бөтенләй камалышта калу ихтималы яный башлый. Эшләр болайга китсә, орышны Туктамыш ихтыярына бирүен дә бар.Ә инде татарлар гаскәренне төркемнәргә бүлгәли башласа, эшләр бөтенләй харап. Туктамыш хан исә бу вакытта «үзәкне дә, ике канатны да тулы тәртиптә тота».

Бер унайдан чыганакларда күзгә чалынган кызыклы хәбәрне дә китереп үтәсе килә. Сугыш кызган чагында Тимер бәк үз оныгы Әбүбәкер мирзага, 8000

кешелек отряды белән,орышкан гаскәргә аш әзерләргә боера. Бу эш татар гаскәре күз алдында махсус башкарыла. Тимер бәк уенча, сугыш кызган чакта учаклар терзегеп җибәрү, казаннар асу гаскәрнең ныклыгын, дошманнан курыкмавын, җиңүгә нык ышануын күрсәтергә тиеш була. Бу чара дошманга ничек тәэсир иткәндер—билгесез, тик Тимер бәкнең үз сугышчыларында ышаныч һәм өмет уятмый калмагандыр, шөт. Сәмәрканд әмире бәрелеш вакытында менә шундый нәрсәләргә дә игътибар иткән, җиңү өчен һәр мөмкинлектән файдалана белгән.

Тимер бәккә татарларда бердәмлек җитмәү дә нык ярдәм итә. Бу сугышны тасвирлаган тарихчылар татарлар лагеренда өлгереп җитешкән хыянәт җимешләренең берәм-берәм тугрылык агачыннан коела башлавы хакында язалар. Инде әйтеп узылганча, Туктамыш ханга барлык олыслардан да тиешле ярдәм килеп җитми. Шул сәбәпле ул көткән хәтле гаскәр туплый алмый. Вакыйгалар уйлаганча барса, Алтын Урда гаскәре ишлерәк тә буласы икән. Олыслардан сонарып килгән кайбер бәкләрнең туп-туры Сәмәрканд әмире корган ятьмәгә килеп керүен искәртеп узган идек. Шулай ук яу кырына чакырылган Мәскәү кенәзе Василий Дмитриевич та (Дмитрий Донскойның улы Василий) ханга хыянәт итә. Сугыштан коты очып, Ул Рязань һәм Суздаль җирләрен әйләнеп уза да Дон аръягына кача. Тик язмыш шуклыгы олуг кенәзне Дон далалары урынына Киев каласына китереп чыгара. Яллаган юл күрсәтүчеләр далада адашалар. Ә Киев бу вакытта Литва кенәзе Витовт кулында була. Витовтның исә күптән Мәскәү кенәзлегенә күзе кыза, ул Василий Дмитриевичны асыл тоткын итеп үзендә калдыра. Киевтән исән-сау котылу өчен олуг кенәзгә Витовтның Софья исемле кызына өйләнүдән башка чара калмый *(Гумилев Л. Н. Древняя Русь и Великая степь—М., 1989).*

Хыянәт агачының икенче ботагы Идегәй мирза кулында була. Мангытлар ханны ташлап китәләр. Дөрес, мангытлар сан ягыннан әллә ни күп булмаска да мөмкин. Тик орыш вакытында гаскәр эчендә хыянәт башлану бер дә рухны ныгыта торган нәрсә түгел. Бу психологик фактор. Үлемгә барганда бер-берене ышаныч киму дигән сүз. Бу хәлдән дә дошман бик оста файдаланган булса кирәк. Аннан соң Тимер бәкнең Туктамыш хан байракчысын сатып алуы, тегенең байракны төшерүе. Монысы инде бөтенләй аркага пычак кадау. Хан байрагының юкка чыгуы татар гаскәренә ничек тәэсир итәчәген дә алдан уйлап куйган була Тимер бәк.

Ләкин сугышның башында Алтын Урда гаскәре Тимер бәкне дә шактый авыр хәлдә калдыра. Әлбәттә, 600 ел элек булган сугышны бөтен ваклыклары белән күз алдына китерүе мөмкин түгел, чөнки аның хакында тулы мәгълүмат юк. Шулай да тарихчы Ибне Гарәбшаһ теркәп калдырган бер вакыйга бу орышка бераз ачыклык кертә, аны икенче яктанрак ачып җибәрә шикелле. Тарихчы сүзләренчә, сугышның бер мәлендә Тимер бәк, гаскәрем тар-мар ителә дип, өметсезлеккә дә бирелә башлый. Шул чакны гомерен җиһангир белән бәйләгән, әле 1370 елда ук, Тимер бәккә хакимият символы булган байрак белән барабан бүләк итеп, ана данлы киләчәк юраган Бәрәкә сәед аның янына килеп туктый. Тимер бәк ана: «Аһ, мөхтәрәм сәед, гаскәрем юкка чыга бит!»—дип кайгылы тавыш белән әйтеп куя. Моңа каршы Бәрәкә сәед: «Син курыкма»,—ди, атыннан төшеп, җирдән бер уч вак таш ала. Кабат иярена сикереп менә дә, атын дошманга таба борып, кулындагы ташларны татар явына таба ыргыта, көчле тавыш белән: «Ягы качды, ягы качды!» («Дошман качты!») дип сөрән сала.

Бәрәкә сәеднең сөрән салуы өметсезлеккә бирелә башлаган Тимер бәккә шундый нык тәэсир итә ки, ул да ана кушылып тагын да көчлерәк тавыш белән: «Ягы качды! Ягы качды!»—дип кычкырып җибәрә.

Бу хәл ике гаскәрнең канга батып орышкан чагына туры килә. Татарлар инде Тимер бәк гаскәренең сафларын өзә дә башлаган була. Тик җиһангирның гайрәтле тавышы сугышчыларның өметен янарта, аларга көч-кодрәт өсти, гаскәр дәррәү күтәрелеп кабат һөҗүмгә ташлана. «Гаскәрдә «ягы качды!» дип кычкырмаган бер генә кеше дә калмагандыр,—дип яза бу хакта Ибне Гарәпшаһ.—Алар тагын бергәләшеп һөҗүмгә ташландылар һәм кумәкләшеп, хискә бирелеп, дошманны кысрыкладылар. Туктамыш (хан) гаскәре чигенергә, качарга мәҗбүр булды.Моны күреп Аксак Тимернең качарга җыенган сугышчылары кире әйләнеп кайтты, чигенгән татарларны эзәрлекләргә керешә. Аксак Тимернең гаскәре аларны

кылычтан үткәрде...» *(Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов..., т. I, с. 456—457).*

Тарихчы вакыйганы менә шулай теркәп калдырган. Әлбәттә, аның нәкъ шулай булуын төгәл генә әйтеп булмый. Ләкин кайчакта бер кешенең талпынуы да гаскәрне һөҗүмгә күтәрү өчен җитә кала. Андый очраклар тарихта билгеле.

Шулай итеп Тимер бәк гаскәре һөҗүмгә ташлана, өстенлек дошман ягына күчә. Туктамыш хан исә, хәлнең авырайганын күреп, бәкләрне, мирзаларны киңәшмәгә җыя. Алардан: «Нишлибез?»—дип киңәш сорый. Ләкин соравына юньле җавап ала алмый. Күбесе ык-мык итә. Кайбер бәкләр ана урманга кереп яшеренергә киңәш итәләр. Башка сыймаслык хәл: хәлиткеч орыш барганда, хан гаскәр күз алдында торырга тиешле чакта аны сугыш кырын ташлап китәргә үгетлиләр, ягъни бәкләр җиңүгә ышанмый, ханны тизрәк озатып, үзләренә дә качып китәргә җай-җирлек әзерлиләр. Ә Туктамыш хан бит сукыр түгел, ул барысын да сизеп-күреп торган. Димәк, хәтәр килгәндә аның таяныр кешесе калмаган. Сонрак, Литва кенәзе Ягайлога язган хатында, ул бу сугышны телгә алачак, «хыянәтчеләрнең мине ташлап китүе аркасында халык та миннән китеп барды», диячәк. «Халык» дигәне—төрле ырулардан торган гаскәрне аңлата. Ә хыянәтчеләр шул ук затлар—Бирдебәк углан, Тордычык бирде, Давыт бәк, Хуҗаметдин, Тәгин бәк—Идегәй мирза тарафдарлары, ханга каршы оппозициядә торучылар, элегрәк ана каршы фетнә-заговор оештырган кешеләр. Идегәй мирза бит шул заговор фаш ителгәч Сәмәркандка качып китте. Ә дуслары Сарайда калды. Вакытлыча койрыкларын кыстылар, хан хезмәтендә йөри бирделәр. Үзләре исә Туктамыш ханга зыян салырга җай эзләделәр. Менә андый көн килде. Посып яткан хыянәт Кондырча буенда кабат башын күтәрде.Бер тән, бер җан булып дошманга каршы орышасы урында Туктамыш ханны урманга кереп качарга кыстыйлар. Хан китсә, үзләренә дә качу җиңелрәк, өстән җаваплылык төшә. Ә Бикбулат углан ханның китүен дә көтеп тормый, сугыш кырын ташлап кача, үзе белән сугышчыларын да алып китә. Ул бит—ханга иң якын торган кешеләрдән.Бикбулат углан аркасын күрсәткәч, гаскәрнең күңеленә шом кереп урнаша, сафларнын бер-берсенә ышанычы бетә. Бу инде, чыннан да, җиңелү дигән сүз.

Ничарадан бичара Туктамыш ханга һөҗүмгә күчкән дошман кулына эләкмәс өчен бәкләрнен сүзенә колак салырга, урманга кереп яшеренергә генә кала. Хан китә, ул китү белән бу хакта шундук дошманга—Тимер бәккә хәбәр итәләр *(Сафаргалиев М. Г. Распад Золотой Орды...—С. 155).* Менә нинди ул татар?! Бер-беренә аяк чалу, көнләшү, бер-беренне ашау—бүгенге тормышыбызга да хас сыйфатлар түгелме? Шушы сыйфат татарда гасырлар буе дәвам итә. Шушы гадәте аркасында татар беткә үч итеп тунын яндыра килә. Икенче төрле итеп әйтсәк, гомуми мәнфәгатьләренә каршы килсә килә, тик татар татарны алга чыгармый, үстерми, күтәрелергә, ныгырга ирек бирми. Аннан соң аптырап үзенә сорау бирә: без нигә алга китә алмыйбыз? Нигә һаман кеше хезмәтендә? Нигә мөстәкыйль түгелбез? Нигә дөньяда хуҗа булып яшәмибез? Сәбәп үзебездә, җәмәгать, милли сыйфатыбызда, дошманны читтән эзләмик. Дошман эчебездә утыра һәм... безне үртәп көлә, көлә...

Шулай итеп, сугыш башында Тимер бәкне ике яктан китереп кыскан, хәтта артына да төшкән татар гаскәре хыянәтчеләрнең астыртын эш йөртүләре аркасында орышның язмышын дошман кулына тапшыра. Инде чигенгән татар гаскәре артында киң Идел җәелеп ятса, алдында—күп яуларда чыныккан тәҗрибәле дошман торып кала. Бу очракта Тимер бәкнең нинди тактика куллануы, нинди маневрлар ясавы шул ук «Төзек-и Тимер»дә чагылыш тапкан. Мөмкин булган барлык чаралар күрелгәннән сон да сизелерлек унышка ирешелмәсә, Тимер бәк аларның соңгысын һәм иң нәтиҗәлесен эшкә җигә торган булган—андый чакта «резервтагы уң кул белән идарә итүче бәкләр-мирзалар һәм җиһангирнын туганнары идарәсендәге резервта торучы сул кул дошман өстенә ташланырга тиеш. Аларның бөтен игътибары дошманның яу башы белән аның байрагына юнәлгән булырга тиеш—дошман сафларына баһадирларча һөҗүм итү кирәк. Аларның төп максаты дошманның яу башын кулга төшерү һәм байрагын аударудан гыйбарәт. Шундый һөҗүмнән соң да дошман каршылык күрсәтсә, ул чакта чират урта кулда тупланган сайланма гаскәргә, аның артында төзелгән баһадирларга җитә. Алар күмәкләшеп

алга ташланырга, дошманны сытып узарга тиешләр. Шушы чаралардан соң хан үзе дә баһадирларча ныклык күрсәтеп орышка ташланырга тиеш... Шушы принципка таянып, мин Туктамыш ханны җиңүгә ирештем һәм аның байрагын бәреп төшердем» *(Тамерлан: эпоха, личность, деяния.—М.—С. 156).*

Сугыш өч көн дәвам итә. Дошман ашкынып һөҗүмгә күчкәннән соң да татар гаскәренең каршылыгы көчле булган, күрәсең. Бу сугышта татарлар 100 меңгә якын кеше югалта. Ә бит сугыш кырында ятып калучылар безнең ерак бабаларыбыз—Идел, Дон, Азак дингезе буе, Болгар олысы төркиләре. Үзбәкләрнең тел шартлатып сөйли торган данлы вә шанлы җиһангире Тимер бәк Идел-Йорт халкына менә шундый һәлакәт, зыян сала.

Әлбәттә, Тимер бәк гаскәре дә бик күп кеше югалта. Нәкъ шул сәбәпле ул Иделнең уң ярына чыгудан баш тарта, татар гаскәрен куа китми. Димәк, аларда да көч беткән булган. Юкса, Идел буйлап бераз төшсән, анда Сарай, Әстерхан кебек төзек калалар җәйрап ята. Тимер бәк анда барырга да җөрьәт итми. Ул белә—татар дәүләтенең потенциалы әле җитәрлек. Татар—үз илендә, аның өстенә кабат барсаң, көч җыеп өлгерүе, арт сабагыңны укытуы да бар. Шуңа күрә ул яуны дәвам иттерми.

Моның икенче сәбәбе дә бар—салкын көзләр җиткәнче өйгә кайтып өлгерергә кирәк. Җылы чакта коры далаларны үтү хәерле. Шуңа күрә ул башта Идел буенын гүзәл табигатендә гаскәрен ял иттерә. Җиһангир үзе Иделнең Үртүбә дип аталган бер атавында урнаша (болай куркынычсызрак!). Гаскәре 26 көн дәвамында үзен рәткә китерә—яралылар дәвалана, сынган-ватылган һәр нәрсә төзәтелә. Бер үк вакытта планлы рәвештә Идел буен талау эше алып барыла. Тирә-юньгә таралышкан аерым отрядлар күпләп ат, дөя, сыер, куй көтүләре куып алып кайталар, авыллардан кызларны, бала-чаганы, үсмер егетләрне җыялар, хәтта Иделнең һәр атавын айкап-тикшереп чыгалар, анда качып яткан халыкны да кол итеп куып китерәләр. Шул заман тарихчысы сүзләренчә, «мона хәтле данлы Урдада *(Тимер бәк урдасында.—С. Ш.)* үзләренә көчкә туеныр ризык тапкан кайбер адәмнәрнең җылкылары белән куйлары шул кадәр ишәйде ки, кайтыр юлда әлеге малларны куып алып барырга көчләре җитми башлады... Шуңа күрә бер өлешен генә алып китәргә, ә бер өлешен ташлап калдырырга туры килде... Тимер (бәк) урдасында хур кызларыдай гүзәлләр һәм чибәр егетләр шул кадәр күп җыелды, Тимернең үзенә дип сайланганнарының саны да 5 меңнән артып киткән иде» *(Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов...,—т. II.—С. 172).* Башка бер чыганак күрсәтүенчә, Тимер бәк бу яуда 4 млн. куй, 40 мең мөгезле терлек, 500 мең ат һәм 500 мең кешене кол итеп куып алып киткән. Дөрес, бу саннар башка чыганаклар белән расланмый. Бәлки, талау кимрәк тә булгандыр. Әмма теркәлеп калган бит.

Бер ай мародерлык кылганнан соң Тимер бәк явы белән килгән Урта Азия ырулары талап җыйган байлыгын, күп санлы колларын, иксез-чиксез көтүләрен куалап юлга кузгалалар. Бу хәл 17-18 июль тирәләрендә була. Бу көнне чал Идел ярлары елау авазлары белән тулгандыр. Газиз балаларының коллыкка озатылуын күреп торган кыпчак-татар даласы үксегән-сыкрагандыр. Тарихыбыздагы бу дата ел саен кайгы көне буларак билгеләп үтелергә тиеш иде ләбаса. Ә хәтерсез татар аны белми дә. Хәер, күп шул бездә андый даталар, артык күп. Бай ул татарның тарихы, артык бай. Бәлки шуңа кадере юктыр...


*Дәвамы киләсе санда*

Kitap küzətü
Китап күзәтү

# ТӨРЕК ТЕЛЕ АША– ЗУР ТӨРКИ ДӨНЬЯГА

Төркиләр борынгы заманнарда ук үз дәүләт оешмаларын һәм югары мәдәниятләрен тудыруга ирешкәннәр. Бигрәк тә аларның авыз иҗаты һәм язма әдәбият әсәрләре ифрат бай, гүзәл булулары белән башка халыкларның да игътибарын җәлеп иткән, еш кына алар өчен дә рухи азык, иҗади өлге булып торган. Элек-электән үк төркичә әсәрләрне башка телләргә тәрҗемә итү киң таралган күренеш булган.

Әлбәттә, төрки телләрдәге әдәбият хәзинәләре бүгенге көндә дә дөнья мәдәниятенең зур һәм кыйммәтле өлешен тәшкил итә. Аларны башка халыкларның да рухи казанышына әверелдерү хәзер дә үзенең актуальлеген саклап кила. Бу чит милләтләр өчен генә түгел, хәтта төркиләрнең үзләре өчен дә шулай. Чөнки дөньяда кырыктан артык төрки халык исәпләнә һәм аерым очракларда аларның телләре бер-берләренекеннән шактый ук аерылып тора.



Менә шул даими ихтыяҗны истә тотып, узган XX йөзнең туксанынчы еллары башында Төркиянең мәдәният министрлыгы төрки халыклар фольклорының һәм язма әдәбиятының иң яхшы үрнәкләрен туплаган 40 томлык Антология төзеп бастыру эшенә керешә. Томнарда материалны урнаштыруның мондый ысулы кулланыла: һәр сәхифә ике баганага бүленә. Сул якта, латин хәрефләренә күчерелеп, теге яки бу төрки телдәге әсәрнең оригиналь тексты басыла, ә янәшә баганада исә аның төрекчәгә тәрҗемәсе китерелә. Монда «Ни өчен төрек теле?» дигән сорау тумыйдыр дип уйлыйбыз. Чөнки, беренчедән, бу Антология төрек әдипләре, галимнәре, педагоглары, шәкерт-студентлары өчен, аларны Төркиядән тыштагы башка төрки халыкларның әдәбият хәзинәләре белән таныштыру максатында чыгарыла. Икенче яктан карасак, гасырлар буе мөстәкыйль дәүләт булып яшәүче, иҗтимагый, сәяси, икътисадый һәм мәдәни яктан зур алгарышка ирешкән Төркия җөмһүрияте төрки дөньяның бәхәссез лидеры булып тора, ә төрек теле исә барлык төркиләр өчен бер-берләренең һәм башка халыкларның әдәби байлыклары белән танышуда арадашчы тел булып хезмәт итә. Әйтик, XIX гасырда һәм XX йөз башында татар язучыларының иҗатында Көнчыгыш кына түгел, бәлки Европа (бигрәк тә француз) әдәбиятыннан төрекчәгә тәрҗемәләр мөһим роль уйнады. К. Насыйриның «Әбүгалисина», «Гөлрәх вә Кәмарҗан»нары нәкъ менә төрекчәдән ирекле тәрҗемәләр булып торалар...

Антология проектын гамәлгә ашыручы генераль редактор итеп танылган тюрколог Нәүзәт Көсоглу, ә баш киңәшче вазифасына доктор-профессор Әхмәт Эрҗиласун билгеләнү эшнең уңышлы башланып китүенә зур этәргеч бирде. Татар халык иҗатының һәм әдәбиятының гаять бай һәм күпкырлы булуын исәпкә алып, алар безгә Антологиянең өч томын тәгаенләделәр. Бу томнарга җитәкчелек итү Төрек тел корумының шәрәфле әгъзасы, академик Мирфатих Зәкиевкә тапшырылды.

Казанда уздырылган сөйләшү-киңәшүләр нәтиҗәсендә, әлеге өч томның берсен

тулысы белән фольклорга, икесен язма әдәбиятка багышларга дигән карар кабул ителде. Беренче томны әзерләү эшенә күренекле фольклорчы профессор Фатих Урманче, ә икенче, өченче томнарны төзүгә әдәбиятыбызның зур белгече, Татарстан фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы Нил Юзиев алындылар. Мирфатих Зәкиев исә гомуми житәкчелек итү белән бергә татар халкы турында зур кереш мәкалә язарга да тиеш булды. Эш шактый кызу тотылды: 1993 ел азагында өч томның да материаллары Антология редакциясенә барып ирештеләр.

Тагын бер кат басым ясап әйтергә кирәк, Төркия галимнәренә һәм наширләренә гаять күләмле һәм катлаулы эш йөкле бу Антология. Күз алдына китерегез: һәркайсы 50 басма табактан торган 40 том! Төрле телләрдә һәм алфавитларда язылган 2000 басма табак текст дигән сүз бит бу. Аларны латин алфавитына күчерергә, төрекчәгә тәрҗемә итәргә, жыярга, макетларга салырга һәм, ахыр чиктә полиграфик яктан бик зиннәтле итеп башкарылган зур форматлы калын-калын китапларга әверелдерергә кирәк. Һәм менә бу эш инде үзенең экваторын узып бара: Анкарада Антологиянең 20 томы дөнья күрергә өлгерде. Шулардан 17, 18, 19 санлылары—татар әдәбияты томнары. Алар өстәмә рәвештә I, II, III дип тә билгеләнгән. Болары инде китапларның үзебезгә генә кагылган эчке бүленеше.

Алдан шуны искәртеп үтик: зур булмаган бу күзәтүдә томнарның эчтәлеген анализлау түгел, ә журнал укучыларны аларда нинди материаллар, кайсы авторларның нинди әсәрләре урын алуы белән таныштыру максаты гына күздә тотыла.

Унжиденче том академик М. Зәкиевнең татар халкы турындагы зур мәкаләсе белән ачыла. Аның беренче бүлекчәсе «Әдәбият, тел һәм тарих» дип исемләнгән һәм ул бөтен тикшеренүнең үзәк проблематикасын билгели. Автор төрки дөньяны татар халкының исем-атамалары һәм аларның этимологиясе, татарларның тарихи яшәү урыннары, Идел-Уралдагы жирле тамырлары, дәүләтчелек тарихлары (бигрәк тә Идел Болгарстаны, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорлары) белән таныштырып үтә. Әлбәттә галим халкыбызның килеп чыгышы мәсьәләләрен гомумтөрки яссылыкта аңлата, бик борынгы чорларга караган язма чыганакларга таянып, скиф-сарматлар, алан-аслар, хуннар, хазарлар, кыпчаклар, болгарлар һ. б. кавем-кабиләләрне тоташтыра торган тарихи бер чылбыр төзеп күрсәтә. Мәкаләдә татар халкының Русия империясендәге, Совет дәүләте чорындагы тормышын, милли бәйсезлек өчен көрәшен чагылдыруга да урын бирелә.

Татар халкының фольклор һәм язма әдәби телләре тууын, үсешен М. Зәкиев шулай ук киң тарихи планда, V—VIII гасырлардагы Орхон-Енисей ташъязмаларында ук кулланылган борынгы төрки әдәби тел белән бәйләнештә яктырта, бүгенге татар теленең функциональ кулланылышы хакында сөйли. Бу күп планлы кереш мәкалә һичшиксез, безнең фольклор һәм әдәбият хәзинәләребезне тел, тарих жәһәтеннән тирәнрәк аңлау өчен дә үзенчәлекле ачкыч ролен үти. Әлеге томнарга төзүчеләр язган кереш мәкаләләргә органик рәвештә ялганып тора ул.

Том «Татар халык әдәбияты» дип атала. Бу—халык авыз иҗатының бездә Тукайлар заманында кулланылган төп исеме. Төрекләрдә ул хәзер дә саклана. «Халык әдәбияты» дию фольклорның язма әдәбияттан күпкә борынгырак булуына ишарә итә Фатих Урманче үзенең кереш мәкаләсендә фольклорның, һәрхәлдә аның кайбер жанрларының, мәжүсилек заманнарында, мифологик карашлардан үсеп чыгуы хакында яза. Томда материалларны урнаштыруда да ул шушы хронологик тәртипне саклый: аларны мәжүсилек һәм борынгы чор шигъри сүз үрнәкләре белән башлап жибәрә Монда «Зыяндаш теле», «Очан теле», «Зәхмәт теле», «Бизгәк теле», «Ут теле», «Елан теле» кебек ырым-арбаулар китерелә Алар артыннан ел фасыллары белән бәйле булган нәүрүз, нардуган такмаклары, «Кояш, шаһит бул», «Янгыркаем, яу, яу, яу», «Жир, жир, көчем бир» кебек келәүләр, сөрән салулар килә Бу текстлар барысы да «Йола һәм уен жырлары» исемле зур бүлектә урын алганнар. Татар халкының кайбер этник төркемнәрендә (бигрәк тә мишәрләрдә) XX йөз башларына кадәр актив яшәештә булган «Ячы такмаклары», «Кыз елату», «Тудыкайлар», «Ишек бавы», «Яр-яр» жырлары, туй мәжлесе вакытында кодаларны, яшьләрне мактау-макташу («Без туганыйны сезгә бирдек», «Ямьнәр керсен кода йортына», «Берегез алтын булса, берегез көмеш»), бирнә сорау, килен төшерү жырлары татар халкының бик уникаль гореф-гадәтләрен гәүдәләндергән, нигездә инде язмада гына саклана торган гүзәл шигъри хәзинә тәшкил итәләр. Бу бүлек безнең көннәрдә дә репертуардан төшмәгән «Ак калач», «Күгәрчен», «Жимчәчәк», «Сөясенме, сөймисенме», «Челтәр элдем читәнгә»

кебек уен җырлары, шулай ук «Әпипә», «Әнисә», «Бас, бас эзенә» һ. б. ш. популяр бию такмаклары белән тәмамлана.

Томның нәүбәттәге бүлеген халык прозасы—әкиятләр алып тора. Үзенең алда телгә алынган кереш мәкаләсендә Ф. Урманче татар халык иҗатының генетик тамырлары, борынгы һәм бүгенге заманнардагы функцияләре, тематик һәм шигъри үзенчәлекләре хакында шактый тәфсилле яза. Ә инде аерым бүлекләрне ачып җибәргәндә ул теге яки бу жанрга конкретрак характеристика биреп үтә, текстлар алынган чыганакларны күрсәтә. Мондый өстәмә мәгълүматлар әкиятләр буенча да китерелгән. Текстлар бүгенге фәндә кабул ителгән төркемләү нигезендә «Хайваннар турындагы әкиятләр», «Тылсымлы әкиятләр», «Гыйбрәтле әкиятләр» дигән бүлекчәләрдә урын алганнар. Арада халкыбызның «Ак бүре», «Ак елан», «Елан патшасы Шаһмара», «Зөлкарнәйн патша» кебек бик үзенчәлекле һәм популяр әкиятләре дә булуын канәгатьләнү белән билгеләп үтәсе килә.

Фольклор прозасы әсәрләренең икенче зур төркемен риваятьләр, легендалар һәм мифологик хикәятләр тәшкил итә. Томда без аларның да иң яхшы үрнәкләре белән танышабыз. Анда бигрәк тә риваятьләр зур урын алып тора. Алар «Болгар чоры», «Казан ханлыгы чоры», «Социаль һәм милли изүгә каршы көрәш», «Татар мәгърифәтчеләре», «Себер татарлары тарихы», «Авыл тарихлары», «Топонимик риваятьләр», «Көнкүреш риваятьләре» дигән бүлекчәләрдә бирелгәннәр.

Бер генә фольклор антологиясенең дә афористик жанрлардан башка дөнья күргәне юк шикелле. Мәкальләр һәм бүтән хикмәтле сүзләр гомер-гомергә халык өчен акыллы киңәшче, үгет-нәсихәт бирүче ролен үтәп киләләр. Табигый ки, бу Антологиядә дә халык афоризмнарына җитди игътибар күрсәтелгән. Алар соңгы вакыттагы яңа бүленеш буенча (мәкальләр, әйтемнәр, алкышлар, каргышлар, антлар, әзер җаваплар, сынамышлар, ышанулар яки юраулар, табышмаклар) урнашканнар.

Безнең фольклорыбызның төп компонентларыннан берсе—халык эпосы. Ф. Урманче үзенең томында бу төр иҗатка хаклы рәвештә зур урын бирә, дастаннар, мөнәҗәтләр, бәетләрнең югары сәнгать дәрәҗәсендәге үрнәкләре белән таныштыра («Түләк», «Идегәй», «Җик Мәргән», «Чура батыр», «Таһир илә Зөһрә», «Шәһре Болгар бәетләре», «Казан бәете», «Урта Тигәнәле бәете», «Суга баткан Гайшә бәете», «Сак-Сок бәетләре» һ. б., һ. б.).

Тема-эчтәлек, шигъри төзелеш җәһәтеннән бәет-мөнәҗәтләргә тарихи җырлар бик якын тора. Бу жанр бездә әле соңгы елларда гына (һәм нигездә Ф. Урманче хезмәтләрендә) мөстәкыйль төстә карала башлады. Төзүче томда да мондый әсәрләрне аерым бирә: алар җырлар бүлеген ачып җибәрәләр *(«Болгар иленең кызлары», «Шәһре Кашан», «Тоткын Сөембикә җыруы», 1812 елгы Ватан сугышы турындагы җырлар, «Хәмидулла качкын» һ. б.).*

Татар халык иҗатының тирән фәлсәфи уйлануларга, хис-кичерешләргә, дәрт-моңга, шигъри бизәкләргә иң бай өлкәсе—лирик җырлар. Һәм аларда тормыш-яшәешнең нинди генә яклары искә алынмый: туган ил, туган як; социаль тормыш, хәсрәтле дөнья; чит җирләрдә бәхет эзләү; гомер агышы, яшәү кадере; хатын-кыз язмышы; мәхәббәт, дуслык, туганлык һ. б., һ. б. Шушы темалары буенча гына да Антологиядәге җырларыбызда гаять зур рухи хәзинә, шигърият тупланган булуын ачык күзаллап була.

Халык иҗаты томы мәзәкләр белән тәмамлана. Бу хронологик тәртипкә һич тә каршы килми, чөнки мәзәк бүгенге көннең бик актив жанры булып тора. Бер кызыклы факт: китапның иң ахырында—Хуҗа Насретдин мәзәкләре. Бу персонаж исеме белән бәйләп сөйләнелә торган мәзәкләр безгә нәкъ менә төрек әдәбияты аша килеп керде. 1845 елда Казанда, төрек теленнән тәрҗемә ителеп, «Ләтаиф Хуҗа Насретдин әфәнде» дигән җыентык дөнья күрә. 124 ләтифаны (мәзәкне) эченә алган бу китап 1881, 1890 елларда тагын ике мәртәбә басыла, андагы әсәрләр тиз арада фольклорлашып китәләр. Бүген, 160 елга якын вакыт узганнан соң, алар яңадан төрек укучысына әйләнеп кайтты.

Инде искәртелгәнчә, Антологиянең 18 һәм 19 томнары язма әдәбият әсәрләреннән төзелгән. Алар—XIII-XX йөзләрдә, ягъни 800 ел вакыт дәвамында иҗат ителгән рухи хәзинәләр. Томнарның беренчесе нигездә Урта гасырлар ядкарьләрен эченә ала. Үзенең кереш мәкаләсендә Нил Юзиев Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорлары, XV йөз урталары—XVIII йөз урталары әдәбиятына тирән һәм тәфсилле анализ бирә. Текстларны ул атаклы шагыйребез Кол Галинең Идел буе болгар-татар әдәбиятының чишмә башы санала торган «Кыйссаи Йосыф» поэмасы

белән ачып җибәрә. Аннан хронологик тәртиптә Сөләйман Бакыргани, Рабгузи, Котб, Мәхмүд Болгари, Хәрәзми, Хөсәм Кятиб, Сәйф Сараи, Кол Шәриф, Саяди, Суфи Аллаһияр, Габди һ. б. авторларның әсәрләре китерелә. Мөхәммәдьяр, Мәүлә Колый, Габдерәхим Утыз-Имәни кебек зур шагыйрьләр иҗаты томда шактый ук тулы күрсәтелгән. Төзүче һәр авторның тәрҗемәи хәле, иҗаты турында кыскача мәгълүматлар да биреп барган.

Әлегә кадәр атап үтелгән әдипләр һәм аларның әсәрләреннән шул ачык күренә: безнең борынгы әдәбиятыбызның төп асылын, төп казанышларын күренекле шагыйрьләр иҗаты билгели. Саф чәчмәдә генә язылган әсәрләрнең җитди үрнәкләрен, мөгаен, Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис»е һәм Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия»се *(«Пәйгамбәрләр тарихы»)* белән чикләп буладыр. *(Әмма соңгы автор үзе Антологиягә шагыйрь буларак кергән.)*

Инде XVIII һәм бигрәк тә XIX йөзләргә килсәк, бу чорларда әдәбиятыбызның реалистик юнәлештә зур үсеш кичерү белән бергә, жанрлар ягыннан да шактый ук төрләнүен күрәбез. Дөрес, әйдәп баручы ролен поэзия һаман саклап килә. Антологиядә Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Габделҗаббар Кандалый, Шәмсетдин Зәки, Мифтахетдин Акмуллалар шигъриятенә тиешле игътибар күрсәтелгән. Бу бүлеккә төзүче тарафыннан язылган «Яңа дәвер татар әдәбияты (XVIII-XIX йөзләр аралыгы)»исемле керештә дә әлеге шагыйрьләрнең иҗаты югары бәя тапкан. Хәлбуки бүлекнең эчтәлеген «Каһарман китабы», «Мәҗмугыл хикәят», «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе», Батырша «Гарызнамә»се, Каюм Насыйриның «Кырык вәзир»е, Фатих Халидинең «Мең дә бер сәхәр»е, Габдрахман Ильясиның «Бичара кыз»ы, Заһир Бигиевнең «Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә»се кебек әсәрләр *(төгәлрәге: алардан китерелгән өзекләр)* бик нык баеталар. Соңгы ике әсәр татар әдәбиятында драма һәм роман жанрларының уңышлы башлангычы булып тора.

18 томның соңгы өлешендә Гаяз Исхакыйның «Шәкерт абый» хикәясе белән XX йөз әдәбиятына күчеш ясала. Монда укучылар Шәриф Камал, Фатих Әмирхан, Мәхмүт Галәү, Галимҗан Ибраһимов, Гали Рәхим, Шамил Усманов, Кави Нәҗми, Афзал Шамов, Гомәр Бәширов, Гадел Кутуй, Әхмәт Фәйзи, Ибраһим Гази, Фатих Хөсни, Габдрахман Әпсәләмов, Ибраһим Салахов кебек күренекле проза осталарының иҗат үрнәкләре белән танышалар.

Шуннан соң XX йөз әдәбияты Антологиянең 19 томында дәвам иттерелә. Төзүче Нил Юзиев гасыр башы һәм совет соры әдәби процессларын «Яңа заманда яңа әдәбият» дигән кереш мәкаләсендә күп төрле яклардан анализлап чыга. Аннан мәйдан авторларның үзләренә бирелә. Менә Дәрдмәнд: «Шагыйрьгә», «Кораб», «Без», «Бүзләрем маналмадым», «Яз», «Видаг» һ. б. шигырьләре; Газизә Сәмитова: «Син елама, яшь туташ»; Галиәсгар Камал: «Беренче театр» *(өзек)*... Шушы рәвешчә байтак сәхифәләрдә шигырь һәм драма нәүбәтләшеп килә. Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Кәрим Тинчурин; Зариф Бәшири, Гыйффәт Туташ, Шәехзада Бабич, Мирхәйдәр Фәйзи... Иң зур урын, әлбәттә, Тукайга бирелгән: 18 бит,41 шигырь. Өстәвенә аның иҗатына Нил Юзиев кереш мәкаләдә дә байтак туктала. Шул рәвешчә шагыйрьнең бөеклеге Антология укучылары алдында шактый тулы булып ачыла.

19 томның күпчелек сәхифәләрен совет чоры әдәбияты алып тора. Күренекле исемнәр бик күп монда. Шагыйрьләр Һади Такташ, Хәсән Туфан, Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Саҗидә Сөләймановалар, драматурглар Таҗи Гыйззәт, Фәтхи Бурнаш, Нәкый Исәнбәт, Хәй Вахитләр... Прозаикларыбызның зур гына өлеше 18 томда урын алуын әйткән идек инде. Бу томда аларга тагын Әмирхан Еники, Рафаил Төхфәтуллин, Гариф Ахунов,Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев һ. б. исемнәр өстәлгән. Ә менә бүгенге әдәби процессыбызның үзәгендә торып иҗат итүче авторларыбыз: Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев, Нурихан Фәттах, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗанов, Туфан Миңнуллин, Ренат Харис, Фәнис Яруллин, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт, Роберт Миңнуллин, Зиннур Мансуров, Разил Вәлиев, Рәдиф Гаташ, Флүс Латыйфи һ. б., һ. б. лар.

Җыйнап әйткәндә, ике томда иң өлкән Кол Галидән алып иң яшь Ркаил Зәйдуллага кадәр булган 136 авторның иҗат үрнәкләре урын алган. Дөрес, бүгенге танылган каләм әһелләребез арасында Ркаилдән яшьрәкләре дә бар, әмма Антологиягә материаллар моннан 9-10 ел элек үк тупланганлыгын онытмыйк. Томнарның авторлар составы турында тагын берничә сүз. Безнең әдәбият хәзинәләребез шул кадәр бай ки, аларны ике түгел ун томга да сыйдыру кыен булыр иде. Материаллар сайлауның никадәр четерекле булуын Нил Гафур улы үзе генә

белгәндер. *(Авыр туфрагы җиңел булсын, ул бу хезмәтен басмада күрергә өлгермичә арабыздан китеп барды.)* Шунсы бәхәссез: төзүче, антология таләпләрен истә тотып, томнарда, мөмкин булган дәрәҗәдә һәр гасырны, чорны, этапны, юнәлешне, жанрны чагылдырырга омтылган. Ул яңарак табылган яки әлегәчә архивларда гына яткан кайбер кыйммәтле ядкарьләрне дә зур дөньяга чыгарырга тырышкан, репрессия корбаннары булган әдипләрнең иҗатына аерым бер игътибар күрсәткән. Әсәрләреннән үрнәкләр китерелмәгән байтак язучыларның исемнәрен кереш мәкаләләрендә искә алып үткән.

Кыскача йомгак ясап, шуны әйтергә кирәк: галимнәребез Фатих Урманче һәм Нил Юзиев хәзер күзәтеп үтелгән томнарга татар фольклорының һәм язма әдәбиятының иң яхшы һәм үзенчәлекле әсәрләрен туплаганнар, алар турында тирән эчталекле кереш мәкаләләр язганнар, фәнни белешмәләр биргәннәр. Томнарны төзүнең житәкче-оештыручысы, халкыбыз һәм телебез тарихы буенча киң мәгълүматлы мәкалә авторы академик Мирфатих Зәкиевнең, татарча материалларны латин алфавитына күчергән һәм төрек теленә тәрҗемә иткән, күбесенең исемнәре тюркологиядә яхшы мәгълүм булган Мостафа Өнәр, Һаяти Дәвале, Фатма Өзкән, Исмаил Түркоглу, Орһан Сөйләмәз, Мостафа Төкәр, Айрат Җәләл *(Төркиядә аспирантурада укучы Казан егете)*, Фәхри Тәмизүрәк, Хакан Акҗа, Гөксел Акҗа, Нури Дурсун, Хатиҗә Ширин, Җанәр Кәримоглуларның хезмәтләре шулай ук югары бәяләүгә лаек.

Татар фольклоры һәм язма әдәбияты дөньяда шактый киң танылу тапкан. Русча тәрҗемәләрдә, Европа, Азия халыклары телләрендә алар буенча йөзләгән китаплар чыгарылган. 200 томлык «Всемирная литература» сериясендә дә безгә шактый урын бирелгән иде. Һәм менә Анкара Антологиясе татар әдәбияты белән төрекләрне һәм төрек теле аша башка төркиләрне таныштыру юлында зур адым булып тора. Моның әһәмиятен тулырак кузаллау өчен, бүген дөньяда 7 бәйсез төрки дәүләт яшәвен, төркиләрнең гомуми саны 150 миллион тирәсе булуын искә төшерергә мөмкин.

Томнарның безнең өчен «эчке» кыйммәте дә зур. Бигрәк тә тел, әдәбият галимнәре, тәрҗемәчеләр өчен. Аннан соң тагын шул: Татарстанда бик күбәүләр уку йортларында яки үзлекләреннән төрек теле өйрәнә. Әлеге басмаларда исә латин алфавитына күчерелгән татар текстлары һәм аларның төрекчә тәрҗемәләре тупланган. Шулар нигезендә, мәсәлән, төрле җыентыклар, хрестоматияләр, сүзлекләр, уку-укыту әсбаплары әзерләп була. Ләкин, аңлашыла ки, Антология томнары Казанга бик чикләнгән санда гына кайтачак. Аларны зуррак китапханәләрдә, уку йортларында, фән-иҗат оешмаларында булдырасы иде.

**Хуҗи МӘХМҮТОВ**,
*филология фәннәре докторы,*
*Халыкара Төрки академиянең хакыйкый әгъзасы*





# 25—ФУРКАН (ЯХШЫНЫ ЯМАННАН АЕРУЧЫ КИТАП) СҮРӘСЕ

**(Фуркан сүрәсе 77 аятьтән тора. Бу сүрә Мәккәдә иңгән. Исеме «Фуркан» сүзеннән килә, ягъни дөреслекне ялганнан аера торган Китап—ул Корьән-и Кәримдер.)**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Фурканны *(Корьәнне)* галәмнәрдәгеләрне кисәтүче *(Илаһның газабы белән куркытучысы)* булсын дип, бәндәсенә *(Мөхәммәдкә)* иңдергән *(Аллаһ)* бөекләрнең бөеге. **(2)** Күкләрнең һәм Җирнең хуҗасы, һичбер нинди бала атасы булмаган, хуҗалыгында Үзенә тиңе булмаган, һәр нәрсәне яралтып *(юктан бар итеп)*, һәрнәрсәгә тәкъдир язып, бер тәртипкә китергән *(Аллаһ)* бөекләрнең бөеге.

**3.** Шуңа да карамастан, Аны инкарь итеп, бер нәрсә дә яралтырга кодрәтләре булмаган төрле ясалма тәңреләр уйлап чыгаралар. *(Аларның ул ясалма тәңреләре)* үзләре *(кеше кулы белән яки Аллаһ тарафыннан)* ясалган. Ул *(бичара)* потлар, сыннар алар өчен файда да, зарар да китерә алмый. Җан алырга да, җан өрергә дә, мәетләрне яңадан терелтеп, каберләреннән кубарырга да аларның *(ясалма илаһларның)* көче юк.

**4.** Кяферләр әйтте:

—Бу *(Корьән Мөхәммәд)* үзе уйлап чыгарган ялганнан башка нәрсә түгел. Бу эштә аңа башкалар да ярдәм иткәндер,—диделәр. Шул сүзләре белән алар мәкерле бер гаделсезлек кылдылар. **(5)** Әйттеләр:

—Борынгылардан калган әкиятләрне ул башка берәүгә яздыртып, иртә-кич үзенә укыттырган да *( ятлап, хәзер безгә сөйләп йөри)*,—диделәр. **(6)** *(Аларга)* әйт:

—*(Корьәнне)* күкләрдәге, Җирдәге һәм яшерен, һәм ачык серләрне белүче *(Аллаһ)* иңдерде,—диген. Хактыр ки, Ул—ярлыкаучы һәм бик тә мәрхәмәтле. **(7)** Әйттеләр:

—Ул нинди пәйгамбәр инде,—диделәр,—безнең кебек ашый-эчә, үзе базар буйлап йөренә. Аның белән берәр сакчы фәрештә иңдерелгән булса *(аның кисәтүче пәйгамбәр икәненә инанган булыр идек)* **(8)** яки аңа *(Күктән)* бер-бер хәзинә коелса, мул җимеш бирә торган бакчасы булса *(ул чагында базар буйлатып йөрмәгән булыр иде)* үзенекен ашар иде. Кяферләр *(мөэминнәргә)* әйтте:

—Сез күз буучы, сихерче кешегә *(Мөхәммәдкә)* ышанасыз,—диделәр. **(9)** *(Ий, Мөхәммәд)* бак, синең турыда алар ни генә сөйләми. Алар тугры юлдан чыкты. Моннан ары алар инде Сәгадәткә ирешә алмас.

**10.** *(Аллаһның кодрәте)* шулкадәр чиксез ки, Ул, әгәр дә ихтыяр итсә, сиңа болардан *(кяферләрнең байлыгыннан, яхшы бакчаларыннан да)* яхшырак, астыннан чишмәләр агып ятучы җәннәт бакчалары бирер иде, синең өчен сарайлар төзер иде.

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде

**11.** Шулай көфер *(сөйләгәннәре)* өстенә алар Сәгатьне *(Кыямәтне)* ялганга чыгардылар. Сәгатьне *(Кыямәтне)* инкарь иткәннәре өчен Без аларга хәтәр ялкынлы тәмуг әзерләп куйдык. **(12)** Ул *(җәһәннәм уты)* аларны ерактан күреп алыр һәм алар аның тагын да катырак гөрелдәгәнен ишетер. **(13)** Куллары муеннарына бәйләнгән хәлдә тәмугның иң тар җиренә ташлангач, алар *(аһ, без)* һәлак булдык, дип акырыр. **(14)** *(Ләкин аларга әйтелер ки):*

—Бүген *(сез)* бер тапкыр һәлак *(булуны)* юрамагыз, күп тапкырлар һәлак *(булуыгызны)* юрагыз.

**15.** *(Ий, Мөхәммәд)* әйт син:

—Бу *(җәһәннәм)* хәерлерәкме, әллә саф мөэминнәргә вәгъдә ителгән мәңгелек *(җәннәт)* яхшыракмы?—диген.—Ул *(җәннәт)* аларга *(мөэминнәргә)* бүләк һәм *(мәңгелек яшәү)* урыны булыр. **(16)** Алар анда мәңге калыр һәм ни теләсәләр, шул булыр. Менә шушы инде *(намазларда, догаларда)* Раббыдан ялварып соралган Сәгадәт. **(17)** Ул Көнне Раббы аларны *(кяферләрне)* Аллаһтан башка табынган нәрсәләре белән бергә җыяр да әйтер:

—Шушы колларымны сез аздырдыгызмы, әллә алар үзләре юлдан яздымы?—дип сорар.

**18.** Алар әйтер:

—Аллаһның кимчелеге юк, Ул бар яктан да пакь дип, Сине мактыйбыз. Сине инкарь итеп, башка илаһларга табыну безгә килешә торган эш түгел. Ләкин Син аларга һәм аларның аталарына шулкадәр мул нигъмәтләр бирдең, тәүбә итәр өчен вакытларын озайттың; ахырда алар Сине бөтенләй онытты вә алар харап булды,—диярләр.

**19.** Менә, сез табынганнар сүзләрегезне ялганга чыгарды. Бәс, сез өстегездән газабыгызны алдырырга да, ярдәмгә дә өмет итә алмыйсыз. Кайсыгыз залим, *(Аллаһтан башканы илаһ итеп табынган булса)*, ана хәтәр җәза газабын татытырбыз.

**20.** *(Ий, Мөхәммәд)* Без синнән әүвәл ашамый торган, базарларда йөрми торган һичбер Пәйгамбәр күндермәдек.

*(Әй, кешеләр)* сезнең бер төркемегез алдында, икенчегезне сынар өчен: бу газапларга *(гаделсезлеккә, тигезсезлеккә)* түзәрләрме икән, дип ярлттык. Раббың бар нәрсәне дә дөресе белән күреп-белеп торучы.

**21.** *(Кыямәт көнендә)* Безнең белән кавышуга инанмаганнар әйтер:

—Безгә фәрештәләрне илче итеп җибәргән булсаң иде яки Раббыбын үзен күргән булса идек *(иман китергән булыр идек)*,—дип *(акланырга маташырлар)*. Хактыр ки, алар тәкәбберләнеп, хәтәр азгынлыкка кереп, хәттин ашты. **(22)** *(Җәза)* фәрештәләре аларга ул көнне күренеп, һичбер сөенечле хәбәр китермәс. Фәрештәләр:

—*(Сезнең өчен җәннәткә керү)* тыелган!—дип әйтерләр. **(23)** Имансызларның мөэминнәргә кылган эшләрен юкка чыгарырбыз, аларны тузанга әверелдереп, җилгә очырырбыз.

**24.** Җәннәткә кергәннәрнең яшәячәк урыны бик тә җайлы һәм мәңге истирахәт кылыр өчен күркәм җир булыр.

**25.** *(Кыямәт)* көнендә болытлы Күк урталай ярылыр, аннан фәрештәләр гаскәре Җиргә таба ургылыр. **(26)** Ул Көнне барлык милек бары тик мәрхәмәтле ярлыкаучы Аллаһ Тәгаләнеке булыр. Кяферләр өчен ул Көн бик тә хәтәр булыр. **(27)** Ул Көнне залим бәндә *(чарасызлыктан)* бармакларын тешләп:

—Их, Пәйгамбәргә ияреп, *(Аллаһ)* юлы буйлап киткән булсам,—дип үкенер. —**(28)** Ни аяныч миңа, ни үкенеч. Тегe мөртәтне дус итмәгән булса идем. **(29)** Ул мине зикердән *(Коръәннән, иманнан, Пәйгамбәрдән)* биздерде. Шайтан инсанның *(башына бәла килгәч)* бер ялгызын упкынга ташлап качучы зат икән.

**30.** Шулчак Пәйгамбәр әйтер:

—Йа, Раббым, минем халкым Хакыйкатьнең үзе булган шушы Коръәнне инкарь итте бит.

**31.** —Без һәр пәйгамбәргә имансызлардан дошманнар хасил иттек. Тугры юлга бастырыр өчен дә, чын ярдәмче буларак та сиңа Раббың берүзе җитәр. **(32)** Ул кяферләр әйтте:

—Нигә син Коръәнне *(Тәүрат белән Инҗил кебек)* берьюлы иңдермәдең?—диделәр.

*(Ий, Мөхәммәд)* Без аны синең күңеләңә *(әкренләп кереп, чыкмаслык булсын)* яхшы урнашсын дип, шулай кылдык. Аны аятьтән-аятькә иңдердек.

**33.** Алар сиңа нинди дә булса мисалга хикәят китерсә, *(аңа каршы)* Без яхшырагын, аңлатмалары белән сиңа китерербез. **(34)** Алар җәһәннәмгә тупланып, йөзтүбән каплатылыр. Юллары азгынлык иде, урыннары да яман урын булыр. **(35)** Хактыр ки, без Мусага китап бирдек. Энесе Һарунны аның ярдәмчесе иттек.

**36.** —Барыгыз,—дидек аларга.—Аятьләребезне ялганга чыгарганнар *(Фиргавен халкы)* янына.

*(Алар Фиргавен токымын үгетләп карады, ләкин имансызлар игә килмәде.)* Нәтиҗәдә, аларны һәлак итеп бетердек.

**37.** Пәйгамбәрләрне ялганга чыгарганнарына күрә, башкаларга гыйбрәт булсын дип, Нух халкын да суга *(туфанга)* батырып үтердек. Залимнәр өчен без гыйбрәтле җәзалар хәзерләп куйдык.

**38.** Гад *(Һуд галәйһиссәләм)* кавемен дә, Сәмуд *(Салих галәйһиссәләм)* кавемен дә, Расс *(Шөгаеб галәйһиссәләм)* кешеләрен дә, алар арасында яшәп киткән башка *(гөнаһлы)* халыкларны да һәлак иттек. **(39)** *(Гыйбрәт алсыннар, дип)* аларның һәрберсенә Без мисали хикәятләр китердек, *(ләкин алар пәйгамбәрләребезне ялганчыга чыгарды, гыйбрәт алмады)* аларның барысын да һәлак итеп бетердек.

**40.** Хактыр ки, алар *(мәккәлеләр Лут пәйгамбәр халкының Садум)* шәһәрен давыллы яңгыр килеп тотканын күрмәделәрмени? *(Күрделәр, ләкин барыбер Кыямәт көнне)* тереләчәкләренә ышанмадылар.

**41.** Сине очратканда алар:

—Шушы да булдымы Аллаһ тарафыннан безгә җибәрелгән пәйгамбәр,—дип мыскыллаудан башканы белмәделәр. **(42)** —Шунысы хактыр ки, әгәр дә без аның котыртуларына каршы каты тормаган булсак, ул безне табынган тәңреләребездән биздергән булыр иде,—диделәр.

Алар озакламый күрерләр, белерләр кем юлдан язган, кем тугры юлдан барганын.

**43.** Үзенең нәфесен *(җенси ихтыяҗларын)* тәңре итеп табынганнарны күрдеңме син? Хәзер инде *(Рәсүлем)* синме аларны якларга алынасың? **(44)** Әллә син аларның күбесе, чынлап та, *(синең үгетеңне)* тыңлыйлар һәм тәүбәгә килерләр, дип уйлыйсыңмы? Алар дүрт аяклы хайваннардан да мәхлуграк булып адашканнар.

**45.** Раббыңның ничек итеп күләгәне озынайтканын караганың юкмыни? Әгәр ихтыяр итсә, Ул аны *(күләгәне)* хәрәкәтсез дә калдыра алган булыр иде. Без Кояшны аңа сәбәпче иттек. **(46)** Соңра аны *(озын күләгәне)* әкрен-әкрен генә үзебезнең янга тупладык. **(47)** Караңгы төнне Ул сезнең өчен бер каплавыч итеп яралтты, йокыны ял итәр өчен, көнне *(исә яңадан уянып, яхшы гамәлләр кылыр өчен)* яралтты. **(48)** Ул кин рәхмәтле буларак, куаныч алып килүче җилләрне яралтты. Күктән саф сулар агызды. **(49)** Үле туфракны тергезер өчен, бихисап кешеләр өчен яралткан хайваннарыбызга *(үлән-агач үссен, дип)* җирне сугардык.

**50.** Хактыр ки, уйлап гыйбрәт алсыннар, дип суны-яңгырларны кирәк

чакта, кирәк урыннарда кат-кат яудырдык, әмма аларның күбесе шөкер итмәде, кяфер булып кала бирделәр.

*(«Соңра гыйбрәт алсыннар өчен, бу суны араларында төрле вакытларда чиратлап яудырдык. Моңа да карамастан, кешеләрнең күбесе янә шөкер итмәделәр, кирелекләреннән кайтмадылар».*

Талат Кочигит тәфсиреннән.)

*(«Хактыр ки, моны (кешеләр) гыйбрәт алсын өчен, аларга төрле-төрле сурәтләрдә аңлаттык (яки: бу суны кирәгенчә яудырдык). Ләкин кешеләрнең күбесе шөкранә кыласы урында үҗәтләнделәр (кирелекләреннән кайтмадылар.*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

*(«Тәхкыйк, өстәге өч аятьне Коръәндә һәм башка китапларда тәкрар әйттек, кешеләр вәгазьләнсеннәр вә гыйбрәтләнсеннәр өчен, кешеләрнең күбрәге вәгазьдән вә гыйбрәтләрдән баш тарттылар, мәгәр Ислам нигъмәтен инкарь итеп, кяфер булудан баш тартмадылар».*

Шәех Ногмани тәфсиреннән.)

*(«Хактыр ки, инсаннар үгет алсыннар өчен, араларында төрле-төрле шәкелләрдә аңлаттык, әмма инсаннарның күбесе үҗәтлекләре белән шөкранә итмичә, кирелекләреннән кайтмадылар».*

Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.)

**51.** *(Ий, Мөхәммәд)* Әгәр дә Без ихтыяр итсәк, *(синең вазифаңны җиңеләйтер өчен)* һичшиксез, һәр илгә *(һәр шәһәргә)* кисәтүче *(пәйгамбәр)* күндергән булыр идек. *(Ләкин Без сине бөтен халыкларның пәйгамбәре буларак күндердек һәм синдә бөтен пәйгамбәрләрнең иң гүзәл сыйфатларын тупладык.)* **(52)** Бер мизгелгә дә кяферләргә бил бирмә һәм шуның белән *(Коръән белән)* аларга каршы булдыра алганча каты орыш.

**53.** Ул ике диңгезне янәшә куйды. Сусынны баса торган төче су һәм тозлы тәмсез су янәшә ага. Бер-берсенә катнаша алмаслык итеп, араларына бәрзах *(элпә-пәрдә)* корды.

*(«Ике төрле су арасындагы бәрзахның гарәпчә мәгънәсе—тел, тасма. Чыннан да, дөньяда янәшә аксалар да, кушылмый торган төче һәм тозлы агымнар бар, аларның арасында йөзләрчә чакрымнарга сузылган бәрзах, тел, тасма, аралык бар. Диҗлә һәм Нил елгаларының тозлы диңгезгә коеп та, диңгез эчендә тозлы су белән катнашмыйча агып барулары моңа мисал. Ләкин бәгъзе шәрехчеләр бу аять эчендә кинаяле мәгънә барлыгын да әйтәләр. Сусынны баса торган татлы су—ул Ислам, тозлысы исә башка бер дин. Мөселманнар агымы бар, бар кяферләр ташкыны, никадәр якын, янәшә яшәсәләр дә бу ике дин, бу ташкын мәңге дә кушыла алмый».*

Хәсән Чантай белән Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.)

**54.** Ул адәмне судан бар кылып, аны *(үрчемле)* нәселле итеп яратты. Раббын—һәрнәрсәгә кодрәте житә торган Илаһтыр. **(55)** *(Шуңа да карамастан)* Аллаһны инкарь итеп, үзләренә файда да, зарар да кылыр куәтләре булмаган *(сыннарга, потларга)* табыналар. Кяфер—Аллаһка каршы *(көрәшүче)* шайтанга ярдәмче.

**56.** Без сине *(мөэминнәргә)* сөенеч китерүче, *(кяферләрне)* куркытучы вазифасыннан башка сыйфатта күндермәдек. **(57)** Әйт:

—Мин бу гамәлләрем өчен сездән һичбер түләү сорамыймын, бары тик Аллаһка тугры юл тотарга теләгән кешеләрне генә эзлимен,—диген.

**58.** Үлемсез, мәңге-бакый *(Аллаһ Тәгаләгә)* инанып, *(Аңа)* сыен, Аны тәсбих илә *(Сөбхәналлаһү вә әлхәмдүлилләһ, сөбхәналлаһи вә бихамдиһи, дип)* данла. Ул бәндәләренең гөнаһ кылуларыннан хәбәрдар.

**59.** Ул күкләрне вә Җирне һәм алар арасында булган нәрсәләрне алты көндә яралткан, соңыннан Гарше көрсидә хаким булган хөкемдардыр. Ул—Рахмәндер, *(әгәр ышанмасагыз)* бу турыда хәбәрдар булганнардан сорагыз.

**60.** —Рахмәнгә сәҗдә итегез,—дигәч, алар:
—Кем соң ул Рахмән? *(Нишләп әле)* без син кушканга сәҗдә итәргә тиеш?—диделәр. Һәм бу *(өндәү)* аларны *(иманнан)* ераклаштырды гына.

**61.** Күктә йолдызлыклар яралткан, алар уртасында бер яктылык чыганагы *(Кояшны)* вә нурлы бер Ай булдырганның даны гаять бөектер. **(62)** Фикерләп гыйбрәт алганнар өчен, шөкер иткәннәр өчен төн белән көнне чиратлап китергән дә—Улдыр.

**63.** Кемнәр Җир йөзендә итагать белән йөри, шулар мәрхәмәтле ярлыкаучы *(Аллаһ)*ның бәндәләре булыр. Һәм алар надан ахмакларның әдәпсезлегенә каршы сәлам белән җавап бирә. **(64)** Алар кичләрен Раббылары каршысында сәҗдәгә китүчеләр. **(65)** Алар:
—Йа, Раббым, безне җәһәннәм газабыннан коткар. Аның газабы коточкыч һәлакәттер,—дип дога кыла.

**66.** Чыннан да, ул *(җәһәннәм)* яшәү һәм гамәл кылыр өчен бик тә яман урын.

**67.** Чыгым малын тотканда *(садәка биргәндә)* артыгын кыланмаган һәм дә бик саран да булмаганнар урталыкта булыр. **(68)** Алар Аллаһка тиң әзләмәс, башкага табынмас. Алар мәҗбүрлектән тыш, Аллаһ тарафыннан тыелган эшне кылмас—хаксызга адәм җанын кыймас, зина кылмаслар. Шушыларның берсен генә эшләгән кеше дә җәзасын алыр. **(69)** Кыямәт көнендә андыйларның җәзасы арта төшәр һәм алар мәңгегә хур булып калыр. **(70)** Яманнан тәүбәгә килеп, иман китереп, игелек кылганнарның яманлыкларын игелеккә алмаштырыр *(кылган гөнаһларын ярлыкап, саваплы эшкә күндерер)*. Аллаһ ярлыкаучы, бик тә мәрхәмәтле.

**71.** Тәүбә иткәннәр һәм игелек кылганнар, һичшиксез, тәүбәсе кабул кылынып, Аллаһның ризалыгын алып, Аның янына кайтарылыр. **(72)** Алар ялган шаһитлек итмәс, буш һәм тәмсез сүз сөйләүчеләр янында тормас, әдәпле рәвештә китеп барырлар. **(73)** Алар Раббының аятьләрен тыңлаганда *(мәгънәсенә)* күз йоммас, ишетмәмешкә салышмаслар.

**74.** Алар әйтер:
—Йа, Раббыбыз, күңелләребезнең куанычы, күзләребезнең карасы кебек *(затлы, пакь)* хатыннар вә балалар бир. Безне саф мөселман халыкларына юлбашчы ит,—дип.

**75.** Менә боларның һәммә барчасы, авырлыкларга чыдам, түзем булганнарына күрә әҗер алачак һәм анда *(җәннәттә)* сәлам илә каршыланачак. **(76)** Анда алар мәңгегә калачак. Аһ, ул нинди гүзәл урындыр, ул нинди рәхәт торактыр.

**77.** Әйт:
—Аллаһка мөрәҗәгать итмәгән булсагыз, Аллаһ сезгә игътибар итмәгән булыр иде. Сез дөрестән дә *(аятьләрне)* ялганга чыгардыгыз. Бәс, сез хәзер җавап газабы тотачаксыз,—диген.

صدق الله العظيم

# РУХИ КУӘТ

## АЗАТ ГАНИЕВКӘ—60 ЯШЬ



Моннан 31 ел элек халкыбызның олы әдибе Мөхәммәт Мәһдиев журналыбызда яшь язучы Азат Ганиев иҗатына багышлап «Чишелеш... нульгә бетми» исемле кызыклы мәкалә бастырган иде. Өлешчә алганда анда менә мондый юллар бар: «Яшь язучының персонажлары—мәҗнүн кешеләр. Боларны романтик шәхесләр дип тә атап булыр иде кебек. Бу шәхесләр «Янәшә»дә генә түгел, «Өмет уты сүнмәсә», «Студент Әсгать», «Тагын күченәбез» һәм башка хикәяләрендә дә очрый. Авторның барлык хикәяләрендә дә төп образ итеп яшьләр алына. Төп герой нинди дә булса бер хирескә (рәсем сәнгатенә, ил гизүгә, үзен ил өчен иң файдалы эшкә сарыф итү юлларын эзләүгә һ. б.) бирелгән була.» *(«Казан утлары», 1971 ел, 7 сан.)* Күренекле әдип бу сүзләрен Азат Ганиевнең 1969 елда дөнья күргән «Тагын күченәбез» исемле беренче китабын укып чыкканнан соң яза. Ул үзенең мәкаләсен «А. Ганиев—бүгенге яшь прозаиклар арасында иң өметлесе» дигән сүзләр белән төгәлли.

Һәм күп тә үтми «Казан утлары» журналы 1972 елгы тәүге санын менә шушы яшь язучының «Сүзсез җыр» исемле повесте белән ачып җибәрә. Бирелә укучы тагын да үзенчәлеклерәк образлар белән очраша. Математикадан мәсьәлә чишеп утырганда өлкән сыйныфта укучы Хәят исемле кыз урыныннан тора да: «Чишелеш нульгә бетә» дип чыгып китә... Хәятны авылда авыруга саный башлыйлар—ул укымый да, эшләми дә... Әсәрнең икенче бер герое Габделхак белән алар урак вакытында, басуда очраша. Бөтен тормышка, яшәешкә битараф шушы сәер кызны бераз күзәтеп торганнан соң Габделхак менә мондый сүзләр әйтә:

—Хәят, син әйтәсең, бөтен нәрсә аяк астындагы таш кебек гади, мине гаҗәпләндерә алырлык бер нәрсә дә юк, дисең! Алайса әйтеп кара: менә бу кап-кара җирдән ничек итеп ап-ак чәчәкләр, зәңгәр, кызыл, сары чәчәкләр үсеп чыга ала? Менә бу бөҗәк нигә тере? Без бер-беребезне ничек күрә алабыз? Бу могҗиза түгелме? Аяк астындагы таш кебек гади дисең. Бу таш гади түгел. Моның эчендә, беләсеңме, нинди серләр бар?

—Йә, әйтеп кара. Нинди серләр бар ул таш эчендә?—диде Хәят, елмаеп...»

Әнә шулай итеп яшь Хәят күңелендә әкренләп кызыксыну уяна. Тора-бара яшьләр арасында мәхәббәт тә туа, әмма ул бәхетсез булып чыга—Хәят бу дөньяны бик иртә калдыра...

Менә шушындый үзенчәлекле эчтәлеккә ия булган «Сүзсез җыр» повесте җитмешенче елларда шактый зур резонанс алды: аның турында матбугатта да, язучыларның әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышларда да байтак җылы сүзләр әйтелде. 1977 елда яшь язучы үзе дә Язучылар берлегенә әгъза итеп алынды.

1984 елда Азат Ганиев «Габделхак» исемле кызыклы повестен «Казан утлары» журналында (5 нче сан) бастырды. Бу әсәр хәзер бигрәк тә актуальләшкән яшь

гаилә проблемасына—ир белән хатын мөнәсәбәтләренә багышланган булуы белән ул чорда аеруча яна һәм үзенчәлекле эчтәлеккә ия иде.

Шуннан соңгы елларда язучының иҗади тормышында күпмедер ел тәнәфес булып алды кебек. Ә бәлки бу чор Азат Ганиевнең яна бер иҗади сикереш, ыргым ясау өчен мая туплавы, көч җыюы булгандыр? Аннан соң, безнең беребез дә күктә түгел, ә җир тормышы белән яши һәм аның котылгысыз рәвештә алга килеп баса торган берсеннән-берсе үткен һәм җитди мәсьәләләрен дә хәл итәргә мәҗбүр бит әле.

Һәм менә 1993 елда Татарстан китап нәшрияты Азат Ганиевнең «Адашкан җаннар» исемле яңа китабын бастырып чыгарды. Аңа укучылар өчен беренче китаптан ук таныш булган кайбер хикәяләр белән бергә «Күнел күзе», «Сөмбел» дигән күләмле әсәрләр дә кертелгән. Ә элегрәк журналда басылган «Сүзсез җыр» повесте исә «Габделхак» әсәре белән берләштерелгән һәм шактый нык үзгәртелгән.

Ике китап арасында ун ел гомер... Әнә шул вакыт аралыгында язучының рухи дөньясы нинди үзгәрешләр кичерде икән соң?

Әсәрләрне укыганда шундук күзгә ташлана торган иң зур үзенчәлек: бу китапта фәлсәфилек бик тә арткан. Әлбәттә, язучының баштагы әсәрләренә дә әлеге сыйфат ят түгел иде, ләкин «Адашкан җаннар» да инде ул китапның йөзен билгеләүче иң төп билгегә әверелгән дисәк тә ялгыш булмас. Бирелдәге геройлар инде җир тормышы белән генә канәгать түгел, алар инде тулаем галәми-космик проблемалар белән: аерым алганда «галәм күләмендә караганда кеше гомере, кеше тормышы, кеше язмышы нәрсә ул?» дигән үтә җитди сораулар белән баш ваталар.

Бу китапка кергән «Сөмбел» повестенең тарихи эчтәлеккә ия булуын да әйтеп үтү кирәк. Анда татарларны чукындыру күренешләре, шул максат белән кулланылган нечкә һәм астыртын хәйләләр ачып салына.

Ә инде «Күнел күзе» әсәрен авторның фантастика жанрындагы иҗат җимеше дип тә карарга була. Әмма, тышкы рәвеше шундый булса да, анда бүгенге чорның җитди проблемалары күтәрелә. Геройларның һәм авторның бик күп уйланулары «очраклылык» төшенчәсе белән бәйле—әсәрнең ул өлешләрен үзләштерү өчен укучыдан түземлек тә, әзерлек тә сорала.

... Әйе, Азат Ганиев күп яза торган автор түгел. Ул кайберәүләр кебек роман-повестьларны «коеп кына» тормый, ә бәлки үзе реаль тормышта яшәгәнне-кичергәнне кат-кат зиһен үлчәвеннән үткәргәннән соң гына, аларның фәлсәфи һәм рухи асылына төшенгәч кенә, вакыйга-күренешләрне бер җепкә тезә, бер системага сала алгач кына—әнә шул чагында гына әдәби әсәр язарга алына. Икенче төрле итеп әйткәндә: хәзер инде Азат Ганиев язучыдан бигрәк философка әверелеп беткән диярга дә була.

Әйбәтме бу, әллә начармы?

Ничек кенә булса да хәзер инде бу хәл безнең алга чынбарлык факты рәвешендә килеп баскан—авторның укучыны тирән уйларга алып керә торган ярым әдәби, ярым фәлсәфи әсәрләре инде безнең кулда. Алар галәм кинлегенә һаман кыюрак үтә баручы җир улларының XX гасыр азагындагы уй-кичерешләре буларак тарихка кереп калачак.

Ләкин... Ләкин шулай да бүген безнең күңелләр чәчмә әсәрләр остасы булып танылган Азат Ганиевне күбрәк юксына. Аныкы сыман мәгънәви яктан үтә саллы һәм тыгыз «мускуллы» җөмләләр, аз гына сүзләр, чаралар белән дә тулы бер күренешне укучы күз алдына китереп бастыра алу таланты, хикәяләүнең җанлылыгы-хәрәкәтчәнлеге... Менә болар барысы да безнең хәзерге прозага бик тә тансык бит!

Талантлы язучы Азат Ганиевне 60 яшь тулу унае белән ихлас котлап, шул ук вакытта без аңа үзебезнең әнә шундый теләкләребезне дә җиткерергә телибез.

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ**

# Хатлардан юллар

* * *

Менә әле генә «Казан утлары»ның яңа санын укып чыктым. Мин аны 1958 елдан–Уфада яши башлаган вакыттан бирле алдырам. Журналны алгач, иң әүвәл күкрәгемә кысам-кочаклыйм аны. Аннан аның изге сәхифәләрен актара башлыйм. Актарып бетергәч, йотлыгып, озак-озак иснәп карыйм. Тәмле ис килә. Кәгазь исе. Яңа кәгазь исе. Шул ис белән ул сәхифәләргә язылган рухи гәүһәрләр дә йөрәк түренә китәдер. Журналны шундый ләззәт кичергәч кенә укый башлыйм. Иң башта шигъри әсәрләрдән рухи тәм алам. Аннан публицистик язмалардан фикер энҗесе эзлим. Шуннан хикәя, повесть, романнарга күчелә.

Ерактагы кояш якын була, дигәндәй, «Казан утлары»ның уты безне–Башкортстанда яшәүчеләрне–тагын да ныграк кыздыра. Күңелдәге, йөрәктәге салкын бозларны эретә. Кыскасы, сез кабызган әдәбият, сәнгать утында җылынабыз. «Кызыл» сүзләр белән әйтсәк, «Казан утлары» утыннан эстетик зәвык алабыз.

**Суфиян ПОВАРИСОВ.**
*Уфа.*

* * *

Олуг әдип Галимҗан Ибраһимовтан башлап Равил Фәйзуллинга кадәр журналны Татарстанның иң күренекле әдипләре җитәкләде. Иң матур елларында журналның тиражы 120000 гә кадәр үсте! Аны Владивостоктан Клайпедага, Мурманск һәм Анадырьдан Бакуга кадәр һәр төбәктә яздырып ала килделәр. Минем туган шәһәрем Мартукта да (Казакъстан) аны алдырып укый иделәр.

Кайсы чорда «Казан утлары» журналы редакциясенә кыенгарак килгәндер, хәзер әйтүе кыен, әмма шунысы бәхәссез–журналның бүгенге җитәкчелеге эстафетаны ил өчен дә, әдәбият өчен дә иң авыр–матавыклы заманда кулына алды.

Журнал редакциясенең, иң әүвәл аның баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинның һәм аның хезмәттәшләре Флүс Латыйфи, Марс Шабаев, Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Алмаз Гыймади, Марат Закир, Камил Кәримовларның фидакарь хезмәте һәм көче белән шушы болгавыр заманда «Казан утлары» сакланып, яңа гасырга да лаеклы басма булып калды.

Журналның бизәлеше-дизайны нык яхшырды, аның полиграфик эшләнеше Мәскәү басмаларының күпчелеген көнләштерерлек. Мәгълүм калын журналлар–«Новый мир», «Знамя», «Октябрь», «Дружба народов»ларның берсе дә күләмнәрен саклап кала алмады, алар юка гына брошюралар булып чыга башладылар, тиражлары буенча да үзләренә байтак еллар инде Дж. Сорос фонды ярдәм итеп килсә дә, «Казан утлары» белән ярыша алмыйлар.

«Казан утлары» журналының бүгенге 10 меңле тиражы соңгы чик булмас, аны әле алда тагын да матур еллар көтә дип ышанам. Бу ышанычның нигезе–журналның ничек яратып, белеп, зур осталык белән эшләнүендә.

Яраткан журналыма, аның хезмәткәрләренә озын гомер, Татарстанга игелекле хезмәт итүдә уңышлар телим!

**Рауль МИРХӘЙДӘРОВ.**
*Мәскәү.*

* * *

Билгеле булган тарихи, сәяси, икътисади сәбәпләр белән милләттәшләребез төрле илләрдә яшәргә мәҗбүр. 1950 нче елларга кадәр ишле генә татар диаспорасы Кытай басып алган Шәркый Төркестанда, бүгенге исеме белән әйтсәк, Цинзян өлкәсендә яшиләр.

Татарларның бу җирдә яшәүләренең тарихы 200 еллап. Татар-башкортлар биргә Пугачев күтәрелеше бастырылгач качып килгән булырга тиеш. Алар күбесенчә Алтай, Тарбагатай якларында утырганнар. Казакъ халкыннан кыз алып, ахырда үзләре дә казакъ тормышына күчеп, тәмам казакълашып киткәннәр.

Шундыйлар мисалы–Жиңсар дигән җирдә яшәүче казакълар үз халыклары төрле кабиләләрдән, илләрдән торганга күрә, татарларны кодалашса да чала-казакъ дип йөртәләр, ягъни ярым, яртысы гына казакъ. Бу чала-казакълашу XX гасырның башларына кадәр дәвам итә. Бүген шул халык Алтай, Тарбагатай, Баянху, Өремче шәһәрләре янындагы тауларда яшиләр.

Татарлар исә, күбесенчә Цинзянның көнбатыш ягындагы өч вәлиә дип тарихка кереп калган өлешендә тупланып, ә Чуа-чак, Гөлҗә, Өремче шәһәрләрендә мәхәлләләр, мәчет, мәктәпләр, клублар, сәүдә ширкәтләре, заводлар төзеп гомер итәләр. 1949 елда Шәркый Төркестан журналында язылып күрсәткәнчә, сан ягыннан 70 мең булган һәм, арта барып, 200 ел эчендә төрле юллар белән качак, сәүдә эшләре, 1917 елдагы фетнәләрдән соң һәм соңгы 1933 елгача килеп урнашкан милләттәшләребез хисабына үскән. Татарлар бу җирдә үз тырышлыгы, фидакарьлеге белән дан тоткан. Шәркый Төркестанның XIX-XX гасыр тарихын татарларсыз күз алдына китерү авыр.

Ләкин бүген, Сталин - Мао-Цзедун сәясәте нәтиҗәсендә, бу җирләрдә татарлар саны 5 меңгә генә калды, анысы да җирле халыклар ассимиляциясе каршында тора. Шулай да, әлегә бирешмиләр.

1988 елдан бирле Сабан туйлары, Габдулла Тукайга багышланган кичәләр үткәрелеп, җәмгыятьләр төзиләр. Әмма иң кирәге–милләтнең киләчәген тәшкил итүче мәктәпләр яки факультатив рәвештә татар телен укыта торган урыннар юк.

**Ирек ГАРИФ,**
*Австралиядәге татар җәмгыяте әгъзасы*

* * *

Халкыбызның рухи көзгесенә әйләнгән «Казан утлары» журналын яратып укып барам. Хәтта сугыш елларында, әле мин ныклап укырга-язарга өйрәнгәнче үк, апа-абыйларымның «Совет әдәбияты» журналын укып йөргәнлекләрен хәтерлим. (Ихтимал, аны колхоз идарәсе алдырган булгандыр) «Казан утлары» үзенең сәхифәләрендә халкыбызның үткәнен һәм бүгенгесен, аның әдәбиятын, сәнгатен һәм мәдәниятын яктыртучы озын тарихлы бердәнбер әдәби-нәфис журнал.

Минем әтием Беренче һәм Икенче Бөтендөнья сугышларында катнашып күп авырлыклар кичерә. Аның империалистик сугышка бәйле «Сугыш бәете» исемле китабы дөнья күрә. Ләкин ул минем көннәргә кадәр сакланмаган. Дөресрәге, кулдан-кулга йөртеп укый торгач, аны гаиләбезгә кабат бирмиләр. Һәрберсе нәтиҗәсез эзләнүләр белән тәмамланган шушы бәетнең язмышы белән кызыксынуым әтиемнең вафатыннан соң тагын да арта төште. Һәрвакыт кешеләргә карата игътибарлы, олы җанлы кеше - «Саба таңнары» газетасының мөхәррире Тәлгат Нәҗмиевтән бу эштә ярдәм итүен сорадым. Озак та үтмәде, латин имлясында нәшер ителгән әлеге бәет миңа тапшырылды. Ә «Казан утлары»ның 1997 елгы 9 санында Тәлгат әфәндене безнең гаиләбезгә багышланган язмасына һәм әтиемнең «Сугыш бәете»нә дә урын бирелде.

Күп еллар үтсә дә, «Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» повесте, Нурихан Фәттахның «Этил суы ака торур» романы, Мәгъсүм Насыйбуллин, Миргазиян Юныс, Мөхәммәт ага Мәһдиевнең әсәрләре бүген генә укылгандай күңелдә саклана. Элекке елларда әсәр журналда тулысынча басылып беткәч, тел белгечләре, тәнкыйтьчеләр тарафыннан рецензияләнде. Мин һәрберсен үземчә анализлап, уй-фикерләремне белгечләр фикере белән чагыштырып карый идем.

Безнең буын кешеләре татар совет әдәбиятын укып үсте һәм бездә язучыларның үзләрен күрәсе килү теләге бик көчле иде. 1950 елда күренекле язучы Кави Нәҗми ТАССР Югары Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелгәч, без–укучы балаларны, юл буена тезеп куйдылар. Байраклар күтәреп торган кулларыбыз беләзектән терсәккә кадәр өшеп чыкса да, гәрчә язучының ап-ак бәс сарган толып якасын гына күреп калсак та –«тере» язучы белән очрашуыбызга чиксез шатландык.

Инде өлкән яшьтә булсам да, «Казан утлары»на булган ихтыяҗым кимеми. Аны алдырмасам, нәрсәнедер югалтам кебек. Чөнки әдәби хәрәкәттәге мөһим нәрсәләрне белеп торырга журнал ярдәм итә.

Хөрмәтле Равил әфәнде, хөрмәтле «Казан утлары» хезмәткәрләре! Сезгә «Укучы сүзе» сәхифәсен булдыруыгыз һәм саклап килүегез өчен дә бик зур рәхмәт.

Яраткан журналымның 80 еллык юбилее котлы булсын!

**Нургания ШАКИРОВА,**
*Саба районы, Татар Икшермәсе авылы.*

*Дусларча шаярулар*

## Болар—безнең хезмәттәшләр, фикердәш-каләмдәшләр



### Равил Фәйзуллинга

*(Шагыйрьнең нәни улы Газизне дә уйлап)*

Кырыклап китабы чыккан...
Иллегә тулмагае...
Фәйзуллинның шәп китабы—
Газизе булмагае!?

### Флүс Латыйфига

*(«Хыянәт»ен уйлап)*

Батырлык кылып кына да
Булмый кайчак дан алып.
Флүс «Хыянәт» итеп тә
Йөри батыр саналып!






### Наис Гамбәргә

*(Шигырьләрен укыгач)*

«Язам, диеп яшәмәгәч,
Бу дөньяда ни гамь бар?
Дуслар килә дә китә ул...
Шигырь кала!
Н. Гамбәр».

### Марс Шабайга

*(Әүвәлге вә хәзерге тәрҗемәләре турында уйлангач)*

Дөньякүләм тәрҗемәнең
Остасына әйләнде:
Уолт Уитменнан югары
Күтәрде Мир-Хәйдәрне!





## Камил Кәримгә

*(К. Шәле дигән әдәби кушаматын искә төшереп)*

«Акты,
действительни факты.
Мамадыштан кайткан чакта,
бер шешә аракыбызны
ат типте дә ватты!»—
дип язды К. Шәле.
Ул шешәне и жәлләде...
Ләбиб Шешәле.

## Марат Закирга

*(«Чебен» дигән хикәясен укыгач)*



Шаклар катып торган мәлем
Ул язганнарга карап...
Чебеннән—фил, филдән—чебен
Ясамагае Марат.

## Мансур Вәлигә



Ат кебек эшләгәнгәме
Зур тәнкыйть өлкәсендә,
Яллары салынып төшкән
Мансурның җилкәсенә.

## Алмаз Гыймадиевка

*(Балалар, үсмерләр хакындагы шаян әсәрләрен укыгач)*



Әдәбият дөньясында
Һәркем—алтын... көмештер...
Миңа калса... Алмазы да
Бик булырга тиештер!

## Рәдиф Гаташка



*(Гүзәлләрен һәм газәлләрен күздә тотып)*

Гаташның гүзәлләре лә,
Гаташның газәлләре!..
Бүген янә гашыйк булдым—
Бер газәл язам әле.

**Ләбиб ЛЕРОН** *шигырьләре,*
**Александр АЛЕШИН** *рәсемнәре.*

# RƏSEMNƏRDƏ—JURNAL TARİXI



Əlməttə yəşəwçe yazuçılar—beznen aktiv avtorlarıbız. *Suldan unğa:* **Şamil Bikçurin, Məxmüt Xəsənov, Rafail Təxwətullin, Ğamil Afzal.**
*80 yıllar.*



90 yıllardağı redkollegiə əğzalarınnan **Marat Məlekov** həm **Nacar Nəcmi.**



M. Cəlil həykəle yanında.
*80 yıllar.*



Ğ. Tuqay muzeyın açu tantanasında.
*1986 yıl.*



Beznen avtorlarıbız—xalıqara PEN-klub əğzaları—Finlandiədə.
*Suldan uñğa:* **Waxit Yunıs, Əxət Muşinskiy, Razil Wəliev, Təlğət Bariev, Rkail Zəydulla, Tufan Minnullin, Məsəğit Xəbibullin, Mədərris Wəliev, Marsel' Ğəliev.**
*1998 yıl.*



Baltaçta tatar ədəbiatı kənnəre.
*90 yıllar.*



"Qazan utları" kollektivı tabiğət qoçağında.
*1998 yıl.*



Redkollegiə utırışınnan ber küreneş.
*2001 yıl.*

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2002 елның икенче яртыеллыгы өчен вакытлы матбугатка язылу дәвам итә. Ул 26 июньгә кадәр барачак. **"Казан утлары"ның индексы—73210, ярты елга язылу бәясе—66 сум.**

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Әлеге квитанцияне кисеп алып, анда тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

Казанлылар исә безнең журналга "Горпечать" киоскларында языла алалар. Бу очракта журналны ай саен шуннан барып аласы була.

80 еллык бай тарихы булган мәдәниятебез елъязмасы "Казан утлары"на язылырга онытмагыз!

Ф.СП-1

Управление почтовой связи
"Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ журнал 73210 (индекс издания)

*Казан утлары*
(наименование издания)

Количество комплектов:

на 2002 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | ли-тер |
|---|---|---|

на ~~газету~~ журнал 73210 (индекс издания)

*Казан утлары*
(наименование издания)

| Стои-мость | подписки | ______ руб. ______ коп. | Количество комплек-тов |
|---|---|---|---|
| | пере-адресовки | ______ руб. ______ коп. | |

на 200 2 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)



## Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### КАЗАНГА–ЮНЕСКО БҮЛӘГЕ

18 мартта Марракеш (Марокко) шәһәрендә ЮНЕСКОның 2000-2001 елларга «Шәһәрләр–тынычлык өчен» мактау дипломнары һәм премияләр тапшыру тантанасы булды. 5 дипломант арасында Татарстан башкаласы Казан да бар. Ул йөзгә якын милләт вәкиле яшәгән җирдә иҗтимагый татулык оештыруда мөһим өлеш керткән өчен ЮНЕСКОның мактаулы дипломына лаек.

Премия алу өчен 76 шәһәр үз кандидатурасын тәкъдим иткән. Халыкара жюри тәкъдиме буенча, ЮНЕСКО генераль директоры карары белән, аларның бары 10сы гына лауреат һәм дипломант булды. 1996 елда оештырылган ЮНЕСКО премиясе гомумкешелек идеалларын һәм кеше хокукларын хөрмәт итү, шәһәр кешеләре арасында ышаныч тудырган өчен бирелә.

### «БӨЕК ИДЕЛ ЮЛЫ»

Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институтында «Бөек Идел юлы» дип аталган журналны тәкъдирләү булды. Журнал нигездә Бөек Идел сәүдә һәм хезмәттәшлек юлының яңадан тууы турында әйтелгән фикерләрне һәм шул уңайдан башкарылган эшләрне үз эченә ала. Анда бүгенге көндә мөһим дип саналган тарихи, мәдәни һәм икътисади мәсьәләләр күтәрелә. Былтыр Казаннан Әстерханга юл тоткан теплоходтагы халыкара конференция дә шул темага багышланган иде. «Россияне аякка бастыру өчен Бөек Идел юлының да ныклы үсеше кирәк»,–диде Тарих институты директоры Рафаил Хәкимов.

Идел ярлары буенда урнашкан татар халкының тарихын чагылдырган мәкаләләрдән тыш, журналда Татарстан Республикасының бүгенгесе, аның зур предприятиеләре турында язмалар да урын алган. «Англо-Каспий» Англия нәшрият йортында бастырылган яңа журнал реклама басмасы булып санала. Ул эшлекле даирәләргә–инвестор, чит ил эшкуарлары, икътисад өлкәсендә хезмәт итүчеләргә тәгаенләнгән.

### БТИҮ КОРЫЛТАЕ

15 апрельдә Г. Камал театры бинасында Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең VII корылтае булды. Ул үзенең өч еллык эшенә йомгак ясады, киләчәккә үзенең эш юнәлешләрен билгеләде.

Корылтайда Татар иҗтимагый үзәге рәисе Рәшит Ягъфәров хисап доклады белән чыкты. ТИҮ рәисе урынбасарлары Гаяз Мортазин, Илдус Садыйков, Юныс Камалетдинов өстәмә докладлар ясадылар. Тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков чыгышы халык санын алу һәм аның сәяси ягын ачыклауга багышланды. Фикер алышулар булды.

Корылтайда катнашучылар югары хөкүмәт органнары исеменә татар халкы яшәешенең төрле якларына кагылышлы егермегә якын мөрәҗәгать кабул иттеләр.

Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең VII корылтаенда «Россиянең колониаль сәясәте кискенләшкән шартларда БТИҮ эшчәнлегенең төп принциплары турында» резолюция кабул ителде.

Корылтайда Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең татарлар яши торган барлык төбәкләреннән килгән делегатлар катнашты.

Эш ахырындагы пленум җыелышында 5 елга вәкаләт белән БТИҮ рәисе итеп яңадан Рәшит Ягъфәров сайланды. Илдус Садыйков, Гаяз Мортазин, Инсаф Хәмитов, Ринат Нургалиев, Юныс Камалетдинов аның урынбасарлары булдылар.

### «ЕВРОПА–АЗИЯ» ФЕСТИВАЛЕ

Март ахырында Казанда «Европа–Азия» дип исемләнгән музыка фестивале булып узды. Заман музыкасына багышланган мондый җыен Татарстанда инде 10 нчы мәртәбә уздырыла. Фестивальдә, Россия регионнары вәкилләреннән тыш, АКШ, Швеция, Франция һәм башка илләрдән килгән музыкантлар катнашты. Фестиваль кысаларында узган концертларда татар композиторлары А. Монасыйпов, Р. Кәлимуллин, Р. Ахиярова, Ш. Тимербулатовларның әсәрләре яңгырады.

Бу фестивальне оештыруга Татарстан Мәдәният министрлыгы, Композиторлар берлеге, Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиллеге, Казан дәүләт консерваториясе, шулай ук Россиянең Композиторлар берлеге, Мәскәүнең Француз мәдәни үзәге, Бөгелмә, Түбән Кама, Яшел Үзән шәһәрләренең администрацияләре зур өлеш кертте.

## САРЫТАУДА ТАТАР РУХЫ

21-30 мартта Сарытауда татар мәдәнияте көннәре булып үтте. Анда Татарстан Республикасыннан Бөтендөнья Татар Конгрессы башкарма комитеты һәм Федераль милли-мәдәни мөхтәрият Советы рәисе Индус Таһиров, һәм Татарстан мәгариф министрының беренче урынбасары Илсур Һадиуллин житәкчелегендәге делегация катнашты.

Мәдәният көне кысаларында Русиянең егермедән артык төбәге татар мәктәпләре житәкчеләре катнашында милли мәгариф буенча фәнни-гамәли конференция уздырылды. Төбәк милли-мәдәни мөхтәрияте, башка жәмәгать оешмалары һәм жирле хакимият органнары белән бергәләп эшләсә дә, зур тәжрибә туплаган Сарытау татар гимназиясенең 10 еллыгын бәйрәм итү—конференциядә үзәк вакыйга иде.

Биредә шулай ук Алтын Урданың терәк шәһәрләренең берсе—Үкәк каласы төзелүнең 700 еллыгына багышланган төбәкара фәнни-гамәли конференция булды.

## ТАТАРСТАНЛЫЛАР МӘСКӘҮДӘ

Мәскәүнең Чайковский исемендәге Концерт залында Татарстан Дәүләт халык музыка кораллары оркестры (житәкчесе—Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты—Анатолий Шутиков) концерты булып узды. Өч сәгатьлек концерт барышында татар халкының танылган композиторлары Н. Жиһанов, Ф. Яруллин, Р. Яхин, А. Монасыйпов, шулай ук рус һәм чит ил классикларының да әсәрләре яңгырады. Мәскәүлеләр Илһам Шакиров, Михаил Казаков, Рөстәм Маликов, Георгий Ибушев, Айдар Фәйзрахманов, Резидә Галимова чыгышларын аеруча жылы кабул итте.

Россия Федерациясендәге Татарстан Республикасының вәкаләтле вәкиле Назиф Мириханов залда утырган тамашачылар исеменнән Анатолий Шутиковка, коллективка һәм артистларга чын күңелдән рәхмәтен белдерде.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР СЕМИНАРЫ

Татарстан Язучылар берлеге, ТР Мәгариф министрлыгы, Яшьләр белән эшләү һәм Спорт министрлыгы белән бергәләп, шушы елның 26-28 март көннәрендә республикакүләм яшь каләм ияләре семинары үткәрде. Анда Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләреннән, Чүпрәле, Яшел Үзән, Кама Тамагы, Мамадыш, Мөслим, Яңа Чишмә, Саба, Чирмешән, Чистай, Балык Бистәсе, Биектау, Әгерже, Лаеш районнарыннан 30 лап югары сыйныфларда укучы мәктәп балалары һәм студентлар катнашты.

Семинар ике көн дәвамында 4 нче номерлы татар-төрек лицее бинасында барды. Беренче көнне яшь иҗатчылар Татарстан Язучылар берлеге житәкчеләре һәм күренекле язучыларыбыз Иллар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Равил Фәйзуллин, Әхсән Баян, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Гөлшат Зәйнашева, Мәдинә Маликова һ. б. белән очраштылар.

Икенче көнне яшьләр Зиннур Мансуров һәм Солтан Шәмси житәкләгән Шигърият һәм Проза остаханәләрендә шөгыльләнделәр, остаз язучылар хозурына үзләренең иҗат үрнәкләрен күрсәттеләр.

Казаннан Гөлназ Вәлиева, Мамадыштан Ләйсән Мөгътәсимова, Түбән Камадан Эссана Мождабаева, Динар Гаязов, Яңа Чишмәдән Индира Гатина, Сабадан Нәркис Хантимерова, Балык Бистәсеннән Рөстәм Исхаков иҗатлары уңышлы дип табылды.

## ПЕН-ҮЗӘК УТЫРЫШЫ

21 мартта Ш. Камал музеенда Халыкара ПЕН-клубы Татар үзәгенең күчмә утырышы булды.

Көн тәртибенә мөһим мәсьәләләр куелган иде. ПЕН-үзәк быел Россиядә узачак халык санын алу уңаеннан татар халкына мөрәҗәгать белән чыкты. Язучылар милләттәшләребезне бу мәсьәләгә зур жаваплылык белән карарга һәм халкыбызны тулы һәм бүлгәләнмичә саклау өчен мөмкин булганның барысын да эшләргә чакыра.

ПЕН-үзәк, татар алфавитын латин графикасы нигезендә торгызуны яклап, быел язучыларның Македониядә узачак Бөтендөнья конгрессы өчен резолюция проекты кабул итте.

«Восточный экспресс» газетасында басылган мәкаләсе өчен Татарстан прокуратурасының Тәлгат Бариевка карата кузгатылган жинаять эшенә килгәндә, Татар ПЕН-үзәге инде үзенең икенче утырышында да, Гражданлык кодексына кагылган эшкә жинаять эше ачу хокукый нормага сыймый, дип белдерә. Бу эш буенча язучыларның жәмәгать яклаучысы итеп Татар ПЕН-үзәгенең башкаручы директоры Әхәт Мушинскийны билгеләде.

Утырышта Т. Миннуллин, Р. Вәлиев, Р. Мостафин, М. Хәбибуллин, М. Госманов, З. Мансуров, Н. Гыйматдинова, М. Галиев, Г. Морат катнашты һәм чыгыш ясады.

## «ИЛҺАМ ЧИШМӘЛӘРЕ» САЕКМАСЫН

Март ахырында Башкортстанның Бәләбәй шәһәрендә яшь шагыйрьләрнең «Илһам чишмәләре» дигән шигърият фестивале узды. Анда Башкортстан, Татарстан һәм Чувашстанның шигъри сүз осталары катнашты.

Мондый фестиваль биредә инде алтынчы тапкыр уздырыла. Яшь талантларны барлауда әлеге чараның әһәмияте бик зур. Татар телендә иҗат итүче Наилә Миннеханова, Нур Шәфиков, Нәсимә Йосыпова, Әхнәф Манзаров, Фәнил Арсаев, Рәзиф Зөбәер, Зәйфә Салиховаларның иҗатлары күпләргә ошады, өлкән әдипләр аларга уңышлар теләделәр. Шушы ук фестиваль көннәрендә танылган татар шагыйре Роберт Миннуллинга, патриотизм идеяләрен, татар халкының асыл сыйфатларын һәм туган як табигатенең гүзәллеген данлаган әсәрләре өчен, Фатих Кәрим исемендәге төбәкара

әдәби премия тапшырылды. Үткән елларда бу бүләккә Татарстаннан шагыйрьләр Ренат Харис, Әхмәт Гадел, Рәдиф Гаташ, Зәет Мәҗитовлар лаек булган иде.

Безнең республикадан Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, мәдәният министры урынбасары Илфак Ибраһимов һәм Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары Римзил Вәлиевләрнең Бәләбәй шәһәрендә һәм районында яшәүчеләр белән иҗат очрашулары да булды.

### ОНЫТЫЛМАС ӘДИП

25 мартта Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтында татар әдәбияты классигы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 115 ел тулуга багышланган республика фәнни конференциясе үткәрелде.

Конференциянең пленар утырышын кереш сүз белән ТӘҺСИнең директоры Н. Хисамов ачып җибәрде. Ул үзенең чыгышында Г. Ибраһимовның бүгенге көндәге кыйммәте, аның әдәбият тарихында тоткан урыны хакында сөйләде. Ф. Мусин исә әдәбиятыбыз классигының иҗатын яңача өйрәнү мәсьәләләренә тукталды. Пленар утырышта шулай ук Татарстан Язучылар берлеге рәисе галим Ф. Галимуллин да чыгыш ясады.

Соныннан конференция үзенең эшен секцияләргә бүленеп дәвам итте.

### КЫРЫМТАТАР ТЕАТРЫНА 100 ЕЛ

Күптән түгел Кырымның Симферополь (Акмәчет) шәһәрендә кырымтатар театрының 100 еллыгына багышланган тантаналы кичә узды. Кичәдә тамашачылар Украина һәм Кырым мәдәният министрлары, Милли Мәҗлес җитәкчелеге, дәүләт вәкилләре катнашты.

Бу тантаналы кичәдә Татарстаннан махсус килгән кунаклар–Татарстан Дәүләт советы рәисе урынбасары Роберт Миңнуллин, мәдәният министры Илдус Тарханов та бар иде. Алар кырымтатар театрын олуг юбилей белән котладылар.

Татарстан кунаклары Кырымдагы татар-башкорт федерациясе рәисе Марат Мөсәлимов белән күрешеп, Кырымдагы милләттәшләребезнең проблемалары хакында да сөйләштеләр. Кырым һәм Татарстан мәдәният министрлары 2002 елның җәендә Казанда уздырылачак кырымтатар мәдәнияте көннәренә әзерлек мәсьәләләре турында фикер алыштылар.

### УНИВЕРСИТЕТТА ЯҢА РЕКТОР

Мәшһүр Казан университетында ике ел буе тулы вәкаләтле ректор булмый торды. Ниһаять, озакка сузылган сайлау-сайланулардан соң яңа ректорның исеме мәгълүм булды. Ул–51 яшьлек Мәгъсүм Хәлимулла улы Салахов, физик, профессор, хезмәтләре чит илләрдә дә яхшы мәгълүм. Галим–«Оптика» белгечлеге буенча гыйльми совет рәисе. АКШ, Югославия, Италия, Голландия һәм Япониядә фәнни эшләр белән шөгыльләнгән М. Салахов–чыгышы белән Ульян каласыннан.

Университет ректорын сайлау үтә киеренке шартларда узды. Яшерен тавыш нәтиҗәләре түбәндәгечә: М. Салахов өчен сайлауда катнашкан 347 кешенең 181 яклап тавыш биргән (көндәшләре: В. Галкинны яклап биргән тавышлар саны–99, В. Чугуновныкы–49, С. Насыйровны–16). Шулай итеп, Мәгъсүм Салахов XXI гасырга чыккач Казан университетының беренче ректоры итеп сайланды. Ул–200 еллык тарихы булган университетның 33 нче ректоры, ә татарлардан–өченче. Аңа кадәр 1930-31 елларда Гыймаз Баһаутдинов, 1935-37 елларда Гыйлем Камай эшләп алган.

### МАРАТ КӘРИМОВ КИЧӘСЕ

Мәгълүм булганча, милләттәшләребезнең бик күп өлеше хәзерге Башкортстан территориясендә яши. Әдәбият-сәнгать дөньясында, табигый, татардан чыккан шәхесләр бик күп. Шуларның берсе Уфада яшәүче татар шагыйре Марат Кәримов. Ул–Башкортстандагы татар телендә иҗат итүче язучыларның җитәкчесе, егермеләп китап авторы, атказанган мәдәният хезмәткәре, үз вакытында журналистикада җаваплы вазифалар башкарган кеше.

Г. Камал театрында аның авторлык кичәсе булып узды. Кичә бәйрәме төстә бик җанлы үтте. Кунак шагыйрьне И. Юзеев, Т. Миңнуллин, Ш. Галиев, Р. Миңнуллин, Ф. Галимуллин, Р. Гаташ һ. б. котлады. Артистларыбыз Р. Таҗетдинов, Н. Ихсанова, Д. Нурлы, И. Баһманов, Х. Җәләй, Р. Сәләхов аның шигырьләрен укыдылар, Р. Закиров, Р. Шәрәфиевалар популяр җырлар башкардылар. Уфалылар үзләре дә бер иҗади төркем булып килгәннәр иде. Язучы С. Сафуанов, күренекле артистлар–Н. Кадыйрова, Ф. Салихов, Ф. Сиражетдинова...

«Казан–читтә яшәүче татарларның кыйбласы, изге мәркәзе ул! Без сезгә тартылып, сагынып яшибез. Казанда мондый кичә уздыру күптәнге хыялым иде»,–диде шагыйрь үзенең чыгышында.

Кичә «Казан» милли мәдәният үзәге һәм Камал театры (директорлары–бертуган Шамил һәм Ренат Закировлар) инициативасы белән оештырылды.

### ФАТИХ ХӨСНИ АВЫЛЫНДА

Елның иң яхшы хикәясе өчен бирелә торган Фатих Хөсни премиясенә быел язучы Зиннур Хөснияр лаек булды.

Олы Мәтәскә язучының туган көне 3 февральдә кунаклар кабул итте. Халык язучысының туган авылына бу юлы язучылар Мөсәгыйт Хәбибуллин, Кыям Миңлебаев, Илсөяр Иксанова, Фәйрүзә Мөслимовалар килгән иде. Алар мәктәптә, авыл мәдәният йортында, язучының музеенда оештырылган очрашуларда катнаштылар.

Килгән кунаклар һәм Фатих Хәсни музее директоры Гөлнирә Имамиева язучы иҗаты турында сөйләделәр, өлкән укытучы Тәскирә Бибарсова истәлекләре белән уртаклашты. Кичә авыл яшьләре һәм мәктәп укучылары әзерләгән концерт белән тәгалләнде.

## РАФАЭЛЬ СИБАТ БӘЙРӘМЕ

Киров өлкәсенең Нократ Аланы районындагы Түбән Шөн авылында яшәүче танылган прозаик, роман һәм повестьлар, әдәби портретлар һәм эсселар, поэма һәм шигырьләр авторы Рафаэль Сибатка 55 яшь тулды. Татарстан китап нәшриятында язучының китабы басылып чыгу да шул көннәргә туры килде. Әсәрләре шактый булса да (байтак әсәрләре безнең журналда дөнья күрде), авторның басылып чыккан беренче китабы әле бу. Китапка «Ялгызак» романы һәм «Яулар кичкән кульяулык» повесте кертелгән.

Татарстан Язучылары берлеге идарәсенең соңгы утырышларының берсендә Рафаэль Сибатка Г. Исхакый премиясе бирелүен игълан итте. Бу гамәл Р. Сибат иҗатын җәмәгатьчелекнең тануы дигән сүз.

## КҮП КЫРЛЫ ИҖАТЧЫ

Әлмәттә шагыйрь, композитор, педагог Разим Вәлиуллинның 60 яше унаеннан әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Үзенең күп кырлы талантка ия булуын ул тагын бер мәртәбә раслады: кичәдә катнашучылар Разим Вәлиуллинның шигырьләрен дә, җырларын да, рояльдә уйнавын да рәхәтләнеп тыңладылар. Юбилярны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин котлады. Шулай ук аны каләмдәшләре, туган ягы Зәйдән, Лениногорскидан һ. б. районнардан килгән җәмәгатьчелек вәкилләре кайнар тәбрикләделәр.

## ИГЪТИБАР: КОНКУРС!

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында», «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Элемтә министрлыгы түбәндәге мәсьәләләрне яктыртуга кагылышлы иң яхшы материалга матбугат чаралары һәм авторлар арасында конкурс игълан итә:

Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклап калу, өйрәнү һәм үстерү; татар телен латин графикасына күчерү.

Конкурста катнашу өчен матбугат чараларына (аларның оештырылу-хокукый рәвешенә һәм кайсы ведомствоныкы булуына карамастан) һәм авторларга 2002 елның 1 маена хәтле Татарстан Республикасы Элемтә министрлыгының матбугат чараларына булышлык күрсәтү бүлегенә гариза һәм 2002 елның II кварталына җентекле эшләнгән план-проект тапшырырга тәкъдим ителә. Анда концепциянең сценарие, бастырып чыгару этаплары, автор (авторлар) һәм материалның эчтәлеге турында кыскача мәгълүмат булырга тиеш.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Президенты Указы белән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире **Урманчиев Фатыйх Ибраһимов улы** Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Язучылар берлегенең Җамал Вәлиди исемендәге бүләгенә әдәби тәнкыйть өлкәсендә озак еллар дәвамында нәтиҗәле эшчәнлеге өчен Казан дәүләт педагогия университетының әдәбият кафедрасы доценты **Рифат Сверигин** лаек булды.

---

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** "Казан утлары" журналы редакциясе хезмәткәрләре. Беренче рәттә *(сулдан уңга)*: **Марс Шабаев** *(бүлек мөхәррире)*, **Флүс Латыйфи** *(баш мөхәррир урынбасары)*, **Равил Фәйзуллин** *(баш мөхәррир)*, **Асия Рәхимова** *(баш бухгалтер)*, **Камил Кәримов** *(бүлек мөхәррире)*; икенче рәттә: **Равил Гәрәев** *(шофер)*, **Алмаз Гыймадиев** *(җаваплы секретарь)*, **Рәдиф Гаташ** *(бүлек мөхәррире)*, **Тәгъзимә Шиһабиева** *(компьютерда җыючы)*, **Гөлзадә Бәйрәмова** *(корректор)*, **Мансур Вәлиев** *(бүлек мөхәррире)*, **Наис Гамбәр** *(бүлек мөхәррире)*, **Тәслимә Сибгатуллина** *(техник мөхәррир)*, **Марат Закир** *(бүлек мөхәррире)*, **Лилия Гатауллина** *(корректор)*, **Радик Вәлиев** *(журналны версткалаучы)*, **Эльвира Камалова** *(бухгалтер)*.

# ЯҢА КИТАПЛАР




**Татар әдәбияты тарихы**. VI том.—Казан: «Раннур» нәшр.—2001.—542 б. Тиражы —20000 данә.

Яше мең еллап исәпләнгән татар әдәбиятын билгеле бер эзлекле тәртипкә салып өйрәнү әдәбият фәненең үткән гасырдагы иң төп вазифаларының берсе булды. Бу эштә Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре зур көч куйды. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1982—1989 елларда «Татар әдәбияты тарихы»ның биш томлыгы дөнья күргән иде. Һәм, ниһаять, 12 елдан соң—безнең кулларда VI том. Алдагы томлыклар Татарстан китап нәшриятында басылган иде, бусы, күрсәтелгәнчә, «Раннур» нәшриятында чыккан. Томның җитәкчесе һәм фәнни мөхәррире—Флүн Мусин. Хезмәт—татар әдәбиятының 60-90 елларын эченә ала. Шул чорның әдәби хәрәкәтенә гомумкүзәтү рәвешендәге керештән соң жанрлар буенча иҗатлары бу чор әдәбиятының төп сыйфатларын билгели дип саналган язучылар турында аерым мәкаләләр урнаштырылган. Алар: прозаиклар—Ә. Еники, А. Расих, Г. Ахунов, Р. Төхфәтуллин, Н. Фәттах, А. Гыйләҗев, Ә Баян; шагыйрьләр—С. Хәким, Г. Афзал, И. Юзеев, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин; драматурглар—Х. Вахит, Т. Миннуллин; тәнкыйтьчеләр—Х. Госман, Г. Халит, Н. Юзиев. Бу әдипләр турындагы мәкаләләрне Ф. Мусин, Т. Галиуллин, А. Әхмәдуллин, Р. Мостафин, Ф. Галимуллин, Р. Сверигин, Ф. Хатипов, Н. Ханзафаров һ. б. язган. Томлыкта шулай ук балалар әдәбияты (Ф. Ибраһимова) һәм әдәби бәйләнешләр (Г. Мөхәммәдова) турында аерым бүлек итеп бирелгән мәкаләләр бар.

«Татар әдәбияты тарихы»ның киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителә торган VI томы, калган биш том сыман ук, үзгәртеп кору чорына тәгәлләнгән иде. Ул әдәбият тарихының бердәм хронологик-концептуаль проспекты нигезендә эшләнде һәм алдагы томнарның логик дәвамы булып тора» диелә кереш сүздә.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)